# казан утлары

1
ЯНВАРЬ-1976

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

1

ЯНВАРЬ
1976

## Бу санда

С. СӨЛӘЙМАНОВА. Әлмәт. Шигырьләр . . . . 3
И. ӘХСӘНОВ. Белоглазов урамы. Шигырь . . . 7
К. РӘХИМОВ. Өлешемә тигән көмешем. Повесть 9
К. БУЛАТОВА. Кышкы җыр. Шигырьләр . . . . 63
Ф. ЯРУЛЛИН. Әнием төсле күренә. Шигырьләр . 66

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Тормыштан — әдәбият мәйданына . . . . . . 70
Г. КАШАПОВ. Бәйгеләрдә... Шигырьләр . . . . 71
Җ. ХӘБИБУЛЛИН. Тынлык турында. Шигырьләр . 73

ПАРТИЯНЕҢ XXV СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Ә. ВӘЛИХАНОВ. Татарстан нефте Ватанга . . . 74
Ә. МАЛИКОВ. Ак чишмә . . . . . . . . . . 81
Ү. САТТАРОВ. «Кара алтын» хикәяләре . . . . . 90
КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . 93

М. Е. САЛТЫКОВ-ЩЕДРИННЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Революцион сатира классигы . . . . . . . . . 95
М. Е. САЛТЫКОВ-ЩЕДРИН. Үзен аямаучы куян. 96

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ 90 ЕЛЛЫГЫНА

Тукайның яңа табылган шигырьләре . . . . . 100

ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Л. КЛИМОВИЧ. Ф. Әмирхан иҗаты . . . . . . 105
М. МӘҺДИЕВ. Ф. Әмирхан жандармерия күзәтүе астында . . . . . . . . . . . . . . . . 110

ДУСЛАР ИҖАТЫ

М. СКОРОХОДОВ. Тирән тыл. Шигырьләр . . . 116
Ленинград шагыйрьләреннән үрнәкләр . . . . 118

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

И. БУТЫЛКИН. Муса янында берничә көн . . . 122
И. ЗӘБИРОВ. Ватан өчен яшәргә өндәде . . . . 130

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

СӘНГАТЬ

И. ҮТӘГӘНОВ. Сәхнә каһарманы . . . . . . . 132

ГАМИР НАСРЫЙНЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Күренекле драматург . . . . . . . . . . . . 138
Г. НАСРЫЙ. Рәхмәтулла абзый әкияте. Хикәя . . 139
Бикмулла хәзрәтнең биш нәсихәте. Скетч . . . . 142

ҖЫР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

И. НАДИРОВ. Ил яшәве — җыр белән . . . . . 146
З. ХӘЙРУЛЛИНА. Иң үткен, иң җитез жанр . . . 153

КИТАП КҮЗӘТҮ

Х. ХӘЙРУЛЛИН. «Мәхәббәт сынавы» сынау үтә . 157
Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Шагыйрь прозасы . . . . . 160

КОНКУРСКА КИЛГӘН РЕЦЕНЗИЯЛӘР

Ф. САФИН. Саумы, бәйрәм! . . . . . . . . . 163
В. РӘХМӘТУЛЛИНА. Чишмә суын үртлагач . . . 164
Р. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. «Фронтовиклар» романында хатын-кыз образлары . . . . . . . . . . . 166

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Р. ВӘЛИЕВ. Теш сызлагач . . . . . . . . . . 169

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

М. ӘМИР. Мыжык карт язмалары . . . . . . . 172
В. МОНАСЫЙПОВ. Шатлыклы кайгы. Хикәя . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 190

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: Зәки Нури

Редколлегия: Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 2/X-1975 ел. Басарга кул куелды 3/XII-1975 ел. ПФ 09043. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91 144 экз. Заказ Я-342. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2ы,

© «Казан утлары», 1976 ел.

## Сажидә Сөләйманова

### Әлмәт

Җан җылысы кушып ут тергездек.
Учаклардан шәһәр башланды.
Ак теләкләр белән нигез салдык,
таудан алдык ап-ак ташларны.

Шуңадыр ла урамнары якты,
тауга кардәш биек йортлары.
Тәрәзәләрендә балкый сыман
без кабызган учак утлары.

Шуңадыр ла җем-җем тәрәзәләр
ай-йолдызлар белән серләшә.
Безнең яшьлек хыяллары булыр,
зәңгәр ялкын сүнми дөрләсә,

манаралар йөрсә кырлар буйлап,
ургып торса кайнар фонтаннар —
безнең яшьлек бүләгебез булыр
әкиятне чын иткән Ватанга.

Әлмәт, Әлмәт, синдә кемнәр тумас!
Без тудырдык сине үзебез.
Нигезеңдә яткан һәр ташыңда
уелып калган яшьлек эзебез.

Шуңадыр ла урамнарың якты,
җем-җем итә төнлә йортларың.
Ә күңелдә һаман балкый сыман
Зәй буеның учак утлары.

### Өстәмә кыйммәт

Мәскәү нефть институтының
Әлмәттәге татар факультеты
деканы В. Козыревка.

Исемең синең ифрат ихтирамлы:
экономик фәннәр докторы.
Без лекторлар, мөгаллимнәр идек, —
бар үзәге эшнең, юк кыры.

Мин тарихтан шигырьләргә киттем.
Әдәбият иде һиммәтең,
син нефтьнең эзләп үзкыйммәтен,
таптың өстәп биргән кыйммәтен.

Театрлар, вузлар һәм шигырьләр
шул өстәмә кыйммәт өстендә.
Солдат һәйкәлләре йөзендә ул,
рәссам бизәкләре төсендә.

Заманалар заманнардан үзгә,
эш үзәге һаман кырларда.
Көзме, кышмы — буровойлар гөрли,
аһәңнәре җырда җырлана.

Ә син инде фәнни трибунадан
кисәтәсең сыман: бел шуны —
тапкан байлыгына яшәтә ала
һәр нефтьче йөзәр җырчыны!

Һәм өстәмә кыйммәт
замананы
йолып ала металл тарифтан.
Галимнәре аның шагыйрь җанлы,
шагыйрьләре килә тарихтан, —

кыйммәт туплап, бурыч йөкләп килә.
Бабайларның сүзсез гозере:
иҗат мәйданнары чиксез киң дә,
тик үзәге аның эш кыры.

## Хирургиядә

*Әлмәт табипләренә*

Яши алар шомлы ак тынлыкта,
аклыклары белән саваплы.
Кешеләрнең һәр сулышы өчен,
бар тормышы өчен җаваплы.

Кан саркыган айбалталар тотып,
газраиллар баса бер якка.
Һәр сәгатьтә яшәү белән үлем
бәрелешә пычак-пычакка.

Бу көрәштә син бит ялгыз түгел,
и оттырма, кешем, оттырма! —
Кылдан нечкә сират күперennнән
кылыч тотып чыга доктор да.

Нечкәлек тә анда, җитезлек тә,
сабыр тәвәккәллек — гаҗәеп!
Алып атса шәрә шәүлә булып
кул астында йөргән әҗәлне —

таң атуга ничә күз елмаер,
ничә йөзгә тагын нур кунар!
Кешеләрнең елмаюын күреп
яшәрәләр икән докторлар.

Яши алар шомлы ак тынлыкта...
Үлем белән мәңге низагта,
мәңге сафта —
доктор яуга керә
ак тынлыкта
пычак-пычакка.

●

Үлән булып җирдә үсәмме мин,
балык булып суда йөзәмме?
Җилләр исә... Төш икән бу дисәм,
өн икәнсең, тормыш,
исәнме!

Бу язда да тагын, бу язда да
шомырт чәчәкләре иснәдем.
Чәчәк алып килде кем бу дисәм,
син икәнсең, тормыш,
исәнме!

Арта торсын юллар исәбе дә,
арта торсын еллар исәбе.
Сахраларга чыксаң, җырлап туймас
җыр икәнсең, тормыш,
исәнме!

Гомер озын дисәм, рас булырмы,
сиздерми дә узды дисәмме?
Күп тә түгел, гомер, аз да түгел,
бер икәнсең —
тормыш,
исәнме!

●

Җил иркендә сине күрдем,
җилкендем дә илердем.
Хыялдагы сурәтеңә
җан өрдем мин, өн бирдем.

Алиһәләр аһ иттеләр,
тал-тирәкләр яшь түкте.
Кем күпсенде, кем юксынды
күккә ашкан яшьлекне.

Алып очты җил-өермә!
Ераклашты тавышың...
Ак кәгазьгә кара сөрмә
Булып төште сагышым.

Алиһәләр аһ ордылар,
тал-тирәкләр яшь койды.
Таллар суга, су дәрьяга,
дәрья ярга ашкынды.

Шул минутта син — сәгадәт.
Сизгер җанга чын сәнгать!
Ярдан алдым, җырга салдым
сурәтеңне, мәхәббәт.

●

Манаралар, корыч манаралар
үсеп чыккан төптән, тирәннән.
Әйтерсең лә җирдән җегәр алып,
ракеталар күккә төбәлгән.

Караңгыдан халкым яралгыда
күргән киләчәге балкуын.
Ул электән яктылыкка баккан,
хыял очларына ай куеп.

Айлар хәзер юлны очлый алмый.
Яңа мәйдан. Корыч манара
тамырланып керә туган җиргә,
тамырларда тормыш яңара.

## Илдар Әхсәнов

### Белоглазов урамы

Девон нефтенә гомерен багышлаган атаклы бораулау остасы Михаил Белоглазов истәлегенә.

Ничәнче яз синсез килә, —
Искәрмәдем мин ансын, —
Исемең йөрткән урам буйлап
Мәңгелеккә атлыйсың.
...Авыр сөйрәп итегеңне,
Юл яручы ат кебек,
Эштән кайтып килүеңме,
Бу тынлыкны ят күреп?
Сүнеп бара Чулпан йолдыз,
Гамьсез йөзә тулган ай.
Колагыңда котылгысыз
Шаулап тора буровой.
Язмыш йөртте алдан әйдәп,
Күпме юллар кичелгән;
Яшәр куыш — шәп дигәндә
Булды барак ишедән!
Яз һавасы керсен әле,
Ачып җибәр тәрәзәң.
Ал бакчада сиреньнәрең
шау чәчәктә янәдән.
...Өйдә түгел, буровойда
Үтте күбрәк тәүлекләр.
Ял итәргә, күчкән җайда,
«Тәрәзәләр» дә җитәр!
Белеп килде мастер таңнан
Буровойда ни барын.
Чытырдатып билен кыскан
Җир куены торбаның.
Җан сорар дип тәвәккәллек
Кем уйлаган ул чакта?
Бер ялгызы җиңәр кебек,
Үзе басты рычагка.
Әйтерсең лә зур афәттән
Кешелекне коткарып,
Җыенды ул рычаг белән
Кузгатырга җир шарын!

Ник ашкынды?!
Бу адымнан
Туктат идең син аны!
Бунтарь йөрәк ярсуыннан,
Күкрәгенә сыймады.
Азмы сынау кичерде ул, —
Юлдаш булды уңышлар;
Үр артыннан чигенде үр,
Кайчан күңел тынычлар?
Соңгы кабат кисәткәндәй,
Стрелкалар биеште.
Чигену белмәс егеткә, әй,
Тау ярырлык бир көчне!
Атылмаган ук шикелле
Вышка торды калтырап;
Күгәренде күкләр йөзе,
Ай чалынды ялтырап.
Яшәү белән әҗәл яман
Тартыштылар җепсәдә.
Чыдамады корыч аркан,
Кешедә кыл түзсә дә...
Нигә хәзер уфтанулар,
Исеме яши телләрдә!
Маяк булып скважиналар
Тезелеп калды үрләрдә.
Ничә язлар җилкенде Зәй,
Болыннарны иңләде.
Шау чәчәктә янәдән, әй,
Шомыртларның иңнәре.
Яшәде ул яши белеп,
Яна-яна эш өчен, —
Девон сулышына биреп
Кайнар йөрәк тибешен!

Мәңгелекнең үрләреннән
Нефть ургый «Дуслык»ка,
Җыр агыла туган җирдән
Бүген алгы сызыкка.
Яңалары баса сафка,
Юллар ярып Себердән.
Дәвамлы бу эстафета
Шөһрәт белән үрелгән.
Ниләр сөйләп җилләр исә
Белоглазов турында?
Юксынырмы язгы кичтә
Сыздыруын гармунда?
Шул урамда калган эзе,
Уй-исәпләр — барысы да...
Бар эшләрен ташлап, үзе
Чыгар кебек каршыңа.
Шаһит булсын язлар моңа:
Тартылгандай кояшка,
Исеме илләр урамына
Нурын өстәп тоташкан!

Җәмит Рәхимов

# ӨЛЕШЕМӘ ТИГӘН КӨМЕШЕМ

ПОВЕСТЬ

## 1



Юлым хәерле булмас микәнни? Без, иртә таңнан кузгалырга тиешле кешеләр, һаман колхоз гаражында таптанабыз. Шофер егетнең тәҗрибәсе җитмиме, машинаның ныклап көйсезләнүеме — белмәссең. Әллә кайтып кына китим микән? Юк инде, өйдә Мәчтүрә апага күз көеге булып торганчы, монда буталуым хәерлерәк. Чыннан да, тиз генә урап килимме әллә? Нарасыйларыма күз салып кына. Өлкәне — Талиясе өчен борчылмыйм, түзәр. Әйткәнне, сөйләгәнне аңлый инде. Гөлиясе өзгәләнәдер, мескенем. «Әни кая?» дип, Мәчтүрә әбисен аптыратып бетергәндер инде.

Тимер баганалары чалышая башлаган иләмсез киң капкага җитәрәк тукталып калдым. Кайтсам, ападан әләгә бит инде миңа. Балаларны котыртып йөрисең, дип бәйләнәчәк. Әй, чәүчәләк тә инде мин! Ният иткәч, кырт кисеп китәргә кирәк, үземне дә, балаларны да ярсытып йөрмәскә.

Кире гаражга таба борылдым. Әрсез уйларым да артымнан калмый ияреп киләләр. Әллә соң авылда калып элеккечә басылып кына эшләргәме? Булмас, ул хакта күп уйландым инде. Кая гына барма — Рамазан баскан эзләр, кая карама — аны хәтерләткән истәлекләр. Аның белән гомер сөргән йорт-җиренә кадәр мине үчекләгәндәй балкып, күңелне тартып тора. Шуннан кузгалмаган булсам, бүгенге хәлгә калмаган да булыр идем, шәт. Юк шул, инде ул нигез минеке түгел хәзер. Анда башкалар яши. Үткән көннәр рәшә дулкыны кебек — аларны кире кайтарып булмый. Җитте, узганнарны исәпләп яшәү мөмкин түгел, иртәгәсе көнгә карарга кирәк.

Яшьлек хатирәләренең һәр таңда яңаруына, кич саен инде кабатланмас мәхәббәтең белән сагышлануга түзәр, күнәр дә идең, шәт. Котны алганы — билгесезлек, иртәгәсе көнгә өметсезлек. Басылып, күңелең утырып яшәрлек торыр урының, йөрәккә ятышлы эшең булмагач, ни дип

калырга монда? Председатель Якуп үз теле белән әйтте: фермалар комплектлаштырылган, җәйсез эш булырлык түгел, ди. Күтәргәсен дә кисеп кенә әйтмәде, сизелеп тора: балалы хатынны мал-туар тирәсенә куясы килми. Урта белемле яшь-яшь кызлар фермага сорап торганда, сайланыр шул. Шушы буй-сының, шушы көч-куәтең белән клуб җыештырып ят, имеш. Гарьлек, билләһи!

Кызык та, катлаулы да икән бу дөнья дигәнең! Әле бер ай элек кенә сорасалар: «Шәһәргә китәсеңме әллә, Галибә?» дисәләр, андый сорау бирүчене тилегә санаган булыр идем, мөгаен.

Үз бәхетеңне җиң сызганып эзләргә кирәктер, күрәсең. Моңа кадәр дулкын каккан уңайга гына йөзеп йөрдем, югыйсә. Ике җирдә ике оя корып карадым — уңмадым. Рамазанга чыктым — нинди дер тынгысыз, шашкын бәхетемне таптым, Ишалгыга Өлфәткә бардым — шыксыз бәхеткә юлыктым. Ләкин язмыш тынгысыз бәхетен дә кызганды миннән. Ямансу, шыксыз бәхеттән исә үзем качтым. Тулы гына түгәрәк бәхет юк микәнни соң ул дөньяда? Бардыр. Кешеләр табып торалар ич әнә...

Барысы да шыксыз көзге көннән башланды. Мин җыештыручы булып эшкә урнашып кайткан күңелсез бер көн иде ул. Кар катыш яңгыр ява, дөньяны нинди дер ямьсез караңгылык баскан. Шуңамы, Мәчтүрә апаның да кәефе юк. Хәер, йөрәгенә төшмәсә, көннәр буе бер сүз дәшми ул.

Балалар әле тормаган, сабыйларга гына хас гамьсезлек белән тәгәрәшеп йоклыйлар. Икебез ике шәүлә булып өстәл янына килеп утырдык. Чынаякларыбызга чәй ясарга өлгермәдек, йөрәккә шом салып, кинәт нидер шатырдады.

— Ай алла, ай алла! Харап булдык! — дип кычкырып җибәрде Мәчтүрә апа һәм, ни өчендер, кайнар самаварны күтәреп тышка йөгерде.

Ни булганын аңлап бетермәдем, тик, куркыныч барын сизгән ана бөркет кебек, балаларым янына барып бастым. Ул да түгел, тәрәзәдән Мәчтүрә апаның ярсулы авазы яңгырады:

— Нәрсә дип терәлеп каттың инде? Ал балаларны! Өй ишелә бит...

Аптырап түшәмгә карадым. Хәлнең аяныч икәне шунда гына барып житте аңыма. Матча стенадан алып уртасына кадәр ярылып киткән иде. Балаларның күзгә күренгән киемнәрен җыйгаладым да үзләрен йолыккалап уяттым. Чырыйлап елап җибәрделәр. Ай-вайларына карамыйча, берсен күтәреп, икенчесен җитәкләп, күрше Бәдәр әбиләргә йөгердем.

Кызларны тынычландырып, ашатып-эчереп, кабат чыкканда, матча шомартылмаган имән терәү белән терәтеп куелган иде инде.

— Ярый әле, Минрахман килеп чыкты, — дип сөйләде Мәчтүрә апа, йомычкаларны җыештыра-җыештыра, — атын туктатып керде дә көйләп тә куйды, рәхмәт төшкере... Ни әйттем Якупка: яңгыр үтә, чери, ишелә дип. Язсыз сорама да, булмый да, ди. Әйтерсең персидәтелнең язын көтә черек матча...

Өйне авыр тынлык басты. Шул шыксызлыкны бозарга теләпме, әйтеп куйдым бит, тиле:

— Инде нишлибез, Мәчтүрә апа?

— Син дә җанымны телгәләмә, ичмасам. — Ул йомычка тулы тазын күтәреп, җилтерәтеп кече якка кереп китте. Ләкин үпкә катыш ярсулы сүзләре аннан да аермачык ишетелә иде. — Бер башыңа урын тапмадың тәмам! Һәркайсы чиркәү кадәр ике йортка хуҗа булдың. Ярамады. Мәчтүрә апаңның шушы черек өен тансыклап кайттың... Ике атадан ике бала белән...

Менә сиңа ишетмәсәң ишет. Менә сиңа дәшмәс Мәчтүрә апа! Юаштан юан чыга, диләр шул. Артыгын тыңлап тормастан, турсаеп, Бәдәр әбиләргә кереп киттем.

Апаның әче сүзләре көнозын башымнан чыкмады. Тарсына икән, үзенә кайтып егылуыма риза түгел икән. Гомере буе минем белән изаланды шул. Алай да авыр сүз әйткәне юк иде, нинди авыр елларда да

бер-беребезгә сыенып яшәдек. Ул чакта ялгызым гына идем шул. Хәзер әнә, үзе әйтмешли, ике атадан ике бала. Әллә йөрәге әрнегәнгә генә әйтеп ташладымы ул ямьсез сүзләрне? Ни генә булмасын, эчемдә ниндидер салкынлык калыккан, кызларым белән бергә аерым оя кору турында уй бөреләнергә өлгергән иде инде.

Бу вакыйга шул килеш сүрелгән, онытылган да булыр иде, шәт. Икенче көнне классташым Манзума белән очрашу ут өстенә ялкын булды, йөрәгемә коткы салып китте ул.

Иртәгесен, Мәчтүрә апаны идарәгә озаткач, каршыбыздагы коега суга чыктым. Күлмәкчән генә идем. Ашыгып кереп барганда, түбән очтан менеп килүче берәүгә күзем төште. Хат ташучы Нәҗияме әллә дип өмсендем башта. Ләкин килеш-килбәтенә караганда, укытучылардан агитатормазарга тартымрак иде ул. Өстендә пальто дисәң пальто, сырма дисәң сырма түгел, кыландырып теккән чаштырдык бер нәрсә шунда. Башында кикрикле модный башлык, аякларында калын табанлы, озын кунычлы итекме, читекме шунда, кулына җыйнак кына сумка тоткан. Мәктәп директоры хатыны Кәримә генә шулай кыланчыкланып киенә бездә. Нишләп йөрер икән соң ул фермалар очында?

Ул якынлашкан саен йөзендә таныш чалымнар арта бара. Гарәп хатыннарыныкы төсле каратут бит, кечкенә генә курнос борын. Елмаюы булды — авыз кырыенда нәни генә чокыр барлыкка килде.

— Манзума димме?! Үзгәрмәсә дә үзгәрмәс икән кеше, һаман япь-яшь!..

— Нихәл, Галибә. Ә син... хи-хи... прумых биргәнсең. Аякка сыер басты мәллә? Хи-хи-хи...

Нәкъ теге еллардагыча, урынлы-урынсыз көлеп җибәрде Манзума. Һаман да шул шыр Манзума икән.

— Ерактан, ахры. Арыгансың кебек. Әйдә чәй эчеп чык, Манзума.

— Һай, җаным, үләм, эчәсем килә,— диде ул, һаман да авызын җыеп ала алмыйча.— Бакалыдан бирле җәяү кайтышым. Җитмәсә, сапушкиларымның да үкчәсе биек.

Мин күрсен дипме, ул тире эчле, алтын сыман ялтырап торган вамоклы итек кигән аягын күтәреп-күтәреп алды һәм кыстатмый гына безнең капкага таба борылды. Чиләкләремне күтәреп аның артыннан ияргдем. Каян килеп чыккан бу шау берле? Әтисе үлгәннән бирле үги анасы янына бөтенләй кайтканы юк иде бугай, күзгә-башка күренмәгәненә җиде-сигез ел бардыр. Ни кубарып йөрүе?

— Әсгать өйләнгән бит. Үги анамның баш баласы, братишка була инде, туйга кайтышым, — дип сөйләнә-сөйләнә, бусагадан атлады ул. Керүе булды, өстендәге пальто сыман нәрсәсен салып ташлады, зыңгылдатып итегенең замогын ярып төшерде, аларын салып атты да түргә узды.

— И-и-и, җаным, шушы пишшурада яшәп ятасыңмы? — диде ул, өй эченә күз йөртеп чыккач. — Кит булмаганны, двариста яшисе заманда.

— Нишлисең бит,— дип, авыз эченнән ботка пешерә-пешерә, чәй яңартырга дип, кече якка кереп киттем. Мин инде аны ник чакырганыма үкенә дә башлаган идем. Ләкин Манзума, нәкъ элеккегечә, ни сөйли башлаганын онытты булса кирәк, түр буйда уйнап утырган кызлар белән чүкердәшә башлады.

— Мәгез әле, маладуж, — сумкасының биге чертләп куйды, — гаратскуй күчтәнәч авыз итегез. Мә, мә, ал, ни стиснәйсә... Монысы кайсы соң әле? Рамазановнамыни? Нишләп бик ябык болай? Кечкенә Галибә булган бу, үзең дә сиплүнык идең бит шулай. Ә монысы күрше авыл кызымы? Ит бүкәне. Апаңның сумкасы матурмыни? Әбәү күзләре, ташкүмер кисәгемени. Күз тимәсен тагы, тфу...

Шаулап торган самавар өстәлгә куелгач, Манзума, чакырганны да көтмичә, табынга килеп утырды. Ул инде башлыгын да салып ташлаган

иде. Чәй ясаган арада мин аның кыскартып киселгән бакыр чәчен, ясалма бөдрәләрен искәреп өлгердем. Манзума, чынаякны кулымнан ук алып, кабаланып эчәргә тотынды.

— Бу иреңнән дә уңмадыңмы? — диде ул, чәй каба-каба. — Расчут алдыңмы?

— Шулайрак килеп чыкты шул, — дидем мин җәелеп китмичә генә.— Үзең соң, тормыштамы?

Ул, ут капкандай ашыгып, чынаягын бушатты да кабат миңа сузды. Иркенләп, аркаларын терәп утырды, аннан соң гына тәмләп сөйләргә тотынды:

— Чыккан булган идем бер малакасуска. Селәгәен агызып, эчеп йөрүдән башканы белмәде. Бер әйттем моңарга, ике әйттем дә, кабат исереп кайткач, йоклаган хәлендә буш бутылка кочаклатып чыгып киттем. Шуның белән прощай. Ха-ха-ха...

Һаман да шул башсыз, шау берле Манзума икән әле бу. Мәктәптә укыган чагында ук шундый иде ул, дөньядагы бернәрсәгә дә исе китми, һәрнәрсә май белән ипи ашаган кебек гади, ансат иде аның өчен. Шундый булып калган икән. Кияүгә чыгуы турында ничек сөйләп утыра бит, ялгыш кына кулын салкын суга тыгып алганмыни!

Манзума көлүеннән кисәк туктап, икенче чынаягын бүлде, баягыча ук йотлыгып эчә башлады. Шапор-шопыр китереп чынаягын бушатты да уйнап торган коңгырт күзләрен миңа төбәде.

— Инде ничек яшәргә думаеш?

— Белгән юк инде, — дидем мин, мондый сүздән качарга җыенып.— Мае, ипие белән эч әле, Манзума.

Ул ризыкка кагылмады, өченче чынаягыннан тагы бер шөпереп куйды да кабат миңа төбәлде:

— Дөньяда җебеп йөрмә син, Галибә. Боларны да саклап ятма. — Манзума кызлар ягына ишарәләп алды. — Бу пишшурага төкер. Гуртка китәргә кирәк сиңа. Кем әйткәндәй, анда заживуш. Менә мин хан сараенда яшим, ирләргә тәтемәгән акчаны алам...

— Син шул әрсез.

— Башыңа төшкәч, әрсезләнерсең аны,— дип дөрләп китте Манзума тагы. — Төрлесе үтте баштан. Маляр булып буяп та карадым, камыншик булып кирпеч тә салдым. Аннан киттем битуншиклыкка. Хәзер кранда, тау кадәр йөкләрне җилтерәтеп кенә йөртәм. Күз өстенә — каш, завутта «Маруся Кадыровна» дип кенә торалар. Әйдә Яшел Түбәгә, үзем урнаштырам.

Дәшмәдем. Кыз чагында ук шапырынырга ярата иде Манзума. Аңа ышанып, оешкан җиреңнән купсаң, үкенеп бетә алмассың. Манзума ишеләр генә юк ди анда, калада...

Манзума чынаягындагы чәен куйды да, кулын минем борын төбенә үк күтәреп, алтынланган сәгатенә карады, аннары урыныннан ук купты.

— Чынлап әйтәм мин сиңа, Галибә,— дип дәвам итте ул киенә-киенә, — ятма монда мүкләнеп. Әле өченче көн генә безнең убшыжитыяга бер лектор килгән иде. Шул әйтә, ни ди, хәзер, ди, имиграция заманасы, ди. Авыл халкының шәһәр халкына әйләнә баруы диюе инде. Тормышның закуны шундый, ди. Закун да шулай булгач, ни дип ятарга кирәк монда? Кил, эшенә дә урнаштырам, убшыжитыясына да. Ел-ел ярымнан квартирлы да булырсың... На всякий случый адрис калдырыйм әле.

Ул купшы сумкасыннан кәгазь, каләм алып нидер язды да миңа сузды. Үзе ашыгып ишеккә таба борылды.

— Фу, жаркы.

Шулай да ишегалдына чыккач, китәргә ашыкмады үзе, шәһәр тормышы хакында яңадан тәфсилләп сөйләргә кереште. Аның сүзләренә

караганда, калада бар да пешкән дә төшкән. Эшләп акча ал да түбәгә төкереп тик ят.

Район үзәгеннән килеп йөри торган вирбаушик Миңлегулов булып беткән бу чистый, теле телгә йокмый. Әле капканы чыккач та сүзе калган икән.

— Мине эзләп интегәсе түгел, — диде ул урам ягтан, — төзүчеләр убшыжитыясын табып, ударник Маруся дип сорасаң, бүлмәгә үк кертеп куярлар.

Дөресен әйтим, аның сүзләре бер колагымнан кереп, икенчесеннән чыккан төсле булган иде. Шулай да нидер әләгеп калган икән. Еш кына кала турында уйлана башладым. Нигә, кеше яшәгән җирдә без тормаска ни? Шөкер, гарип-гораба түгел, эштән курыккан юк... Бара-тора бу уй төннәрен дә тынгылык бирми башлады. Хыялланам-хыялланам да җилкенеп куям, инде бөтенләй китәргә булып бетәм. Ул да түгел, монда кадәр Яшел Түбәдән ары дөньяга чыкмавым искә төшә дә куркып китәм. Кызларымны калдырып, тулай торакта яшисемне күз алдыма китерәм дә чәчләрем үрә тора. Русча белмәвемне исәплим дә бөтенләй сүреләм. Шулай итә-итә уй киләбем чуалып бетә. Икенче төнне аны тагы сара башлыйм. Янә ярсып бетәм, янә күңелем кайта. Шул рәвешле айга якын вакыт үтте.

Ни гаҗәп, Манзума коткысы җиндә бит тәки. Икеләнү, шикләнү, куркулар акрын гына чигенеп, тәвәккәллек канат җәйде. Кыш керүгә мин инде төпле фикергә килеп җиткән идем. Китәргә, бер көн тормый шәһәргә күчәргә. Безнең кебек ятимәләр анда да бардыр әле. Кеше югала, ачка интегә торган заман түгел, ничек тә яшәрмен. Торырга бērәр почмак кына табылсын. Авылдан китүемә Мәчтүрә апа каршы каршысын, «Кая бармак буласың син бу бирнәң белән», ди, ике балам барлыгына ишарәләп. Ике бала! Нишлисең бит, язмышың шулай булгач. Ничек тә үстерермен, тәрбияләрмен әле, дәүләт ярдәм итеп торганда бирешмәм. Шул уйлар, шул җилкенүләр алып килде мине колхоз гаражына...

Машинаны төш җитәрәк кенә көйләп бетерделәр, шулай да юлга чыгасы иттеләр — колхозның йомышы җитди һәм ашыгыч иде бугай.

Менә бер бульдозер ярып үткән кар траншеясы эченнән — кышкы юлдан җай гына барабыз. Шофер егет, әле бөтенләй малай гына булуга карамастан, бик җитез кылана, күп кенә хәрәкәтләре белән Рамазанны хәтерләтә. Теге чакны, юләр кыз чагымда, беренче тапкыр кереп, очынып-сикергәләп утырган кабинада булгангамы, һаман Рамазан турында уйланам. Монда ул вакыттан бирле берни дә үзгәрмәгән диярлек. Бөгәлҗәсенә пәке белән уеп «Р. Р.» хәрефләре төшерелгән шул ук кара баранка, алда — приборлар өстендә шул ук өй рәсеме — тәрәзә капкачлары һәм кәрнизләре бизәкләп эшләнгән зиннәтле гүрничә. Тик ул инде саргаеп беткән дә утыргычның кара күне сизрәп, сиртмәләре төртеп чыккан. Бар булган яңалык — каршы тәрәзәне урталай бүлеп торган тимер рамга җеп белән асылган шайтан малае. Ул машина барган шәпкә тыпырчына, тәрәзә пыяласына сугып-тибеп ала.

Көпчәкләрнең карлы юлда җиңелчә тирбәлүеннән күз әләнә, таныш кабина, күңелгә якын әйберләр йөрәк хисләрен еракта калган көннәргә алып китәләр... Рамазан белән май заводына барабыз, имеш. Ул, гадәтенчә, күзләрен алга төбәгән килеш, әчке бер моң белән җырлап җибәрә:

> Уфаларга баруларым
> Гөлсирин өчен генә.
> Януларым-көюләрем
> Гел синең өчен генә.

Аңа кушылып, көлемсерәп, очынып барам икән. Машина кисәк кенә тартылып, сикереп алды һәм колак төбендә генә шыксыз бер аваз

ишетелгәндәй булды. «Ике атадан ике бала!» Йокы кача, йөрәк ничектер чәнчеп, әрнеп ала.

Шофер никадәр генә гайрәтләнмәсен, аңа карап машинаның тизлеге артмый, мотор теге чактагыча тигез гөрләми. Искергән шул инде безнең газик. Әнә тыны беткәндәй гыжлый, томау төшкәндәй төчкереп-пошкырып ала, «Нигә инде мине һаман җәфалыйсыз» дигәндәй чинап елый.

— Гараж тулы яңа машина, ни пычагыма шушы карт алашаны куа торганнардыр,— дип сукранып куйды юлдашым...

## 2

Сөйләүләренә караганда, үзем мин Бакалыда туганмын, тик буйны Гөлбакчада җиткердем. Әтиемне белмим, әнине бик аз хәтерлим. Әти армиягә киткәндә, бишектәге сабый булганмын. Ул бер ел хезмәт итүгә, фин сугышы чыккан һәм Бакалыга беренче кара хәбәр безгә килгән. Биш яшемне тутырганда, бердәнбер таянычым — әни дә үлеп китте. Бәхеткә каршы, Гөлбакчада әнинең бертуганы Мәчтүрә апа яши икән, шул үз канаты астына алды мине. Ул еллардагы башка хатыннар кебек Мәчтүрә апа да тол, тегермән очындагы салам башлы бәләкәй генә өйдә яши иде.

Мин белгәннән бирле, Мәчтүрә апа колхоз дуңгызларын карады. Аның ял алганын да, башка эшкә күчеп торганын да хәтерләмим: гомер буе ферма белән ике араны таптады, шуннан ук пенсиягә чыкты. Гомеренә бер кинога, театрга димим, җыелышка барганы булдымы икән апаның?! Юктыр. Клубка аяк басса да, сайлау көннәрне генә булгандыр. Еш кына ул кичен дә фермага дежурга китеп югала, өйдә кунганда да кичке эше бетүгә үк ятып йоклый торган иде. Ахры шуңа, безгә кеше керми-чыкмый. Шулай бар дөньядан аерылып, чын мәгънәсендә ятим булып яшәдек без.

Мондый өнсез, кыргыйрак тормышның шәүләсе миңа төшми калмаган, күрәсең. Мәктәпне искә алмаганда, анда-монда чыкмыйм, гөрләшеп уйнарга, шаулашып көн уздырырга дус кызларым да юк иде. Класста да ничектер боегып, яшьтәшләремнән читләшеп, иң арткы партада ялгыз утыра идем. Мәктәптән ара-тирә Манзума белән кайтуларны исәпләмәгәндә, япа-ялгыз идем мин. Укытучым белән Мәчтүрә ападан башка дөньяда яшәвемне белүче булды микән?

Шул йомык гадәтемнән үсә төшкәч тә арына алмадым. Кешеләр белән аралашасым, урамга чыгасым килмәүдән түгел, юк. Сәбәп башкада иде. Инде йөрәгендә дәрт бөреләнә башлаган кызның киң дөньяга карыйсы, кеше арасына керәсе килмимени? Минем дә яшьтәшләрем сыман кинога, кичке уеннарга бик чыгасым килә иде, бик. Тик киим дисәм юньле күлмәгем, чабата урап бәйләргә оегым булмады. Мәчтүрәападан калган сәләмәләргә уранып тереклек иттем шунда.

Борынгылар әйтмешли, дөнья миңа, мин дөньяга рәхәт күрсәтмәдек. Укуымның рәте-башы юк иде. Ул авыр сугыш елларында кая инде дәрес кайгысы, таң атуга ничек тә бер ашауны уйлап уза иде көннәр. Мәктәп юлында җиденче класска кадәр селкенеп йөрдем дә китап-дәфтәргә кул селтәдем. Ник укымыйсың диючe, дәрескә бар дип тиргәүче булмагач, тәмам тынычландым.

Мәктәптән суынуымның үзенә бер сере дә бар иде. Ул — колхозда эшләү, янәсе, үз тамагымны үзем туйдырам, кырда, фермада кешеләр белән аралашам, башка кызлар кебек клубка, аулак өйләргә йөрим. Ләкин минем бу хыялыма да тормышка ашарга насыйп булмаган икән. Теләгемне Мәчтүрә апага әйтүгә, ул кырыс кына: «Өлгерерсең, мин эт җиккән дә җиткән», — дип куйды. Мәчтүрә апага да үпкәләп булмый.

Бигрәк авыр заманнарны тарттылар бит. Көнне төнгә ялгап эшләвенә күрә тияре булса иде. Инде сугыш беткәнгә дә байтак вакыт үтте, тик безнең тормышның гына алга киткән җире күренми. Нигә дисәң, колхозыбыз һаман хәлләнә алмый. Мине эштән тыюы да әнә шуннан — дөньяга үпкәләвеннән иде Мәчтүрә апаның.

Шулай итеп, мин тагы берничә ел тоткынлыкта диярлек утырдым. Аш пешерәм дә идән юам, сыер савам да абзар чистартам. Ләкин чишмә башыдай аргып, кайнап торган яшьлекне, нидер даулап-ярсып типкән йөрәкне тыеп торып буламыни? Анам урынына калган апама каршы дәшмим дип түздем-түздем дә, сабыр канатларым сынды ахырда. «Колхоз эшенә чыгармасаң, ФЗӨгә китәм», дип дуамаллана башладым.

Апа мине һаман да сабыйга санап, баштарак дәшми йөрсә дә, әнидән калган агач чемоданга әйберләремне тутыргалый башлагач, чыдамады: «Алай бик җилкәң кычытса, чык соң. Түлке кайтып елама мина», — диде.

Мәчтүрә апа сөйләшеп куйганмы, насыйбы шулай булганмы, мине машинага йөкче итеп билгеләделәр. Уйлап карасаң, исең китәрлек. Ул чакта колхоздагы бердәнбер машинага бит! Мине! Йөкче итеп! Борын асларындагы төкләре карала башлаган малай-шалайлар да бар иде, югыйсә. Менә сиңа язмыш юк диген дөньяда!

Шатлыгымнан исереп, төнозын йокламадым. Иртәнге ашны да көтмичә, алачыкка төшеп киттем. Колхозның гаражы да, мастерское да яртылаш җир астындагы шул алачык иде ул елларда. Килсәм, тирәюнь тып-тын, инде буявы шактый уңарга өлгергән йөк машинасы ватык лобогрейкалар янында моңаеп тора. Каян килгәндер ул әрсезлек, кабинаны ачтым да сиртмәле утыргычка менеп утырдым. Моннан соң гел шушында йөриячәкмен ич мин!

Кулдан тотучы булмагач, тагы да батырайдым: рульне уңга да, сулга да борып карадым, сикәлтәле юлдан баргандай, башым кабина түшәменә тигәнче сикереп-сикереп алдым. Шулай күпме иләсләнгәнмендер, иртәнге кояшның пыяла аша төшкән ләззәтле җылысына изрәп, йоклап киткәнмен.

Машина алдындагы калай капкачның шыгырдап ачылуына сискәнеп киттем. Күземне ачсам, тәгәрмәч өстендәге канатта — шофер Рамазан абый. Ул елмайган, авызы гына түгел, йөнтәс ак кашларына кадәр көлә сыман.

— Нәрсә, иркә, өйгә кертмәделәрме әллә? — диде ул, ничектер мыскыллырак итеп. — Төнлә озак йөрмиләр аны.

Әйтерсең оят бер эш эшләгәнмен, кызышып, тирләп чыктым. Кабинадан төшә-төшә, нишләп йөрүемне аңлатып бирдем.

— Әһә, синмени инде ул чибәр туташ, — диде ул, уенын-чынын бергә кушып. — Болай булгач, эш гөрлиячәк икән безнең. Нәрсә алар анда, машина кабинасын детсад дип белгәннәрме! һе...

Ул, кулына чиләк тотып, тимер мичкәләр ягына китеп барды, мин дә аңа иярдем. Рамазан абый чиләген миңа бирде дә мичкәләрнең берсен шаңгыратып ачты һәм аны кыйшайтып:

— Чиләгеңне менә болайрак тот әле, иркә,— диде.— Курыкма, тешләми ул.

Шофер нәрсә әйтсә, шуңа йөгереп торам. Бензин дә салдык, инешкә суга да төшеп мендек. Рамазан абый миңа карап-карап торды да:

— Үзең болай булган нәрсәгә охшыйсың, иркә, — дип куйды. — Тик сыйракларың бик сыек икән. Нинди куләгәдә яттың соң син? Исемең ничек?

— Галибә.

— Исемең дә шәп икән. Кем кызы соң?

Ике авыз сүз белән генә кемлегемне сөйләп бирдем.

— Ал-лай, — диде ул, машинаның кай җиренәдер су сала-сала. — Мәчтүрә апа асылы икәнсең. Яле, җилтерәтеп кенә су алып мен дә кабинаны юып чыгар.

Очынып инешкә төшеп мендем, утыргыч артына кыстырылган чүпрәкне алып, кушканны үтәргә әзерләндем. Ләкин бик кыен эш икән ул кабина юуы. Бөтен җире тимер, иркенләп ышкып та, корытып та булмый. Рамазан абый миңа карап бераз елмаеп торды да кулымдагы чиләгемә үрелде.

— Бир әле, иркә.

Ул ике як ишекне дә киереп ачты да чиләктәге суны кабина эченә селтәп җибәрде. Бөтен җирдән болганчык су агып чыкты.

— Менә шулай юалар аны, — диде ул ниндидер төксә, өйрәтүле тавыш белән. — Дүрт-биш чиләк сипсәң, чиста Марзия идәне кебек ялт итәр.

Инеш белән машина арасын ничә ураганмындыр, Рамазан абый әйткәч кенә туктадым. Аның исә эше пешми, ахры. Машина алдындагы тишеккә кәкре тимер тыгып, аны әйләндерә-әйләндерә дә туктап тора, маңгаендагы тирен сөртеп ала. Аннан калай астына тыгылып, нидер бора, чарт-чорт китереп ала. Алай да кабынмый машина.

— Моның чаткысы югалган, иркә. Шуннан, аяк астыннан эзли тор әле, — диде дә алачыкка кереп китте.

Су түгелеп былҗыраган җирдән күпме генә эзләсәм дә, чаткыга охшаган әйбер күренмәде. Мүкәләп машина астына кердем, балчыкка буялып беттем, ләкин чаткы түгел, тимер кисәге дә тапмадым. Ул арада Рамазан абый килеп чыкты. Инде орышыр бу мине дип торганда, шаркылдап көлеп җибәрде.

— Эзләмә, монда икән, — диде ул, көлүеннән тыела алмыйча.

Аннары мотор тирәсендә бераз кайнашты да бер җилләнүдә машинасын кабызып җибәрде. Шуннан кузгалдык без. Әллә кем булып кабинада утырып барам, авызым үзеннән-үзе ерыла. Тик колхоз идарәсе янына килеп туктагач кына, песи булып бер почмакка чүмәштем. Идарәгә бер кереп, бер чыгып йөргән кешеләргә күтәрелеп карарга да оялам. Бәхеткә каршы, бу газап озакка сузылмады, кулына кәгазь тотып, Рамазан абый килеп чыкты. Менә китәбез дип шатланып утырганда, кем янынадыр тукталды. Исәнләшүләреннән бригадир Шәрәф абзый икәнен чамалап алдым.

— Син мине бала караучы да, грузчик та итмәкче, ахры, — диде Рамазан абый тегенәргә.

Шәрәф абзый гадәтенчә җай гына акланырга, майлап-җайлап күндерергә тотынды.

— Ни, Рамазан туган, ир-атлар трактор, чәчкеч тирәсендә җитешми. Үзең беләсең, сабанда сайрашыр чак. Ни, болай чирләшкә сыман күренсә дә, бик тә булган бала ул. Көйләп-җайлап йөртсәң, эшләр, эшләр, алла боерса. Аннан мин әйттем анда, төяшерләр.

— Көйләп-җайлап, имеш. Үзең төяп-бушатсаң диген, ичмасам.

Рамазан абый кинәт кенә ишеген ачып кабинасына керде дә, урынына утырыр-утырмас, машинасын үкертеп кузгатып та китте. Аның ак кашлары астындагы күзләре ничектер хәтәр ялтырый иде бу минутта. Бөтенләй почмакка сеңдем. Менә нәрсәгә аркылы-торкылырак сөйләшкән икән. Мин-чебешне түгел, ир-атлар көткән. Чыннан да, нинди эшче инде мин?

Бераз юл узгач, Рамазан абыйның ачуы басыла төште, ахры, машина тигез, салмак эшли башлады, үзенең дә күзләре үзгәрде, көлемсерәү төсе алды.

— Чәчүчеләргә симәнә ташырга барабыз, иркә, — диде ул, һаман да шул мине баласыткан тавыш белән.

Дөресен әйтим: аның сүзен ишеткәч, тагы да шүрләп калдым. Машина хәтле машинага капчык төяп бушата башласам, үләм ич мин. Әллә соң төшеп калыйм микән? Анда, кеше алдында, хур булганчы...

Көенүем юкка булган икән. Амбар янында халык гөж итеп тора иде. Күңелләре күтәренке, көлешә-көлешә бодай орлыгын җилгәргечтән үткәрәләр. Без килеп туктауга, машинаны урап алдылар, капчыклар әллә тиде, әллә тимәде кулыма.

Басуда инде безне чәчүчеләр көтә иде. Җир башына җитүгә, егетләрнең берсе — түбән очның Борын Әхтәм — сикереп кузовка менде һәм капчыкларга ябышты. Чирек сәгать дигәндә, мин инде буш кузовта басып тора идем. Көнозын шулай: төяп озаталар, бушатып алалар. Белмим, нигә дип утырып йөримдер мин машинада?!

Колхозга, авылдашларга файдам тигәндерме-юкмы ул көнне — аны-сын әйтә алмыйм. Шунысы бар: ул елгы язгы чәчү күземне ачты минем. Уйлыйм-уйлыйм да хәзер гаҗәпләнеп куям. Унсигез яшемә кадәр кайда яшәгәнмен дә гомеремне нишләп уздырганмын соң мин? Дөньяның шушы матурлыгын күрми ничек түздем икән?! Ул язгы иртәнең гүзәллеге! Ул күмәч булып күпергән буразналардан җинелчә пар күтәрелүе! Җылымса җилдә талгын гына тирбәлеп утырган көр уҗымнарга, алар өстендә талпынып-талпынып сайраган тургайларга гына кара да арып-талганда да берсен-берсе шаян сүз белән дәртләндереп җибәрүче авылдашларны күр син! Бу ямьгә, бу хозурлыкка ни җитә?!

Рамазан абый да баштагыча төксе түгел. Һаман да шулай тупасрак шаярткаласа да, сүзләрендә мыскыл сизелми. Бала-чага дипме, әллә инде, ходаем, җиткән кыз итеп карыймы, җае чыккан саен ярдәм итә, матур-матур сүзләр әйтеп мине кызарта, аңлашылып бетмәгән әллә нәрсәләр сөйләп куя.

Инде мин дә аңардан куркып-өркеп тормыйм. Үзе кебегрәк шаяртып җавап бирергә тырышам, кайчак уен-көлкене үзем үк башлап җибәрәм. Беренче көннән үк абыем кебек якын булып китте ул.

Без ургып аккан чишмәләр, яшәреп килгән чирәмлекләр, ак күбеккә батып утырган әрәмәлекләр яныннан узабыз. Тирә-юньгә хуш ис бөркелә, шомырт чәчәгенең илаһи исе башны әйләндерә. Ул да булмый, изүләрен чишкән бөреләре белән купшыланып утырган туйралыкларга барып керәбез, яшькелт-сары йомгак булып әниләре янында кыймылдашкан каз бәбкәләрен, яшь бозауларны өркетеп, авылны үтәбез.

Һәр күренеш — минем өчен зур бәйрәм. Дөнья ямен күбрәк күргән саен тыным кысыла, йөрәгем ныграк тибә башлый, атылып итәгемә төшәрдәй була. Шушы рәхәт, шушы җәннәт кайда булган да, аның турында нигә берәү дә әйтмәгән миңа?! Юк инде, мине шушы бәхетемнән берәү дә аера алмас!

Һай, тиле дә чаклар булган соң! Шулай шатланып, дәртләнеп, алгысып берничә көн эшләүгә, пошамanга төштем. Чәчү бетеп тә бара. Аннан соң миңа эш калмаса? Кешегә генә түгел, мал-туарга да кычкырып дәшмәүче, һәрчак уенын-чынын кушып сөйләүче Рамазан абыйдан аерсалар? Элеккечә тагын ялгызым өйдә утырып калсам? Акылдан язачакмын ич мин! Туктаусыз саруны кайнатып торган шөбһәмне Рамазан абыйга да әйттем. Ул исә авызын ачмый гына эчке бер ым белән көлеп куйды:

— Муеның булсын, иркә, муеның. Камыты табылыр.

Сүзе дөрес булып чыкты бит, әй. Чәчү бетүгә, безне сөт ташуга куйдылар. Яңа эштә тагы да күңеллерәк булып китте. Әле авылдашлар йокыларыннан да тормаган була, безнең машина дымсу тузанга беренче эз салып урамнан уза. Тынып калган фермаларны үтүгә, тауга күтәреләбез һәм урманга барып керәбез. Һай, матур да соң инде иртәнге урман! Әле таң яктылыгы үтеп кермәгән куе агачлар арасында серле тынлык. Аланнарда исә бар үсемлек чык дингезендә. Гөлҗимеш

куакларында, тукранбаш, какы яфракларында күз яшедәй саф су бөртекләре шул кадәр мул ки, беренче карауда алан ак ефәк шәл ябынган сыман. Күз явын алырлык шул бәллүр япманы ярып беренче узабыз без. Машинаның тәрәзәләре ачык, чык тамчылары чәчри, иркәли. Рамазан абый юри кабинадан башын чыгарып бара. Бу аның гадәте. Нигә дисәң, иртә таңда ул кәефсез, йокысы туймаган була.

Җитез газик ябалдашлары белән баш өстендә чатыр корган эре урман арасыннан бара, ул да түгел, киек җәнлекләр дә ерып үтмәслек туйралыклар яныннан уза. Тәгәрмәч астыннан гына көртлек күтәрелә, ниндидер кошлар яшел күләгәгә посалар. Икенче мизгелдә инде борма юл безне зур-зур аланнарга, быел гына киселгән такыр кварталларга алып чыга.

Җәйләүгә без сандугачлар чык тамчыларын эчеп бетергәнче үк барып җитәбез. Анда тынлык качкан була инде бу вакытта. Яшел толымнарын салындырып утырган каеннарның әле берсе, әле икенчесе янында чиләкләрдә сөт безелдәве ишетелеп кала.

Без, савымчыларга игътибар итмәстән, мул сулы чишмә буасы янына килеп туктыйбыз. Анда безне судан тимер чалмаларын гына күрсәтеп торган сөт бидоннары каршылый. Кичен савылган сөтне әнә шулай салкын суга батырып куялар кызлар. Югыйсә, ул эчи, әрәм була.

Рамазан абый беренче бидонны судан тартып алуга, ярдәмгә көтүчеләр килеп җитә, хисапчы Сәйдә күренә, күбек ташып торган чиләкләрен тотып, терлекчеләр җыела башлый. Менә шунда китә инде чыркылдашу.

Җәйләүдә минем кебек җебегәннәр түгел, авылның чәтнәбиләре. Күбесе сугыш афәте аркасында утырып калган, акыл җыйган кызлар. Үзләре әйтмешли, чиратларын уздырып кайткан яшь хатыннар да юк түгел. Һәрнәрсәне — кирәген дә, кирәкмәсен дә — аты-юлы белән сөйлиләр, тартынып тормыйлар. Мин исә, аларның еш кына тупаска күчеп китә торган уен-көлкеләрен ишетмәмешкә салышып, машина әрҗәсендә бидоннар тезеп маташам. Дәшми-тынмый эшләвем болай сер бирмәс өчен генә. Дөресен әйтсәм, эчемдә өермә минем — кызларга җен ачуларым чыга. Туктале, ачу гынамы соң бу? Мин көнләшәм, билләһи, көнләшәм. Нигә дисәң, алар һаман әрсезләнәләр, уенга сылтап кына Рамазан абыйга сырпаланалар, үз итеп кенә сугып алган булалар.

Менә бу газаплы минутлар да үтә. Кирәкле кәгазьләрне алуга, кузгалып та китәбез. Уф, бу шайтан туеннан котылдык бит. Без тагы икәүдән-икәү. Кабат борылмалар саныйбыз, куелыклар яныннан узабыз, инде чык пәрәнҗәләрен ачып ташлаган аланнарга килеп керәбез.

Хәтәр җирләрне үтеп, олы юлга чыгуга, Рамазан абый җырлап җибәрә:

> **Ал кадыйм түшләреңә,**
> **Гөл кадыйм түшләреңә.**
> **Былбыл булып, гөлгә кунып**
> **Керәсең төшләремә.**

Көн дә бер вакытта, бер үк җирдә җырлый башлый ул. Нигә дисән, аның инде йокысы ачылып беткән, шоферга хас хәрәкәтләрне кул-аяклары үзеннән-үзе ясый.

Ул җырлый, мин аңа карап барам. Куркып кына, аның әрекмән яфрагыдай зур колагы артына посып күзәтәм мин аны. Нигә дисәң, шушы яшемә җитеп, бер генә ир-атка да күтәрелеп караганым юк иде әле. Чын менә, Рамазан абый белән күпме эшлибез, мин исә аның күзләре нинди икәнен дә әйтә алмыйм.

Рамазан абыйның бөтен игътибары юлда. Яшь бозауныкыдай озын керфекләре алга төбәлгән, кымшанмыйлар да. Салам чәче маңгаена төшеп, мең бөртеге мең якка тырпайган ак кашына тоташкан. Аның болай да җәлпәк борыны миңа бөтенләй күренми. Ул авызын ачмый да сы-

ман. Ә тавышы көр, моңлы. Үзе җырларның рәтен-башын белми бугай. Яңарак көйләргә җырлый башласа, буразна боза торган көйсез сабан кебек, берсеннән икенчесенә күчеп китә. Шулай да тавышы шәп аның. Мондый табигый моңны радиодан да ишеткәнем юк.

Гаҗәп, нишләп шул кадәр моңлы ул? Шундый сорау һич кенә дә башымнан китми. Бервакыт Мәчтүрә ападан сорадым.

— Бәхетсез, шуңа моңлы,— диде ул, бәхәсләшергә урын калдырмыйча.

Дөрестер, сөйләүләренә караганда, бер дә рәхәт күрмәгән бит ул. Әтисе, колхозлашудан куркып, Донбасс ягына чыгып киткән, шунда ташка басылып үлгән. Ике абыйсы сугышның беренче көненнән үк фронтка алынганнар, алар артыннан ук апасы хәрби заводка эшкә киткән. Малай чактан ук атлар караучы өченче абыйсы кыен елларда бер кесә бодай өчен эләгә. Урында яткан әнисе белән торып кала Рамазан абый. Өйдә рәт-баш чуала, мал-туар бетә, йорт таркала: келәт, абзаркура берсе артыннан икенчесе ишелеп төшә башлый. Дәррәү генә таралган туганнары исә кайтмыйлар да кайтмыйлар: кайсы үлеп кала, кайсы күңеленә ошаган җирдә төпләнә.

Мәктәбен ташлап, төпкә җигелә Рамазан абый. Олылар белән берәттән колхозда эшли, бакчасында бәрәңгесен үстерә, аз булса да колхоздан икмәк тә тия үзенә. Тик булганын да пешереп ашатучы юк, үзе үк йорт эшләренә тотына. Белем җимеше тимәсә дә, әрсезлекне, уңганлыкны кызганмаган аңардан табигать. Ертып-ешып дигәндәй, шоферлар курсына кергән, аны тәмамлап, сугыштан соңгы беренче машинага авылда ул утырган.

Шуннан тормышы бераз тернәкләнә башлый моның. Сыер алып җибәрә, сарыгын, тавыгын асрый башлый. Дүрт почмаклы җыйнак кына яңа өй җиткереп кере. Өе калай башлы, биек, күркәм. Андый хуҗалыклар сирәк иде әле бездә ул елларда. Тик тынычлап яшәргә насыйп булмаган икән бичарага, кышын чирле әнисен җирләде. Хәзер инә ялгызы яшәп ята. Сыерын да үзе сава, ашарына да үзе пешерә. Җәйләүдәге теге әрсез «алабайлар» аның тирәсендә юкка сырпаланалар дисеңме?

Җәйләүдән май заводына кадәр булган егерме чакрым ара шул рәвешле үтә. Заводта без сөт аертканны көтәбез. Дөресрәге, мин көтәм, Рамазан абый машинасы тирәсендә маташа: нидер бора, сүтеп ала, ниткәндер тимерләр белән кайнашып, майга батып бетә. Һич булмаса, машинаның тузаннарын сөртеп йөри, кабинаны юып ала.

Кайтканда ул тагы җырлый, акрын гына мин дә кушылам. Ул миңа карап елмаеп куя:

— Менә бит нинди күңелле, — ди.

Аннан соң без яшь бозауларга аерткан сөт эчереп мәшәкатьләнәбез, җәйләүгә фуражын, тозын, акбурын илтәбез. Мал-туар тирәсендә эш бетәмени?

Китаплардан укыганны исәпкә алмасам, буй җиткереп мәхәббәтнең нәрсә икәнен белмәдем мин. Кичләрен, Мәчтүрә апа йоклап киткәч, кулга эләккән беренче китапны укый-укый идем дә тиле кеше кебек көлеп җибәрә торган идем. Кайсы китапны гына алма, егет кызны, кыз егетне ярата, елашалар, саргаешалар, акылларыннан язар чиккә җитәләр. Кан кардәшең булмаган чит-ят кеше өчен саргаеп, саташып йөр, имеш. Мең ялган инде шунда, эш юктан язган берсе. Шулай да укуы кызык.

Ләкин көлке куа килде. Теге җәйне үзем шул көнгә калдым бит, дивана. Һич көтмәгәндә булды ул. Беркөнне җәйләүдән кузгалып, байтак юл алгач, Миләшле алан турында машинабыз туктады да калды. Рамазан абый, капкачны ачып, мотор тирәсендә казына башлады, мин куп-шыланып утырган миләш куагына таба юнәлдем. Шундагы матурлыкка сокланып күпме йөргәнмендер, янәшәмдә генә нидер чыштырдаганга

котым алынып, артыма борылдым һәм Рамазан абый белән күзгә-күз очраштым.

— Рамазан абый! — дип кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым.

— Әү, җаным.

Ул мине кочагына кысып алды, иреннәремнән үпте. Әллә үпмәде дә микән? Белмим, хәтерләмим. Бу минутта мин дөм-исерек, дөньядан кул селткән кеше. Исемә килгәндә мин машина әрҗәсендә, бидоннар өстендә утыра идем. Рамазан абый исә басмага менгән дә мине үгетли:

— Төш, тилемсә, очып каласың бит.

Мин һаман турсаеп утыргач, шактый кырыс итеп шелтәләп тә алды:

— Төш диләр, праваны алдырасың ич!..

Шул исереклегемнән тиз генә айный алмадым. Без инде көндезләрен генә түгел, кичләрен дә бергә уздырабыз. Гомер аяк басмаган су буйларын, әрәмәлекләрне урыйбыз, тау башларында йөрибез, нидер сөйләшәбез, туктаусыз көләбез. Ниһаять, шул елгы сабан туе чәчләребезне бәйләде. Ул сагышлы-саташулы көннәр, туй мәшәкатьләре, ыгы-зыгылы сабан туйлары үттеләр дә киттеләр.

3

— Галибә апа! Галибә апа дим!

Кем дәшә? Каййдан дәшә? Кайсы заманнан дәшә? Аңыма килә алмый оеп утырам. Тавыш тагы кабатланды:

— Галибә апа, йоклап киттегезме әллә?

Шофер егет икән. Минем саташудан тәмам шикләнеп, машинасын туктаткан, бөтенләй аптыраган кыяфәттә миңа карап тора. Мин гаепле елмаеп, аңа таба борылдым һәм акланырга теләгәндәй:

— Яшьлегем белән очраштым, — дидем.

Егет дәшмәде. Чытык кына елмаеп, стартерга басты, һәм без кабат кузгалып киттек.

Инде асфальтка да чыктык. Ләкин машинаның хәле җиңеләймәде, «ютәлли-ютәлли» берничә чакрым барды да бөтенләй туктап калды.

— Шабаш, — диде шофер үрсәләнеп, — ичмасам, Яшел Түбәгә дә җитә алмадык.

Ул, кабинадан чыгып, капотны күтәрде һәм башы белән калай астына чумды. Туктагач кына абайлап алдым: җил көчәеп, көн тәмам суыткан икән. Берничә минутта тәрәзәләргә боз элпәсе йөгерде, ул да түгел, алар ап-ак бәс белән капландылар. Пошаманга төшеп, үземне-үзем тиргәп алдым. Кичкә каршы ерак юлга кем чыга инде?

Суык иң элек аякларга үтте, аннан пальто эченә керә башлады. Болай бүкән кебек утырып, тәмам туңуың бар. Салкын чәчеп торган тимер ишекне ачып, юл буендагы кар өеменә сикердем.

— Нәрсә, булырлык түгелме?

Шофер дәшмәде, борынын лышт-лышт тартып, мотор эчендә казына бирде. Машина артына чыгып йөренергә, сикеренергә тотындым. Инде күз бәйләнеп килә иде, тау-кашлакларда сирәк-мирәк чайкалган факеллар ачыкланып, аларның шәүләсе астан гына йөзгән каурый болытларга алсу җилкән булып төште. Чагылларда, басу түрендә ут күлләре, якты манаралар пәйда булды. Безнең яннан кырыкмаса-кырык төрле машиналар узалар да, тик берсе дә туктамый, безгә ярдәм кулы сузучы күренми.

Өтеп торган салкын һавада дәһшәтле шуышып йөргән күләгәләрдән шомланып, шофер тирәсенә елыштым. Ул, моторга җан керәсенә өметен инде тәмам өзеп, машина канатында тын гына утыра иде. Шул чак машинаның теге ягыннан даңгырдык калын тавыш ишетелде:

— Нәрсә, энекәш, көймә комга терәлдеме?

Тавышның иясен күргәч, имәнеп киттем: таныш булмаган кешенең йөзе пластмассадан ясалган битлектәй иләмсез, җитмәсә, мазутка буялып беткән. Шулар өстенә факелдан төшкән яктылык аңа әкиятләрдәге

фантастик бер зат кыяфәте өсти иде. Юлаучының өстендә майланып, беләүләнеп беткән сырма, шомарып, пәке үткерләрлек булган кыр сумкасын җилкәсе аша аскан иде.

— Бензинең киләме? — диде ул, машинаның икенче канатына басып. — Чаткың бармы?

Аның сөйләмендә ниндидер таныш чалым сизеп алгандай булдым.

— Барысы да бар, кабынмый, чукынган,— дип сукранды шофер һәм теш арасыннан гына «черт» иттереп төкереп куйды.

— Ә син, туташ, бөтенләй тунгансың, тизрәк кер кабинага, — дип боерды «маскалы» кеше һәм, бияләен салып, моторны капшаштыра башлады. — Хәзер үк суыңны җибәр, харап итәсең радиаторыңны!

Каян килгән акыллы баш. Шоферы да шуны тыңлап тора тагы, ул машина астына кереп бераз мышкылдауга, каяндыр челтерәп су ага башлады. Шул арада кемдер юлбасарларча әче итеп сызгырып җибәрде.

Кузовының яртысына брезент корылган газик каты чыелдап акрынайды да безнең алга чыгып туктады.

— Трос, трос әзерлә,— дип кычкырды, «маскалы» кеше һәм һич көтелмәгән җитезлек белән теге машинаның шоферы янына йөгерде. Бераздан инде без, бөркәүле газик артына тагылып, Яшел Түбәгә таба бара идек.

Калынлы-нечкәле торбалар, зур-зур тимер чыгырлар, миңа таныш булмаган әллә ниткән җиһазлар тулы зур, иркен ишегалдына кергәч, машина туктады, һәм әлеге кеше, кабинадан төшеп, безнең янга килде.

— Әнә шул аулак почмакка куй, — диде ул, кулы белән бер аралыкка ишарәләп. — Курыкма, чуртым да булмас машинаңа.

Аңа ияреп, коймалары купкан кысан аралыктан чыктык һәм тапталып беткән сукмак буйлап якты утлар чәчеп торган йортларга карап юл алдык. Ул безне кар баскан бараклар, алар янәшәсендә мин кем дигәндәй кукраеп утырган ике катлы өйләр арасында йөртте-йөртте дә берсенең ишеген каерып ачты. Өшүебез тәмам җиткән иде, аңа тагылып ук эчкә уздык. Ишекләре ачып куелган иркен кухнясыннан ук моның тулай торак икәнен чамалап алдым.

«Маскалы» кеше хуҗаларча нык-нык басып кухняга узды да шәрран ярып кычкырып җибәрде:

— Исән генәме, Маруся түтәй! Исәннәрмесез, кызлар?!

Аның шулай гөр итеп сөйләшүе кабат бик таныш булып тоелды миңа. Кайда һәм кайчан ишеттем соң мин мондый дыңгырдык тавышны?

Хатын-кызлар дәррәү генә кыркылдашып, көлешеп алдылар. Сүзләреннән бары «Хаммат абый, Хаммат абый» дигәннәрен генә хәтерләп калдым.

— Ярый, кызлар, уйнар-чыркылдашыр чак түгел,— диде Хаммат дигәннәре, — эш сурьюзный монда. Маруся түти, менә бу туташны иң җылы, иң йомшак урыныңда йоклатып чыгар әле... Ә син, энекәш, мулла кебек ялманып торма, монда калдырмыйм мин сине, үзебезгә апкитәм...

Ул шулай уенын-чынын кушып гөрләде-гөрләде дә шоферны ияртеп чыгып китте. Газ плитәсендә бәрәңге кыздырып маташкан кызларның берсе, имән кискәседәй юаны, эшен ташлап яныма килеп җитте.

— Туңмаганмы? — диде ул, кулы белән бит алмаларымны сыйпап, һәм, төрткәләп диярлек, плитә янына алып килде, пальтомны салдырып, шәлемне чишә башлады. — Тәмам өшегәнсең бит.

Сүз сөйләр хәлгә җитеп җылынгач, кызлар мине бүлмәләренә алып керделәр, кайнар бәрәңге, чәй белән сыйладылар. Аннан буш караватларның берсенә яткырып, өстемә ике-өч кат юрган яптылар.

Бүгенге мәшәкатьләр, борчылулар һәм хафаларга караганда, бик тиз изрәп йокыга китәрмен сыман иде. Әмма, ни гаҗәп, аек акыл мигә оныталып, томаланып китәргә бирми, башымда кырыкмаса-кырык төрле уй

кайный. Артык арганлыктанмы, өшегәннәнме бу, әллә юл буе Рамазан белән төшләнеп, хыялланып килүдәнме? Әллә соң әлеге «маскалы» кешенең таныш сыман тоелган тавышы сәбәпчеме моңа? Ни генә булмасын — йокы качты, уй өермәсе мине кабат узган көннәремә алып китте. Туган авылым булып беткән Гөлбакча белән, Рамазан истәлекләрен саклаган изге урыннар белән аерылышу кичем иде шул бу минем.

## 4

Без Рамазан белән начар яшәмәдек. Бер-беребезгә төчеләнеп, чүкердәшеп тормасак та, мөнәсәбәтләребез күркәм, матур иде. Ул мине эчү белән газапламады, бозык юлда йөреп интектермәде, көнләшеп тәңкәмә тимәде. Бал-май эчендә йөзмәсәк тә, мохтаҗлык күрмәдек. Үзем шул сабан туеннан соң ук фермага бозаулар карауга күчтем, семьялы кешегә авыл эчендәге эш кулайрак булыр, дип уйлаштык. Аннан килеп, соңгы елларда терлекчеләргә игътибар да артты: көрәп алмасалар да, хезмәт хаклары зарланырлык түгел, акчасын да, өстәмә түләүгә тигән бүләк-мазарын да ала идек.

Рамазанга килсәк, аны инде сөйләп торасы да юк. «Җен Рамазан» дигән даны авылда юкка гына таралмаган. Мондый кушамат алама гадәте, яисә берәр зәгыйфьлеге өчен тагылмаган аңа. Эшнең авырын-җинелен сайламыйча, алны-ялны белми тырышуын, төн йокыларын калдырып теләсә кая юлга чыгып китүен, йөкнең авыр башыннан күтәрүен искә алып сукканнар аңа бу тамганы. Колхоз башлыклары да, авылдашлар да үлеп торалар иде аның өчен.

Малын да тапты, булганының кадерен дә белде. Шулай да безне якыннанрак белгән кешеләр: «Болар рәхәт күрде»,— димәсләр. Дөнья куып, мәшәкать эчендә кайнап үтте безнең гомер. Беләм, мәшәкатьсез, уй-исәпсез генә берәү дә тормыш итми. Шулай да һәрнәрсәнең чамасы-үлчәве була. Безнекендә исә юк иде ул чама дигән нәрсә. Комсызланып, теше-тырнагы белән ябышкан иде Рамазан тормышка.

Йорт-җирен мин килен булып төшкәнче үк тернәкләндергән иде ул. Дүрт почмаклы өен авылда беренчеләрдән булып калай белән яптырды. Бабасыннан ук калган чормасыз таш келәтен кыеклап толь белән коршыды. Шулай да абзар-кура ачык та тишек, коймалар череп ауган, мунчага да күршеләргә йөри идек әле.

Бергә яши башлавыбызның беренче көннәреннән үк әнә шулар турында ачынып, йорт-җирне яңарту хакында канатланып сөйләргә ярата иде Рамазан. Сүз шуңа борылдымы, эшләгән чагы булса эшен, ашаса кашыгын ташлап, дөньясын онытып хыялланырга тотынып иде. Имеш, иң әүвәл, карчык, өйне алты почмаклы итәбез. Аннан соң чиратта шалкан кебек ак эчле усактан буралган җылы сарай, печән киптерергә, аны өяргә, кисеп-ярылган утынны тутырып куярга кәртинкә кебек абзар-кура, алты почмаклы ак мунча, тегермәнче Җәлалныкы кебек дүрт метр биеклегендәге урыс капка. Һа-а-ай, болар гына идеме соң аның башында?! Урынга яткач та, шуларны саный-саный, йоклап китә алмый интегә иде, мескенем. Әйтер иде, син көлмә әле, карчык, дияр иде. Менә күз алдыңа китер: имеш, өй каршында да, төзеләчәк веранда янында да алмагачлары шау чәчәккә күмелгән ян бакча, тавыкларга җылы кетәк, ишегалдында да, мунча, абзарларда да электр лампочкалары, бакча эчендә генә кое, аның өстендә су кудыру насосы...

Әле болары эшләп беткәчкә дә планнар бар. Кирпечтән салынган кухня, пыяла белән каплаган теплица, алыначак автомобильгә гараж, җәйләрен эштән кайткач коену өчен душ, ишегалдына асфальт, анысы булмаган тәкъдирдә таш җәю. Аннары килеп, туачак улыбызга өй. Монысы инде безнекеише генә түгел: ул ике катлы булып, аста кухня һәм

хуҗалык кирәгенә ярашлы бүлмәләр, өстә кунак залы. Кыйблага караган як исә гел пыяладан торачак, ул буйда идәннән түшәмгә кадәр гөлләр үсәчәк, үзе әйтмешли, кышкы сад-бакча булачак. Болары әле минем хәтердә калганнары гына. Үзе көн саен шуларны сөйләп тә очына чыкмады бугай.

Мин, җүләр, аның хыялларын онытылып тыңлыйм һәм, аларның чынга ашачагына аз гына да шикләнмичә, сабыйларча куана идем. Тик боларның чиреген генә тормышка ашыру өчен дә күпме көч түгәсен, күпме төн йокыларын калдырасын уйлап та карамаганмын. Дөресрәге, ул кадәресен нечкәләп торырга вакыт та булмады. Таң беленер-беленмәс, ашыга-кабалана, торып аш саласың, сыерны савып, көтү куасың, тавыгын, үрдәген ашатасың. Ул арада фермага йөгерергә кирәк. Көндезен бераз бушанып аласың алуын. Инде ял итеп булмасмы дип, йөгереп кайтасың. Кая ул ял! Хатын-кызга эш бетәме соң йортта! Кер кайнатасы, идән юасы, мич агартасы... Һи-и-и, саный башласаң, бармакларыңны кушып та җитмәс.

Җәен аеруча эш күп авылда. Планнарын мин түгел, үзе дә онытты бугай Рамазан, караңгылы-яктылы гаражга китеп бара, икенче караңгыда гына кичке ашка кайта, әле анда да тынычлап ашарга бирмиләр үзенә. Капка төбенә килеп туктавын көтеп кенә торалар авылдашлар. Кайсы йорт кузгаткан — идәнлеге, түбәлеге, тегесе-монысы кирәк. Икенчесе мич чыгартмакчы — комын, кирпечен кайтарырга исәпләп йөри. Һай, аз идеме соң мәшәкать ул елларда! Сугыш чорында шәрәләнеп калган авыл яңадан тернәкләнә, күтәрелә, яңара иде. Мескенкәем, Рамазанны әйтәм, ник кенә берсенә «арыдым» яисә «машинам ватык» та фәлән-төгән дисен, колхоз башлыгының фатихасы бар икән, тамагын тиз-тиз ялгар иде дә берәрсенең йомышына китеп барыр иде. Рөхсәт язуыннан башка гына да күп юллады бугай. Шуңа да дус-ише күп, теләгән нәрсәсен тапмый калмый иде.

Шул рәвешле көннәрне төнгә ялгаган җәйге чорда кая инде үз өендә эш кузгату. Сөйләгәннәр, хыялланганнар акрын гына көтә бирделәр. Баксаң, миңа гына шулай тоелган икән. Рамазанның уенда исә һәрнәрсәнең срогы билгеләнгән, материаллары юлланган булып чыкты. Бер кайтуында ул машинасына сөям салып кайта, икенче карасаң, җепсәлеген, ишек-тәрәзә яңагына ярарлык агачын төягән. Иртәгесен аларны ярдырып, телдереп алган була. Аларын урнаштырып бетерүгә, я цемент, я таш белән кайтып төшә. Бервакыт ишегалдында атлап йөрер ара, абзар тирәсендә мал ябарлык урын калмады. Боларның барын каян ала да кем белән хәзерлидер, ничек төйидер. Мин аның эшенә тыкшынмыйм, соңгарак калган кичләрендә, йоклаганга салышып, янына да чыкмый идем кайчак. Моның үзенә күрә сәбәбе, үпкәсе дә бар иде. Ул йөксез кайткан чагында да туп-туры өйгә керми, һаман ишегалдында, абзар тирәсендә кайнаша — нидер үлчи, шакылдый, сукыр ат кебек дөп-дөп басып караңгыда һаман йөренә. Токмачым утырып, чәем суынып бетә. Җен ачуым чыга. Ничек арымыйдыр да ничек түзәдер адәм баласы! Төн уртасында гына керүенә карамастан, мине шаярткан булып маташа, имеш, әнисе, әллә сүндең дә? Тәүлегенә нибары ике-өч сәгать йокы белән кала иде кайчак...

Шулай төн ката ялгызы бер базар ясап йөрүенә кәефем кырылса да, еш кына кызганып куя идем, бахырны. Берчак төнге унберләрдә кайтып төште бу. Машинасын ишегалдына кертеп сүндерде дә, бортын ачып, нидер бушата башлады. Вакыт соң булуга карамастан, йөген орды-бәрде ыргытмый, тавышсыз гына каядыр күчерә, өя. Беренче кат бугай шомланып куйдым. Кайдан ала ул бу кадәр материалны, әллә соң урлашамы? Шигем җиңде. Ут яндырмый гына киенеп, болдырга чыктым һәм, өй почмагына ышыкланып, күзәтә башладым. Әрҗәдә таң кебек якты, шәм кебек төз каен агачлары — ярдырыргадыр инде.

Ул аларны җирдән үрелеп кенә ала һәм, ян башына салып, абзар артындагы бәрәңге бакчасына алып китә, шунда кеше күзеннән ераккарак урнаштыруы иде. Чираттагы агачны күтәргәндә хәле беттеме, уңайсыз туры килдеме, йөге дөпелдәп җиргә төште, үзе ыңгырашып куйды һәм уфылдап каен өстенә утырды. Түзмәдем, атылып янына килдем:

— Соң, көн бетәр дисеңме әллә?

Ул дәшмәде, лач иттереп җиргә төкерде дә аннары гына:

— Әллә син дә дөньяда бар, карчык? — дип куйды.

Ачыктан-ачык әйтмәсә дә, мин аның тел төбен аңлап алдым. Бу аның төнге эшләрендә ярдәмләшмәвемә кинаясе иде. Йөкнең калганын бергәләп бушатырга тотындык. Өченче агачны бакчага керткәндә эчемдә нидер чатнап киткәндәй булды, агач кулымнан ук төшеп китте. Үзем җиргә чүктем. Рамазан аны-моны дәшми генә каенны тагын янбашына күтәреп салды да юлына китеп барды. Шул чак мин үземнең йөкле икәнемне аңышып алдым. Ләкин моңа сөенергә дә, көенергә дә белмәдем ул вакытта.

Миңа ул-бу булмый калды. Икенче көнне, кәефем яхшыра төшкәч, кичәге шигемне әйттем үзенә: урлашу дигән нәрсәдән биниһая куркам мин. Рамазан исә гадәтенчә тавышсыз гына көлеп әйтеп салды:

— Юкка чәпчемә, карчык, бар да шито-крыто.

Шуннан соң күпме вакыт узгандыр, безнең арада шул хакта шактый кырыс сүз булып алды. Уракка төшкән чак иде ул. Көн уртасында Рамазан кайтып төште. Тамак ялгарга гына туктаганда машинасын ишегалдына кертмәне юк иде аның. Бу юлы, иске-моски такталардан коршылган капканы ачып, эчкә узды һәм шунда ук двигателен сүндерде. Аннан ачык тәрәзә аша миңа кычкырды:

— Әйдәле!

Мин өйдән чыкканда, ул капчык белән себерке тотып машинасы янында басып тора иде.

— Бар әле бераз физзарядка ясап ал,— диде ул миңа, гадәтенчә тупасрак шаяртып.

Әрҗәгә менгәч, гаҗәпкә калдым. Менә ни өчен кирәк булган икән аңа планкалар! Әле уракка төшкәнче үк Рамазан йорттан дүрт-биш такта салып чыгып киткән иде. Шул көнне үк аларны тар гына рейкалар итеп телдереп кайтты һәм кузов идәнендәге ярыкларга шуларны кадаклап, күзгә күренер-күренмәс тишекләрне томалап куйды. Ярыклар, әйтергә кирәк, юк дәрәҗәсендә, һәрхәлдә, бөртек коелырлык түгел иде. Икмәк әрәм-шәрәм булмасынга тырышып йөрүедер инде, дип фикер йөрткән идем мин ул чагында. Бүген исә шөбһәләнеп калдым, эшнең чын мәгънәсенә төшенә башлагандай булдым. Сирәк кенә итеп кадакланган рейкалар арасына арыш тулган. Йөкчеләр бөртекне көрәкләр белән бушатканнар да кузов идәнен себереп маташмаганнар.

Күңелем тартмаса да, әрҗәне яхшылап себереп төшердем. Җыеп алгач, капчыкка якын арыш булды. Йөрәгем сыкрануын җиңә алмадым:

— Шушы көнгә калдыкмыни без, Рамазан? — дидем ачынып.— Авылдашлар өлешенә кул сузабызмы?

— Соң, тилемсә, кемгә дип тырышып йөрим, ә? — диде ул бу юлы, ахры, шаяртмыйча.

— Беләм, аңлыйм,— дидем мин, аның ачуын чыгармас өчен иплән кенә. — Шулай да харам ризык кирәкми миңа!

— Сиңа кирәкмәсә, малларга кирәк, — диде ул, минем белән сәнлашасы килмәвен белдереп. — Аннары, кем әйтер моны урлау дип? Себермәгез, калсын, дидемме мин аларга?!

Шул рәвешле акланырга маташса да, тайгак юлга таба бер адым ясавын тиз төшенде Рамазан — бүтән мин аның сыңар уч та икмәк алып кайтканын хәтерләмим.

Безнең йорттагы очсыз-кырыйсыз мәшәкать, төн ката икәүләп чабышып йөрүләр җәй буена барды. Хәтта яңгырлы көннәрдә, бөтен авыл кырылып мунча кереп ял иткәндә дә, вакыт бушка узмый иде безнең. Өстән явып торганда Рамазан лапас астында такта шомарта, нидер юныша, кирәк чакта пычкы башыннан тотарга мине дә чакыра. Шул арада мунчага су ташып, анысын өлгертергә дә кирәк. Тик барыбер төнсез бармый идек мунчага. Көн яктысында юыну — вакытны заяга уздыру, ди торган иде Рамазан. Көннең һәр минуты эшкә багышланган иде безнең. Кая ул кинога яисә кунакка бару. Кулдан килсә, тәүлекне ике тапкырга озынрак сузар идек. Дөресен әйтим, үземне-үзем күрәсем килмәгән көннәрем күп булды. Беркөнне хәтта яшь бозаулар арасында йоклап калганмын. Шулай да сер бирмим, түзим дидем. Төптәнрәк уйлап карасаң, ул да, көн итим, тормышыбыз тормыш булсын дип, тырышып йөри бит. Менә көз җитәр, эшләр саегыр, без дә кешечә яши башларбыз.

Тик бу юанычым да сабын күбеге булып җилгә очты. Көз якынлашкан саен, безнең йортта ыгы-зыгы кызды гына. Урак бетүгә, каяндыр ике машина бүрәнә кайтарып ташлады. Аннан бәрәңге алырга тотындык. Менә кыр эшләре дә бетте, көзге пычраклар башланды. Авыл халкы җинел сулап куйды. Озакламый каз өмәләре, кунак алу, туй-төшемнәр кузгалыр. Әмма борын-борыннан калган гореф-гадәтләр безнең өчен түгел иде. Карлы-бозлы яңгыр астында өйгә ике почмак буратырга тотындык. Мин тышта күшегеп балта чапмыйм чабуын. Шулай да өмәчеләргә көненә өч аш әзерләп табан итләрем калмый, кичләрен, табын җыярга аптырап, исерекләр әңгәмәсен тыңлап утырам. Боларына да түздем — кирәкнең кыйммәте юк.

Менә ике почмакны бурап бетерделәр. Инде бераз тын алырга да була. Кышка каршы өйне күтәртмәс, язга кадәр тынычларбыз, дип фикер йөрттем үземчә һәм Рамазанга да шундыйрак киңәш бирдем.

— Бураң өч урында ишегалды тутырып ятканда нинди тынычлык ди ул,— дип элеп китте Рамазан.— Күрмисеңмени, шикәр кебек ап-ак бүрәнәләр бит. Күтәреп, башын япмасаң, кара мунчага әйләнәчәк ич өең.

Аныкы да дөрес. Бураны күтәрттек. Өзенеп-йолкынып дигәндәй, калаен таптык. Акчасын әйтүем түгел, калае юк иде ул елларда. Өйнең зур ягын калай, кече ягын такта белән ябып булмый бит инде.

Болары да үтте, кыш керде. Рамазан төннәрен, ут яндырып, алгы якның тәрәзәләрен, идән-түбәләрен эшли башлады.

— Мичен яз да чыгартырбыз. Тик менә машина тәгәрмәче әйләнгән арада мунчаны да буратып аласы иде, — диде Рамазан.

Йа хода, бу мәшәкатьләрнең очы күренерлек түгел икән. Әллә соң эшне ташларгамы? Башыма әнә шундый уй килгәч, эсселе-суыклы булып киттем. Бөтен яшьлегемне Мәчтүрә апаның өен саклап уздыруым җитмәгән идемени миңа? Тагын шулай дүрт стена эченә ябылып гомеремне үткәрермен микәнни? Анысына бит әле балага баткач та вакыт бар. Әллә соң хатын-кызның язмышы шулмы? Тукта, теге чакны, беренче тапкыр колхоз эшенә аяк баскан язымда, ни дип ант иткән идем соң? «Юк, мине шушы эшемнән, шушы бәхетемнән берәү дә аера алмас», дидем бугай. Шунысы аяныч, мине якты дөньяга җитәкләп чыгарган кеше Рамазан үзе үк аяз көнемне томаламакчы. Тормышның аяусыз законы шушымы әллә? Нигә соң безнең берсе дә кешечә түгел? Күнелең утырган эштә рәхәтләнеп эшләп, бер чама белән генә тормыш көтүгә ни җитә? Акрынлап булыр иде әле барысы да. Дөнья малы дип, үзеңне бетереп булмый бит инде.

Әнә шундый уйлар мине төннәр буе йоклатмый, саргайта иде. Фермага, малкайларым янына барып, шайтанымны тотып атланырлык ныклы куллы, дөньяның вак-төяк мәшәкатьләренә төкереп тә бирмәүче хөр

күңелле терлекчеләр белән аралашканда гына ул кара фикерләрне оныттып торам. Ялгызым калуга, мин инде әнә шул катлаулы сорауларга җавап эзләп кайныйм. Кайдадыр, бик тирәндә боларның барысына да җавап та җитлегеп килә иде бугай.

Беркөнне төшке ашымны мичкә генә куеп киттем. «Үзең алып аша, безнең бүген җыелыш», дип язу калдырдым Рамазанга. Болай ялганлавымның үзенә күрә сере бар иде. Иртәнге эшләремне авыштыруга, Мәчтүрә апаларга киттем. Ул да яңа гына фермадан кайткан икән, бик шатланды. Шулай булмыйни, бердәнбер киңәшчесе, иң якын кешесе ич мин аның. Миңа исә ул — ата да, ана да. Апа, хәзинәдә барын чыгарып, табын әзерләде, үзе әйтмешли, гөрләшеп кенә чәй эчәргә җыенып йөри. Минем исә үз хәсрәтем хәсрәт, күңелемә җыелганны ничек әйтеп бирергә белми аптырап утырам, эчемдәгене актарып салсам, аңламас дип куркам. Ә вакыт дигәнең үтә дә үтә. Менә өстәлгә самавар да менеп утырды, чынаяклар чәй белән тулды, мин генә һаман сүз җае таба алмый интегәм. Шулай да ул үзе сораша башлаганчы әйтәсе иде бит сүземне.

— Тормыйм мин, апа, Рамазан белән, кайтам,— дип, кисәк кенә әйтеп салганымны сизми дә калдым.

Мәчтүрә апаның күзләре чынаягына төшә дип торам, кашлары йөзеннән кубып чыгарга җитте.

— Нәрсә?! Шундый кешедән аерылмакчы, шул муллыктан качмакчы буласыңмы?! Ашаган табагыңны буяган нәрсә! Кайт! Авызын ачса, үпкәсе күренеп торган Галибәне өрлектәй ирләр «аһ» итеп көтеп торалар ди. Минем кебек дуадак гомер сөрмәкче буласыңмы әллә?

Калганын тыңламадым, учларыма капланып елап җибәрдем. Киңәш салырга үз әниең булса, аңлар иде ул синең йөрәкне. Ә моңа нәрсә, үзе гомерендә бер рәхәт күрмәгәч, башкалар минем кебек нәүмизләнеп яшәмәсеннәр диюедер инде. Югыйсә, кешегә түгел, мал-туарга да авыр сүз әйткәне юк иде бит.

Шуннан бирле мин үз эчемә бикләнеп яши башладым, андагы ялкынны кешегә сиздермәдем, ә ялгыз башым гына нинди дә булса карарга килерлек көч тапмадым үземдә. Ләкин тиздән булып үткән вакыйгалар минем уйларыма, тормышыма катгый төзәтмә кертteләр.

...Кичке аштан соң Рамазан тагы ишегалдына чыгып китте. Капкалар шыгырдатып, нидер дөпелдәтеп шактый йөрде ул. Мин инде аның бу гадәтенә күнегеп беткән. Өй эшләрен бетердем дә түшәккә баш төрттем. Шулай да йокы алмады. Туктале, нәрсә булып чыга соң бу? Бәлки Рамазанныкы дөрестер, тырышмый, тирләми генә йорт-нигез ныгымый, мал-туар үрчеми. Ул шундый тынгысыз булмаса, болай яшәр идекмени без? Әнә түр буйда сандык кадәр радиоалгыч, ялтырап торган сиртмәле караватт, шифоньер. Кием-салым дигәнең аңарга гына сыешмаган, тагы ике сандык тулы. Кибеткә кайту белән урындыклары, караватлары, шкаф-өстәлләре бериштән булган гарнитур алам дип тора. Ашыйм дисәң мае, сөт-катыгы алдыңда, иттән өзелгән юк. Онын инде сөйләп торасы да түгел, каядыр барып биш ташлы тегермәндә крахмал итеп кайта. Эше бар икән, аннан кем курыккан, үзебезгә ич.

Әнә шулай үземне юатырга өлгермим, колакка икенче бер өн килә. Соң син ул сандык кадәр радиоалгычны кабызып тыңлаганың бармы? Аның өстендә «Азат хатын» журналы ята, килүенә атна-ун көн. Ачып караганың бармы соң аны? Шифоньердагы җиде затлы күлмәгеңнең кайсын киеп кая барганың бар синең, Галибә? Ашау-эчү дисең. Кем ач хәзерге заманда?! Әйе, табының нигъмәттән сыгылып тора синең, ә йөзеңә сары суккан. Йокысызлыктан, тынгысызлыктан коры шәүләгә калгансың. Нигә кирәк мондый тормыш? Ә туачак бала? Карында кичеш үк ятим калырмы шулай?

Ишек тавышы уйларымны бүлде. Гаҗәп, Рамазан бүген гадәттәге-

дән иртәрәк кереп килә иде. Мин, йоклаган булып, стенага борылып яттым һәм юрганымны башымнан ук бөркәндем.

Мондый чакта керфегенә йокы кунамы соң! Үзем берни уйламаска тырышам, ә күз алдымда Рамазанның һәр хәрәкәте. Менә ул ут кабызыр да иплəп кенә чишенер. Арып-талуына карамастан, һәр әйберен урынына әләр, бусага төбендәге аяк киемнәрен стена буена бер рәткә тезәр. Шуннан соң гына юыныр һәм үзенә дип куйган бер банка сөтне эчәр. Аннан караватына килер һәм, теләндә башка сүз булмагандай, «йоклыйсың, карчык, ә?» дияр. Җавап булмагач, барып утны сүндерер.

Ни гаҗәп, ул бүген утны яндырмады. Һич булмаганны, кием-салымнарын кайсын кая атты да каршы як буйдагы диванга ауды. Башта ул мина сиздермәскә тырышып кына уфылдап ятты, аннан соң тынып калды, йокыга китте бугай.

Рамазанның бик каты ыңгырашканына уянып киттем. Үпкә-ачулар кая очкандыр, атылып янына бардым.

— Ни булды, Рамазан?

— Бил, — диде ул ыңгырашып.

Бер мизгел нишләргә белмичә аптырап калдым. Аннан ут кабыздым, казан астына ягып җибәрдем, сандык төбендә яткан җылыткычны табып алдым. Рамазан борчак-борчак тир эчендә ята иде. Стаканга аракы салдым.

— Эчеп карыйсыңмы әллә, Рамазан?

— Юк, — диде ул авыр гына, — лутчы компресс яса.

Анысына мамыгы, бүзе кая соң әле? Юып-үтүкләп сандыкка салынган чүпрәкләремне тартып чыгардым һәм, иске күлмәгемне ертып, компресс әвәли башладым. Башымда исә бер генә уй: мөгаен, ялгызы бүрәнә күтәреп авырттырган бу билен.

Шул көзне, елгаларда су тунгач, безнең яндагы зур агач күперне сүтеп ташладылар, тимер-бетоннан яңасын ясамакчылар, имеш. Бөтен тыкрык кибеп таш була язган имән агачлары белән тулды. Рамазанның күптән күзе яна иде ул бүрәнәләргә. Нигә дисәң, мунча бурый башларга вакыт җитте, ә иң аскы нигезгә бүрәнәләр юк. Көннәр яхшы чакта юллый алмый калды. «Таш фундамент өстенә усак бүрәнәне салдың ни, салмадың ни — барыбер ике-өч елдан череп төшәчәк»,— дип йөрде. Теге имәннәрне китерүчеләрдән сорап та карады Рамазан, «сатыгыз» дип тә бәйләнде. Алай да булмагач, үзләрен өйгә чакырып, авызларын аракы белән дә чылатмакчы булды. Эчкән чагында ике агач кына түгел, күпере белән бирергә вәгъдә итсәләр дә, айныгач батырлыклары җитмиме әллә инде, җайлары чыкмыймы — һаман суза киләләр иде. Безнең исә якшәмбегә өмәчеләр — балта осталары чакырылган.

Мин уйлаганча булып чыкты да. Рамазан, ялгызы маташып, бер бүрәнәне бакчага керткән, икенчесенә чыккан. Тик анысын киртә аша күтәреп төшергәндә билен кузгаткан.

Компрессның да, җылыткычның да файдасы тимәде. Үз машинасында Яшел Түбә больницасына илтеп салдык. Анда озак ятты Рамазан. Башлаган эшләр аны көтеп, таралып ята бирделәр. Йорт тынды, мәшәкать кимеде. Инде больница юлыннан кайтып кермим. Элеккеге уйларымны башымнан чыгарып ташладым. Шундый хәлендә аның ялгызын калдырып китү бернинди киртәгә дә сыймас иде. Менә терелеп чыгар, инде мондый хәлдән соң артыгын комсызлануын ташлар, без дә башкалар кебек иплəп кенә көн күрербез, нәниебезне үстерербез, дип уйладым мин.

Яз җитеп, җирләр кипкәч кенә кайтты ул авылга. Савыккан, тазарган һәм... элеккеге гадәтләре дә барысы шул көенчә калган иде. Ул гынамы, больницада заяга узган өч ай вакытын куып җитәргә ашыккандай, элеккегедән дә комсызланып ябышты Рамазан тормышка. Ләкин

мин инде боларга игътибар итәр хәлдә түгел идем, озаклямый үземне бала табу йортына озаттылар.

Язгы чәчүләр бетеп, авылда эшнең кимеп торган чагы, халыкның сабан туйлары көтеп, дәртләнеп йөргән вакыты. Шуннан файдаланып, мунчаны җиткердек, утын китереп кистек-ярдык. Шулай кайнашкан арада сабан туйлары да узды, печән өсте җитте. Монысы инде авыл кешесенең ал-ял белми эшләгән чагы.

Урманчы Халикъ Рамазанга елдагы аланнарны — Күккүз тау башындагы кварталны бирде. Анда печән быел да каерылып үскән икән. Без печәнгә җыендык. Без дигәнем — үзем, өч айлык кызым Талия һәм аны карау сылтавы белән урманга чыгарга атлыгып торган Мәчтүрә апа. Ана нәрсә, ялгыз башы, ишеген бикләп чыкса, кайда да тормыш. Җитмәсә, пенсиягә киткәннән бирле гел өендә ята, туеп беткәндер. Мин бала карарга да, фермада эшләргә дә, печән чабарга да көчем җитүенә ышанмыйча, мөдирдән ял сорадым. Эшемнән канәгать иде Мәннаф, сатулашып тормады, бер атнага рөхсәт итте. Печән өстендә бер атна үзе бер гомер! Рамазанны исә җибәрмәделәр. Шофер кешегә җәен ял кая инде ул!

Менә без Күккүз тау башында. Бала көйсезләнмәгәндә, көнозын чалгы белән селтәнәм, урак белән йолкынам. Колхоз башлыкларыннан качып-посып булса да, Рамазан да килеп чыккалый, ашап та тормастан, чалгысына ябыша. Кичен исә ул туп-туры печәнлеккә килә, күз бәйләнгәнче чаба, аннан коры печәнне чүмәләгә куябыз. Атна дигәндә, өч машиналык печән чабып, киптереп өйдек. Кайтаруы миңа тимәде тиюен, төяшергә иптәшләрен чакырды Рамазан.

Төн чыккачны өчне юлладылар болар. Аларга аш-су хәзерләп, үземә дә йокы тимәде. Җитмәсә, иртәнге якта түшәмгә печән ыргытып маташтык. Шулай керфек какмаган килеш эшенә китеп барды, мескенем, мин дә болар янына ашыктым.

Сәгать сигезләрдә ферма янына мотоцикл килеп туктады, мөдиребез Мәннаф икән.

— Син, Галибә, ни... бар әле кайт,— диде ул, күзләрен миннән яшерә-яшерә.— Рамазан ни... Хәтәр ярдан суга төшкән анда..

## 5

Куркып, шабыр тиргә батып уяндым. Әллә йокламадым дамы? Тирән уйларымнан айныдым гына, ахры. Ничек кенә булмасын, күземне ачканда кат-кат юрган астында, лычма су эчендә ята идем. Өстемә бастырганнарны каерып ташладым да торып утырдым.

Тукта, кайда соң әле мин? Түшәменә урам утларыннан яктылык төшкән биек кенә иркен бүлмә. Түр буйдагы караватта кемдер стенаны ишәрдәй итеп гырлый. Ходаем, әллә ир-атлар арасында инде?.. Бераздан күзем ияләшә төште. Башта урындыкка ташлаган киемнәремне танып алдым. Аннан күзем комод өстенә, андагы көзгегә, бизәнү әйберләренә төште. Ә, әйе, Фәнүсә исемле кызлар бүлмәсендә йоклап ятам бит әле. Кинәт кабынган лампочкадай, хәтердә кичәге юл, «маскалы» кеше калкып чыкты. Ул да түгел, йөрәкне чеметтереп кызларым искә төште. Мескеннәрем, берни белми йоклап яталардыр. Үзем булмагач, ачылган өсләрен ябучы да, саташканда аркаларыннан чәбәкләп тынычландыручы да юктыр инде. Әниләре дөньяда килеш шулай ятим булып яшәрләр микәнни нарасыйларым?! Йөрәгем сызлап, сикереп торганымны сизми дә калдым. Юк, булмый миннән. Кадалып китсен каласы. Таң гына атсын, кире кайтам да китәм. Илдә чыпчык үлми, диләр, бер-бер җаен табарбыз әле.

Ярсуымны басарга тырышып, тәрәзә янына килдем. Тышта әле караңгы, шулай да төн таңга авышкан бугай. Бөтен тереклек иясе үлеп йоклый торган вакыт. Ләкин җиде төн уртасында да тынмый икән бу кала дигәнең. Урамнан сирәк-мирәк булса да машиналар үтеп тора, биек-биек йортлар өстендә нindидер шәүләләр уйный, каяндыр тимер чыңы ишетелә. Безнең Гөлбакча түгел икән шул бу, җир маен төннәрен дә юллап торалар икән нефтьчеләр. Болай тәүлек әйләнәсенә мәшәкатьләнәсе булгач, эш тә күптер инде Яшел Түбәдә. Яши торган йортлары да, Манзума әйтмешли, хан сарае икән. Тәрәзә тупсасы астындагы тартып куелган гармун күреге сыман тимердән җылы бәреп тора, пәрдәләре затлы. Ятаклары гына да хөрмәтле кунакка әзерләнгән диярсең, йомшак сиртмә өстендә сөттәй ак урын-җир. Шулай да үзләренә генә булсын инде. Кайтам, нарасыйларым янына кайтам!

Борчулы уйларымнан арынырга тырышып, тәрәзә буенда күпме генә торсам да, таңны аттыра алмадым. Аптырап, кабат урыныма барып аудым. Тик йокы качкан иде инде. Урын-җир уңайлы булудан да бигрәк, күңеле тыныч булсын икән кешенең. Дөньяң түгәрәк, җаның тыныч булса, йокы ястык сорамый, кайда да бик татлы. Минем кебек җиде юл чатындагы кешегә кая инде ул тынгылык. Тиле, хафаны үзең эзләп йөргәч ни...

...Без Хәтәр ярга килеп җиткәндә, Рамазан анда юк иде инде. Шәһәр ягына узучы беренче машинаны туктатып, Яшел Түбәгә больницага озатканнар. Юл уртасында сары төстәге мотоцикл аунап ята, колхоз тракторчылары Шушмадан Рамазанның газигын сөйрәп алырга маташалар. Милиция киемендәге ике кеше нидер үлчи, теткәләнеп беткән дәфтәргә нидер яза иделәр. Башым катып аптырап калдым. Тракторлар үкерә, кемнәрдер нидер сөйли, кычкыра. Барысы да төштәге кебек. Тракторчы Мәрди бугай: «Бик борчылма инде, Галибә, мужыт мотоциклист гаепледер әле», дигән булып, мине тынычландырмакчы. Һай, җаным, кем гаепле икәнен белә инде Галибә. Тынгысызлыгы, комсызлыгы харап итте аны, рульдә йоклап киткәндер, мөгаен. Тукта, нишләп харап булсын ди, бәлки бәрелгән-сугылган гынадыр. Больницада диләр ич.

Милиционерлар шәһәргә кайта икән. Алар машинасына утырып, Яшел Түбәгә киттем. Больницага ук илтеп куйдылар үземне. Тик Рамазанны исән-имин күрергә насыйп булмаган икән, юлда ук җан биргән, мескенем. Тиле кеше сыман, болдыр ташына карап күпме утыргандырмын, басынкы гына ягымлы тавышка айнып киткәндәй булдым.

— Үлгән артыннан үлеп булмый, тынычланыгыз, ханым, — диде ак халатлы пеләш ир-ат.— Хәзер машина килеп җитә, мәетне алып кайтырга мөмкин.

Мәет?! Кичә генә җир җимертеп эшләп йөргән, төнозын печән ташыган кешегә мәет дисеннәр, имеш. Саташулы авыр төш түгелме соң бу? Яшәвең кебек ашкынып, дөньядан китеп үк бардыңмыни, Рамазан?!

Юк шул, төш түгел иде бу кара көн. Ниндидер томан эчендә акрын гына авылга кайттык. Шундый ук шыксыз эңгер-меңгер эчендә, мәетне саклап, төн кундык. Иртәгесен бөтен авыл купты. Өйгә кемнәрдер керде, чыкты, ниләрдер китерделәр, алып киттеләр. Шыпырт кына: «Мәет, зират, кабер» дип сөйләштеләр, мине кызгандылар, сабый баланы көйләгәндәй җитәкләп йөрттеләр.

Шул хәтле дә дус-ишләре бардыр дип уйламаган идем. Рамазанны озатырга бөтен авыл килде. Менә күтәреп чыгып та киттеләр. Эчемдә нидер өзелеп төшкәндәй булды.

Артык зур кайгыдан хисләр тупасланамы, өендә кеше кайнап торгангамы, якынының үлүен аны җирләү сәгатьләрендә ансатрак кичерәсең кебек. Хәсрәтнең чыны, коточкычы үлек чыккан йортта ялгызың калгач башлана икән.

Башта Мәчтүрә апаларда яшәдек. Кайтып мал-туарларны, тавык-чебешләрне барлап ашатам да тагы апаларга китә идем. Тик болай яшәп булмый бит инде. Шыксыз йортка күнәргә, ятим тормышка кабат иялешә башларга кирәк. Тау кадәр хәсрәтем дә, кызым да үзем. Ярый әле, юанырга мал-туар, юатырга күршеләр, Мәчтүрә апа бар, онытылып торырга эшем бар. Шулар сүрелтә-сүрелдерә йөрәкне. Алар да булмаса, тфү, тфү, үз-үзеңә кул салырсың, дивана. Кечкенә чебешем — Талиям үзе бер куаныч, хәлебезнең мөшкеллеген аңламаса да, бер иптәш үземә.

Кайгың бар дими, йөрәгең яна дими, гомер үтә генә. Кыш керде, салкыннар башланды. Рамазан барында искә дә кермәгән нәрсәләр, әрсез чебен булып, мигә үрмәли, әллә ниләр уйланыла. Утын алырга чыккан саен, әрдәнәләрне барлыйм, малларга ашарга салган саен, печән запасын чамалыйм. И Рамазан, исән чагында кадереңне белмәгәнмен шул, юк хәсрәтне бар итеп йөргәнмен... Утыны да, печәне дә җитәр быелга. Ләкин, гомер булса, кабат кышлар киләсе бар. Акча кытлыгы күргәнем юк югын. Тик утын, печәнне акча үзе кайтармый бит әле, һәркайсының артыннан йөрисе, кисәсе, чабасы, китерәсе бар. Хатын-кыз кулыннан гына килә торган эш түгел. Рамазанның дус-ишләре ташламаса әллә. Әмма һәркемнең үз тормышы, үз мәшәкате бар шул... Сыерны асрап булмас инде анысы, утынны китереп, кисеп куйсаң да ярар.

Алдыма баскан әнә шул катлаулы мәсьәләләрне миннән дә алда тормыш үзе чишә башлады. Бәла ялгыз йөрми диләр бит. Кыш уртасында, бозавы аркылы килеп, сыерым зыянлады. Рамазанның еллыгына дип, башта бер сарыкны, утын китерергә дип икенчесен суйдырдым. Үзләре генә калгач, соңгы икесе көтүдән кайтмый йөдәтә башладылар. Теләсә кайда куныр йөри торгач, берсен бүре алды, актыккысын сатарга туры килде. Ишегалдында тибенеп йөргән тавыклар гына торып калды.

Икенче кыш тагы да миһербансызрак булды. Утын аз әзерләнде. Ятсам да, торсам да, уемда шул хәсрәт. Язга кадәр җитәрме, кыш өстеннән ягулык эзләп җәфаланмаммы? Өстәвенә, Талиям чирләп йөдәтте. Колхозда ясле булмагач, аны әле Мәчтүрә апада, әле Бәдәр әбидә калдырам. Ялгызын гына өстеннән бикләп киткән чаклар да була. Салкын тиде, ахры, корк-корк ютәлли башлады. Түләүсез ял алып, аны дәваларга туры килде. Кыскасы, тол хатын өлешенә тигәннәрнең бары да өстемә ишелде генә.

Минем ялгыз талпынуны, бәрелү-сугылуны бар кешедән элек Мәчтүрә апа күреп, сизеп тора. Үзе гомергә тол яшәп, ялгызы дөнья куганга, ул минем хәлне йөрәгеннән кичерә, мине кызгана иде. Үземә сиздерми генә мине шул газаплардан коткарырга план корып йөрүе икән бахырның.

Шулай дуадак каздай талпынып, яшәргә тырмашып йөргән көннәрнең берендә ул мине чәйгә чакырды. Фермада кичке эшләрне бетердем дә туп-туры анда кайттым. Талиям да шунда булгач, бигрәк тә кулай, куна калсам да ярый.

Мин кайтып кергәндә өй эче тәмам кызган, стенага, тәрәзәләргә кызыл башлы сөлгеләр эленгән иде. Өй тулы хатын-кыз: Бәдәр әби дә, тирә-күршедәге башка карчыклар да шунда. Миңа таныш булмаган бер апа да күренә. Җыйнак, чиста киенгән, шуңамы, бик яшь күренә. Тыйнак кына, басынкы кеше бугай: сүзен чамалап кына сөйли, гайбәткә катнашып китми.

— Ишалгыдан Маһруй кодача, — дип пышылдады миңа Мәчтүрә апа, мич тирәсендә уралган арада. — Бик тә инсафлы, бик тә әйбәт хатын. Инде дә барлык белән яшиләр. Минрахман кода тире-яры, чүпрәк-чапрак җыя. Дөнья бәһасе кеше инде.

Кодача дип сөйләсә дә, мин ул хатынның Гөлбакчага килгәнен хәтерләмим. Шулай да очрашканбыз икән без аның белән. Маһруй кодача, Мәчтүрә апага ияреп, Рамазанның кырыгына килгән булган. Кара кайгыма көеп, ул чакта игътибар итмәгәнмен дә үзенә.

Мәүлет укытырга дип җыйган икән карчыкларны Мәчтүрә апа. Табын борынгыча — идәндә. Иң түрдә, мендәр өстендә, указсыз мулла Хәйбери остабикәсе Вәсфия — күгәргән калай тавышы чыгарып, көйли-көйли нидер укый. Ул да түгел, барысы да бик әдәпле булып ахирәт турында сөйләшеп китәләр, теге дөньяда адәм балалары башына төшәчәк коточкыч нәрсәләр хакында гәпләшеп, йөрәккә шом салалар. Ләкин «теге дөнья» хәлләре, әллә чын, әллә ялган, тиз туйдыра, үзләре дә сизмәстән, фани дөнья вакыйгаларына, авыл хәлләренә күчеп китәләр. Имеш, зимагур Хәсән хатыны, ире нифттә йөргән арада, тик ятмый, имеш, Әттем Шәйхулла кызы кияүгә чыкмый гына корсак тутыра... Кыза торгач, Гөлбакчаның һәр йорты диярлек телгә алына, барысы да бер-бер начар ягы белән инде. Үзләре яхшы да, аларны ашка чакырган Мәчтүрә апа әйбәт.

Шул рәвешле бөтен авылны «тарап» чыкканчы, токмачны бушаттылар, бәлешнең төбенә төштеләр, казны ботарлап юк иттеләр дә тирләп-пешеп чәй эчтеләр. Аннан бердәм кузгалып, тарала башладылар.

Алар чыгып киткәч, Мәчтүрә апа самаварын яңартты. Мин идәндәге савыт-сабаны, урын-җирне җыеп алганчы, өстәлгә яңа табын әзерләнде.

— Өчәүләп, гөрләшеп кенә эчик әле бер, — диде Мәчтүрә апа, чынаякларга чәй агыза-агыза.

Өченчебез — Маһруй кодача. Ул әледән-әле миңа карап ала, эшем, тормышым турында сораша. Ул да түгел, ялгызлыкның авырлыгы хакында сөйләп китә. Мәчтүрә апа исә аның сүзен куәтләп утыра:

— Шулай шул. Утыз улың булганчы, у... ирең булсын, дигәннәр борынгылар,— дип куя ул, кулындагы сөлгесе белән тирләгән битен сөртә-сөртә.— Гомер буе Лотфулламны көтеп үзем дурак булдым. Үлгән үлгән инде, кире кайтмый. Әйбәт кенә кеше килеп чыкса, кияүгә барырга кирәк. Вәт шул.

Янган йөрәккә ни дип тоз салалар дисәм, сере бар икән. Минем кылны тартып карамакчы болар. Үземнең исә андый фикерне башыма да китергәнем юк иде. Үгетләренә түздем-түздем дә, сүз һаман шул тирәдә әйләнгәч, савыт-саба юу сылтавы белән, кече якка кереп киттем. Ни сөйләшкәннәрен ишетмим дип, савытлар шалтыратам, дөбер-шатыр итәм. Шулай да колакка килеп-килеп чалына бит.

— Хәзер инде яучы йөртү заманасы түгел, — ди Мәчтүрә апа, — үзе килеп чыксын, танышсын, сөйләшсен.

Бу сүзләрнең төп мәгънәсенә ике-өч көннән соң гына төшендем. Апа үзе аңлатып бирде. Имеш, Маһруй кодачаның мине димләргә килүе булган. Солдаттан кайткач, байтак кына чит-ят җирләрдә каңгырап йөргән Өлфәт исемле улы бар икән — килен эзләп йөри булып чыга. Имеш, Рамазанның кырыгына килгәч, мине ошатып киткән. Шуннан, тире җыю сылтавы белән, мине күреп кайтсын дип, ире Минрахманын Гөлбакчага җибәргән. Ниндидер абзый чоланда эленеп торган тиреләрне алып киткән иде шул. Акчасын да мул түләде. Аның күңеленә дә хуш килгәнмен, имеш. «Насыйбың булса, шушы көннәрдә егет үзе әйләнмәкче, — ди апа, — кара аны, авызың белән кош тотып торма».

Ак та, кара да димәдем, көлдем генә. Тик апа бу эшкә чын-чынлап тотынган икән. Миңа әйтми-нитми генә Ишалгыга барган да Өлфәт хакында сорашып кайткан. Тулы бер китап инде. Фермадан өйгә кадәр сөйләп тә очына чыга алмады.

Аның сүзенә караганда, Өлфәт инде дә чибәр, таза, карап кына торырлык икән. Шулай да мыскалламаган ефәк түгел, ди. Читтә чагында азып-тузып, исерткеч белән шаярып йөргән, имеш. Бер кызга өйләнгән

дә булган. Ата-анасы киленне өнәмәгәч, аерылганнар, авылга ялгызы гына кайткан, ди. Хәзер әчү-тартуы юк, бөтенләй муллага әйләнгән, имеш. Шундагы кирпеч заводында токарь булып эшли икән. Әти-әнисе кабат чыгып китүеннән бик куркалар, шуңа өйләндерергә ашыгалар икән.

Өлфәт турында шуннан да артыгын сөйләми Мәчтүрә апа. Әмма инде кодачасының йорт-җире, алма бакчалары, умарталары, бура хәтле сыеры, каз-үрдәкләре хакында өч көн рәттән тезде, шәт. Аныңча, Минрахманнан да бай, юмарт, игелекле кеше бөтен Рәчәйдә юк. Маһруй кодачадан да сабыр, кешелекле, аңардан да чиста, диндар кайнана җир йөзенә бүтән тумас та, булмас та.

Апаның бу сүзләрен дә чынга алмадым, кызыклы бер әкият итеп кенә тыңладым да башымнан ук чыгарып ташладым. Дөнья мәшәкатьләре, кызым кайгысы ул сүзләрне күмеп киттеләр. Ләкин шул гөнаһсыз хатын кузгатып җибәргән өермә минем тирәдә һаман әйләнә икән әле. Беркөнне Мәчтүрә апа тагы чәйгә чакырды. Дәшмәсә дә бара торган җирем, аны-моны исәпләмәстән, киттем кичтән. Талиям йоклап калды.

Мин килеп кергәндә, идән уртасында ишеккә аркасы белән каланча гәүдәле бер ир-ат басып тора иде. Ул әйтерсең лә буй-сынын күрсәтү өчен юри шулай баскан: башы матчага тиеп тора диярлек, киң җилкәләре зәңгәрсу пинжәген ертып җибәрер төсле. Гәүдәсе төз, чалгы йөзедәй үткер сырлы, киң балаклы чалбары бик килешле. Бу кешенең Өлфәт икәненә шигем юк иде минем.

Менә ул борылды да күптәнге таныш сыман кулын сузды:

— Исәнме, Галибә.

Куллары нык, берсе-берсе соскы көрәк кадәр бардыр. Үзенә сиздермәскә тырышып кына, йөзенә күз төшереп алдым. Шул мизгел эчендә аның кара тут йөзле булуын, чем-кара кашларының тоташ икәнен күреп алдым. Чыннан да күркәм генә иде егет.

Сүз ябышмады. Бер-беребездән унайсызланып тик утырабыз. Ярый әле, тыштан Мәчтүрә апа килеп керде, табын әзерли-әзерли, ферма хәлләре турында сүз куертып җибәрде. Өстәлгә самаварын утыртты да, сыныкка сылтау табып, тагы каядыр чыгып китте. Табын янында икәүдән-икәү генә калдык.

Ниләр сөйләшкәнбездер, сүз юктан сүз булсын дип кенә барган әңгәмә хәтердә каламыни? Күбрәк бер-беребезне сынашып утырдык бугай. Өлфәтнең оялчанрак сөйләшүеннән чыгып, кыюсыз, ахры, дип уйладым.

Ул, тартыныбрак утырса да, эшне тиз тоту ягында иде булса кирәк, кызарды, тирләп чыкты, шулай да килүенең максатын әйтеп бирде:

— Ни бит, Галибә... ни... мин дә синең сыман ялгыз... Әллә соң нимә... уртак оя корып җибәрәбезме?

— Ай-һай, житез икәнсең? Ашыккан — ашка пешкән.

Гаилә кору кебек зур эшнең болай тиз генә хәл ителмәвен аңлатырга тырыштым, ялгыз башым түгеллегенә ишарәләдем, кызымны телгә алдым. Ләкин бала булуы икеләндерми иде бугай аны.

— Өй иркен, күңел киң, сыяр идек әле, — дип шаярткан була.

Кич буе сөйләшеп утырдык, күп нәрсә аңлаштык. Шулай да бер нәрсәне төшенеп җитмәдем. Ул, тора-тора да, минем әнисенә һәм әтисенә ошавым хакында сөйли башлый. Үзенең хисе хакында ләм-мим. Миңа да ошыйсың дип читләтеп әйтүе микәнни байгышның?

Өлфәт аннан соң да килгәләде. Көзге пычракларда да, кышкы салкыннарда да, язгы юл өзегендә дә таптады ул Гөлбакча белән Ишалгы арасын. Яраттым дип әйтә алмыйм, әмма ошый иде миңа Өлфәт. Эчеп-исереп килгәне булмады, кулын уйнатмады. Шулай да, ныклы бер карарга килеп, ризалык бирергә батырчылыгым җитми иде әле минем.

Инде үзем күпме сынадым, Мәчтүрә апа Ишалгыга кабат барып кайт-ты (мактап туймый), тик һаман җөрьәт итмим. Төннәрем йокысыз үтә. Өлфәткә кияүгә чыксам, Рамазан рухына хыянәт итәрмен сыман. Талиям язмышы өчен дә борчылам, каксалар-суксалар, нишләрсең. Шул ук вакытта эчке бер өн: «Гомереңне заяга уздырма, кызый», — дип, йөрәккә вәсвәсә сала иде.

Шул рәвешле ел ярымлап вакыт үтте. Инде Мәчтүрә апа да гаҗиз, елап-елап үгетли, үзенең тол тормышыннан бихисап гыйбрәтләр китерә, мине кияүгә чыгарга димли иде.

Ниһаять, сыгылдым. Җылымса апрель көнендә Минрахман абзыйның туры биясе мине Ишалгыга алып китте...

## 6

— Хаммат абый, җаным, мине аласыңмы? — ди кызларның берсе. Тавышы Фәнүсәнеке, кичә мине чишендергән кызныкы.

— Туеңнан калдырсаң, мәңге бәхил түгел, — дигән була икенчесе. Ирештерүләредер инде, буйдак кеше, күрәсең, Хаммат дигәннәре.

— Туемда гына түгел, куенымда булырсың,— дип шаярган була бит әле тубал авыз.

Алар шулай бераз шуклангач, Хаммат сүзне җитдигә борды:

— Ярый, кызлар, уен бер була. Вупшем, кунакка әйтегез, иркенләп йокласын, машиналары тиз генә рәткә керерлек түгел әле. Шоферы, буксирга дип, колхозларына кайтып китте.

Сикереп торганымны сизми дә калдым. Тик эчке күлмәктән икәнемне абайлап алгач кына, юрганыма төрендем.

— Ни дисез сез?

— Әһә, үзе дә уянды,— диде Хаммат бүлмәне ярып.— Син, туташ, туйганчы йокла да сигезгә промыселга кил. Барасы юлыңа үзем утыртып җибәрермен. Инде йокламыйм дисең икән, чәй эч тә, әйдә үзем белән үк.

Ул шулай сөйләнә-сөйләнә чыгып китте. Мин, ни дияргә дә, нәрсә эшләргә дә белмичә, торып киендем, юынып алдым һәм аптырап калдым. Шофер белән Хаммат нигә кирәк соң әле миңа? Манзуманы эзләргә кирәктер, мөгаен. Төзүчеләр торагын кайдан табарга? Тагы шул мәрхәмәтле Хаммат ярдәм итмәсме? Фәнүсәдән Хамматны кайдан эзләргә икәнен сорадым.

— Хәзер табабыз аны,— диде Фәнүсә, табын әзерләп.

Эзләп интегәсе булмады, шул ук йортның икенче подъезды ир-атлар торагы икән. Ничек керергә дип, тартынып торырга да туры килмәде. Фәнүсә кереп тә китте, Хамматны култыклап килеп тә чыкты.

Өчәүләп олы юлдан атлыйбыз. Инде көн яктырып килә. Кырын-кырын гына Хамматка карап алам. Кичә кичен дә, бүген таңда да аның йөзенә ныклап игътибар итмәгән идем. Тик юлда факел яктысында күргән беренче тәэсир буенча гына ул әле минем аңымда һаман «маскалы» кеше. Чыннан да, сәер генә ир-ат икән бит бу. Әллә гарип инде, ходаем. Борыны гадәти кеше борыны гына түгел, авызы да чалышрак бугай, күзләре әллә кылый тагы. Шулай да ул инде кичәге кебек үк имәнгеч түгел, бөтен җитешсезлекләре үзенә килешеп тора сыман. Кием шулай үзгәртә, күрәсең, кешене. Агач күрке — яфрак, адәм күрке — чүпрәк, дип, юкка гына әйтмиләрдер. Бүген ул өстенә кара дуп тун кигән, ачык изүеннән күрән йон костюмы, кызыл нейлон күлмәк якасы, күгәрчен күзе төшерелгән киң соры галстугының төене күренеп тора. Башында затлы мехтан тегелгән йөнтәс бүрек, аягында исә котып очучысыныкы кебек эт тиресеннән теккән унталар.

Көн яктыра барган саен, Хаммат йөзендәге таныш чалымнар да арта бара сыман. Мин инде аны кайчандыр күргәнемә икеләнми башлыйм. Туктале, безнең Гөлбакчаның Мөхәммәт түгелме соң бу?! Юк, кисеп кенә әйтә алмыйм. Әкият Мөхәммәтнең авылдан чыгып киткәненә күптән, бик күптән бугай шул инде. Җитмәсә, анда чагында да бер-ике тапкыр гына күргән идем мин аны. Анысы да бала чакта. Кыяфәтенең башкаларныкы кебек булмавы гына хәтердә. Мөхәммәтне бар белүем Рамазан сөйләве буенча да, аның турында Гөлбакча халкы хәзер дә искә алып көлешә торган мәзәкләрдән генә. Авылга бер дан булган ул заманында. Үтә дә мал җанлы, дөньядагы барлык тереклек иясен кызганучан иде диләр Мөхәммәтне. Авылдашлар аның йөкле арбага утырганын күрмәгәннәр — атка авырга килә, янәсе. Дөрестерме, юктырмы, бер заман аның белән менә мондыйрак бер хәл булганын да сөйлиләр. Безнең Гөлбакчада «Аҗаган» дигән тау бар. Аның түбәсендәге кечерәк кенә чәчүлек җиргә ел саен борчак чәчәләр иде. Сугыш елларында исә аңа кул җитмәгән, берничә ел кысыр яткан җирдә котырып үлән үскән. Шуны чабып, төннәрен печән ташый иде халык. Бер кичне Мөхәммәт тә киткән шунда. Бик шәпләп төягән бу олавын һәм кайтырга чыккан. Тауның иң текә җиренә җиткәч, аптырап калган Мөхәммәт. Ничек төшәргә? Ат тыя алырмы олауны? Шулай икеләнеп тора да бер карарга килә бу. Җирән алашаны туарып, арба артына бәйли, үзе тәртә арасына җигелеп, таудан төшә башлый. Тик ерак китә алмый, олау моны төртеп ега да бар куәтенә түбәнгә оча. Бәхеткә каршы, үзе исән кала Мөхәммәт, аты да тезгенен өзеп, һәлакәттән котыла. Егет аңына килгәндә, аның баш очында Саз урамының Фәттах басып тора икән. Ду китереп сүгә башлый бу Мөхәммәтне: «Тилемсә син, ахмак, ди, тау төшкәндә атны туаралармыни?! «Җирән алаша тапталса, нишләр сең»,— ди, имеш, Мөхәммәт.

Әнә шундыйрак әкәмәтләре булганга, Әкият Мөхәммәт дигәннәр дә инде аны. Бу бер дә андый беркатлыга охшамаган, бик төпле, акыллы күренә. Кем белә, шул Мөхәммәт үзгәрсә генә.

Урам тынлыгын башлап Хаммат бозды:

— Танышкач танышып бетик инде, — диде ул, миңа борылып, — хатлар язышып торырлык булсын. Кай иләрдән һәм кая барыш?

Сорауның беренче өлешен җавапсыз калдырсам да, артык җәелми генә нишләп йөрүемне әйтеп бирдем:

— Төзүчеләр торагы кирәк иде миңа. Иптәш кызым яши анда, эшкә урнаштырырга вәгъдә иткән иде.

— СМУгадыр инде, — диде Хаммат.

Мин, аның сүзен аңламасам да, сөйләгәнемә ачыклык кертергә ашыктым:

— Бетон заводына диде бугай.

— Тимер-бетон заводы, — дип төзәтеп куйды Хаммат.

Моңа кадәр сүзсез генә атлаган Фәнүсә борынын тартып куйды да бәхәсләшкән кешедәй ярсып тезеп китте:

— Ни пычагыма сиңа завод! Үзе тавышлы, эше дә авыр, диләр. Менә безнең промысел, ичмасам. Көн буе сахрада йөрисең. Яз, җәй айларында сулап торасы да түгел инде. Җәннәт. Ул Зәй буендагы шомыртларның хуш исе, ул үзән-кырлардагы чәчәкләрнең күз явын алырлык булып җирдә тибрәнеп утырулары. Таулар, әрәмәләр, урманнар. Шулар арасында скважиналар таралып ята. Ялгызың җырлый-җырлый, берсеннән икенчесенә үтүе үзе бер гомер. Ә кышы, кышы диген әле! Чаңгыга басасың да таудан түбәнгә атыласың! И-и-их! Менә кайда ул дөньяның рәхәте!..

Фәнүсә сүзләренә колагым торды. Эшләре авылдагы сыманрак икән бит. Каралты-курада ябылып эшләүне бик өнәп бетермим мин. Җитмәсә, Хаммат та аның сүзен җөпләп тора:

— Кәнишне, нифткә керергә,— дип кушылды ул үзенең мөгерәбрәк торган тавышы белән.— Эше алай ук уен булмаса да, бездә хыт куыш ягы иркенрәк. Телисең икән, әнә үзең кунган убшыжитыя, инде фатир дисең икән, баракта булса да биреп торалар. Начармы-яманмы — үз почмагың, утын әзерләп интегәсе түгел.

Бу сүзләрдән соң Хаммат миңа ниндидер тылсымчы, күрәзәче булып тоелды. Үз итеп аңа карап алдым. Миңа ни кирәген белеп сөйлиме әллә? Сизгер кешедер, минем хәлне дә, нужамны да аңлап алган, мөтаен.

Атлый торгач, икәүләшеп чын-чынлап димли башладылар болар. Имеш, промыселга кадрлар бик кирәк чак. Имеш, алар конторы Яшел Түбәдә иң зур, иң абруйлы предприятие. Аларча, нефтьчеләр арасына эләгүең үзе бер бәхет. Акчасы да төшә, тормыш өчен башка уңайлыклары да җитәрлек.

— Ике уйлама да,— ди Фәнүсә,— тот та гаризанны яз. Бүген үк, хәзер, барып җиткәч тә.

— И-и миннән буламы соң инде нефть чыгару.

— Була, ник булмасын,— ди Фәнүсә бөтен урамны ярып,— үзебез үрәтәбез, иеме, Хаммат?

Хаммат алай ук сагыз кебек сыланмый, шулай да сүзләре үтемле, ышандыргыч:

— Теләк булсын, теләк, калганы — вакыт эше.

Җиде юл чатындагы кеше сыман аптырап калдым, ни диярге дә белмим. Эшнең болай уңайга баруы шатландыра да бит, күрмәгәнбелмәгән нәрсә шикләндерә шул.

— Миңа кая урнашсам да барыбер дә бит.

— Соң шулай булгач,— дип, тагы элеп алып киттеләр болар,— тәвәккәллә дә вәссәләм.

— Сандугач булырга маташкан әтәч хәленә калудан куркам шул.

— Бигрәк куркак булып чыктың әле син, туташ,— диде Хаммат, үзенчә шаяртпкан булып.— Кайсы авылныкы дисең әле?

Җавап бирмәдем. Аның чыннан да Әкият Мөхәммәт булып чыгуыннан шикләндем. Сораша башлар, аптыратып бетерер. Минем исә үткәннәрне кузгатасым килми иде. Урынсыз сорау бирүен үзе дә төшенде, ахры, сүзне тагы промысел хәлләренә борды.

Барып җиткәнче, тәмам күндереп бетерделәр мине. Эш мәсьәләсендә Хаммат үзе сөйләшергә булды.

Промысел конторы дигәннәре кечерәк кенә бер барак икән. Үзе җыйнак, чиста. Урталыктагы бер бүлмәгә кергәч, Хаммат миңа:

— Син шунда утырып тор, без менә монда кереп ызгышып чыгабыз әле,— диде дә «Өлкән инженер» дип язылган ишекне ачып, кереп китте. Уйнап әйтмәде, ахры, ярты сәгать буе кычкырыштылар шул бүлмәдә, кешеләр дә туктаусыз кереп-чыгып йөрде. Карга оясы кадәр бүреген тотып, Хаммат та килеп чыкты һәм миңа карап та тормастан, каршы ишеккә юнәлде. Кара пыяладагы язуына караганда, монысы башлык кабинеты иде.

Бик эшлекле кыяфәттә шак-шок басып йөргән мастерлар да таралып бетте, киенгән-ясанган хатын-кызлар килә башлады. Хаммат юк та юк. Инде мине онытты бу, күрәсең, дип торганда, ишек ачылып, анда Хамматның зур башы күренде. «Әйдә» дип миңа кул изәде. Кереп җитмәдек, шул ук Хаммат:

— Менә шушы сеңелкәш инде ул,— дип куйды.

Кара чәче малайларныкыдай маңгаена төшеп торган бәләкәй генә башлы яшь кеше, миңа урын күрсәтеп, алдындагы кәгазьләренә карап торды да, маңгайга чирткәндәй кинәт кенә:

— Ни эшли беләсез? — дип сорады.

— Ни дип... төрлесеннән, әлбәттә. Укымагач ни... сәнәк тә кирәк инде безгә.

— Ясно,— дип куйды мөдир һәм, минем барлыкны бөтенләй оныткандай, Хамматка таба борылды. — Үзең тапкансың икән, үзең эшкә дә өйрәт инде син аны, Фәезханов. Өйрәнчегеңне, кем әле, Фәнүсәме, үнжиденче рәткә самостоятельныйга күчерербез. Разряды да, тәҗрибәсе дә җитәрлек.

— Була, өйрәтәм. Аюны да биергә өйрәтәләр, шулай бит, сеңелкәш?! — диде Хаммат.

— Белмим инде...

Алдыма кәгазь китереп куйдылар, кулымнан тотып диярлек гариза яздырдылар. Ничек итеп эш киемнәре алырга кирәклеген әйттеләр дә, иртәгә вахтага чыгарга кушып, саубуллаштылар. Менә сиңа мә, уйламаганда-нитмәгәндә оператор ярдәмчесе булдым да куйдым. Нефть чыгаручы! Кызык та соң бу дөнья дигәнең!

## 7

Автобус, таеп асфальт юлдан читкә салуламагаем дигәндәй, үрне акрын гына төште дә кар диңгезе уртасында нәни утрау булып торган юкә урманы янында туктап калды. Хамматка ияреп мин дә автобустан чыктым.

— Менә шушы инде безнең кәнсәләрия, — дип куйды Хаммат, карт юкә ябалдашлары астында утырган җыйнак кына ак бинага күрсәтеп. — Үзебезчә, зур итеп «үзәк культбудка» дип йөртәбез.

Төнлә яуган йомшак кар өстенә беренче эз салып шунда таба атладык. Хаммат бина тирәсендә хуҗаларча, бар нәрсәне барлап, әйләнгәләп йөрде дә каяндыр көрәк тартып чыгарды һәм ишекне күмгән кар көртен ишеп, аны як-якка ыргыта башлады.

— Мәгънәсез, шуны да күрәмәгән, — дип тиргәнде ул авыз эченнән генә. Бу сукрану төнлә бирегә эшләгән операторга кагыла иде бугай.— Вахтасын да әдәмчә тапшырмыйча, өенә сызган бит, ә!..

Аннан ул янгын тактасы артыннан зур гына ачкыч алды һәм ишекне ачып эчкә узды. Мин дә бусагадан атладым.

— Хәтерләдеңме? — диде Хаммат кирә-керешкә,— ачкыч һәр вакыт шунда булыр.

Культбудканың исеме җисеменә туры килеп тора. Мондагы ике бүлмәнең алдагысы ашау-эчү, көнкүреш өчен яраклаштырылса, эчтәге як кызыл почмакны хәтерләтә иде. Киң һәм озын өстәлгә кызыл постау җәелгән, өсте тулы газета-журнал, шахмат, домино ише уеннар да күренә. Стеналарда плакатлар, диаграммалар, хәтта күркәм генә картиналар да бар. Бу яктагы кечкенә өстәлгә исә клеенка җәелгән, өстенә телефон аппараты белән амбар кенәгәсе куелган иде. Янәшәдә сәке сыман бер нәрсә, өсте тулы савыт-саба, кашык-аяк, электр плитәсе. Идән, стеналар чиста диярлек, тәрәзәләргә ак дисәң ак, сары дисәң сары булмаган пәрдәләр эленгән. Шулай да монда шыксыз, күңелсез иде. Нилектән болай икәнен тәрәзәләргә каткан бер илле бозны күргәч кенә төшендем — бирегә тыштагы кебек үк салкын икән.

Хаммат «чылт» иттереп стенадагы кнопкаларның берсенә басты һәм почмактагы электр миченең сиртмәләре кызарып, фантастик елан төсен алды. Ул да түгел, сизелеп җылы төшә башлады.

— Әллә кичтән үк кайтып киткәнме бу юньсез? — дип сөйләнә-сөйләнә, Хаммат амбар кенәгәсен (вахта журналы дигәннәре шул икән) кулына алды һәм актаргалап «Һы-һы» диештереп утырды. Кисәк торып, кием шкафын ачты һәм аннан майланып, беләүләнеп беткән киемнәр

чыгарды, миңа зур якка кереп торырга кушты. — Ярый, Галибә, мин киттем, — дип кычкырды ул бераздан.

Ашыгып алдагы якка чыктым.

— Соң мин... Минем эш нидән гыйбарәт?

— Культбудкада хатын-кыз барлыгы сизелсә, бүгенгә шул җиткән...

Авызын да ермый шаяртткан була тагы. Әйтерсең утырып торырга килгән кеше. Тик ашыгыбрак үпкәләгәнмен икән, аның эш кушуы шул булып чыкты. Ул миңа идән юа торган чүпрәкләр, чиләк күрсәтте, алай-болай су җылытсаң дип, искерәк кенә бер бак кертеп бирде, үзе ашыгып китеп барды.

«Хатын-кыз барлыгы сизелсә»нең мәгънәсен шуннан соң гына төшендем. Чыннан да, идәннәргә байтактан хатын-кыз кулы тимәгән, почмакларда, тәрәзә төпләрендә тузан, түшәмнән пәрәвез тасмалары асылынып-асылынып тора, кашык-савытлар чирканмый гына кулга да тотарлык түгел. Су җылынган арада пәрәвезләрне җыеп алдым, тәрәзә төпләрен тәртипкә китердем. Аннары идән юып, савыт-сабаларны чистарттым. Пәрдәләрне алып, кайнатырга салдым. Аларын да чайкап элсәм, эшем бетә дә бугай.

Һе, шушы микәнни оператор ярдәмчесенең эше? Җыештыр да ю, тузан сөрт, кер чайка. Нәкъ Гөлбакча клубындагы кебек, мәйданы гына бәләкәй. Промысел да промысел дип, авыз суларын корттылар тагы. Мондый эшне теләсә кайсы мәктәптә дә таба идем ич. Мине кызганудан идәннәрен юып торыр өчен генә алдылармы әллә?

Көнелем төште, культбудкаларына кул селтәп кайтып китәр хәлгә җиттем. Тик кайнап торган керне калдырып булмый бит инде. Сүлпән генә кыймылдап, аларын чайкап элдем. Вакыт үтсен өченгә, тәрәзә пыялаларын чистартырга тотындым.

Бөтен җир ялт итте кебек, культбудка яктырып киткәндәй булды, тәрәзәләр көлеп тора сыман. Шулай булмыйни, сигез сәгать буе алты почмаклы өй кадәр бина җыештыр, имеш. Балалар уены. Шуның өчен мактап торган була бит әле Хаммат. Кайтып керүенә, салпы якка салам кыстырды:

— Кулларың алтын икән, Галибә! — ди.

Шулай да күңелнең кай җиредер китек, бүгенге көнемнән канәгать түгел идем мин.

Кайтырга дип автобуска утыргач та шул халәттән арынмадым. Нуҗәли хатын-кызның язмышы шундый? Кая барсаң да чүпрәкләрен, савыт-сабаларын ияреп йөрсен, имеш. Мин бит нефтьчеләр янына ирләр белән берррәттән эшләргә, машиналар, электр җиһазлары өйрәнергә дип килдем. Әллә соң эшләре хатын-кызга ышандырырлык түгелме? Ярый, бүген үк Манзуманы эзләп табарга кирәк.

Шулай да нидер тыеп калды бит. Төзүчеләр торагын эзләмәдем, ашханәдә тамагымны туйдырдым да туп-туры Фәнүсәләр янына кайттым.

Хаммат белән Фәнүсәгә ачуланып төн буе турсаеп чыксам да иртүк автовокзалга киттем. Автобус тулы операторлар, мин белмәгән ниндидер мастерлар, инженерлар. Бер хәсрәтләре дә калмаган диярсең, авызларын җәеп мәзәк сөйләшеп баралар. Үпкәмне Хамматка сиздерә алмадым. Аның каравы, кичәге җирдә автобустан төшкәч, бөтен монзарымны селкеп чәчтем. Хаммат исә әйтерсең саңгырау, кайтарып ник кенә бер сүз әйтсен. Җитмәсә, «Һа-а-а, бүген егетләр көне!» дип, үзенекен лыгырдап бара. Монысы инде бөтенләй... Ачуым ташып чыкты, культбудкага керүгә:

— Бүген тагы кайда хатын-кыз барын сиздерергә? — дип, дорфа тына әйтеп салдым.

Ул дәшмәде шкафны ачып, мазутлы киемнәрен чыгарды да, аларны култык астына кыстырып, алгы якка узды. Өстен алыштырып чыккач кына:

— Чаңгыга басканың бармы? — диде.

Монысы нәрсә тагы? Чынлап сөйлиме, уйнапмы? Болытлы көн кебек ишелеп төшкән кашларына караганда, бер дә шаярырга исәпләми. Ни дип җавап бирергә дә белмәссең.

— Мәктәптә чакта бер-ике тапкыр җәфаланган идем, — дидем аптырагач.

Шуның белән сүз бетте. Хаммат будкадан чыгып кайдадыр уралды да кулына бер пар чаңгы тотып керде. Аннан мине тәрәзә янына чакырды.

— Ә-ә-әнә теге аргы калкулыкны күрәсеңме? Нәкъ түбәсендә кое сиртмәсе кебек бер нәрсә тирбәлә. Утыз җиденче скважина дигәнебез.— Ул кинәт борылып миңа сынаулы караш ташлап алды.— Чаңгы тагып шунда... Так, ике скважина арасы 400 метр, утыз җиденчегә — 800. Барып кайтуы чакрым ярым. Так, шунда өч мәртәбә барып кайтасың бүген.

— Шул гына җитмәгән иде! — дидем мин, Хамматның тукмак борынына карап. Ходаем, бигрәк килбәтсез инде, ничек эшләрсең моның белән, дигән уй үтте башымнан.

— Менә нәрсә, Галибә, — диде Хаммат тыныч кына. — Син безгә эшкә дип килгәнсеңдер бит. Бәс, шулай икән, бездә тәртип мондый — кушканны үтиләр! — Чыгып китәргә дип ишек бавына тотынгач, ул туктап калды һәм миңа карамый гына сүзен дәвам итте: — Мин дә шулай үгезнең мөгезеннән элэктерергә дип килгән идем нефтькә. Шатланып каршыладылар, «Кирәк, синдәй егетләр бик кирәк безгә», диделәр. Инде конкрет эшкә килгәч, мунча директоры постын тәкъдим иттеләр. Әле чын мәгънәсендә мунча булса ярар иде, унлап кеше пычтырдап чыгарлык бер таш келәт шунда. Үзем директор, үзем билет сатам, үзем үк кулга чүпрәк алып идәннәрне сөртәм. Ягъни өстәлнең бер ягына чыгып боерык бирәм дә икенче ягына чыгып: «Есть, үтәлер», дим. Эше эш инде аның — түздем. Менә хатын-кызлар көнендә мәхшәр тек мәхшәр инде. Тартынып та тормыйлар, каһәрләр, анадан тума ялангач килеш килеп алдыма басалар да: «Нигә пар юк та, суы нигә салкын да фәләнфәсмәтән», дип теңкәгә тиеп бетәләр. Көн дә барам промыселга: «Аннан алыгыз, зинһар, бәдрәф чистартырга булса да куегыз», дип ялварам. Ишетергә дә теләмиләр. Алты ай иза чиктем шулай. Аннан соң гына участокка күчерделәр, анда да өйрәнчек итеп...

Хаммат артыгын сөйләп тормады, аңласаң шуннан үзең аңла инде дигәндәй, кулын гына селтәде дә ишекне ачып тышка атлады. Мин чыкканда ул инде чаңгыларын тагып урыннан кузгалган иде. Алпамша гәүдәле кеше димәссең, ыргылып китте дә, күз ачып йомганчы, ак кар өстендә каралып торган юкәләр арасына кереп тә югалды.

Чаңгыны тагуы бер азап булса, кузгалып китүләре мең азап иде. Яңа туган бозаудай аяклана алмый интектем, шулай да киттем бит кузгалып. Егыла-торуларның санына, маңгайга, аркаларга чыккан тиргә караганда, шактый юл алган булырга тиеш идем. Борылып карасам, культбудка янәшәмдә генә. Гарьлегемнән шартларга җиттем һәм бөтен көчемне җыеп сөзәк үргә таба кузгалдым.

Кара, ярыйсы гына күңелле шөгыль икән бу чаңгыда йөрү! Бөтен тәнгә ниндидер ләззәтле арганлык йөгерә, салкынча һава тулудан күкрәк киңәеп, сулышлар иркенәеп киткәндәй була. Басу түрендәге хозурлыкны әйткән дә юк инде. Бирелән, калкулык өстеннән, бөтен тирә-як аермачык күренә. Мамык юрган астында үзәннәр, әрәмәлекләр изрәп ята. Таулар исә, күкрәкләрендәге яткыллардан ташып чыгарга торган куаклык ташкынын да туктатып, кырларга сокланып калганнар. Ә скважиналар — гүя җылы яңгырдан соң үсеп чыккан гөмбәләр: басу түрен тутырганнар, әрәмәлекләргә, туйралыкларга кереп сыенганнар, тау тү-

бәләренә менеп басканнар. Шуларның чын хуҗасы булу, аларны барлап, көйләп, җайлап йөрү бик рәхәттер, мөгаен. Промыселга аяк басмас борын ни дип тәртәгә тибәм соң әле? Хаммат та алай ук иләмсез кеше түгел, кай ягы беләндер ягымлы да кебек. Кешеләр сиңа ярдәм кулы сузсын да, син көйсез бала сыман тыпырчын, имеш. Ай, җүләр дә инде мин!

Кашлак маңгаенда бер мизгелгә тукталып тору халәтемне үзгәртте дә куйды. Нигә икәнен дә белмәстән, сабый баладай шатланып, талпынып алдым. Йөрәк кысылып алгысый, каядыр ашкына — әйтерсең мине нидер тарта. Шул көчкә буйсынып, алга, калкулыктагы скважинага таба кузгалдым.

## 8

Инде өченче көн культбудка белән утыз җиденче скважина арасын таптыйм, егыла-тора йөри торгач, сукмак салып бетердем. Хәзергә бар шатлыгым шул — көннән-көн чаңгыда иркенрәк, кыюрак хис итәм үземне: кич бер дә егылмый әйләнеп кайттым бугай. Табигать матурлыгына, дөнья ямена сокланып үзем кырда йөрим, үзем туктаусыз уйланам: бер дә эш-мәшәкатьләре юк микәнни боларның? Алай булгач, ни пычагыма кеше тоталар? Көн дә чаңгы тагабыз да Хаммат бер якка, мин икенче якка чыгып китәбез. Кызык.

Ләкин Хаммат минем кебек җил куып йөрми икән. Шушы төбәктәге унике скважинаны карап, тикшереп чыга ул. Карап кына калмый, һәркайсында эш таба, озак-озак юана, шуңа да культбудкага кич кенә әйләнеп кайта. Моңа кадәр Фәнүсә белән икәү эшләгәннәрен берүзе башкарып йөри икән, бахыр. Моны мин бүген аңладым.

— Ялгызың йөреп ялыккансыңдыр инде? — диде Хаммат миңа, иртән эшкә килгәч, — җыен, бөтен хуҗалыкны күрсәтәм мин сиңа бүген. Иртән яхшы ашагансыңдыр бит?

Юкәлекне ярып узган рәткә килеп чыгуга, скважинага юлыктык.

— Чыгырлы коедан су алганың бармы? — дип сорады Хаммат, чаңгы бауларын чишә-чишә.

Алмаган кая ул! Безнең тегермән очында бердәнбер су чыганагы салкын сулы чыгырлы кое иде инде. Үзе тирән, үзе зур авызлы иде. Бер елны авыл картлары аны чистартып та маташтылар, чиләкне дүрт дилбегә бәйләп төшергәннәре хәтердә. Ә бер елны... Туктале, чыгырлы коеның ни катнашы бар соң монда?

— Һе, күргәнең юк, алайса? — диде Хаммат, авызын ерып. — Ничево, менә бүген әйләндереп карарсың.

Ул скважинаның һәр болтын барлап, карап, әйләнгәләп йөрде дә, кечкенә генә чыгыр янына килеп, аны әйләндерә башлады. Аннан кисәк кенә туктап миңа эндәште:

— Мәле, җылын бераз.

Хаммат трап янына китеп барды, ниләрдер сүтеп-ныгытып шунда маташа. Үзем әйләндерәм, үзем икеләнәм: төшеп тә житкәндер инде ул кыргыч дигәннәре. Аптырагач, Хамматка кычкырдым:

— Булдымы?

— Һәй, кая әле. — Ул салмак кына атлап яныма килде, бераз вакыт минем эшкә карап торды да сорап куйды: — Кыргычны ник төшергәнне беләсеңме соң?

— Каян белим инде мин?

— Алайса, тыңла.— Хаммат бик әһәмиятле тема аңлаткан укытучы кыяфәтендә сөйләп китте: — Коелар тирән монда, ике чакрымга якын. Шул тирәнлектәге катламда хәлвәгә сеңгән үсемлек мае сыман ята

ул нефть дигәнең. Анда жылы, кызлар куенындагы кебек. Шуңа сыек та җир мае. Җир өстенә күтәрелгәндә ул акрын-акрын суына, менеп җитәргә бер чакрым чамасы калгач, нефтьтән парафин аерыла башлый. Нефтьченең иң мәкерле дошманы инде ул парафин дигәнең. Торбаның эчке стенасына утырып йөдәтә, кыргыч төшерми торсаң, бөтенләй томалап та куя.

Кыргыч үзе скважина эчендә булгач, нинди икәнен күрергә туры килмәде. Мин аны күрәк итеп тә, идән кыра торган үтмәс чыра пычак итеп тә күз алдыма китердем. Әллә өй юганда стена кыргычлый торган кәкре тимер кебек микән ул?

— Ниндирәк нәрсә соң ул кыргыч? — дип сорадым Хамматтан.

Ул иренмичә, сабый балага акыл өйрәткәндәй бастырып кына сөйли:

— Торба эченә сыешлы пешкәк сыман нәрсә ул. Саңаклары димме, канатларымы бар. Аска төшкәндә алар кыргыч эченә җыела. Күтәрә башладыңмы, шул канатларын тырпайта һәм парафинны этеп алып менә. Вәт шул. Чыгырдагы тимер чыбык сүтелеп беткәнче әйләндер син аны. Аннан күтәреп карарбыз.

Шулай диде дә үз эшенә китеп барды.

Келтер-келтер чыгыр әйләнә, тимер чыбык сүтелә, аның белән бергә уйларым да сүтелә. Һай, Мәчтүрә апада яшәү дәверендә күпме генә сулар алынмаган инде ул чыгырлы коедан! Буем арба тәгәрмәче биеклеге чагымнан йөрдем мин ул коега, көянтәгә аскан чиләкләрем җиргә сөйрәлеп бара кебек иде. Тупас агач чиләкне бер төшереп мендергәнче җыларга җиткән чаклар аз булмады. Шулай да алары аккан су кебек үткән дә киткән инде. Шул коега бәйле бер вакыйга гына онытылмаслык булып йөрәккә сеңеп калган.

Кышкы чатнама суык көннәрнең берсе иде. Караңгылы-яктылы суга чыктым. Мәчтүрә апа ашыктырып калды: яңа томаланган мич күмереннән казандагы су кайнап бетә язган — ярылуы бар. Кабаланам. Җитмәсә, коеның тирә-ягы, хәтта бурасына кадәр боз белән капланган. Мин чиләкне төшереп җибәрүгә, кемдер ат җитәкләп килеп туктады. Эчерергәдер инде, хәзер ашыктыра да башлар. Мышный-мышный бар көчемә чыгыр әйләндерәм. Менә чиләк менеп тә җитте. Бер кулым белән чыгырны тоткан хәлдә, икенчесе белән чиләккә үрелдем. Шул чак чыгыр ычкынып китте һәм мин, чиләк кабат чумганчы дип, бар көчемә коега ташландым, чылбырны тотып та алдым. Ләкин шул мизгелдә аягым таеп китте һәм су тулы чиләк мине үзе белән аска сөйри башлады. Күз алларым караңгыланды, зиһенемне югалтканмын.

Исемә килгәндә, боз өстендә утыра идем. Чиләгем кабат коега төшеп киткән, үземне теге атлы кеше тотып калган икән.

— Җүләр син, әллә шулай ыгы-зыгы килергә ярый. Бетә яздың бит! — дип кыздырып алды бу мине.

Коткаручыма күз ташладым. Киндер ыштаннан кып-кызыл булып тез башы күренеп торган кечкенә генә кеше иде ул. Әллә малай гынамы? Йөзенә карагач, мин аны олы кеше дияргә дә, яшь кеше дияргә дә белмәдем. Тез башы кебек үк кызыл борыны шундый зур, әйтерсең тукмак, авызы чалыш, күзләре дә үзгә иде минем коткаручымның.

Мин аңыма килеп беткәнче, ул чиләкне күтәрде, аның суын минем чиләкләргә бушатты һәм олы кешеләрдә генә була торган күкрәк тавышы белән:

— Бар, өеңә ычкын, бозга ябышып катасың бит, — диде.

Рәхмәт әйтергә дә онытып, өйгә йөгердем.

Соңыннан белдем: безнең Гөлбакчаның атаклы Мөхәммәте булып чыкты ул. Тукта, андый күзләр, андый авыз-борын башка берәүдә дә булуы мөмкин түгел. Чыгырымны ташлап, кычкырып җибәрдем:

— Хаммат! Хаммат!..

Ул, кулындагы ачкычларын да куеп тормастан, минем янга ташланды.

— Нәрсә, чыбык өзелдеме әллә?

— Юк ла. Ни... Синең чын исемең Мөхәммәтме?

— Каян казып чыгардың аны?

— Дөресе генә, Мөхәммәтме?

— Мулла кушканы шулай иде,— диде ул, бүрегенең колакчынын төшерә-төшерә. — Руслар ансатлаштырдылар... Ә син кыргычны забойда озак тотма, Галибә, сразы күтәрергә кирәк.

Чыгырны кирегә әйләндерә башладым.

— Каян башыңа килде әле ул? — диде Хаммат, тимер чыбыкны дөрес уралуга көйли-көйли.

— Мин дә бит Гөлбакчаныкы, — дидем мин, эшемнән тукталмый гына. — Тегермән очындагы чыгырлы коены, бер елны кышкы салкында шунда төшә язган кызыйны хәтерлисеңдер әле?

— Син... син Рамазан хатынымыни?! Менә бит... Читтә озак йөргәч... Танымадым, валлаһи, танымадым. Тау белән тау гына очрашмый, диләр шул.

Ул, эшен бетереп, мазутлы кулын чүпрәккә сөртте, аны янәшәдәге тимер ящикка ыргытты да сорашырга тотынды: — Соң, Мәчтүрә апа исәнме? Кызың үсәме?

Ул миңа беравык гаҗәпсенеп карап торды, ләкин бу хакта кайтарып сорамады.

— Менә бит син, әй, Рамазан дус хатыны дисең... Сугышып китәрсең, билләһи, — дип сөйләнде ул, нидәндер акланырга маташкандай. — Әй, гомерләр, гомерләр...

Хамматның эше ашыгыч иде бугай, шулай гөрли-гөрли трап янына китеп барды.

Кыргычны күтәрә торгач, тирләп пештем, күлмәкләрем лычма су булды. Юкәдә икән чикләвек, дип уйладым эчемнән. Һәркайсында болай маташа башласаң, тәүлек тә җитмәс.

Тик алай ук коточарлык түгел икән. Күрше скважинага, Хаммат әйтүенчә, эчтән пыялаланган торбалар төшерелгән булып чыкты. Андый торбаларга парафин утырмый икән, кыргычның кирәге калмаган. Мин скважиналарны игезәкләр сыман бер төсле итеп күз алдыма китерә идем, алар кырыкмаса-кырык төрдә: берсенә электрлы батырма насос төшерелгән, икенчесенә — сиртмәле насос. Ә культбудка янындагы скважинага кыргычны автомат төшереп-күтәрә икән. «Андый автоматлар тиздән бөтен промыселда булачак», — ди Хаммат.

Коточарлык ук булмаса да, эш табылып кына тора операторга. Скважиналарның кайсына яңа сальниклар тутырдык, кайсында нефть агып-тамып торган фланцларны кыстык, кайсында арматураны солярка белән юып, тирә-ягын тәртипкә китердек. Җитмәсә, өч-дүрт скважина Зәй буендагы әрәмәлектә үк, кар ерып аларга барып-кайтуы гына да ярты сыеңны ала. Шулай да мине шиккә салганы эшнең болай муеннан булуы түгел иде. Һәр скважина, Хаммат сөйләгән һәр нәрсә — минем өчен серле карурман, башваткыч. Укымый, өйрәнми торып кына оператор булырмын димә.

Хаммат та нәкъ шуны искәртү өчен көнозын үзе белән йөртте дә бугай инде. Культбудкага кайтуга, шкафтан калын гына китап алып миңа сузды:

— Укырга кирәк сиңа, Галибә.

Китапның рәсемнәрен караштыра башладым. Әллә ниткән җиһазлар, буровой вышкалары, исемнәрен уку өчен генә дә тирләп чыгарлык әллә нәрсәләр турында язылган иде анда.

— Сүз бу китап хакында гына бармый,— дип ялгап китте ул,— техникумга керергә кирәк сиңа.

— Ходаем, миннән буламы соң инде. Русчам да такы-токы ич.

— Булыр, булыр, — диде ул нык итеп. — Башта учкомбинатка йөрерсең, монда күргәннәреңне укып ныгытырсың. Тырышмый гына берни дә чыкмас, кәнишне. Көндезен — эш, китапларга — төн кала.

Хаммат вахта журналын алып, аны тутыра башлаган иде дә берике сан язуга туктапып калды, сүземнең үтеме җитмәде дип уйлады, ахры, тагы миңа таба борылды.

— Аннан соң без дә бар бит әле монда, Галибә. Мин менә өченче елымны атнага дүрт көн кичке техникумга йөрим. Исеме генә кичке аның, сменалы эштәгеләргә көндез дә дәресләр була. Аңа кадәр кичке мәктәп. Авыр, бик авыр укуы, инә белән кое казу, дип юкка гына әйтмәгәннәр. Иптәшләр ярдәм итмәсә, ташлаган да булыр идем инде. Аларның кулы нык. Әйтик, мастер Арсеньев...

Ул сүзен әйтеп бетермәде, телефон шалтырады. Диспетчер участокта эшләрнең барышы белән кызыксына иде бугай.

— Яңа ел бәйрәмендә нишләргә уйлыйсың? — диде Хаммат, трубканы куеп.

— Берсекөнгә ялым да бит, иртәгә эшкә шул, — дидем мин үкенечле тавыш белән.

— Ярый, бер генә көн ялгызым да курыкмам, — диде ул, урынынан кубып. — Кайтып кил кызларың янына, сагынганнардыр.

Беренче карашка килбәтсез генә кешенең әнә шулай хәлеңне уртаклашуы, үз итеп сөйләшүе, бөтен мәшәкатьне үз өстенә алып, миңа ял бирүе ничектер күңелне йомшартып җибәрде, йөрәгем бу кешегә рәхмәт хисе белән тулды. Шулай да эчемдәгене чыгарып селкемәдем. Әллә ни уйлавы бар. Табигать тарафыннан кимсетелгән кеше бит. Үзе беркатлы тагы, йөрәген ярып бирергә әзер.

Мине кайтарып җибәрү каян башына килгән соң әле аның? Һич уйламаганда, авылны, кызларымны искә төшерде. Йөрәгем сулкылдап, сагынып куйдым сабыйларымны. Их, һич югы, әнә теге юкәдә чыкырдап утырган саесканныкы кебек кенә канатларың булса икән. Җил кебек исеп очып кайтыр идем дә кызларымны күреп килер идем. Тәрәзәдән үрелеп кенә карасам да, күңелем булыр кебек. Әллә соң бүген кич үк китим микән? Фикеремне Хамматка да әйттем.

— Диваналанма, — диде ул шактый кырыс итеп. — Туңып үләсең киләме?

Чыннан да, кайтып китмәсен бу дуамал дипме, кичен Хаммат тулай торакка килеп керде, кулында — төенчек.

— Мәле, кызларыңа бераз гына күчтәнәч монда, — диде ул, ничектер уңайсызланып. Мин алырга да, алмаска да белми аптырап торгач, тавышын күтәреп әйтеп салды: — Ал, ал, акчаң юк ич әле.

Бүлмәдәш кызларның өйдә юк чагы. Ходаем, кайтып керсәләр, әллә ни уйлаулары бар. Нишләргә соң?

— Тартынма, — диде Хаммат, төргәген өстәлгә куеп. — Рамазан минем җан дустым иде, семьясына кулдан килгәнчә булышу минем бурыч та бит әле. Моны инде ярдәм дип тә булмый, шулай да ал әле син аны. Балалар янына коры кул белән кайтмассың бит.

Таң белән юлга чыгасы булгач, иртәрәк ятмакчы идем. Ләкин Хаммат һаман китми, Гөлбакча турында туктаусыз сораша. Ничек исемнәрен онытып бетермәгән диген, фәлән абзый исәнме дә тегән абзый ни хәлдә? Үлгәннәр турында ишеткәч, көрсенеп башын чайкый, шул гомер кайтмый яшәве өчен үзен тиргәп ала. Әтисе белән әнисе дөнья куйганнар икән, — авылдашлар бар, Гөлбакча бар бит әле анда.

— Туң йөрәк булып ничә ел үткән,— ди ул ачынып. — Менә бит, ә вакыт юк та юк, имеш. Юк, быел сабан туена кайтам, әбизәтелни кайтам.

Шулай уфтанып шактый утырды да кайтып китте.

Ярый әле килгән, кичнең үткәне сизелми дә калды. Барыбер йоклап булмаячак иде. Әнә бит унбер тулып килә, шулай да күз эленми. Изрәп китәргә тырышып-тырышып ятсам да, уй дигән тынгысыз ташкын мине тынламый, аның үз агышы агыш. Мидә кызган шарлар тәгәрәшеп йөргәндәй ниндидер бер тынгысызлык. Уйларым үзеннән-үзе Хамматка барып бәйләнә. Нишләп бик яхшатлана әле ул? Тумыштан кешегә игелекleme, әллә... әллә берәр нәрсә өметләнеп ураламы минем тирәдә? Булмас, Мөхәммәт... Хаммат андый булырга охшамаган. Рамазанның җәмәгате дип ярдәмләшергә тырышуыдыр инде. Рамазан сөйләвенә караганда, Әмәк белән Шәмәк кебек булганнар алар. Әле менә хәзер хәтергә төште. Бервакыт, печәндә чакта, Мөхәммәт турында төнозын сөйләгән иде миңа Рамазан. Авылда чакта Мөхәммәтнең «Вәкил җене» дигән кушаматы да булган. Шуңа бәйләнешле кызык кына бер мәзәк хәтердә калган.

Имештер, бер елны Гөлбакчага район үзәгеннән вәкил килеп төшә. Ыспай гына киенгән кәттә егет була бу. Аны фатирга Хафиз абзыйларга, ягъни Мөхәммәтләргә урнаштыралар. Көнозын басуларда йөреп, арып кайта вәкил һәм, чишенеп тә тормастан, урынга ава. Ләкин йокларга иртәрәк була әле. Җитмәсә, Хафиз абзый белән Василә апа эштән кайтып җитмәгәннәр, чәй кузгатучы да юк. Кесәсеннән газета чыгарып, укып ята вәкил. Өйдә тыныч, рәхәт, йокымсырап үк китә.

Шул вакыт нидер кыштырдаган кебек була. Вәкил, сискәнеп, түр буйдагы сәке ягына күз сала һәм агарып ук кала. Сәке астыннан коточкыч бер йөнтәс нәрсә чыгып килә икән. Егет сөрән салып урамга чыгып чаба.

Хафиз абзыйларның кырдан кайтып килеше икән. Шомлы хәбәрне ишеткәч, хуҗалар да шикләнеп калалар. Тирә-күршеләрне җыеп, чалгы-сәнәкләр белән коралланалар да, кат-кат тәкъбир әйтеп, ишекне ачалар. Карасалар... идән уртасында Мөхәммәт утыра, ди, ул баштанаяк каз мамыгына баткан, адәм чистартып бетерерлек түгел, ди.

Хәл болай булган икән: көн буе ялгызы өй саклаган Мөхәммәт, карыны ачкач, эзләнә башлый, ләкин арыш ипиеннән башка нәрсә тапмый. Сөт яисә катыкка юлыгу нияте белән чоланга чыга һәм бал чүлмәгенә тап була. Тамагы туйгач, сәке астына кереп, Василә апаның мендәргә әзерләп куйган каз мамыгы өстенә ятып йоклый.

Дөрес булгандырмы, юктырмы — анысын кисеп әйтә алмыйм. Шунысы хак, Мөхәммәтне төрлечә ирештерү, кимсетүләр еш булган ул елларда.

Әнә шундый хикмәтлерәк кеше инде ул Мөхәммәт. Сугыштан соң ул авылда озак тормый, каядыр китеп бара. Шәһәрдә нефтьтә эшли икән дигән хәбәре генә авылга килеп ишетелә.

## 9

Таңга кадәр урында аунасам да, йокым йокы булмады. Хыялланып, саташып беттем. Төн өстеннән авылга җәяү чыгып китәр хәлгә җиттем. Шул ашкыну белән автовокзалга да бик иртә килгәнмен. Шулай да вокзал инде ачылган, вышка төзүчеләр диспетчеры өстәле янында мазутлы тун кигән берничә кеше утырып тора иде. Минем сыман йокысызлыктан интегүчеләрдер инде.

Эчендә пар чыжлап торган калын торбалар янында җылы, рәхәт. Монда килгәч йокы исемә төште: күз эленә, йокы баса. Автовокзалда халык арткан саен көчәя барган шау-шу, ыгы-зыгы, сихерле бишек җыры булып, изрәүне көчәйтә генә иде. Ниһаять, репродуктор шытырдап куйды, чыш-пыш итте, ул да түгел, буровойларга бара торган автобусларның номерларын атый башладылар.



Җиде рәвеш ◆ Әле шушы тылган нишам ◆

Безнең уңайга баручы автобусны табып, иң арттагы рәткә утырдым. Вышка төзүчеләр дә кереп тулды. Ул да түгел, машина кинәт кенә урыныннан кубып, олы юлга чыкты һәм Гөлбакчага таба юл алды. Әйтүләренә караганда, безнең авылга барып җитми ул, Бакалыдан сулга борылып, яңа нефть мәйданы — Якты Күлгә китә. Бакалыдан алтыҗиде чакрым гына безгә. Йөк машинасы булса да туры килер әле, һич тә булмаса, җәяү кайтып җитәрмен.

Карап, тыңлап барам да, бигрәк тә гамьсез, уй-исәпсез кебек бу вышка төзүчеләр. Юлга чыкканнан бирле телләрендә җыен әкият, мәзәк, уен-көлке. Ул арада өерелеп кәрт тә суга башладылар. Бер генә дә борчулары юк микәнни?.. Уй-исәпләре булмаса да гаҗәп түгел шул, тормышлары көйле ич: өйләре җылы, суы, газы кергән, ашарга дисәң кибет тулы сөте-мае, колбасасы-балыгы тулып ята дигәндәй, конфетшикәрен әйткән дә юк.

Ә минем эчтәге утлы төен үзен бер генә минутка да оныттырмый. Кызларымны юксынуданмы, күңел утырмауданмы бу? Бер уйласаң, чәбәләнерлек әллә ни юк. Эшем көйле генә күренә. Аның кырда, табигать эчендә булуы якынрак та әле миңа — нәкъ авылдагы кебек. Бергә эшләүче иптәшләр дә әйбәт кенә төсле. Мастер Арсеньевына кадәр «Галиба» дип кенә тора. Җитмәсә, игелекле җан Мөхәммәт кул астына эләктем, җил-яңгыр тидермәс кебек. Бушка эш киемнәре, итек бирделәр, тулай торакка урнаштырдылар. Белемсез-нисез бер ятим хатынга күп тә инде бу. Тагы ни кирәк сиңа?

Шулай дип юатам үземне. Ләкин, ни гаҗәптер, эчтәге төен язылмый да язылмый гына бит. Кызларым каршында зур җинаять эшләгәнмен төсле. Иң кыен елларда башымнан сыйпап үстергән авылым минем китүемә рәнҗи сыман. Һаман да Рамазан хәтергә төшеп йөдәтә, төшләргә кереп аптырата. Аның рухы алдында гаепле шул мин. Ни дип кенә киткән булдым шул Ишалгыга?! Кеше коткысы белән йөреп табасыңмы әллә бәхетне! Манзума әйтмешли, үзең тир түгеп эзләргә кирәк аны. Шулай булгач, ни дип һаман авыл ягын каерам әле? Бер ниятләгәч, һич югы, берәр ел эшләп карыйсы иде нефтьтә.

Автобусның стенага бәрелгәндәй кисәк тукталуы уйларымны өзде. Тәрәзәгә карадым. Машина Бакалы кибете янына килеп туктаган иде.

— Без сулга, абыстай, төшәсеңме? — дип кычкырды шофер — тәбәнәк буйлы бүлтерек. — Югыйсә, буровойга алып китәбез үзеңне.

— Төшәм, төшәм, рәхмәт, — дидем мин, кесәмнән тиеннәр чыгарып.

Шофер кул гына селтәде, вышка төзүчеләр бердәм шаулаша башладылар:

— Бар инде, бар.

— Әни-карчыгыңа сәдака бирерсең кайткач.

Мин юл кырыена сикердем. Вышкачылар, нидер кычкырып, ат кебек кешнәп калдылар.

Гөлбакчага туры бара торган юл болай ук шәптән түгел. Бүген машиналар да узмаган бугай, бульдозер эзенә төнге җил түшәгән ап-ак карда җәяүле сукмагы гына. Шулай да көтәргә булдым.

Машиналар килә тора, борылып Якты күл ягына китә тора. Безнең төбәктә нефть юк шул, колхоз машиналары гына узса инде... Юк, күренмиләр. Әнә теге ике машина гына үтсен дә...

Алдагысы, иләмсез зур йөк машинасы, тизлеген дә киметмичә, сулга борылды. Аның артыннан килүче автобус исә яныма ук килеп туктады һәм аннан минем кочакка диярлек бер хатын-кыз сикереп төште.

— Ишеттем, ишеттем. Чытлык. Нифтяник булдым дигәч тә, хәл белергә дә кереп чыкмый, — дип шаулады ул ишектән ук.

Мин аны тавышыннан ук таныл алдым.

— Ачуланма, Манзума, урнашып йөрү мәшәкате һаман, — дидем

мин, акланырга тырышып, һәм сүзне икенчегә борырга ашыктым: — Син дә бик ешладың әле.

— Кайтып килми булмый, — диде ул, затлы пальтосын каккалап, — яшь киленгә вак-төяк нәрсәләр алган идем.

Чатнама суык булуга карамастан, Манзума җиңелчә киенгән. Башында теге чактагы кыландырып теккән башлыгы, аягында шул ук замоклы сапужкилары. «Көяз туңмас, калтырар» шушы була инде.

— Күптән көтәсеңме? — диде ул, мине юлдан читкәрәк этәреп.

— Ярты сәгать булыр.

— Киттек пишучкым. Попутный очраса, туктатабыз аны,— диде Манзума, гадәтенчә кискен итеп. — Бер каш сикертсәң, эреп китә ул шофер халкы.

Сөйләшә-сөйләшә атлый торгач, кай арада никадәр җир дә киткәнбез. Бакалыны да чыкты, аны алкалап яткан Шушма бозын кичтек, әрәмәлекләрне үттек. Юл карлы булса да, киң, икебез ике тәгәрмәч эзеннән барабыз. Болай сөйләшергә ансат. Сүзгә мавыгып юл озынлыгы сизелми дә. Машина килмиме дип артка карап алабыз да тагы ләчтит сатарга тотынабыз. Дөресрәге, мин сөйлим, Манзума тыңлап бара. Ни гаҗәп, башка чактагыча җәелеп мактанмый ул бүген, хәтта юкка-барга шаркылдап көлми дә, сорау арты сорау яудыра гына.

— Ну, ничек, нифттә каласыңмы?

— Төпле генә фикергә килмәдем әле.

— Безгә килер булсаң, главный белән сүләшәм.

— Кирәкми әле.

— Ник?

— Үзем дә белмим, кабат авылга кайтмагаем.

Манзума миңа тиле кешегә карагандай сәер караш ташлап алды,— дивана бу Галибә дип уйлый бугай.

— Пуныл, — дип куйды ул шактый гына дәшми барганнан соң. — Теге нәмәстәң пакуй бирми торгандыр. Тагы Ишалгыга ычкынырга йөрисеңдер әле.

— Аллам сакласын!

— Ник? Кыйныймы? Издиватсе итәме?

— Юу-ук.

— Эчә торгандыр. Алкагулдыр.

— Анысы да бер чама гына.

— Алайса, анасы аждаһа инде?

— Үз әнием, үз әтием кебекләр.

— Соң, шулай булгач! Тагы пычагым кирәкме сиңа? Тормышлары бик әйбәт дип сөйлиләр бит. Әллә соң теге... ирлеге юкмы?

— Сау-сәламәт ул.

Манзума тагы дәшми-тынмый гына барды да кинәт тирә-юньне ярып кычкырып җибәрде:

— Сумашеши син! Вәт!..

Мин аңа карап алдым һәм тавышсыз гына көлеп куйдым. Холкын белгәнгә, үпкәләмәдем, хәтерем дә калмады. Тик ул сүрелә төшкәч кенә тирән көрсенеп әйтеп салдым:

— Их, Манзума, мәхәббәттән башка бәхет юк икән ул!

Ачынып әйткән бу сүзем дә канәгатьләндермәде Манзуманы. Каян табып бетерәдер, сорау өстенә сорау өя, шул арада кабат мине тиргәп ала. Тәмам интектереп бетерде. Юлның да очы күренми, ичмасам. Түзмәдем, аңласаң шуннан аңла инде дип, Ишалгыдагы тормышны сөйләп бирдем.

Шиксез бәхетемне табу һәм аннан качу тарихы мине нык тәэсирләндергән иде. Күзгә яшь тыгылып, бугазга ниндидер төен калкып йөдәтте. Манзума исә керфеген дә селкетмәде.

— Исең киткән икән,— диде ул, бер дә пошынырга урын калдырмаслык итеп,— дүрт бала белән калучылар да бар. Әнә безнең краншик Хәтимә дүртесен дә кеше итте. Әй, хәзерге заманда ни, хөкүмәт ярдәм итеп торганда...

Гөлбакчага килеп кердек. Үзем дә сизмәстән адымымны кызулатканмын икән. Манзуманың «чапма инде» диюенә карамастан, кабаланам, хәтта сулышым капты. Өй турына җиткәч, Манзума белән саубуллашырга да онытып, йөгереп кереп киттем. Бусаганы атлауга, сумкамны бер тарафка ыргыттым да кызларыма ташландым...

## 10

Пошынулары, борчулары, шулар арасында ялтырап-ялтырап киткән сөенечләре белән ел үтеп тә китте, яңасы башланды. Ни алып килер ул минем ятим тормышыма: бәхетнең тагы берәр төре белән очрашырга насыйп итәрме, әллә көтелмәгән сынаулар әзерләгәнме? Зарланмыйм: моңа кадәр минем кала тормышы гел уңайга бара, юлымда яхшы кешеләр очрап тора. Күңелем сизә: яңа ел тагы да шатлыклырак булыр төсле. Әнә бит Хаммат та: «Барактан булса да квартир бирерләр кебек», дип өметләндерә. Ул промыселның профсоюз комитеты члены, начальство тирәсендә уралгач, барын белеп, ишетеп тора. Озакламый йөз квартиралы яңа йорт өлгерә, имеш. Гөлбакча халкының яртысы сыешлы инде. Тик безнең ише нефтькә әле генә аяк басканнарга өметләнергә бәлки юктыр әле... Зәйсу мәйданын ачканнан бирле эшләүчеләр дә бар, имеш, чиратта. Шулардан бушаган бараклардан эләксә инде безгә.

Ләкин тормышның үз агышы агыш. Ул миңа сөенечләрдән элек яңа сынаулар әзерләгән булып чыкты. Әйтерсең лә ул: «Кара, кызый, нефть чыгару син уйлаганча уен түгел, белең сыек булып чыкмасмы, сыгылып төшмәссеңме?» дип кисәтә иде.

Яңа ел бәйрәменнән соң көндезге вахтага оператор Иркәбай чыкты. Мин әле өйрәнчек кенә, шуңа күрә бу атна буе аның кушканын үтәп, ул боерганнарга йөгереп торырга тиеш булам.

Хамматның өзек-тәтек сөйләвеннән һәм смена алышынганда берничә тапкыр «Исәнме, сау бул» кебек очрашулардан Иркәбай белән аз-маз таныш идем инде мин. Ул нефтьтә күптән эшли, шушы юкәлек артындагы егерме-утыз йортлык кына поселокта үз өендә яши икән. Өе тулы бала-чага, ди. Хамматның аңа адресланган «тозлы» сүзләреннән соң, Иркәбай минем күңелгә иренчәгрәк, җае чыкса, эш вакыты белән дә исәпләшмичә, салгалап, качып-посып йокларга яратучы бер кеше булып урнашып бара иде.

Шулай да өченче көн иртән, үзе белән бер вахтага баскач, аны башкачарак кабул иттем. Өс-башына артык әһәмият бирмәсә дә, сөйкемле киң генә куе кашы белән зур күзләре дә шулай ук «бериштән», хәтта какча яңакларын да каратут баскан. Кешегә туры карарга базмый торган оялчан, йөзе һәрчак көләч, тик күз кабаклары гына шешенгән сыман. Эшнең рәте-башын белә бугай, бик төпле сөйләнә. Ләкин аңа карата күңелемдә уяна башлаган матур өметләрем кичкә кадәр челпәрәмә килде.

— Син Галибә, үзең белгәнчә кара инде скважиналарны, — диде ул берәр сәгать чамасы культбудкада утырганнан соң, — Хаммат артыннан бер өч көн мыш та итми эшлиләр әле алар. Минем хатын сырхаулап тора, алай-болай булса мин гел өйдә, — авылны кергәч тә икенче йорт

Аңа ни дип җавап кайтарырга да белмәдем. Эш вакытында шулай туарылырга ярый микәнни? Әллә соң монда эленке-салынкы йөреп тә үтә микән? Хатыны да чирләгәч, өендә эше дә күптер инде. Әйдә, үзе беләдер...

Ялгызым калгач, ниндидер сәер хәлгә төштем. Бу кадәр зур хуҗалыкка беркайчан да баш булганым юк иде әле. Күңелдә ниндидер шомнидер ватылыр, нидер кырылып чыгар сыман, скважиналарның кайсынадыр ут кабардыр төсле. Шулай да карлы сукмактан урманга кереп барган Иркәбайга кычкырмадым — үземне сынап карыйсы килә иде.

Чаңгыларымны тагып, теге атнада Хаммат белән йөргән эзгә чыктым. Юл уңаендагы беренче скважинага кыргыч төшереп күтәрдем, башкаларында әйтерлек тә эш булмады: сиртмәле насосларның каешлары исән, агып-тамып торган урыннар күренми — барысы да ниндидер бер моң белән тигез генә эшлиләр иде. Культбудкага әйләнеп кайтканда мин инде үземә күрә ачыш ясагандай булдым. Әллә ние юк ла бу эшнең. Күп булса сменага бер карап әйләнәсең, ул-бу килеп чыга икән, скважинаны ябып диспетчерга шалтыратасың — электригы дисәң электригы, слесаре дисәң слесаре килеп җитә. Зуррак хәвеф булганда эшләр җир асты ремонтчыларына яисә капиталь ремонтчыларга тапшырыла. Икенче сменага килеп, хәл-әхвәл сорашкан Хамматка да шул хис тәэсирендә эреләнебрәк җавап бирдем бугай, ул миңа бер мәл «ни булган бу кызыйга?» дигәндәй карап торды.

Иртәгесен Иркәбай белән дә масаебрак, эшне төптән белгән кешедәй сөйләштем. Ул исә моңа шатланды гына.

— Әйттем бит бер ние юк диеп, — моны ул йөзен читкә бора төшеп белдертте. Авызыннан аракы исе килеп тора иде аның. Ахры, шуңа артыгын сөйләшеп, җәелеп утырырга исәпләми иде, урыныннан купты. — Урман артындагыларын үзем карармын мин, син тегеләрен ура инде... Кирәгем чыкса, өйне беләсең.

Иркәбай урманга кереп китәргә өлгермәде, телефон шалтырады. Егерменче нефть җыю пункты берничә сәгатькә ремонтка туктала икән. Җир мае шунда ага торган скважиналарны кичекмәстән ябарга кирәк — диспетчерның шуны кисәтүе. Ватман кәгазенә төшерелгән схема янына килдем һәм кара сызык белән егерменче җыю пунктына тоташкан түгәрәкләрне санап чыктым. Алар бишәү иде. Күзләремне йомып, аларның кайдалыгын хәтергә төшердем һәм ашыгып ишеккә борылдым.

Тукталырга тиешле скважиналарның икесе культбудка янәшәсендә генә. Аларның япкычларын томаладым да, яңа эз салып, турырга гына Зәй буена төшеп киттем. Бу кадәр дә кызу йөргәнем юк иде әле чаңгыда. Сәгать тә үтмәгәндер, эшемне бетереп кайтып килә идем инде.

Культбудка янәшәсендәге скважинаның мернигын күргәч, йөрәгем «жу» итеп китте. Аның өстендәге люктан озын-озын «кара еланнар» чыгып җиргә таба шуышалар иде. «Япкычларны томаламаганмын» дигән уй ток суккандай узды башымнан. Бар көчемне җыеп, шунда ыргылдым, чаңгыларымны да салып тормастан, үзәк япкычка ябыштым. Ләкин ул ныгытып ябылган булып чыкты. Алай булгач каян килә соң бу нефть? Әнә бит мерник стенасында инде аерым ерганаклар гына түгел, карасу-көрән сыеклык ташкын булып ага, тирә-яктагы кар көртләре күзгә күренеп чугә, карала иде.

Соравыма җавап табарга өлгермәдем, кара ташкын калкударак утырган икенче скважинада да күренде. Нишләргә дә белмәстән, анда ташландым. Менә табышмак. Бередә дә үзәк япкыч томаланган, ә нефть дигәнең каяндыр агып мерникларга тула һәм аңа сыешмыйча, шомлы фонтан булып, кайнап-шаулап ирекә омтыла иде.

Скважина янына басып катып калдым, тамакка ниндидер утлы төер калыкты. Үзеңнең көчсезлегеңне танудан да авыррак нәрсә юктыр дөньяда. Инде нишләргә? Иркәбайны эзләп чабарга кирәктер, мөгаен. Ансат

кына табылган чарага шатланып, урманга таба кузгалдым. Үзем йөгерәм, үзем уйланам: туктале, ни дип чабулыйм соң? Иркәбайны эзләп тапканчы, тирә-юньне нефть ташкыны басачак ич. Шулай да кайдан килеп туларга мөмкин соң бу җәфа? Скважиналар ябык, сыек ягулык агып чыга торган линияләрдәге япкычлар гына ачык. Димәк, шуннан тула, димәк, коллекторда басым күтәрелгән. Ябарга, булган япкычларның барын да томаларга!

Чаңгыларымны салып аттым да, имәнгеч кара кар боткасын ерып, мерник янына килдем, япкычны томаладым. Ургып-гөҗләп торган ташкын тынып калды. Шатлыгымнан канатланып икенче скважинага йөгердем, аннан өченчесенә, дүртенчесенә...

Кайту юлына борылганда, мин инде кыйнап ташланган кеше хәлендә идем. Өр-яңа сырмадан, мамык чалбардан саркып нефть тамып тора. Газы тынга каплана, баш әйләнә, күңел болгана. Артымда шомлы кара эз, әйтерсең карны ниндидер бер фантастик киек ярып язган.

Культбудкага ничек кайтып җиткәнмендер, белмим. Скважина янында зур-зур агрегатлар, янгын машиналары, бер төркем кеше күргәч кенә аңыма килдем. Башларына этәч кикриге сыман тимер каскалар кигән янгынчылар арасыннан ике кеше — мастер Арсеньев белән Хаммат килеп чыкты һәм алар мине култыклап культбудкага керттеләр.

— Хәзер үк өсләреңне алыштыр, — диде мастер, форточкаларны ача-ача. — Ярый әле, япкычларны томаларга башына килгән. Иркәбай кайда соң?

Дәшмәдем. Пычтырдап торган сырманы, чалбарны бусага төбенә салып аттым. Нефть эчке киемнәргә үтәргә өлгермәгән иде. Шуны гына көткәндәй, каршыма врач килеп басты, пульсны, кан басымын тикшерде, нииндидер дарулар бирде.

Мине ашыгыч ярдәм машинасында туп-туры мунчага алып кайттылар. Агуланып җитмәгәнмен икән. Юынып чыккач, хәл алып, тулай торакка кайттым һәм шунда ук ятып йокладым.

Кичәге башваткычның җавабын бүген иртән генә, вахта автобусына утыргач белдем. Диспетчер шалтыратып-шалтыратып та күрше участокка хәбәрне җиткерә алмаган. Аларның скважиналары тау башында. Чыгарылган нефть үз җае белән һаман агып торгач, ул-бу хәл бардыр дип шикләнмәгәннәр дә, җир маеның безнең мерникларга тулып, ташып ятуы башларына да килмәгән.

Хамматлар исә төнозын эшләгәннәр: түгелгән нефтьне агрегатлар белән суыртып җыйганнар, җиһазларны солярка белән юганнар. Без килгәндә инде скважиналар ап-ак булып кабат көязләнеп утыра иде. Тик тирә-якта гына хәвеф шәүләсе булып шомлы каралык сакланган. Иркәбайның да йөзе скважина кырыендагы кар кебек караңгы, боек. Аңа промысел җитәкчеләреннән бик нык эләккән, үзен операторлыктан алып, түбән разрядлы эшкә, гади генә итеп әйтсәк, кем кая куша, шунда йөрүгә күчергәннәр. Ярый әле, промыселда калдырганнар, балаларын җәлләгәннәр, күрәсең.

## 11

Кулымдагы китабымны ябып уйга калдым. Җир шарында өч миллиардтан артык кеше яши диелгән. Шунысы кызык: очсыз-кырыйсыз халык диңгезе эчендә бер-беренә охшаган бер пар да юк икән. Шулайдыр шул. Озыны янәшәсендә кыскасы, матуры янында ямьсезе, уңганы, уңмаганы... Күзгә күренми торган сыйфатлар турында сөйләп торасы да түгел. Бергә яши, эшли торган иптәшеңнең дә кешелеклеме, түгелме, булдыклымы, булдыксызмы икәнен тиз генә белмисең. Уртак эштә бигрәк тә. Моңа кадәр миңа колхозда һәм кирпеч заводында күмәк эш-

ләрдә булырга туры килде. Анда йөкне һәркем тигез тарта төслеі җиң сызганып тырышканы да, эшләгән булып буталып йөргәне дә. Ә оператор хезмәте кебек бөтен җаваплылык бер җилкәгә салынган җирдә кемнең кем булуы шунда ук беленә икән. Иркәбайны гына ал инде, бер атнада бөтен барлыгын тотты да селекте. Аның сансызлыгы аркасында, нефть түгеп хур булдык. Әле икенче көнне килгәч тә искитәрлек берни булмагандай сөйләнеп утыра. Җир астында нефть — океан, имеш, синең белән мин түгеп кенә бетерерлек түгел.

Бер скважинаның туктап калуы да Иркәбайның ялкаулыгыннан. Үзем карармын дип киткәч, скважиналар янына бөтенләй бармаган. Кыргыч төшермәгәч, фонтан торбаларына парафин тыгылган. Ремонтчылар чакыртып, аларны күтәртәсе, парлыйсы бар. Ә сводкада инде ничәнче көн минус языла.

Иркәбай белән эшләгән бер атна эчендә күңелсезлек булмый калганын хәтерләмим. Җитмәсә, кичә вахтага кызмача килде, тәмсезләште, искә төшерергә чирканыч сүзләр әйтеп җанымны мәсхәрәләде. Аның урынына билгеләнгән оператор кайчан чыгар инде. Әллә шуңа Хаммат белән эшлисе атнамны көтеп алдым. Менә бүгенге ял көне дә үтеп бара, иртәгә аның белән вахтага.

Ләкин Хаммат белән очрашу сәгате бүген суккан икән. Кышкы кояшның кандай кызыл салкын нурлары сүнеп барганда бүлмәгә үзе килеп керде.

— Күр әле моны, ял йортындамыни, — диде ул, гадәтенчә, тавышы белән бөтен бүлмәне тутырып. — Әйдә, киен!

Урынымнан кузгалмый гына аңа сораулы караш ташладым. Кая чакыра бу мине? Эшкә дисәң, үзе бик купшы киенгән: өстендә каракүл якалы затлы пальто, якасына тиң бүрек, галстуктан. Һай, җүләр, үзе барасы булса, синең арттан килеп тә йөрми инде ул. Торып сушилкага киттем һәм мазутлы киемнәремне күтәреп кердем.

— Чиста киемнән барсаң да була, — диде ул серле итеп.

Спецовкамны урынына элдем дә, сизри башлаган пальтомны, киез итекләремне киеп, мамык шәл урадым һәм инде коридорга чыгарга өлгергән Хаммат артыннан киттем. Кухняда кер үтүкләп маташкан Фәнүсә безне серле генә елмаеп озатып калды.

Бу гадәти булмаган сәфәрне ни дип юрарга да белмичә, Хаммат артыннан атлыйм. Төнгә каршы кая алып бара бу мине?... Уенда бер-бер начарлыкмы әллә? Булмас, бер атна буе икәүдән-икәү кыр уртасында йөргәндә дә ул мина кул сузу түгел, әдәпсезрәк сүз дә әйтмәде. Азгынлык аның табигатендә үк юк бугай. Ә Фәнүсәнең күзләре? Әй, аның бөтен уенда шул гына ич, адәм рәтле сүз сөйләгәне дә сирәк.

Шәһәр уртасында мәһабәт булып калкып торган Культура йортына борылгач, шик-шөбһәләрем таралып, башымда бер генә сорау калды. Киногa чакыруы шушы микәнни байгышның?

Юраганым юш килмәде. Без Культура йорты каршындагы мәйданны үтеп, тар гына тыкрыкка борылдык. Инде тәмам икеләнеп, шүрли үк башлаган идем, Хаммат:

— Менә килеп тә җиттек, — дип куйды.

Кар көрте эчендә бөтенләй тәбәнәкләнеп калган баракка таба борылдык һәм корыч арканга авыр тимер аскан ишекне дөбер-шатыр ачып эчкә уздык. Хаммат коридорның ике ягы буйлап тезелгән дистәдән артык ишекләрне санагандай караштырып барды да, берсе янында туктап, аны төртеп карады, аннары кесәсеннән ачкыч чыгарып, йозакны ачты һәм эчкә атлады. Ул да түгел, бүлмәдә ут кабызды. Бераздан аның иләмсез тавышы ишетелде.

— Нәрсә куркып калдың, тотып ашарга берәү дә юк монда!

Каушый төшеп кенә ишек янына килдем. Бүлмә, чыннан да, буш, шыксыз иде. Шулай да эчтән рәхәт булып җылы бәреп тора.

— Безнең Артамонов яшәде бу бүлмәдә, — дип башлады Хаммат, карашы белән түшәм-стеналарны айкап. Тавышыннан тәрәзә пыялалары зыңлап куйды.— Хатыны булмаган нәрсә, күрәсең, чисталыкка интеккәннәр болар... Ну, ничево, буяп, акшарлап җибәрсәң, яшәрлек әле бу...

Бу минутта мин аны тыңламый идем инде. Бүлмәгә ничек кергәнемне сизми дә калдым һәм, сират күперен үтеп оҗмахка эләккән кешедәй шатланып, мичен, тәрәзәләрен карый башладым. Тыштан күренгәнчә, бик тәбәнәк түгел икән лә. Түшәм-стеналары да Хаммат әйткәнчә үк пычрак түгел. Иң әһәмиятлесе — тәрәзә астына тартып куйган гармун сыман зур батареясы, суы бар. Сөенечемнән кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым:

— Хаммат! Рәхмәт инде!..

— Тукта, рәхмәт әйтергә ашыкма әле. Синең кебек квартирсызлар аз дип беләнеңме? Ордер алу өчен ныклап көрәшәсе бар әле. Тырышып карарбыз мена.

Барак бүлмәләрен кемгә бирү-бирмәүне местком утырышында тикшереп тә тормыйлар икән хәзер. Аның эше — бөтен уңайлыклары булган капиталь квартирларны бүлү. Ә бушап калган барак бүлмәләрен нишләтүне промысел җитәкчеләре белән киңәшеп йорт идарәсе хәл итә, ди. Шулай да аларына ия булуы да ансат түгел икән. Хаммат, тырышып карарбыз, дигән була да бит, ни булып бетәр инде?

Тулай торакка мин яңа уй-исәп, яңа ашкыну белән кайттым. Өмсенеп калу гына булмаса ярый инде.

Бу атна, Хаммат белән эшләвемә карамастан, тынгысыз һәм борчулы булды. Мәшәкатьләр графиктагы сигез сәгатькә генә түгел, тәүлеккә сыешмый башлады. Эшкә чыгуыбызның беренче минутларыннан ук тотынды ыгы-зыгы. Культбудкага кереп, киемнәребезне алыштырырга да өлгермәдек, телефон шалтырады. Нефть җыю пунктыннан икән. Хаммат кулындагы трубкадан бераз гына борчулы тәкәббер тавыш миңа ук ишетелеп тора:

— Нефтегез кая?

— Кая булсын, — ди Хаммат, бер дә исе китмәстән, — ага.

— Агуын ага да, кая коя икән соң ул? — дип бәйләнде әлеге тавыш. — Безгә килгәне күренми.

Таңга таба җыю пунктына сыек ягулык кереме кинәт кенә азаеп калган. Хамматның әйтүенә караганда, мондый хәл берничә скважина берьюлы туктап калганда, яисә нефть үткәргече ярылганда гына була икән. Төнлә электр энергиясе бирүдә өзеклек килеп чыкмаган. Димәк, скважиналар эшләгән. Шик нефть үткәргечтә. Шуны әйтергә дип, икеөч сәгать буе шалтыратсалар да, телефон трубкасын алучы булмаган.

— Разрядын кискәнгә үҗәтләнеп йөри, башсыз,—диде Хаммат, Иркәбайны телгә алып. — Бөтенләй куганнарын көтә, сантый.

Хаммат, диспетчерга шалтыратып, сварка агрегаты хәстәрли торырга кушты да, чаңгыларын тагып, басу түренә, авария булырдай шикле урыннарга чыгып чапты. Скважиналарны карап кайту тулысы белән миңа калды.

Мин культбудкага әйләнеп кайтканда, ул инде лом, көрәк ише коралларын әзерләп, сварщиклар көтеп утыра иде.

— Җылы урын, кайнар аш белән саубуллашырга туры килә бүгенгә, Галибә,— диде ул, борчылуын сиздермәскә тырышып.— Авария! Линияне мөмкин кадәр сафка бастырырга кирәк. Болай да 300 тонна минус. Ә хәзер тиз генә мена бу скважиналарны ябарга булыр.

Ул стенадагы схема янына килде һәм тукталырга тиешле скважиналарны санап чыкты:

— Менә шулай да булгалый бездә.

Баярак чаңгыда өшемәгән төсле булсам да, эчкә суык төшкән икән — җылынып кына булмый. Шулай да назланып культубудкада утырыр чак

түгел, чаңгы тагып кабат скважиналар янына киттем. Шуннан инде тиз генә кайтырга туры килмәде. Эшемне төгәлләүгә, Иркәбайны эзләп чаптым, аннан Хамматлар янына киттем. Зәйгә төшә торган сөзәктә моторлар гөрелтесе һәм эшчеләрнең ара-тирә кычкырып алулары авария урынын әйтеп торалар иде.

Кышның кодрәте каршында йөз ат көчле бульдозер мескенләнеп калган, эшкә лом һәм кәйләләрне җигәргә туры килде. Тынсыз җиргә житкәч тә куанырга насыйп булмады: торбадан бәреп чыккан нефть, туфрак белән аралашып, май тамып торган хәлвә сыман нәрсә барлыкка китергән. Противогаз киеп эшләү кулны тота, күзлек пыялалары тирли, биттән кайнар тир ага. Ярый әле, сварщиклар тракторларына будка тагып килгәннәр. Күлмәкләрдә тир сыгып алырлык булганчы эшлибез дә кереп тимер мич янында кипшенәбез.

Ул төнне Зәй буендагы басуда моторлар гөрелтесе, хезмәт ыгы-зыгысы тынмады. Кешеләр арыдылар, тәмам сөйләшмәс булдылар. Хамматның ара-тирә шаярткалап куюы да нәтиҗә бирмәде. Шулай да кулларындагы кораллары нык тора иде әле нефтьчеләрнең.

Ярык торбага соңгы җөйне салганда, тирә-юньдәге ут күлдәвекләре сыекланып, безнең юкәлек өстендә таң яктылыгы талпына иде инде.

Авария бетте — өстән тау төште. Ләкин Хаммат белән безнең яңа эш көне башлана гына иде әле. Кичә туктаткан скважиналарны кичекмәстән җибәрәсе, башкаларын карап әйләнәсе бар. Тагы миңа кушсалар, нишләрмен? Беләкләрдә җеп өзәрлек тә көч калмаган, баш кургаш тутырган сыман авыр. Иркәбайның да хәле минекеннән яхшырак түгел иде бугай, баскан җирендә оеп-оеп китә, күзләре ачылган арада туктаусыз сукрана. Хаммат безгә карап-карап торды да тонык бер тавыш белән:

— Барыгыз, кайтыгыз, — диде. Үзе чаңгыларын эзләп китте. Без аны-моны искәргәнче, ул инде, алга иелә төшеп, скважиналар рәтө буйлап китеп бара иде.

Тәүлек буе эшләгән кешенең муенына камыт кидереп ялгызын калдыру һич кенә дә килешә торган нәрсә түгел, уңайсызланып калдым. Шулай да бу минутта минем хәл ояттан узган иде инде, башны иеп культбудкага таба кузгалдым. Иркәбай да миңа иярде.

Ордеры кулга төшмәсә дә, эштән соң Фәнүсә белән бүлмәне акшарларга дип сөйләшкән идек. Кая инде. Үзем кайта алмадым. Хәзер, бер тәүлек эшләгәннән соң, ләкин кайгысымы. Кайтып керүгә, ашап та тормыйча, урыныма аудым.

Бу атнада бүлмәне буяп чыгарга насыйп булмаган икән. Әлеге авария шаукымыннан айнып бетмәдек, скважиналарның берсенә сузылган линиядә «колбаса» хасил булганы беленде. Нефть үткәргечкә тыгылган парафинны нефтьчеләр шулай дип йөртәләр икән. Ул торба юлының инкелләрдәге өлешенә тупланып, бөке хасил итә дә сыек ягулык юлын томалап куя икән. Кабат сварка агрегаты китерергә, кабат туң балчык чабарга туры килде. Торбага махсус тишекләр тишеп, аны күчмә парлау агрегаты белән җылыттык, «колбасаны» шул тишекләрдән кудырып чыгардык. Монысы да теге авариядән ким булмады. Шулай итеп, киеренке хезмәт эчендә бер атна үтеп тә китте.

## 12

Квартир дигәннән, тәмам пошаманга төшерде ул мине. Анда күчеп, барыбыз бергә җыйналып яшәүне күз алдыма китерәм дә, шатлыктан йөрәгем кысылып куя. Инде аңа башка берәү ия булу ихтималын уйлыйм да, тәнем чымырдап китә, күзләремә яшь килә. Эштән арып кайтуыма карамастан, төннәр буе шул бүлмә белән хыялланам. Әле бәхет кошы тоткан кешедәй елмаеп куям, әле салкын кабергә эләккәндәй

котым очып, сискәнеп китәм. Уттан чыгам да — суга, судан котылам да — утка. Хамматы да кисеп кенә бер сүз әйтми, ичмасам. Әллә инде өмсендереп кенә калмакчы шулай. Туктале, нигә дип Манзума белән киңәшмәскә? Ул әрсез алабай бирәр чарасын табар, шәт. Ни дип башта ук аның янына йөгермәдем соң?

Күп борчылулардан соң табылган шушы карарымны тормышка ашыру дәрте белән йокым йокы булмады. Таң атканчы ук төзүчеләр торагына йөгердем. Шимбә көн ялыдыр әле Манзуманың. Шулай да соңгарсаң, чыгып китүе бар браматның.

Торакта ял иртәсе икәне сизелеп тора: кызларның байтагы йоклый, ял көне итеп каядыр барырга җыенган берничәсе генә үтүк кыздырып маташа иде.

Манзума да йокы симертә иде әле. Дәшә-селеккәли торгач та уянмый йөдәтте. Салкын кул белән куенына тыгылгач кына чырыйлап кычкырып җибәрде, күзләрен ачты.

— Нишләп йөрисең, ә, төн пәрие? Лунатик булдың мәллә?

Ашыга-кабалана хәлемне, шөбһәләремне сөйләп бирдем.

— Кайчан барып караган идегез? — дип сорады Манзума иренеп кенә.

— Өч-дүрт көн элек.

Ул өстенә салкын су сипкәндәй сикереп үк торды.

— Ахмак син, бисталкувый. Шул көннән бирле буш тоталар димени квартирны?!

— Соң бит ордер юк. Хаммат та ашыкмаска кушты.

Манзума ярсып киенә башлады.

— Бозау ул синең Хамматың, беләсең килсә. Куркак. Законник. Нинди ордер ди ул баракка хәзерге заманда. Акбурың, пумалаң бармы? Аннан да главные тәрәзә пәрдәсе кирәк, соңгармаган булсак, бүген үк челтәрләр эләргә кирәк. Занятый дип белсеннәр. Аңыштыңмы? — Ул, киенә-киенә, аяк өсте генә колбаса белән ипи капкалады да, каядыр чыгып, бер савыт акбур, төзелеш кләе, пумала алып керде, чемоданнан ниндидер челтәрләр чыгарды. — Нәрсә терәлеп каттың?! Төенлә шуларны.

Инде чыгып китәбез дигәндә, Манзума ниндидер тартмалар актарып, аннан карга борыны, отвертка ише тимер-томырлар, кадаклар алып сырмасы кесәсенә салды.

Юл уңаена безнең торакка кереп, Фәнүсәне дә иярттек. Ул сылау, буяу эшенең рәте-башын белә, элек төзелеш идарәсендә маляр булып йөргән. Манзумага менә дигән иш инде.

Килә-килешкә тәрәзәдән эчкә карадык? Бәхеткә каршы, бүлмә буш булып чыкты. Ачып керергә ачкыч кына юк. Манзума, ташбаш, аның да уйлаган икән. Кесәсеннән карга борыны белән отвертка чыгарды да йозакның чатын-чатка аерып ташлады.

— Хамматка ышанып торсаң, алырсың квартир,— дип тиргәнде ул, әллә акланырга, әллә мактанырга теләп.

Әле дә ул бар. Бу кадәр әрсезлек буламы соң миннән. Күршеләргә кереп кайнар суын, чиләген алып чыкты, басып эшләргә иске өстәл, урындык табып керде. Бар икән кеше дә, чистый ала бәбәк.

Манзуманың да, Фәнүсәнең дә буяу эшенә куллары ятып тора, ут уйнаталар. Мин исә суын ташып, тегесен-монысын биреп торам. Кичкә кадәр ялт иттердек бүлмәне, идәнен юып чыгардык. Тәрәзәсенә пәрдәчелтәрләр элдек, ишеген башка йозак белән бикләп алдык.

Шулай да пошынуым арттыгына. Күпме көч түгелде, инде әзергә бәзер башка кеше килеп керсә? Ордерың булмагач, берни эшләр хәл юк, калдырасың да китәсең. Аннан бүген күчеп килсәм, аш пешереп ашарлык савыт-сабам, ятып йокларлык урын-җирем юк. Хәер, алары гына зур мохтаҗлык түгел: кашык-аяк кибет тулы хәзер, матрасы,

мендәренә кадәр бар. Бәяләре дә шалкан бәясе. Эш берничә мендәрдә генә калса, аларын Мәчтүрә апа да арттырмый калмас. Инде ризалашып үзе киләм дисә, аңардагы урын-җир барыбызга да җитәрлек. Тик гомер иткәч, идәндә йоклап, тәрәзә төбендә ашап яшәмәссең бит, өстәле, караваты кирәк. Менә туздыр йорт-җирне. Рамазан белән яшәгәндә барын булдырган идек бит. Таратып, ярты бәясенә сатып бетердек. Башың эшләмәгәч ни. Менә бие инде хәзер.

Әнә шундый уйлар төнен генә түгел, икенче көнне эштә дә тынгы бирмәделәр. Кызлар үсеп килә. Кешедән күреп, кием шкафы, радиоалгыч, фәлән дә фәсмәтән диярләр. Алары белән генә дә канәгатьләнмичә, телевизор сорап йөдәтеп бетерерләр. Заманасы башка шул, сорасалар да берни әйтә алмыйсың. Ул кадәр акчаны кайдан алырга? Икенче разрядлы оператор ярдәмчесенә хезмәт хакын бик санап бирәләр. Кассада бераз акчам бар да бит. Аңарга гына әллә ни майтарып булмас. Фәнүсәгә, кызларга сүз катар идең, юклыкны сиздерәсе килми. Нинди генә хәлдә булсаң да, горурлык дигән нәрсә бар бит әле. Хаммат белән киңәшер идем, әллә ни уйлавы бар. Җитмәсә, бүген үзе дә, местком утырышы дип, конторда калды. Ялгызым булгангамы, башымда һаман шул квартир, һаман шул йорт кирәк-яраклары. Уйланам-уйланам да үземне юатып куям: әй, вакыты белән бар да булыр әле, исәнлегем — байлыгым. Иң әһәмиятлесе—рөхсәте, ордеры юк бит әле менә.

Әллә эштә андый-мондый мәшәкать чыкмаганга, әллә һаман бер үк уйлар белән кайнаганга, көн бик акрын узды бүген. Хәтта вахта автобусы да гадәттәгедән озак кайтты сыман.

Юл киемнәремне дә алыштырып тормастан, хуҗалык товарлары кибетенә киттем. Кашык, пычак, стакан ише, көченү белән кирәге чыгачак вак-төякне сумкага тутыргач, мебель кибетенә сугылдым, бер уңайдан дип, раскладушка алдым һәм баракка ашыктым.

Менә инде минем үз куышым бар. Дөрес, ул узган елдан калып кышлаган карга оясы кебек ялангач, шыксыз. Шулай да үземнеке. Тулай торактагы тавыш, ыгы-зыгы тәмам туйдыра башлаган иде инде. Тик менә Манзума сүзе белән оятка калмасам гына ярар иде.

Әйберләремне коридор идәненә куеп, ишекне ачтым һәм ашкынулы бер хис белән эчкә уздым. Ул да түгел, электр тогына эләккәндәй катып калдым. Мин үзалдыма хыялланып йөргән арада бүлмәне кемдер оятсызларча басып алган. Уң як стена буендагы ялтыравыклы тимер карават, өр-яңа кием шкафы, урталыктагы түгәрәк өстәл әнә шул турыда сөйлиләр иде. Килмешәк үзен шул кадәр иркен тоткан ки, өстәлгә өр-яңа ашъяулык җәеп, пыяла банкага ясалма чәчәкләр утырткан.

Кинәт бик күңелсез булып китте, тамак төбенә каты төен калкып, бугазны кыса, авырттыра башлады. Ачынып елап җибәрдем. Ләкин шунда ук үземне кулга алдым: юк, болай балавыз сыгып торырга ярамый, промыселга да, коммуналь-торак конторына да барырга, Хамматны да, кирәк икән мөдирне дә аякка бастырырга, бу оятсыз баскынчыны бүлмәдән куалап чыгарырга!

Культура йорты каршындагы мәйданда каршыма Хаммат белән Фәнүсә очрады. Ачу-үпкәләрем йөземә чыккан, күрәсең, Фәнүсә, кулындагы төенчеген җиргә куеп, миңа ташланды:

— Ни булды, Галибә?

Елап җибәрүдән курка-курка гына хәлне сөйләп бирдем. Икесе берьюлы шаркылдап көлергә керештеләр.

— Хәзер, хәзер куалап чыгарабыз ул баскынчыны, — дип, мәйдан ярды Хаммат, көлүеннән тыела алмыйча. Тынычлана төшеп аларга ияздем. Хаммат, берни булмагандай, скважиналар турында сорашып бара. Әй, кеше кайгысы кешегә ни!

Бая ишекне бикләргә дә онытканмын икән. Хаммат хуҗаларча нык басып эчкә узды, кулындагы әйберләрен куеп, төенчекләрнең берсен чишеп җибәрде һәм өстәлгә бертөсле бизәкләре белән игезәкләрне хәтерләткән тәлинкә, чынаяклар тезә башлады.

— Хәзер кергән бирәбез ул имансызның!

Мин инде бернинди баскынчы булмавына инанып, тәмам тынычланып калдым. Шулай да хезмәттәш иптәшләремнең кыланышларына төшенеп бетә алмый торам. Ул арада Хаммат үзе күтәреп килгән зур сумкадан бер бөтен ипи чыгарып өстәл уртасына куйды.

— Яңа йортта аш-су мулдан булсын, хуҗалары ипи кытлыгы күрмәсен, — диде ул, ничектер тантаналы итеп. Аннан аның янәшәсенә консервлар, конфет-хәлвә ише татлы нәрсәләр тезде, колбасасын, сырларын өйде. Иң соңыннан гына ак пәрәнҗә ябынган ике шешә китереп бастырды да караватт астыннан өч аяклы утыргычлар тартып алды.— Ягез, утырыгыз!

Шуны гына көткәндәй, бүлмәгә Манзума килеп керде.

— Күр әле боларны, миннән башка гүләйгә итмәкчеләр,— диде ул, култыгына кыстырган электр чәйнеген миңа биреп. — Яңа квартир котлы булсын.

— Бүтән чакырасы кешең юкмы, Галибә? — диде Фәнүсә тәрәзә пәрдәләре рәтләп йөргән җиреннән.

Каушавым чигенә житте.

— Мин ни... — дип, мескен тавыш белән авыз эчемдә ботка пешердем. Аннан шактый батыраеп әйтеп салдым: — Туктагыз әле нәрсә була соң бу? Сүземне Хаммат тавышы күмеп китте:

— Өй туе бу, Галибә. Менә ордер! Болары сиңа самостоятельный тормыш башлап җибәрү өчен.

— Соң... соң...

— Соңы да, иртәсе дә юк, — дип тезеп китте Фәнүсә. — Беразын местком бирде, калганы Хаммат байныкы... Курыкма, бер син генә бурычлы түгел аңа. Менә өстемдәге пальтомның да бәясе түләмәгән әле. Акрынлап, үз җаебыз белән бирербез әле, иеме, Хаммат?!

— Бурычлы үлми, чирле үлә, — дип куйды Хаммат.

Ул сүзен әйтеп бетермәде, шешәнең бөкесе каты шартлап түбәгә очты, рикошет ясап идәнгә төште һәм сикерә-сикерә шкаф астына кереп югалды. Хаммат исә чынаякларга вак куыклары биешеп торган шәраб сала башлады.

— Ягез, Галибәнең балалары белән җыелып, шатлык белән имин яшәве өчен, — диде ул, чынаягын күтәреп.

Бу минутта мин үземә таба сузылган шәрабны да, кунакларымның битләрен дә күрмим, күземне яшь пәрдәсе каплаган иде. Тик иреннәрем генә: «Рәхмәт инде, рәхмәт, дусларым», дип пышылдадылар.

## 13

Тулай торакта, кызлар арасында чыркылдашып яшәгәндә, алай ук ямансу булмаган икән әле. Ялгызым бер бүлмәдә утырып калгач, бөтенләй кыен булып китте. Урыным җылы, йомшак, өстәлем тулы ризык, шулай да нидер җитми, йөрәк сулкылдый, күңел каядыр ыргый. Бигрәк яман нәрсә икән бу ялгызлык! Башка әллә ниткән шыксыз уйлар калка: дөньяда син берәүгә дә кирәкмисең кебек, әйтерсең лә бөтен кеше тарафыннан онытылган, ташланган бер җан иясе. Менә ни өчен промысел тарта икән күңелне. Анда хезмәттәшләр бар. Һәр мизгелдә үзеңнең кирәклегеңне, ил муллыгы өчен эш башкарганыңны сизеп торасың. Гаҗәп, вахтада берүзең чакта да ялгызлык тоймыйсың анда.

Ә монда күңел буш, ялангач. Җитмәсә, күршеләр дә авылдагы кебек аралашып яшәмиләр.

Күпләр, кешенең бәхете хезмәттә, диләр. Бәхәсләшмим, хак сүздер ул. Ләкин Робинзон да утрауда үткәргән еллары буе эшләгән, тырышкан бит. Әмма бәхет килмәгән аңа. Әйе, кеше бәхете кешеләр арасында, алар белән бергә җиң сызганып эшләүдә икән. Янәшәңдә якының, үз дигәнең, җилкәсенә башың салып сыенырлыгы да булса һәм ул сине чын йөрәктән ихтирам итсә, мондый бәхет — иң олы бәхет!

Мин инде үзем бәхетле дип санаган әнә шул тормышка бер адым ясадым. Кешелекле, ярдәмчел иптәшләр арасында күңелемә ошаган эш таптым. Вахтадан соң аралашырга Манзума, башка иптәшләр бар. Кызларым белән Мәчтүрә апаны да алып килсәм, дөньям түгәрәкләнә яза. Дөрес, аның бер почмагы китек калачак. Бәлки гомеремнең ахырына кадәр шулай китек калыр ул. Эчеңдәге иң яшерен серләреңне сөйләрлек, авыр чакта иңенә таянырлык кеше инде табылмас. Янәшәңдә үзең сөйгән һәм сине өзелеп яраткан кеше барын тоеп яшәү хисе Рамазан белән бергә кабергә керде бугай. Анысы инде татлы сагыш, якты хатирә булып кына калыр.

Хәерле булсын. Китек җире китек килеш калыр, кулдан килгәнен түгәрәкли торыйк. Конторга барып, Арсеньевтан сорарга да авылга китәргә кирәк... Һай, ахмак та инде мин, буш буем белән ни кырырмын мин анда. Төенли башлагач, кием-салымы да, башкасы да байтак җыелыр әле. Юлаучы машинага ышанып, төен-чемоданнар күтәреп, балалар ияртеп, юлга чыгып буламы соң? Вахта автобусын сорап карыйсы иде. Көндезге сменаны илтеп кайткач, барыбер кичкә кадәр тик тора ич. Арсеньев кына булдыра алмый икән, хуҗага керергә, тотып ашамас әле.

Җылы, йомшак автобуста кайтып, кызларым белән очрашу, җыйнаулашып шәһәргә күчеп килү уеннан ләззәтләнеп, йокымсырап ук киткәнмен. Кинәт кенә өстемә салкын су койгандай булды, йокым качты. Менә тиле димә син мине! Мәчтүрә апа килмим дисә? Ул кызлар белән нишләп бетәм соң мин? Талиясенә быел җиде тулды. Анысы аңлар, ялгызы гына өйдә дә калыр, шәт. Ике яшьлек Гөлиясен нишләтермен? Шәһәрдә карчык-корчык табуы да кыен. Өсләреннән бикләп китсәм, көнозын нишләп бетәрләр? Бүлмә җылы җылысын. Тик аңа карап кына ана йөрәге тынычлана аламы? Хаммат турысын әйтте: «Яслегә тиз генә өметләнмә, Галибә», — диде. Чиратта миннән кала да илле-алтмыш кеше бар икән. Яңа гына квартир алгач, кат-кат йөдәтеп йөрүе дә уңайсыз. Оятсыз икән бу хатын диярләр. Ни булса шул, алып килим әле башта. Җан биргәнгә юнен бирер, бербер әмәле табылмый калмас.

Иртән чәй генә эчеп алдым да, эш киемнәремне киеп, конторга киттем. Диспетчер бүлмәсенә кереп Арсеньевны көтәргә булдым. Әнә мастерлар күренгәли дә башладылар. Алар дөп-дөп басып керәләр дә диспетчер Кадыйр абзый янына үтәләр.

Арсеньев нишләптер соңгарыбрак килде. Тавышсыз гына, диспетчер янына үтте дә журналга карап уйга калды. Башкалар сыман сабырсызланмый, тыпырчынмый. Димәк, безнең эшләр әйбәт, дип уйлап алдым мин һәм мастер бу якка чыгуга сүз катарга булдым. Ничегрәк башлыйм икән? Әмма бу хакта баш ватарга туры килмәде, Арсеньев үзе мине күреп алды.

— Ә син нишләп монда, Галибә, вахтага соңгардың бит?!

Йомышымны сөйләп бирдем.

— Ачуланма, Галибә, бүген җибәрә алмыйм, иртәгә, — диде ул, тыныч кына. — «Барометр» әнә сиксән тонна минус күрсәтә. Теге суланган скважиналарның арматуралары туңган булырга охшаган. Эш

күп бүген. Хәзер күчмә парлау агрегаты сорыйм, шуңа утырып китәрсең.

Мондый кешегә ничек карышасың инде. Әнә бит кырылмый, жикерәнми. Карады, уйланды, сәбәбен дә белеп алды. Скважиналар тик торганда кем җибәргән инде сине. Баштагы сыман җил куып йөрүләр бетте инде, Галибә.

Авылга бүген кайтмау, бер уйлаганда, әйбәт тә булды әле. Кичен Манзуманы күреп аның белән киңәшергә була. Теге чакны заводның балалар комбинаты бар дип сөйләнгән иде. Гөлияне шунда урнаштырып булыр, шәт. Ә нигә кичне көтәргә? Бүген беренче сменада бугай бит Манзума.

Шәһәргә керүгә, автобусны туктатып төшеп калдым һәм бер читтәге бушлыкта утыручы заводка таба киттем. Чыннан да, көндезен эшләгән Манзума, сменасын тапшырып, душта коенып маташа иде. Аңа мин килгәнне җиткерделәр, ахры, киенү-чишенү бүлмәсенә анадан тума шәрә килеп чыкты.

— Ә, Галибә. Чишен, давай, — диде ул, юеш битен елмаю белән балкытып, — бер күнлек гөнаһларны юып төшерик.

— Һәй, анын кайгысымы соң миндә!

— Синдә инде гел дөнья кайгысы. — Манзума ачуланды шикелле, йөзе караңгыланып киткәндәй булды.— Чишен, әйдә. Сезнең промыселда мондый җәннәт юк бит.

Анысы хак. Әллә соң коенып чыгаргамы? Манзума икеләнеп торырга калдырмады, мазутлы сырмамны салдырып атты.

Кысан душта икәүдән-икәү коену минем өчен уңайрак та булып чыкты әле. Сүз уңаеннан гына йомышымны сөйләп бирдем.

— Безнең деткомбинат бар да бит, — диде Манзума, йөнтәс сөлгегә сөртенә-сөртенә,— тулыдыр инде ул. Бала-чага булмагач ни, кызыксынганым да юк. По блату әллә кайдагы чурт балаларын урнаштыралар дип, хатыннар зарланып йөриләр шунда.

Үзем киенәм, үзем һаман шул хакта уйланам. Манзума да шатландырырлык сүз әйтмәде. Аңа ни, үз баласы булмагач. Нишләргә соң? Бөтен өмет Мәчтүрә апада.

Күңелсезләнүемне Манзума дә сизеп алды, ахры, душтан чыгуга беләгемнән тотып:

— Туктале, Галибә, кереп чыгыйк әле вчужтеки бабай янына, — диде.

Тупыллар арасына посып утырган беркатлы бинага таба атладык. ул да түгел, иркен генә коридорга килеп кердек.

— Син шунда гына тор, — диде Манзума һәм ишегенә «Завком» дип язылган бүлмәгә шакымый-нитми кереп китте. Әллә берәр нәрсә кысылды, әллә күгәненең рәте юк иде, ишек сызык кына ачык калды. Кызыксынуым шул кадәр көчле иде ки, бусага төбенә килеп, колак салдым. Тик якын ук торып тыңлауның кирәге юк икән. Әллә бүлмәсе бик кечкенә, әллә хуҗасы көр тавышлы, сөйләшкәннәре коридорга ук ишетелеп тора.

— Һо-о-о, безнең ударник! Күптән кагылганың юк иде, уз әйдә, уз, — диде картларча карлыкканрак, шулай да көр тавыш, — нинди җилләр китерде, Маруся Кадыровна? Ял йортына путевка кирәктер, мөгаен.

Манзума ни диптер җавап кайтарды. Икәүләшеп рәхәтләнеп көлешеп алдылар. Аннан киттеләр җыен килде-киттене сөйләшеп, тыңлыйсы килми башлады. Бик тә сүз куертырга ярата торган бабай булып чыкты бу завком дигәннәре: һаман лыгырдыйлар, һаман көлешәләр. Әй, кеше хәле кешегә ни! Чү! Тынып калдылар, әллә чыгалар инде. Юк, бабай дигәне телефон трубкасын күтәрде, ахры, «Әйе, тыңлыйм» дигәне ишетелеп китте. Телефонда да бик озак гәпләште бу карт. Әллә

соң кайтып китим микән? Менә «шылт» иттереп трубканы куйды, ул да түгел, Манзума сүз башлады:

— Мин, Әндри Фиафунович, бик зур гозер белән кердем бит әле, — диде ул җитди итеп, — деткомбинаттан бер урын кирәк иде.

— Менә сиңа мә! — дип шаркылдап көлеп җибәрде тегесе. — Каян килгән әле ул бала? Әллә төнлә тулай торакка ләкләк ташлап киттеме? Ну, бу хәзерге ләкләкләрне! Ирсез хатын дип тормыйлар, бала калдыралар да китәләр.

— Көлке түгел, Әндри Фиафунович, — дип дәвам итте Манзума, — асрауга кыз алдым. Урын бирмәсәң, иртәгәдән эшкә чыга алмыйм. Үзең утыр кранга.

— Туктале, шаяртма, Маруся Кадыровна.

— Шаяртмыйм, чын.

— Һе, каяле, кәгазең-мазарың бармы?

— Документлаштырылмаган әле, — дип кызды Манзума, — ышанмасагыз, иртәгә кызны күтәрәм дә киләм.

Тынып калдылар. Шыгырдап өстәл тартмасы ачылды, ниндидер кәгазьләр кыштырдады. Аннан кабат карлыккан аваз яңгырады:

— Мәле, алма ашап кара, — диде бабай. — Тот, тот, үз бакчамнан. Алай... Ышануын ышанмыйм, Маруся Кадыровна, ну, бер урын чамалап карармын. Иртәгә кичке буйда сугыл.

Артыгын тыңлап тора алмадым. Шатлыгымнан йөрәгем ярылырга җитте, коридордан чыгып киттем. Шулай да күңел ышанмый, шикләнә. Шулай ансат кына булыр дисең әллә?

Манзума чыгып шик-шөбһәләремне басты:

— Курыкма. Әйтсә эшли торган карт, — диде ул, мине култыклап. Сөйләшә-сөйләшә автобус тукталышына таба атладык.

Юкка шикләнмәгәнмен икән. Мәчтүрә апа шәһәргә күчүдән баш тартты. Нигеземне ташламыйм дигән була. Җитмәсә, председатель Якуп бүрәнәләр китерткән икән, кояш карый башлауга, өеңне сипләтеп куям, дип әйтә ди. Апа минем бөтенләй китүгә дә һаман каршы, чит-ят җирдә ничек яшәрсең дип, балавыз сыгып алды. Шулай да юлга үзе җыйды: мендәр-ястыкларыннан да өлеш чыгарды, анда кирәгер дип, ябынмый саклаган юрганын төрде, көзен суйган каз мамыкларын күтәреп керде. Сават-сабалар да төйи башлаган иде дә, үзем туктаттым.

Җыена торгач, төенчекләр байтак булды. Алар янына ике капчык бәрәңге, берничә бәйләм суган, бер кисәк ит тә куйгач, автобус тулды диярлек. Ә кызлар әллә кайчан менеп утырганнар, әниләре янына китәсе булгач, очынып йөриләр.

Менә төяләсе әйбер төялде, ыргытыласы иске-москы ыргытылды. Мәчтүрә апаның болай да мескен өе ялангачланып, боегып киткәндәй булды. Апа үзе дә ничектер бөрешеп, юашланып калган кебек. Урын-җире алынган караватка утырды да өнсез тора. Мин чыгып китәргә дә, утырырга да базмыйм. Тизрәк кузгаласы иде, автобусның кичке вахтага өлгерәсе бар бит. Шуны искә төшерергә теләгәндәй, шофер сигнал биреп алды. Мәчтүрә апа сискәнеп китте һәм кулларын ияге турына күтәрде.

— Ягез, бер дога, — диде ул һәм авыз эченнән генә укый башлады. Тик догасын бетермәде, битен кулларына каплап елап җибәрде.

— Ничек яшәрмен тагы ялгыз...

Үзем аны юаткан булам, үземнең күзләремә яшь тыгыла. Еламаска тырышкан булам, ләкин буылам.

— Соң китик бергә, Мәчтүрә апа?!

— Юк инде. Шушы Гөлбакча туфрагында гүр иясе булырга язсын, — диде ул, яулык очы белән күзләрен сөртә-сөртә. — Инде бик кыенга килсә, чирләп-нитеп егылсам, хәбәр итәрмен...

— Без кайткалап йөрербез, Мәчтүрә апа, — дидем мин һәм урыннан кузгалдым.

Ул безне капка төбендә күз яшьләре агыза-агыза озатып калды.

## 14

Бу гомерне һич кенә дә үтмәс дип йөрмә икән. Минем Яшел Түбәгә килгәнгә дә дүртенче ай. Шул арада никадәр яңалыклар булып өлгерде: квартир алдым, кызларымны төяп килдем, берсе мәктәпкә әзерлек группасына, икенчесе яслегә урнашты. Һаман да шул Хамматлар, Манзумалар изгелеге инде, промысел җитәкчеләренең яхшылыгы. Шулай итеп, бер оя булып яшәп ятабыз. Мәчтүрә апа гына... Өем өстемә ишелеп төшәр, дип кайгырмый шул хәзер, колхоз, ай-һай, әйбәтләп сиплэп биргән бит, түбәсе дә шифердан... Үзем ике ай буе вахтадан буш арада укып, махсус курс бетердем — «өченче разрядлы оператор» дигән белешмәм дә бар. Шулай матур гына эшләсәң, берәр елдан менә дигән нефтьче булырсың дип торалар.

Әмма Гөлбакчаны юксыну сагышы һаман кимеми әле. Шулай булмыйни, барыбер туган авылым кебек ич ул миңа. Ул сагыш шулай гомергә бетмәс, акрын гына сызар инде. Бетмәсә бетмәс, тормышымның бер җайга салынып, түгәрәкләнеп баруы үзе зур куаныч әле. Дөнья көннән-көн яктыра, матурлана сыман. Тик бер көнне генә күгем болытлап, ямьсезләнеп куйгандай булды.

Манзума туеннан соңмы, Фәнүсәнекеннән соңмы булды ул хәл. Кайсыныкы икәнен хәтерләмим дә инде, икесе бер атна эчендә кияүгә чыктылар бит. Кичен эштән кайтсам, бүлмәдә кызларым белән Өлфәт утыра. Бер олау күчтәнәчләр төяп килгән. Мин кайтканчы дип, Талия белән икәүләп, ясләдән Гөлияне дә алып кайтканнар.

Өлфәт шактый бирешкән, сулыгып-ябыгып киткән. Шулай да элеккечә чибәр, күркәм. Өсте-башы да әйбәт кенә: кара йон костюм эченнән зәңгәр свитр киеп алган, аягында затлы ботинкалар. Күптән түгел генә Яшел Түбәгә килеп, тагы бораулаучы ярдәмчесе булып кергән икән.

Чакырсаң да, чакырмасаң да, кунак кунак инде. Тиз генә бәрәңге әрчедем, колбаса кистем. Аларын кыздырып алдым, чәй кайнаттым, маен, шикәрен өстәлгә куйдым. Түгәрәкләнеп табынга утырсак та, сүз ябышмады безнең. Балалар да шунда булгач, Өлфәткә дә җәелеп китәр җай юк. Тик утырабыз шунда юк-барны сөйләшеп.

Менә кызларны йокы басты, урыннарына тәгәрәштеләр. Өлфәт кенә китәргә ашыкмый, һаман эшем, тормышым турында сораша. Сәгать әнә унберне дә сукты.

— Ярый, Өлфәт, иртәгә бәйрәм түгел, — дидем мин, өстәл янынная кузгалып,— синең дә кайтасы җиреңә атлыйсың бар.

Ул тирән итеп көрсенде, ләкин урыныннан кузгалмады, арада берни булмагандай тыныч кына әйтеп куйды:

— Мин инде китмәскә дип килгән идем, Галибә. Ни әйтсәң дә...

— Юк, Өлфәт, үзеңне дә, мине дә алдама. Мәхәббәт юк ич безнең арада. Димәк, бергә яшәү дә юк. Үзең яраткан теге кешеңне бәхетле ит.

Ул тагын көрсенде.

— Кияүгә чыккан шул.

— Аптыраганнан килдең, алайса?

— Алай димә, Галибә, кызларыбыз, балалар бар бит. Ятим үсмәсеннәр.

— Әниләре исән чагында ятим булмаслар, Өлфәт.

Мин аны чыкмый йөдәтер, карулашыр дип көткән идем. Ләкин Өлфәт әрсезләнеп маташмады. Шулай ук тирән көрсенеп урыныннан кузгалды да пальтосына үрелде.

— Шулай да кергәләп йөрергә ярыйдыр бит, Галибә?

— Юк, Өлфәт, үзем турында начар сүзләр йөрүен теләмим мин. Гөлияне күрәсең килә икән, әнә яслесен беләсең.

Ул башкача сүз катмады, акрын гына борылып, башын салып чыгып китте. Шуннан бирле күренгәне юк.

Гомер үтә тора, ә Зәйдә су ага да ага. Бүген әнә ярларына сыешмыйча ташып чыкты. Язгы ташу кузгалды!

Соңгы атналарда, көннәр җылытып җибәргәч, безнең мәшәкатьләр кими төшкән иде әле. Суланган скважиналарның арматуралары, нефть үткәргечләр туңып йөдәтми, аларны парлап азапланасы түгел. Күз ачкысыз буранлы көннәр, салкыны тынга каплана торган төннәр артта калды. Рәхәтләнеп эшләргә дә бит, менә бу кар сулары тагын бәлагә салды башны.

Хикмәт шунда: Зәй буендагы скважинабыз су эчендә калды. Дөрес, болыннарда карлар йомшап, сукмаклар бата башлаганчы, бик җентекләп карадык без аларны. Шулай да гөрләтеп сыек ягулык биреп торган скважиналарга атна буе күз-колак булмый ничек түзәсең. Ярый әле, Хамматның тәҗрибәсе, тик тормый торган кылбырдык гадәте бар, югыйсә, нишләр идең. Язгы ташкын чорына дип, әрәмәлектә көймә тота икән ул. Хәер, ул ялгашка көймә дисәң хәтере калыр. Алай да гамәленә ярый икән. Әле бүген дә шуңа утырып әрәмәлеккә кереп китте Хаммат. Мине алмады, «Сине батырсам, кызларыңа ни җавап бирермен», дип шаярткан була. Аның эшен бетереп чыгуын көтеп утырам. Сикерепсикереп аккан кар суына карап уйга талганмын икән.

Нишләптер бүген озак маташты. Киткәненә ике сәгатьләп бар, күренми дә күренми. Әллә көймәсе белән капланды инде. Алай дисәң дә аптыраш, болында су ул кадәр үк тирән түгел лә, ярып булса да чыгар иде. Шулай да күңелдә хафа, әллә кызганам инде шул Хамматны?

Су эчендә утыртма читән булып торган зирекләр артында нидер чупылдады, ул да түгел, әлеге тагарагына баскан Хаммат күренде. Ул, кулындагы колгасын төпкә терәп этә-этә, мин утырган кашлакка якынлашып килә иде.

Нидер булганын ерактан ук сизеп алдым. Өстендәге брезентовкасы кабык булып каткан, үтәли җебүдән каралып тора, битеннән, чәчләреннән әллә су, әллә тир тама. Сул кулы канга баткан иде.

— Ни булды, Хаммат? — дип каршыладым мин аны, су читенә үк килеп. — Каплабндыңмы әллә?

Ул дәшмәде. Колгасына таянып җиргә сикерде дә көймәне ярга сөйрәп чыгарды. Аннан соң гына:

— Шактый азапланырга туры килде, — дип куйды.

Мин, аңа аркан борылып, чалбарым эченнән күлмәк итәген тартып чыгардым һәм аны ярып җибәрдем.

— Кая, кил әле, Хаммат.

Аның ишкәк кадәр кулы күшегеп кызарган, беләзегенә хәтле тирән җәрәхәт сузылган иде. Бирегә йод-мазар юк, ә канны туктатырга кирәк. Ярага чиста кулъяулыгымны ябып, кулны күлмәк итәгенә урый башладым. Куәтле, эшчән кул күзгә күренеп калтырый иде.

— Хам-мат, бөтенләй туңгансың ич, бала. Әйдә, тизрәк культбудкага!..

Сабый балаларча җитәкләшеп культбудкага йөгердек. Аяклардагы авыр күн итекләр җебеп, парланып торган балчыкка баталар. Чирәмлерәк җирләрне сайлыйбыз. Тик анда да ансат түгел: кипшенергә өлгермәгән туфракта аяк таеп-таеп китә, су тулып, ыргып аккан ерганаклар Үолга киртә булып сузыла. Тирләп төштем, Хаммат та шактый җылынды бугай, кызарып чыкты. Шулай да тукталырга ярамый иде.

Культбудка ишеге киерелеп ачылган көе калган. Аны ябып электр мичен кабызып җибәрдем һәм кабаланып Хамматның өстендәге киемнәрен салдыра башладым. Ул инде эчке күлмәк-ыштаннан гына калды.

— Сал, боларын да сал, юешләр ич, — дип кычкырдым мин аңа, бала-чаганы өйрәткәндәй.

Ул кызарып миңа карады. Шунда гына мин аның чит ир булуын уйлап алдым һәм ашыгып эчке бүлмәгә уздым.

Мин чыкканда Хаммат инде шкафта булган коры киемнәргә төренгән иде. Аны мич кырыенарак утырттым, аптечкадан йод, бүз ише әйберләр чыгардым. Аларны өстәлгә куеп телефонга ябыштым, диспетчерга хәлне сөйләп бирдем. Аннан үзем белгәнчә, әйбәтләп, Хамматның кулын бәйләргә керештем. Сызлануын басарга, игътибарын читкә тартырга тырышып, ни булганын сорашам.

Скважиналарның берсе янында болганчык ташу суына бөркеп-бөркеп нефть бәреп ята икән. Болай күп тә түгел ди үзе, ташу суы кайтканчы гына берәү дә белмәс иде. Тик мондый хәлгә Хаммат йөрәге түзәме соң? Ул көймәсеннән төшеп, муеныннан су эчендә кармаланып, җир мае саркып торган фланцны тапкан һәм аның болтларын кысарга тотынган. Шул чак ниндидер тимергә эләктереп кул аркасын ярып җибәргән икән. Шулай да эшен бетерми судан чыкмаган.

Җәрәхәтен бәйләп бетердем дә, бүздән элмәк ясап, кулын муенына астым. Кул аркасында ямьсез булып гомерлек җөй каласын кем белгән ул вакытта.

— Кулың шифалыдыр синең, Галибә, — диде ул басынкы гына, — авыртуы басылып китте. Шулай иркәләнеп гомерем буе янында утырыр идем.

Шул чак ишек төбендә генә «ашыгыч ярдәм» машинасы чинап җибәрде.

## 15

Яз көне Хамматның салкын тидерүе минем язмышка да тәэсир кертте. Аны больницага салдылар, башка операторлар да кайсы кая җәйге ялга җыена башладылар. Мастер Арсеньевта гына ял кайгысы түгел, ул бер төбәктән икенчесенә чаба, еш кына үзе үк оператор булып скважиналар янында эшләп кала иде. Хаммат янына больницага барып, әллә Иркәбайны кабат үз эшенә куйыйк микән дип киңәшеп тә караган. Тик местком членыбыз каты бәгырьле икән: «Көрәк начальнигы булып йөрсен әле бераз», дип әйтә икән. Тагыниләр сөйләшкәннәрдер, анысын мастер миңа әйтеп тормады, тик икенче көнне:

— Әллә соң, Галибә, тәвәккәлисеңме?! — диде.

Бу аның миңа өлкән оператор камыты кидерергә маташуы иде. Вакытлыча, Хаммат терелеп чыкканчы гына, билгеле. Шулай да җөрьәт итмәдем.

Шул көннәрдә генә безнең бригаданың ике операторы бөтенләйгә дип Төмәнгә китеп бардылар.

— Суйдылар, пычаксыз суйдылар! — дип сыкранды Арсеньев. — Теләсәң нишлә, Галибә, бүгеннән скважиналар синеке!

Нишлисең, җиң сызганып эшкә тотынырга туры килде. Ярый әле, бәла-каза килеп чыкканы юк, нефть чыгару бер җай белән бара да бара. Уку комбинатында укыганнар, Хаммат өйрәткәннәр эзсез калмаган, күрәсең, һәрнәрсәнең җаена төшенеп торам. Шулай да туйдырды ялгыз яшәве, ни әйтсәң дә, Хамматның киң җилкәсе артында ышыграк иде. Тик аның тиз генә әйләнеп кайту чамасы күренми шул әле. Больницадан чыгуга, Кавказга китеп барды, бүген атна була бугай.

Тукта, нәрсә дип аны бик еш искә төшерәм соң әле мин? Әллә юксынам инде шул беркатлыны? Алай булса да гаҗәп түгел. Ул кемнән ким? Хәзер инде аны элеккеге Мөхәммәт димәссең. Йөзе чистарып, шомарып киткән. Сирәк тишелеп чыккан иген уҗымын хәтерләткән ярым шәрә кашлары шактый куерган — күзләре өстендә бик төзек ярым алка төсле

күренәләр. Шуңамы, күзләре дә элеккегечә чагыр түгел сыман, авызы шактый җыелып, урынына утырган кебек. Җыелды, нык җыйнакланды Мөхәммәт. Аны инде «вәкил җене» димәссең. Хәзер аның турындагы ярым чын, ярым уйдырма хикәят-мәзәкләрнең дә күбесе онытылып беткән. Тик кайберләрен һаман искә төшереп, көлешеп алалар гөлбакчалылар.

Безнең Гөлбакчада «мәңгелек директор» дигән бер кеше яши. Минем яшьтәшләр аңына «мәктәп» дигән төшенчә белән бергә килеп кергән кеше ул. Бала килеш кенә фронтка киткән абый-апалар да аны һәрчак «директор абый» дип телгә алалар иде. Аннан соң күпме сулар акты, ил өстеннән зилзилә үтте, сугыштан соң гына да утыз ел гомер узды, ә ул һаман мәктәпкә җитәкчелек итә. Өстеннән галифе чалбары белән хәрби кителен беркайчан да салмый торган, зур авызлы, чандыр кеше ул безнең Гарәфи абый. Авылның яше-карты ярата үзен. Сөйләргә дисәң, бөтен кешене авызына карата, уку-укыту җене кагылган бер абый инде.

Әнә шул Гарәфи абый янына Хафиз абый килеп керә бер көнне. «Мәңгелек директор» аны колачын җәеп каршылый: «Әйдүк кенә, Хафиз абый». Шулай булмыйни, гомергә мәктәпкә аяк басмаган кеше бит. Бик тәфсилләп исәнлек-саулык сорашкач, төп йомышына күчә Хафиз абзый:

— Укытасы иде бит малайны, Гарәфи энем, укытасы иде.

— Мин дә шулай уйлыйм, — ди директор, тагы да ачыла төшеп, — өч ел бер класста таптана бит Мөхәммәт. Әйдә киңәшик соң, ничек күңелен утыртыйк укуга...

— Аңардан... Мөхәммәттән инде әллә кем чыкмас чыгуын,— дип, аның сүзен бүлә Хафиз.— Шулай да укытасы иде, укытучы итеп булса да чыгарасы иде бит малайны...

Өстәлгә килеп төшкән йодрык тавышыннан тотлыгып кала Хафиз абзый. Караса, директорның күзе маңгаена менгән, үзе кызарып-бүртенгән, сүзен әйтә алмый тора.

— Во-о-он! Вон моннан! — дип кычкырып җибәрә ул бераздан.

Шуннан күп тә үтми, Мөхәммәт укуын бөтенләй ташлый.

Әле хәзер дә мәҗлесләрдә көйсез-моңсыз килеш җыр сузып утыручыларга: «Син, фәлән, җырыңны сөйләп кенә бир инде», диләр бездә. Монысы да шул гөнаһсыз Мөхәммәткә бәйләнгән канатлы сүз. Хәтерем ялгышмаса, хикәяте менә болайрак.

Уракка авылның яше-карты купкан илаһи иртәләрнең берсендә була бу хәл. Кояш әле Гөлбакчаның бихисап тауларына чалма булып уралган томан аша карарга да өлгермәгән, ә көлтә ташучыларның безнең якларда «шайтан арбасы» дип аталган чатыр олаулары бер-беренә тагылып диярлек Олы басуга юл алган. Аларга әйтерсең бөтен авыл төялгән: җитен сакаллар яшь киленнәрнең чуар яулыклары белән аралашкан, йөзләрен сагыш баскан сабыр аналар янына йокылары туймаган ялан аяклы малайлар елышкан. Авылны чыгуга Рамазан җыр башлап җибәрә:

Агып китте, тоталмадым,
Яулыгым кар суына шул,
Яулыгым кар суына.

Җырласа җырлый инде Рамазан. Аның ниндидер сихри бер моны йөрәкне телеп-телеп ала иде. Үзең дә сизмәстән аңа ияреп, көйли-моңлана башлыйсың. Бу юлы да шулай була, җырны барлык уракчылар күтәреп ала:

Кар сулары тотып торам
Йөрәгем ярсуына шул,
Йөрәгем ярсуына.

Гомуми җилкенү Мөхәммәткә дә тәэсир итми калмый, чатыр арба почмагына атланып чайрап барган хәлдә, ул да җырчыларга кушыла — иртәнге томан шикелле талгын гына аккан җырда үгез тавышы ишетелеп киткәндәй була. Көйсез мөңгерәп әлеге матур аһәнне бозуын абайлап та өлгерми, киленчәкләрдән кемдер: «Син, Мөхәммәт, җырны сөйләп кенә бир инде лутчы», дип куя.

Уйлый башласаң, искитәрлек инде: кайчандыр «укытучы булып кына да чыга алмаган» Мөхәммәт техникум тәмамларга дип йөри, мине дә шунда кирәргә йөдәтә. Быел көзен керү имтиханнары тапшырып карарга батырчылыгым җитәрме, юкмы? Әй, гомерләр! Кайчандыр «балта — тапур, нужык — пычак, ипие инде хлип кенә» дип, русча «сөйләп» бөтен урам малаен шаккатырган Мөхәммәт бүген үзе русчаны су урынына эчә. Кайтса-китсә кулында гел китаплар.

Тукта, нәрсә дип шул Хаммат белән төшләнеп утырам соң әле? Эштән туенып киттемме, әллә ялгызлык бастымы күңелне? Эш дип, бил сындырырлык нәрсә юк ла, кыргычны да кул белән төшереп күтәрмим хәзер. Җәй башыннан скважиналарның барына да автоматлар куеп бетерделәр. Ялгызлык дисәң, анысын да татыган юк диярлек. Эштә килепкитүче өзелми, кайтсам — кызларым уртасында. Алайса, нишләп юксынам соң Хамматны? Әллә сагынам инде үзен... Ә нигә, сагынсам ни гаебе бар? Сагыну түгел, яратсаң да берние юк. Ул кемнән ким? Менә дигән кеше! Аның кебекләр күбрәк булсын иде әле дөньяда...

*Лениногорск, 1972—1974 еллар.*

● ● ● ●

## Клара Булатова

### Кышкы җыр

...Юл үтә яп-якты кырлардан,
Кайларга сузыла бу юллар?
Ашкынып соңлаган юлчыдай,
Каядыр атыла йолдызлар.

Атылган йолдызлар югала,
Билгесез киңлеккә чакырып.
Ә безнең маяклы юлларда —
Яңа ел китергән яктылык.

### Әнисә

Кырда аккан көләч гөрләвекләр
Тугайларга язгы ямь бирсә,
Карашыңнан кырны ямьләндереп
Син йөрисең кебек, Әнисә.

Күзкәйләрең күктәй зәңгәр синең,
Биткәйләрең бераз сипкелле,
Сипкелләрең шушы март аенда
Тууыңа билге шикелле.

Йөзләреңне куеп таң җиленә,
Зур чаннарга карап торасың.
Бу чаннарда — әлмәтлеләр нефте!
Тамчысы да әрәм булмасын.

Быел язда алар алган уңыш
Илгә-көнгә шатлык, ямь бирсә,
Бу шатлыкта синең өлеш тә бар,
Оператор дустым Әнисә.

## Мегада[1] учак янында

Мегада учак янында
Сөйләнде күпме шигырь.
Ят кеше итеп тормады,
Үз итте безне бу җир.

Елганың таллы ярында
Төн инде җиргә иңде.
Балыкчы агай табынга
Чакырып алды безне.

— Килә дә китә тиз генә,
Ашыга сезнең халык.
Үтешли генә кагылып,
Ни генә булсын табып?!

Ил уртак, дөрес, җир уртак,
Шулай да ара ерак.
Тормыш ул анда тегеләй,
Ә монда болаерак.

Беләсең килсә бу ярда
Ярмәк тә учак яккан.
Халыкны безнең якларга
Иң элек балык тарткан.

— Элгәре шулай, ә хәзер?
— Хәзерме нәрсә тарта?
Күп еллар элек бу ярга
Салынган иске Варта.

Ул чакта, әйтик дөресен,
Ихтыяр, теләк белән
Себергә, брат, кем килсен —
Килгәннәр этап белән...

Шушында туып, шушында
Тормышын корган буын,
Килмешәк түгел Себердә,
Ул инде хуҗа бүген.

Хуҗалар хәзер ишәя,
Зурая, үсә Варта.
Яшь кала — Түбән Вартага
Халыкны нефть тарта.

Моңарчы дөнья күрмәгән
Хәзинә чыга аннан.
Чыганак һаман киңәя —
Самотлор...
Мега...
Аган...

---

[1] Мега — Төмән өлкәсендәге елга исеме (Обь кушылдыгы)

Бу якка хәзер төбәлә
Ил күзе, дөнья күзе.
Кешенең җаны үзгәрә,
Үзгәрә Себер йөзе.

Йөр әле, әйдә, танышып,
Күр әле бер килгәчтен.
Бөтенләй монда урнашып
Калсаң да үкенмәссең.

Тик тыштан кырыс күренә,
Чынлыкта җылы бу җир.
Ияреп илнең үзенә,
Яңара бара Себер!

...Балыкчы туктый сүзеннән,
Мегада көймә үтә.
Күңелем Себер җиреннән
Яңа җыр алып китә.

## Ашыгып «җиңги» димәсен...

Көянтәләрем алам да
Чиләкләремне тагам,
Чиләкләремне тагам да
Инешкә суга барам,
Инешкә суга барам.

Мин үтәм, үтәм урамнан,
Үләнгә чык төгелгән,
Ах, нигә үтә су юлы
Сезнең капка төбеннән.
Ах, нигә, нигә су юлы
Үтә капкаң төбеннән?

Үткәндә шушы турыдан
Битләрем уттай яна.
Җитмәсә, артымнан энең
«Җиңги» дип үртәп кала.

Ашыгып «җиңги» димәсен:
Тый әле шул энеңне.
Читен бит алай дигәчтен,
Үзе шундый күңелле.
Үзе шундый күңелле дә
Тик... иртәрәк түгелме?

Кодалар әле күренми,
Килерләр берәр заман.
Көянтәләрем алам да
Чиләкләремне тагам.
Чиләкләремне тагам...
Килерләр берәр заман.

## Фәнис Яруллин

### Әнием төсле күренә

Арганда үзенең тезендә
Йоклатса берәрсе җыр җырлап,
Ул кеше әнидәй ягымлы
Күренә күземә чын-чынлап.

Карыным ачканда берәрсе
Утыртса табынның түренә,
Ул кеше әнидәй бик якын,
Әнидәй сөйкемле күренә.

Урамда йөргәндә иркәләп
Башымны сыйпыйлар кешеләр.
Алар да кай ягы беләндер
Әнигә охшаган төсләләр.

Кешеләр, кешеләр, кешеләр!
Ягымлы, сөйкемле һәммәсе.
Һәрберсе кемнеңдер әткәсе,
Һәрберсе кемнеңдер әнкәсе!

### Оптимист

Сорадым: «Хәлең ничек?»
Әйттең син: «Гөлләр кебек».
Чәчәкле яз иде тышта,
Һәр чәчәк охшап кояшка
Тора иде нур сибеп.

Сорадым: «Хәлең ничек?»
Әйттең син: «Гөлләр кебек».
Уттай кызу иде көннәр,
Яңгыр көтеп бөтен гөлләр
Утыра иде көеп.

Сорадым: «Хәлең ничек?»
Әйттең син: «Гөлләр кебек».
Тышта салкын көзләр иде,
Бакчадагы гөлләр инде
Бә  пар иде кибеп.

## Беренче кар

Беренче кар төшә җиргә,
Төшә дә эреп бара.
Бер малай телен чыгарып
Кар аулап йөгереп бара.

Керфекләре ап-ак булган,
Күзләре шатлык чәчә.
Әйтерсең бу малай үзе
Дөньяга аклык чәчә.

Берни дә кирәкми аңа,
Ул бүген шундый юмарт.
Җир-күкне бүләк итәр ул,
Килүче булса сорап.

...Теле белән карлар тотып
Йөгергән малай төсле,
Бар иде йөргән чагыбыз
Тыя алмыйча хисне.

Беренче яуган карларның
Аклыгы гына калган.
Беренче сөйгән ярларның
Шатлыгы гына калган.

●

Юл буенда бер чәчәк
Зәңгәр күккә караган.
Җиргә энҗе коела
Тәнендәге ярадан.

Атлар да таптый аны,
Тузан да каплый аны.
Котырып искән җилләр
Чак өзеп атмый аны.

Көнгә ничә мәртәбә
Егыла да тора ул.
Яраларын ялый да
Башын күккә бора ул.

Бетте дигәч — терелә,
Гел кояшка үрелә.
Дөнья аңа көннән-көн
Матур булып күренә.

## Январь ае

Январь ае. Түбәләрдән
Шып та шып тамчы тама.
Тәрәзәләремне ачып,
Кулларым сузмыйм аңа.
Белеп торам. Язлар әле
Читтә йөри каңгырып.
Уйнатма, кыш, күңелемне
Тамчыларың тамдырып.
Кырыслыгың күрсәт әйдә,
Битне сарсын бәсләрең.
Синең салкын җилләреңнән
Атылып чыксын яшьләрем.

Январь икән январь бул син,
Буран уйнат, кар очыр.
Тамчың белән алдалама,
Яз димәмен барыбер.

## Ауда

Дуслар белән ауда йөрим,
Кулда мылтык — төзә дә ат.
Әллә нинди киекләрне
Яшерә күк һәрбер куак.

Әнә-әнә берәү чаба,
Килә бугай монда таба.
Басып киеп бүрегемне,
Тарттым кинәт күрегемне.

Киек шундук тәгәрәде,
Суккаланды-бәргәләнде.

Аннан гына калды тынып,
Бөтенләйгә күзен йомып.

Дуслар мине мактадылар,
Бигрәк туры тиде, диләр.
Бер атуда тәгәрәттең,
Шундый ерак иде, диләр.

Дусларыма сүз әйталмый
Баганадай басып торам:
Мин бүрегә төзәдем бит,
Тәгәрәгән мескен куян.

## Ышану

— Зур үскәнсең инде син, — дип
Әйтсәләр сабый чакта,
Ышанабыз шул сүзләргә,
Бәп-бәләкәй булсак та.

— Син һаман ять-яшь торасың, —
Дисәләр әгәр безгә,
Ышанабыз бу сүзләргә,
Сакал җитсә дә тезгә.

Ышанабыз, куанабыз,
Моңарда артык сер юк:
Зурлар күңелендә яшьлек бар,
Сабый күңелендә — зурлык.

## Кыска шигырьләр

●

Тормыш бит ул эстафета,
Һәркем үз юлын үтә:
Берәүләр туктаган җирдән
Берәүләр алып китә.

Күчеп кешедән-кешегә,
Күчеп куллардан-кулга,
Киләчәккә атлый дөнья,
Дөнья — мәңгелек юлда.

•

И күңелем, күңелем —
Яклауга мохтаҗ сабый:
Һәркем яралый ала,
Һәркем төзәтә алмый.

•

Шигырь язып куйды шагыйрь,
Фикерен әйтте оста:
Шигыренә дөнья сыйды,
Шигыре сыйды учка.

## Ак болыт

Әй, ак болыт, ак болыт,
Матур болыт, шәп болыт.
Кояш сине агарткан,
Җилләр өреп кабарткан.

Дөнья гизеп йөрисең,
Кайгы-хәсрәт күрмисең.
Ымсындырып алдыйсың,
Яңгыр булып яумыйсың.

Кыяфәтең бик серле,
Буласың син күп төрле:
Бер күргәндә — кош кебек,
Бер күргәндә — буш кебек.

...Әй, шигырем, шигырем,
Була күрмә ак болыт.
Эчеңдә тамчың булсын,
Яшенле камчың булсын.

•

Зур теләгем эшкә ашмый калды:
Хыялланып күпме йөреп тә
Бер тапкыр да гармун тарталмадым
Башларымны куеп күреккә.

Йөрәгемдә кешеләргә әйтер
Моңнарым да, юкса, бар иде.
Җырланмыйча йөргән җырларыма
Күкрәгемдә урын тар иде.

Туып-үскән авылым урамыннан
Гармун уйнап үтсәм кичләрен,
Бер кайгым да калмас кебек иде,
Басылыр кебек иде хисләрем.

Ләкин тормыш минем кулларыма
Гармун бирер диеп торганда,
Тоттырды да үзенең дилбегәсен,
Алып чыгып китте юлларга.

Онытылды гармун кайгылары,
Йөрәгемдә калды моңнарым.
Сөйгән ярым торган урамнарда
Гармун уйнар өчен соңладым.

Тик бу юллар бушка узылмады,
Хыялымның таптым дәвамын.
Яшьлектәге яшерен хисләремне
Шигырьләргә хәзер саламын.

# ТОРМЫШТАН — ӘДӘБИЯТ МӘЙДАНЫНА



*Нефть җайланмалары начальнигы, Социалистик Хезмәт Герое Мәсъгут Миннекаев.*

*Х. Вәлиев рәсеме.*

Буш урында мәһабәт шәһәр үсеп чыга дибез. Ләкин аның алдан хәзерләнгән җирлеге, яралгысы була. Бер сәбәпсез шәһәр тумый.

Татарстан язучылар союзының 1963 елда рәсмиләшкән Әлмәт бүлеге белән дә шундыйрак күренеш. Ул әдәби түгәрәк, әдәби берләшмә баскычларын үтеп, шуларга нигезләнеп үсте.

Яшь әдәбиятчылар үз җырларын, үз моңнарын нефть фонтаннары арасында, кайнар хезмәт шау-шуы эчендә таптылар. Шәһәр редакцияләреннән, кичке техникум һәм мәктәпләрдән, вахта юлларыннан кайтып, каләмгә тотындылар.

«Каты токым» романы белән бөтен Союз укучысына танылган (хәзер ул әсәр чит ил телләренә дә тәрҗемә ителә) Шамил Бикчурин, үзенчәлекле шагыйрь һәм шагыйрәләребез Саҗидә Сөләйманова, Энҗе Мөэминова, Клара Булатова, Рәшит Әхмәтҗанов беренче әсәрләрен Әлмәттәге әдәбият-иҗат түгәрәге утырышларына тотып килделәр, шуннан әдәбиятка путевка алдылар. Прозаиклар Мәхмүт Хәсәнов, Марсель Зарипов, Мөсәгыйть Хәбибуллин, драматург Сәет Кальметов, нефть якларындагы иҗат берләшмәләре белән тыгыз элемтәдә торып, яңадан-яңа әсәрләр яздылар.

1955 елда Әлмәткә «Татарстан яшьләре» газетасы корреспонденты булып килгән яшь шагыйрь Әдип Маликов, әдәбият-иҗат түгәрәге члennары белән бергә кайнап, ярдәмләшеп, хезмәт героикасын чагылдырган якты рухлы поэма, шигырьләрен, повесть һәм очеркларын бирде.

Хәзер Тукай премиясе лауреаты Гариф Ахунов күренекле «Хәзинә» романын, «Хуҗалар»ын, күп кенә повесть, хикәя, очеркларын, пьесаларын, кыскасы, заман сулышы белән сугарылган иң яхшы әсәрләрен нефтьчеләр арасында яшәп иҗат итте, әдәби көчләрне туплау, аларны әдәбият мәйданына чыгару эшенә лаеклы өлеш кертте.

Әлмәт утлары һәм әдәби учаклар яктысы бу якларга Рафаил Төхфәтуллин, Гамил Афзал, Юныс Әминов кебек каләм осталарын чакырып ала. Алар үзләре-

нең иҗат активлыкларын биредә тагын да арттырдылар, яшь авторларны тәрбияләүдә көчләрен кызганмадылар.

Нефть якларында хәзер дә ышанычлы әдәби алмаш үсеп килә. Алар арасында без төрле һөнәр ияләрен — район газетасы хезмәткәре, күптән түгел СССР Язучылар союзы члены итеп алынган, «Канатлар талмасын», «Картлык — кемгә шатлык?..» шикелле әйбәт повестьлар авторы Хәниф Хәйруллин, әсәрләре аерым китап булып чыккан яки әдәби журналларда еш басылган авторлардан рәссам Азат Ганиев, нефтьче-инженерлар Альберт Хәсәнов, Җәмит Рәхимов, Владимир Мальцев, тегүче Флера Гыйззәтуллина, редакция хезмәткәрләре Иван Винокуров, Ирек Бәдретдинов, Нур Әхмәдиев, Әсрар Галиев, укытучылар Фәһимә Галиева, Венера Туктарова, Рәшит Бәшәров исемнәрен күрәбез.

Әдәбият берләшмәләре хорына яңа, үзенчәлекле авазлар өстәлә бара, сәнгать мәйданына яшь рәссамнар килә.

Бу санда аларның кайберләре иҗатыннан яңа үрнәкләр бирелә.

# Газиз Кашапов

*...Туган елым дәһшәтле елларның берсе — 1942. Үткән сугышта атакага бара алмасам да, дары исен алып килгән җилләрне тойдым.*

*Шушы давыллы җилләр кабатланмасын дип, унтугыз яшемдә өстемә соры шинель кидем... Тормыш юллары, бигрәк тә хәрби юллар гаять катлаулы икән. Фаҗигале очрак мине госпиталь койкасына салды, гомерлеккә дигән офицер погоннарыннан аерылырга мәҗбүр итте. Мин үземә яңа профессия, яңа дуслар таптым. Хәзер Әлмәт шәһәре газетасы редакциясендә эшлим. Поэзиягә, гомумән, әдәбиятка гашыйкмын. Алар миңа бетмәс-төкәнмәс рухи азык бирәләр.*



## Бәйгеләрдә...

Бәйгеләрдә җиңеп килгән кебек,
Ялларына ятып атымның,
Аяз көндә олы юлга чыгып,
Еллар кочагына атылдым.

Җырлап уздым илем кырларыннан,
Җил-давылны азмы кичердем?
Исерсәм дә кайгылардан түгел,
Хезмәт шатлыгыннан исердем.

Илләр гизеп бәхет эзләмәдем.
Ялларына ятып атымның,—
Ленин биргән идеалларны яклап,
Дошманнарга каршы атылдым.

Яраланып аудым Ил чигендә,
Туган туфрак — каным аккан җир.
Тик бер теләк: үлсәм Ил туфрагы,
Ил чирәме булсын яткан җир.

## Йолдызлар...

Йолдызлар... йолдызлар багалар,
Җиргә юл күрсәтеп яналар.
Караңгы төннәрне җылытып,
Яктылык учагын ягалар.

Йолдызлар... йолдызлар җемелдәп,
Серләрен сөйлиләр кемнәргә?
Нигә соң кешеләр гашыйклар
Йолдызлы зәңгәрсу төннәргә?

Йолдызлар... йолдызлар шаһитлар
Кайгыга, шатлыкка, яшәүгә.
Шуңадыр хаклылар мәңгегә,
Мәңгегә сүнмичә яшәргә!

Йолдызлар... йолдызлар...

## Талларыма гашыйк

Озын юлга чыктым таң атканда,
Авылымнан — җитез пар атларда.

Җырлап уздым урман буйларыннан,
Ак каеннар чыкмый уйларымнан...

Кочкан чакта Байкал кыяларын,
Тугайларга очты хыялларым...

Чүлләр киңлегенә сыялмадым,
Сагыну хисләремне тыялмадым...

Кабат кайттым туган якларыма,
Кара туфрак, кашка атларыма.

Алданмадым дөнья малларына.
Мин һаман да гашыйк талларыма!

## Җәдит Хәбибуллин



*Тәүге тапкыр яктылык, авазлар белән очрашкан мизгел — 1948 елның яз башы. Туган җирем — Лениногорск районының Түбән Чыршылы авылы.*

*Урта мәктәпне тәмамлаганнан бирле нефтьче булып эшлим. Хезмәт мәктәбе мине күп һөнәргә өйрәтте, күп төрле кешеләр белән очраштырды.*

*Дөньяда катлаулы нәрсәләр күп. Ләкин хезмәт, шигърият — иң гади, иң тугрылыклы дуслар, минемчә.*

### Тынлык турында

Акканы беленми елганың,
Җил дә юк...
Юкәләр, миләшләр тынлыкка
баш игән.
Кошлар да белгертми үзләрен —
Бу тынлык барсына, барсына
баш икән.

Тик менә,
Тынлыкта уйларын тыялган
Кешеләр дөньяда бар микән?!

### Яз

— Гөрләвекләр кушылып,
елга булыр
Һәм җырлары синнән ерагаер,
Тыңлап кал!
Кушылып җырлап кал!
Көн эссе —
Үзгәрер иртәгә җир өсте.
Әй, кызый, чык инде!
...Кайдадыр яз дәшә.
Саф-кайнар тойгылар янәшә.

**Әгъзәм Вәлиханов,**
Ленин орденлы «Татнефть» берләшмәсе начальнигы, Социалистик Хезмәт Герое

# ТАТАРСТАН НЕФТЕ ВАТАНГА ХЕЗМӘТ ИТӘ

1973 елның җәендә Татарстан нефте үзенең 30 еллыгын билгеләп үтте. Шушы вакыт эчендә республикабыз нефтьчеләре 1 миллиард 300 мең тонна «кара алтын» чыгардылар. Бу — шул чор эчендә бөтен илдә чыгарылган нефтьнең өчтән бере диярлек.

Әмма Татарстан нефтенең тарихы бу утыз ел белән генә чикләнми, ул гасырларга барып тоташа. Казан губернасындагы җирле халык XVIII йөз башында ук «җир дегете» бәреп чыккан урыннарга игътибар итә. Петр патша заманында чыккан «Ведомости о военных и иных делах» дигән газетада 1703 елда Казан губернасында нефть булуы турында беренче рәсми хәбәр басыла. Илебездә нефть промышленносте барлыкка килүдән 100 ел элек сәяхәтчеләр Татарстанның кайбер районнарында нефть чыганаклары булу хакында язып калдырганнар.

Хәзерге Татарстан территориясендәге Нәдер авылы старшинасы Уразметов бай бу җир асты хәзинәсен файдаланырга да тырышып карый. 1754 елда ул нефть куу заводы сала һәм нефтьтән керосин эшкәртә. Бу завод турында бүтән белешмәләр юк. Мөгаен, хуҗасына ул күп файда бирмәгәндер. Россиядә капитализм үсеш алгач хәзерге Краснодар крае территориясендә Баку, Грозный шәһәрләре тирәсендә нефтьнең гаять бай ятмалары табыла. Узган гасырның алтмышынчы елларында «нефть бизгәге» Идел буена да килеп җитә. Баерга теләп төрле кешеләр нефть эзләргә керешәләр. Бөгелмә алпавыты Малокиенко Сок һәм Чишмә елгалары буенда 75 метр тирәнлектә берничә скважина казытып, 2000 пот асфальт, 100 чиләк керосин ала. Әмма нефть ятмасына юлыкмый, бөлә һәм бу эшне ташларга мәҗбүр була.

Идел буендагы җир асты байлыклары чит ил капиталистларын да кызыктыра. 1875 елда Америка геологы һәм капиталисты Шандор бу якларга килеп чыга. Ике ел дәвамында разведка эшләре алып бара. Ул Шөгер һәм Сарабиккол авыллары янында 175—354 метр тирәнлектә ике скважина бораулый. Аннан соң 1878—1880 елларда Бельгиядән «Бранун һәм К°», 1879—1884 елларда «Траузе һәм К°» фирмалары, Швециядән бертуган Нобельләр фирмасы (1910), Англиядән «Казан ойл фильд» җәмгыяте (1913—1914) — болар барысы да Татарстан территориясендә нефть ятмаларын ача алмыйлар.

Уңышсызлыкка очраган чит ил капиталистлары, Идел-Урал тирәләрендә нефть юк һәм булуы мөмкин түгел, дигән ялган хәбәр тарата. Алар өчен Россиянең урта бер җирендә нефть промышленностеның үсүе файдалы булмый. Конкуренциядән курыккан чит ил капиталистлары нефть булуы мөмкин булган җирләрне сатып алалар һәм анда разведка — эзләнү эшләренә комачаулыйлар, шуның белән безнең илдә «нефть ачлыгы» тудырырга омтылалар. Бу чорда Россиядә капитализм шактый үсә,

аңа арзан ягулык бик күп таләп ителә. Әмма нефть чыгару озак вакытлар дәвамында бик акрын үсә: елга 8—10 миллион тоннадан артмый. Барлык нефтьнең 80 процентын Баку бирә.

Патша Россиясендә геология фәне белән идарә итүчеләр — Никитин, Ерофеев, Нечаев, Замятин консерватив караштa торалар. Алар, хәзерге Татарстан җиренең Пермь катламнарында кечкенә ятмалар булса да, алардан сыек нефть чыгару мөмкин түгел, дип раслыйлар. Шушы раслау нигезендә һәм чит ил капиталистлары йогынтысы астында Татарстанда разведка эшләре бөтенләй туктатыла.

Алдынгы галимнәр — Мәскәү университеты профессорлары Г. Д. Романовский белән А. П. Павлов, Казан университеты профессорлары Штукенберг, Гловинский һәм Ноинский исә бөтенләй башка караштa тора. Алар җир өстенә бәреп чыккан нефть тирәндәге зур ятмалар белән бәйле дигән нәтиҗәгә киләләр. Әмма ул вакытта безнең якларда ике йөзгә якын ел дәвамында барган нефть эзләү эшләре реакцион галимнәрнең җиңүе белән тәмамлана.

Бары тик Бөек Октябрь социалистик революциясе геология фәнен диалектик материализм тәгълиматы белән нигезләде һәм аның зур темплар белән үсеше өчен мөмкинлек тудырды. Гражданнар сугышы иң кызган чорда, 1918 елда, Владимир Ильич Ленин күрсәтмәсе нигезендә, Баш нефть комитеты төзелде. Аның составына нефть буенча зур белгеч, соңыннан академик Иван Михайлович Губкин да кертелде. Ул — чын-чынлап совет нефть геологиясенә нигез салучы. В. И. Ленин боерыгы буенча, Комитет Татарстан территориясенә экспедиция оештыра. Әмма көчләрнең аз, техниканың зәгыйфь булуы аркасында бу экспедиция уңышка ирешә алмый. Бу уңышсызлык консерватив фикердәге галимнәргә кабат Идел-Урал районнарында нефть юк дигән теорияне якларга нигез була. Ә И. М. Губкин бу теорияне фаш итеп, Идел-Урал төбәгендә эзләнүләрне дәвам иттерергә кирәклеген кабат яклап чыга.

Ягулык кытлыгы бик нык сизелә ул елларда. Бакуда һәм Грозныйда нефть промыселлары элеккеге хуҗалары тарафыннан җимерелгән иде. 1921 елда, нефть промышленностен национализацияләү турында В. И. Ленин кул куйган Декрет чыккан вакытта, илдә бары тик 4 миллион тонна нефть алына. Бу — 1916 елда чыгарылган нефтьнең бары тик 40 проценты гына.

Нефть промышленностен аякка бастыру буенча кискен чаралар күрергә кирәк иде. Идел-Урал районына яңа геологик экспедиция җибәрелде. Владимир Ильич Ленин, Партия Үзәк Комитеты прогрессив геологларга һәрьяклап булышлык итте, аларга уңышлы эш алып бару өчен тиешле мөмкинлекләрне тудырды.

Әмма табигать үзенең җир асты байлыкларын бик тиз һәм җиңел генә ачарга теләмәде. Идел-Урал буйларында чыннан да нефть ятмалары барлыгын исбат итү өчен ун ел ныклы хезмәт кирәк булды. 1929 елда Уралда, Чусовские Городки дигән урында беренче куәтле нефть фонтаны бәрде. И. М. Губкин председательлегендә хөкүмәт комиссиясе Идел белән Урал арасындагы төбәктә системалы рәвештә нефть эзләү буенча бишьеллык (1929—1933) программа әзерләде. Бу вакытта инде бораулау эшләренең техник дәрәҗәсе шактый үсте, ике-өч мең метр тирәнлектәге скважиналар бораулауга мөмкинлекләр булдырылды. Партиянең XVII съездында Урал тауларының көнбатыш һәм көньяк итәкләрендә нефть базасы булдыру буенча мөһим чаралар күрү бурычы куелды. Уралда гына түгел, Идел буе районнарында да нефть эзләү киң җәелдерелә башлый. Партиянең XVIII съезды директиваларын үтәп, нефтьчеләр Куйбышев, Оренбург өлкәләрендә, Башкортстанда зур нефть ятмалары ачтылар. «Икенче Баку» барлыкка килде. 1941 елда инде Идел-Урал төбәгендә 1,8 миллион тонна нефть чыгарылды. Шулай ук Татарстанда да геология-разведка эшләре интенсив рәвештә дәвам итте. XVIII съездан соң, 1939 елда, И. М. Губкин инициативасы белән, Татарстан геология-разведка тресты оештырылды.

1943 елның җәендә, каты сугышлар барган вакытта, Шөгер янында нефть ятмасы барлыгы беленде. Беренче җиңүчеләрнең — бораулау мастеры Гарифулла Хәмидуллинның, геологлар Анатолий Венедиктович Лукин белән Сергей Петрович Егоровның исемнәрен без хәзер дә хөрмәт белән искә алабыз. Татарстан нефтенең туган көне дә безнең хәтерләрдә нык саклана — 1943 елның 3 августы.

Беренче җиңү белән канатланган нефть разведчиклары тирәнрәк геологик катламнардан нефть эзләүгә күчтеләр. 1946 елда Баулы янында девон нефте ятмалары, 1948

елда уникаль Ромашкино ятмалары ачылды. Ромашкинода бораулаган беренче скважина әле дә нефть бирүен дәвам итә.

Ромашкино ятмаларын ачкан геологларга, бораулаучы-разведчикларга, галимнәргә — М. Ф. Мирочникка, А. М. Мельниковка, С. П. Егоровка, И. А. Шпильманга, А. П. Клешовка, С. Ф. Федоровка, Н. С. Голобоковка, С. И. Маковскийга, А. В. Лукинга, Ф. Г. Ефремовка, С. И. Агеевка Дәүләт премияләре, ә А. А. Трофимукка исә Дәүләт премиясе лауреаты һәм Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде. Күп кенә эшчеләр, нефтьчеләр орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде.

Хәзер, «Татнефть» берләшмәсе оештырылганга 37 елдан соң, без горурланып әйтә алабыз: трест коллективы партия һәм халкыбыз ышанычынаклады, бай практик тәҗрибә белән коралланып, хәзерге заман техникасы ярдәмендә, хезмәтен, эзләнүләрен дәвам иттерә. Нефть разведчиклары Татарстан территориясендә генә 130 нефть чыганагы ачтылар. Аларга 760 нефть ятмалары керә. Разведка эшләре барлык перспектив районнарда бара. Хәзер инде бораулау вышкалары Кама тамагы янында Идел буенда да, Казан тирәсендә дә күренә.

Нефть эзләүчеләр 1954—1959 елларда аеруча зур уңышларга ирештеләр. Яңа Зирекле, Бондюг, Түбән Кама, Беренче май, Алабуга, Салагыш, Озерное, Комаровск, Конзулинск тирәләрендә бай нефть ятмалары табылды. Республиканың көньяк-көнчыгыш якларында да разведка дәвам итә. Ул якта инде Октябрь Норлаты, Татар Кандызы, Тавель, Ямаш, Ульяновск, Макаровск һ. б. нефть ятмалары ачылды. Татарстан соңгы елларга кадәр, Себердә нефть табылганга чаклы, җир астыннан эзләп табылган сыек ягулык запасы буенча илебездә беренче урынны алып килде.

Нефтьне эзләп табу әле эшнең башы гына. Табылган хәзинәне җир өстенә чыгару, аны кыска вакыт эчендә халык, ил байлыгы итү эшләре дә шулай ук катлаулы булды.

Нефтьчеләр үз индустриясен промышленность бөтенләй булмаган районнарда башлап җибәрделәр. Һәм ул кыска вакыт эчендә барлыкка килде. Чөнки безгә бөтен ил ярдәм итте: кечкенә генә Бөгелмә станциясенә төрле яклардан эшелоннар бербер артлы агылып кына торды. Уралдан бораулау җайланмалары, Куйбышев, Волгоград, Пермьнән вышкалар, бораулар, Әзербәйҗаннан трубалар, Мәскәү, Ленинград, Уфа, Грозныйдан төрле промысел җиһазлары килде. Шул ук вакытта Бөгелмә төрле яклардан дистәләрчә тәҗрибәле бораулаучыларны, нефть чыгаручыларны кабул итте. Якын-тирә авыл кешеләре дә нефтьче һөнәрен үзләштерергә керештеләр.

Ул вакытта, хәзерге кебек үк, нефтьчеләрнең девизы бер иде: «Ватанга нефтьне күбрәк бирик!»

1950 елда Татарстан нефтьчеләре, илебезнең башка районнарындагы нефтьчеләр белән берлектә, «Бик яхшы сыйфатлы бригада» исемен алу өчен бөтен союз социалистик ярышына кушылдылар. Алар арасында Баулы бораулау конторасыннан яшь мастер М. Нургалиев, «Татарстанразведка» трестының нефть чыгаручыларыннан К. Хөсәенов, И. Бычков, А. Ураков, С. Кокалин, Ш. Мотыйгуллин бригадалары бар иде. Бу ярыш аннан соңгы елларда традициягә әверелде. Шуны да әйтергә кирәк: «Татнефть» берләшмәсе оешканнан бирле андагы предприятие коллективлары, бригадалар һәр елны бөтен союз социалистик ярышында алдынгы урыннарны алып килделәр. Татарстан нефтьчеләре күп тапкырлар бораулау эшләрен югары темплар белән башкару, техник прогрессны тизләтү, күп скважиналарга хезмәт күрсәтү, нефтьне югалтуларга каршы көрәш буенча социалистик ярыш инициаторлары булдылар.

Республикабыз нефтьчеләре 1950 елдан башлап һәр елны нефть чыгару планын арттырып үтиләр.

Илленче елларда Ромашкино ятмаларында иң мөһим эш — бораулау эше иде. Скважиналар күбрәк кирәк! — Татарстан нефтьчеләре бораулау эшләрен камилләштерү өчен шулай тырышты.

Бораулау эше авыр һәм катлаулы. Һәр бораулау вышкасы үзе бер завод ул. Бораулаучылар үз хезмәтләренең нәтиҗәсен — нефтьне генә күрмиләр. Әлбәттә, алар капшап кына борауламыйлар — геологик-техник наряд була, анда барлык үтеләсе токымнар күрсәтелә, бораулан асы горизонтларга характеристика бирелә, скважинаның торышын төрле приборлар белдереп тора. Шулар ярдәмендә нефть катламына җиткәнче ике километрга якын тау токымнарын тишеп үтелә.

Татарстан нефтьчеләренең тагын бер мактаулы эше шунда: алар ул вакыт өчен әле яңа булган турбобурны бик тиз үзләштерделәр, аның моңа кадәр күрелмәгән мөмкинлекләрен ачтылар. 1950 елда А. Юдин бригадасы турбобур белән станок-айга 1000 метр бораулады. Заманы өчен бу зур казаныш булды. Аңа кадәр бары тик 200—250 метр гына бораулана һәм бер скважина бораулау өчен 180—200 көн кирәк иде.

Берничә айдан А. Юдин рекордын яшь мастер М. Нургалиев бригадасы узып китте. Бригада станок-айга 1225 метр бораулады. Ә 1953 елда Мөгаллим Гыймазов бригадасы 3023 метрга җитте. Ул турбобурны әйләндерү өчен эремә урынына су кулланды. Аңа кадәр су технологик процессны дорфа бозу булып санала иде.

Татарстан бораулаучылары үзләренең бер-бер артлы рекордлары белән дан алдылар. Хезмәт җитештерүчәнлеге күтәрелгәннән-күтәрелде: Д. Нурисламов бригадасы станок-айга 5 мең 600 метр... Н. Драцкий бригадасы — 6646 метр... Сунцевныкы исә 6778 метр!

Техниканы һәм технологияне камилләштерү, эшне эффектлы оештыру, кадрларның квалификациясен күтәрү нәтиҗәсендә еллык бораулау 30—35 мең метрдан 1973 елда миллион ярым метрга җитте. Бер скважина бораулау өчен киткән акча өч мәртәбәгә якын кимеде.

Вышка монтажлаучылар ирешкән уңышлар турында да берничә сүз. Илленче еллар башында, бораулаучылар турбина белән бораулауны үзләштергән чорда, вышка төзү 30—40 көнгә сузыла иде. Бораулаучылар вышка төзелеп беткәнне көтеп, озак вакытларны бушка үткәрергә мәҗбүр булдылар. Бораулау темпы үскәннән-үсә барганда вышка төзүчеләрнең барлык эшләрне кулдан башкарулары белән килешергә мөмкин түгел иде.

1952 елның 12 октябре илебездә вышка төзү тарихына матур сәхифә булып керде. Бу көнне беренче тапкыр вышка блоклап күчерелде: өч километр ераклыкка күчерү өчен бары тик ике тәүлек кирәк булды.

Вышка төзүдәге бу яңа алым бөтен берләшмә буенча бораулау темпын үстерергә, республикадагы нефть ятмаларын үзләштерүне тизләтергә, нефть һәм газ чыгаруны даими арттыра барырга мөмкинлек бирде. 1952 елда эксплуатация вышкасын төзүгә 36, разведка вышкасын 95 көн кирәк булган булса, хәзер алар 2,7 һәм 7,6 көндә корылып бетә.

Тиз үсеш өчен нефть ятмаларын эшкәртү буенча яңа алымнар эзләргә кирәк иде. Ромашкино ятмалары, мәсәлән, үзенең күләме һәм запасы буенча илебездә иң зурлардан булып исәпләнде. Галимнәр исәпләгәнчә, аларны традицион юл белән эшкәртсәң, моңа 300 ел кирәк буласы икән. Республикабыз нефтьчеләре һәм Бөтенсоюз нефть фәнни-тикшеренү институты галимнәре бу проблеманы хәл итү өчен зур эзләнүләр алып бардылар. Хәтта Башкортстанда һәм Баулы ятмаларында инде киң кулланылган тирәли суландыру юлы белән катлам басымын күтәрү ысулы да биредә ярамый иде. Өр-яңа ысул кирәк! һәм ул табылды. Татарстан нефтьчеләре дөньяда беренче булып эчтән суландыруны уңышлы кулландылар. Бу исә нефть чыгаруны 6 тапкырга арттырырга, йөзләрчә миллион сум дәүләт акчасын янга калдырырга мөмкинлек бирде.

Нефть ятмаларын эшкәртүнең яңа системасын уйлап тапкан һәм аны уңышлы кулланган өчен «Татнефть» берләшмәсенең бер төркем хезмәткәрләренә һәм Бөтенсоюз нефть фәнни-тикшеренү институты галимнәренә: Ф. А. Бегишев, П. С. Васильев, Р. Ш. Мингәрәев, М. М. Иванов, А. П. Крылов, М. И. Максимов, А. П. Чопоров, В. А. Каламкаров, А. Т. Шмаревларга 1962 елда Ленин премиясе бирелде.

Эчтән суландыру системасы яңа проблема — су проблемасын хәл итүне китереп чыгарды. Шуны әйтү дә җитә: хәзер катламга тәүлегенә ярты миллион кубометрдан артык су кудырыла. Ә скважина һәртөрле суны кабул итми, аңа махсус чистартылган су кирәк. Якын-тирәдәге Зәй, Чишмә елгалары гына җитмәде, алтмышынчы еллар башында Карабаш сусаклагычын кордык. Ул хәзер менә дигән ял итү урыны да. Әмма бу проблеманы хәл итүдә иң мөһиме — Камадан су юлы үткәрү булды. Бу бик зур корылма. Кама суы трубалар буйлап 150 километрдагы нефть чыгару объектларына кудырыла.

1967 елның җәендә катламга беренче миллиард кубометр су куылды. Бу үзенә



*Операторлар.*

*М. Хәеретдинов рәсеме.*

күрә кечкенә бер юбилей иде. Ә 1971 елның 14 маенда Татарстан нефтьчеләре беренче миллиард тонна нефть чыгардылар. Бу ике миллиард саны арасында бәйләнеш зур. Эчтән суландыру алымы кулланылмаса, бер миллиард тонна нефть чыгару бик озак елларга сузылыр, моның өчен бик күп дәүләт акчасы тотылыр иде. Шуны искә төшерик: бер миллиард тонна нефть чыгару өчен Баку нефтьчеләренә ярты гасырдан артык вакыт кирәк булды.

«Татнефть» берләшмәсенең тагын бер казанышы шул: бездә чыгарыла торган нефтьнең үзкыйммәте илебездәге башка нефть районнарындагыга караганда шактый арзан. Нефть продуктларын куллanучы объектларга якын урнашканлыктан, Татарстан нефтен күчерү дә арзанга төшә. 1973 елда һәр эшчегә чыгарылган нефть бу тармак буенча илдәге санга караганда ике мәртәбә артык булды.

1956 елда ук инде «Татнефть» берләшмәсе нефть чыгаруның күләме буенча, Бакуны һәм Башкортстанны узып китеп, илебездә беренче урынга чыкты. Озак вакытлар дәвамында Татарстан бөтен союзда чыгарыла торган нефтьнең өчтән бер өлешеннән артыгын биреп килде. Бу үзгәреш халык хуҗалыгына 20 миллиард сум саф табыш бирде, нефть чыгаруга тотылган акча алты мәртәбә артык кайтты.

«Татнефть» берләшмәсе, үзенең оешкан көненнән башлап, нефть ятмаларын эксплуатацияләү ысулларын камилләштерүгә зур игътибар бирде. Бу җаваплы участокта төп рольне операторлар үти.

Баштарак нефть скважиналары бер-берсеннән еракта һәм һәр скважинага бер оператор хезмәт күрсәтә иде. Ә бу тәүлегенә өч оператор кирәк дигән сүз. Яңгыр астында да, буранда да, караңгы төннәрдә дә скважиналарга илтә торган сукмаклар буйлап кеше шәүләсе күренергә тиеш... Аның эше гаять авыр иде ул вакытларда. Моны җиңеләйтү өчен бездә бик күп чаралар күрелде. Озак эзләнүләрдән соң, Татарстан нефтьчеләре, Татарстан нефть фәнни-тикшеренү институты галимнәре белән берлектә, насос-компрессор трубаларын пыяла белән каплау ысулын уйлап таптылар. Соңрак труба эчләрен махсус сумала белән каплау да үзенең уңай нәтиҗәләрен күрсәтте. Гаять зур хезмәт таләп итә торган парафиннан чистарту проблемасы шулай хәл ителде. Бу ысул хәзер илебезнең бик күп нефть районнарында кулланыла.

Әмма шулай да әле һәр смена саен бер оператор эшли иде. Тикшеренү, эзләнү нәтиҗәләрен тирәнтен анализлаганнан соң, скважиналарны җирле автоматика эле-

ментлары белән тәэмин иткәч, операторның, производствога зыян китермичә, барлык бер сменада гына эшләргә мөмкинлек расланды. Хәзер, инде унбиш ел үткәч, моңа беркем дә гаҗәпләнми, хәтта яшь операторлар элек скважиналарга тәүлек буена хезмәт күрсәтелгәнен белмиләр дә.

Татарстанда нефть чыгару интенсив рәвештә алып барыла.

Бу — скважиналардагы нефть фонды белән эзлекле һәм планлы эш итүне сорый. Менә шуның өчен дә туктап калган скважиналарны сафка бастыру, аларны җир астында ремонтлау, капиталь ремонт үткәрү юлы белән сафка бастыруга зур игътибар юнәлтелә. Мәсәлән, 1973 елда гына да скважиналарга 2617 шундый капиталь һәм 17860 агымдагы ремонт үткәрелде.

Илленче еллар ахырында Татарстан нефтьчеләре алдына промыселларның үзләрендә нефтьне тоздан аеру һәм стабильләштерү бурычы куелды. Бу эш нефтьчеләр өчен гадәтләнмәгән яңалык иде. Шуңа карамастан, безнең нефтьчеләр кыска вакыт эчендә бу яңа производствоны үзләштерделәр, бу эшне тормышка ашыру өчен яңа җайланмалар корылды. Аларга хезмәт күрсәтүче яңа белгечләр әзерләнде. Нефтьне әзерләүдәге бу яңалык «Дуслык» нефть үткәргече өчен кирәк иде. Ә ул турыдан-туры Әлмәт шәһәреннән башлана. Хәзер Татарстан нефть промыселларында әзерләнгән югары сыйфатлы нефть Европадагы социалистик илләргә — Польшага, Чехословакиягә, Германия Демократик Республикасына, Венгриягә җибәрелә.

Моннан берничә еллар гына элек нефть районнары өстеннән самолетта очканда скважина яннарында факеллар дөрләп януын күрергә мөмкин иде. Матур күренеш иде бу. Хәтта шагыйрьләр алар турында күп кенә шигырьләр яздылар. Әмма безнең өчен, нефтьчеләр өчен, бу зур кимчелек булды, чөнки бик кыйммәтле чимал булган газ янып юкка чыга иде. Аларны җыеп саклау һәм файдалану озак вакытлар дәвамында безнең нефтьчеләр өчен зур проблема булып килде. Моның өчен меңнәрчә километр промысел коммуникацияләре, йөзләрчә насос һәм компрессор станцияләре төзергә, газны чистартырга, бу арзан, шул ук вакытта чиксез файдалы продуктны заводларга, промышленность һәм көнкүреш өчен файдаланучы предприятиеләргә озатырга кирәк иде. Соңгы елларда инде газ факеллары нефть районнары пейзажын «бизәми». Татарстанда һәр елны дүрт миллиард кубометрдан артык газ чыгарыла һәм файдалануга тапшырыла. Нефть белән чыга торган газ Ленин комсомолы исемендәге Миңлебай газ-бензин заводында эшкәртелә. Татарстан нефтеннән һәм газыннан алынган продуктлар Түбән Кама нефть-химия комбинатында, республикабыз башкаласы Казанда, Әлмәт, Бөгелмә, Чаллы, Лениногорск шәһәрләрендә, Җәлил, Азнакай, Баулы һ. б. бик күп урыннарда файдаланыла.

Берләшмә коллективы зур нефть өчен көрәштә «булдыра алмыйм» дигән сүзне белмәде һәм белми. Ул үзенә тапшырылган иң катлаулы бурычларның телсә кайсын хәл итәргә сәләтле. Коллективны яңадан-яңа үрләргә әйдәүче көч — социалистик ярыш. Ул өстәмә эчке резервларны ачарга, производствода рационализаторларның һәм новаторларның иҗади инициативасын үстерергә зур этәргеч бирә.

Төмән нефтьчеләре белән социалистик ярышта Татарстан нефтьчеләре җиңүче булып чыкты. 1975 елда нефтьчеләр көнендә «Татнефть» берләшмәсенә профсоюзлар Үзәк Комитетының күчмә Кызыл байрагы тапшырылды.

Берләшмә коллективы тугызынчы бишьеллык планны 1975 елның сентябрь башында вакытыннан элек үтәде. Бишьеллык чорында бораулаучылар барысы 7 миллион 300 мең метр тау токымы борауладылар. Бу — 4490 скважина дигән сүз. Планнан тыш 759 скважина борауланды.

Берләшмәдә партия, профсоюз, комсомол оешмалары, администрация белән берлектә, һәр патриотик башлангыч киң үсеш алсын өчен, Татарстан нефтьчесе исемен югары йөртү, тирән белемгә, югары квалификациягә ирешү өчен барлык чаралар күрелә. Республикабызның нефть чыга торган якларындагы шәһәрләрдә эшче яшьләрнең кечкенә һәм смена мәктәпләре, нефть һәм газ техникумнары эшли. Инде унбиш елдан артык яшәү дәверендә Мәскәү нефть, химия һәм газ промышленносте институтының Татарстандагы кичке филиалында йөзләрчә нефтьчеләр производстводан аерылмыйча югары белем алдылар. Илебезнең төрле вузларында белем алучылар да бик күп. Предприятиеләрдә уку комбинатлары, төрле семинарлар, алдынгы тәҗрибә, коммунистик хезмәт мәктәпләре эшчеләрнең квалификациясен күтәрәләр, рационали-

зация һәм уйлап табуны киңәйтүгә ярдәм итәләр. Бездә һәр елны диярлек алты-җиде мең камилләштерү тәкъдиме тормышка ашырыла, алар тугыз-ун миллион сум дәүләт акчасын янга калдырырга мөмкинлек бирә. Хәзер коллективта һәр алты эшченең берсе — рационализатор.

Нефтьчеләр гел эш белән генә мәшгуль түгел. Алар матур итеп, күңелле итеп ял итә дә беләләр. Үзешчән сәнгать коллективлары, бию ансамбльләре, хор капеллалары республика конкурсларында даими рәвештә алдынгы урыннарны алалар. Спортчыларыбызның да уңышлары шактый. Әдәби китапларны да нефтьчеләр күп укый. Һәр концерт һәм спектакль — нефтьчеләр өчен зур бәйрәм. Әлмәттәге Татар драма театры чын-чынлап милли культураның учагы булып әверелде. Газеталарга, техник, әдәби журналларга язылучылар елдан-ел арта бара. Болар барысы да Татарстан нефтьчеләренең культура зәвыклары үсә баруы турында сөйли.

КПСС Үзәк Комитеты, Совет хөкүмәте нефть промышленносте үсеше турында даими кайгырта, нефтьчеләрнең фидакарь хезмәтенә зур бәя бирә. Безнең коллектив члennарына дүрт мәртәбә югары хөкүмәт бүләкләре бирелде.

1970 елда Татарстан Ватанга 100 миллион тонна нефть бирде. Сигезенче бишьеллыкта Татарстан нефтьчеләре 463 миллион тонна «кара алтын» чыгардылар. Бу казанышны хөкүмәтебез зур бәяләде. Биш кешегә Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде, меңгә якын кеше орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде, «Әлмәтнефть» идарәсенә Ленин ордены тапшырылды.

Тугызынчы бишьеллыкта нефть промышленностен үстерү буенча КПССның XXIV съезды директивалары республика нефтьчеләрендә яңа хезмәт энтузиазмы тудырды. Бишьеллыкта һәр елны 100 миллион тонна нефть алырга дигән вәгъдәләрен алар үтәп кенә калмадылар, югарыда әйткәнчә, арттырып үтәделәр. Һәм менә күптән түгел газеталарда шатлыклы хәбәр басылды: бишьеллыкның хәлиткеч елында ирешелгән уңышлар өчен безнең коллективның 485 кешесе СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнде, ә оператор А. Сафиуллинга иң югары хезмәт бүләге — Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде.

Республика нефтьчеләре үз максатларын ачык күрәләр: ул — бай нефть ресурсларын Ватанга хезмәт итәргә тапшыру.

Хәзер Ленин орденлы «Татнефть» производство берләшмәсе 50 мең кешедән торган бердәм коллектив. Аңа унбер нефть һәм газ чыгару идарәсе, өч бораулау эшләре идарәсе, өч разведка эшләре идарәсен берләштергән «Татнефтьгаз» тресты, уннарча ярдәмче предприятиеләр һәм оешмалар керә.

Нефтьчеләр хәзерге заман техникасы, соңгы фәнни казанышлар белән тәэмин ителгән. Болар киләчәктә нефть чыгару эшләрен интенсификацияләүне тагы да үстерергә, техник, технологик, оештыру эшләрен тагын да камилләштерергә мөмкинлек бирә. Беренче миллиард тонна нефтьне Ватанга 26 ел эчендә биргән идек, ә икенче миллиард тонна «кара алтын» унбер-унике ел эчендә тапшырылыр дип ышанабыз. Безнең төп бурычыбыз шул, хыялыбыз, хезмәтебез шуңа юнәлдерелгән.

**Әдип Маликов**

# АК ЧИШМӘ



Тагын атна-ун көн шулай торса — эш харап. Туфракта дым калмады. Үләннәр көеп бара. Киләсе ел өчен дә куркыныч, тамырлары үлә. Каеннар, мескенкәйләр, өнә ничек саргаешып утыралар. Күздән коры калды, кышын рәтләп кар яумады...

Машина туктауга, ул хуҗаларча нык адым белән бодай җиренә таба юнәлде, башларын игән саллы башакларга үрелде, берничәсен бергә уып карады. Тук орлыклар уч төбендә сары гәрәбә сыман җемелдәшеп яталар. Берәр атнадан комбайн кертергә ярый. Картлар әйтмешли, быелгы миһербансыз елда шундый уңыш үстерә алу үзе зур могҗиза.

Күзне иркәли, күзгә рәхәтлек бирә торган яшел дөньяга килеп керделәр. Бер чүп заты күрмәссең. Куяннар качышлы уйнарлык буй үстергән кукурузлар кайнар җилдә моңсу гына шаулашып, хәсрәтле тирбәлеп алалар: их, яңгыр кирәк.

Колхоз председателе җир астына су кудыра торган иске, әллә кайчангы девон скважинасына күз төшерде. Янына барып тыңласаң — зыңлаган, сызгырган авазлар ишетелә. Су басымының көче әйтеп адәм ышанырлык кына түгел, калын таш стенаны тишеп чыгарлык. Шул ташкыннан безгә дә өлеш чыгарсалар, иллә дә шәп буласы бит! Басулар рәхәтләнеп, иркенләп бер сулыш алыр иде. Сиптергечләр табарга кирәк, торбалар сузарга... Суын бирсәләр, анысын гына җайлар идек әле.

Председатель Алмаз Минһаҗетдиновның уйлары тирәнгәрәк китте. «Зәй» колхозы кырларыннан, җир аслап, унбер рәт челтәр-челтәр тимер торбалар уза. Кайсысыннан нефть, газ, кайсысыннан саф су, тозлы су ага. Алар безнең җирләрдә урнашкан биш йөз девон скважинасына гына түгел, Миңлебай газ эшкәртү заводына да, «Дуслык» магистральләре аша Европа илләренә дә барып тоташалар. Бөтен ил буйлап сузылган электр һәм элемтә кабельләре — һәммәсе Җир-ана күкрәгенә җөйләнеп тегелгән. Әйтәсе дә юк, бу кырлар асты-өскә килеп айкалып беткән. Барысына да түзгән шул баһадир җирне тилмертмәскә иде суга.

Председатель үзен юатып та алды. Елгабызны буып, культуралы көтүлекләрне сугара башладык. Башкасына да чират җитәр әле. Күршең үзеңнән әйбәт булсын, диләр бит. Моңарчы нефтьчеләр белән уртак тел табып яшәдек. Үз көчебезгә генә таянсак, көлеп торган культура сарайларын, икешәр катлы ул таш мәктәпләрне кайчан өлгертер идек әле. Терлекчелек фермаларын әйтәсеңме, үзләре бер шәһәр сыман. Кесәңдә акчаң булса, башыңда мең төрле уй туа...

Машина асфальт юлга чыкты. Зур заводны хәтерләткән челтәрле корылмалар яныннан уздылар. Әйләнәсе таш стена белән уратып алынган. Тимер капкадан пропускасыз якын да җибәрмиләр. «Иркеннефть» идарәсе салдырган корылма бу. Тапкан нефтьләрен шунда тозлы судан, газдан аералар.

Минһаҗетдиновны анда яхшы беләләр, пропуск-фәлән сорап тору юк. Азмы якалашырга туры килде ул халык белән. Әле анда, әле монда торбалары тишелеп, уңдырышлы җирләрне тозлы су белән яндыралар. Әнә ничәмә гектар җир кутырлап ята. Туфрак өстендә тоз бөртекләре җемелди. Юдырсаң, агулы су грунтка таралып, башка урыннан тагын җир өстендә өйләнеп чыгачак. Чишмәләргә, агымсуларга кушыла. Туфрагын бөтенләй алыштырып, тирес черемәсе ташысаң гына инде.

Юл читында туктап торган самосвал машинасын күргәч, Алмазның йөзе яктырып киткәндәй булды. Газизулла абый. Баш агроном. Мине көтә булыр. Яңа машина алырбыз дип, ничәмә ел йөргән «Луноход»ны саттырды да хәзер самосвалга калды. Акча да бар, машина җиткереп булмый. Сер бирми тагын үзе. Барыбер пенсиягә китәсе, яңа машинаны яңа баш агрономга бүләк итәрбез, янәсе.

Кояш белән бергә, сәгать өчтән торып, бригадаларда күпме йөрсәләр дә, алар әле бүген очрашмаган, күрешмәгән иделәр. Гадәттә, иртәнге сәгать сигезләрдә колхоз идарәсе йортына кайтып, бөтенесен шунда уртаклашалар. Өлгергән кадәр, әлбәттә.

— Исәнме, Газизулла абый?!

— Саумы, Алмаз Гыйльфанович?! Әллә, мин әйтәм, Ак Чишмә болыннарын да карап өйләнәбезме? — диде баш агроном, эшлекле сүзгә күчеп.— Нәдергә шул яктан су үткәрмәкче идек бит.

— Әйдә соң...

Самосвал юл читендә калды, Газизулла абзый председатель машинасына күчеп утырды. Болын юлыннан бераз баруга, ургылып аккан чишмә янында туктап машинадан төштеләр. Күрер күзгә суы көмештәй саф, тонык.

Баш агроном суны учына алып, чөмереп карады:

— Әллә авыз тәме юк, әллә чишмәсенең тәме... Күп эчелде бит заманында, буталуың да бар.

Колхоз председателенең кинаяле елмаюын күргәч, Газизулла абзый, акланган сыман, сүзен дәвам итте.

— Шөкер, Польша, Германия, Чехословакия чишмәләреннән дә авыз иттек, тутыккан саз суларын да ятып эчтек. Мондый сәер тәмне бер дә хәтерләмим.

Чишмәнең тәмен Алмаз да, яшь шофер да ачык кына билгели алмады. Әллә тозлырак шунда, әллә... киресенчә, һәрхәлдә, эчәргә ярарлык түгел. Аргырак чишмә янына киттеләр. Анысы да ургылып агып тора. Тәме дә шундый ук.

— Булмаса, самосвалга салып, кәҗә алып киләбез,—диде баш агроном уенычыны белән бергә,— ул хайван эмульсияле суга борын да төртми, химлабораториян дә кирәк түгел.

Борчуга төштеләр, уйга калдылар. Элек печәнчеләр өбәт вакытларын шушы чишмәләр янында үткәрә иде. Суы саф, йомшак, чәйгә генә тотарсың. Малайлар хәтта шуңа ипи манып ашый иде. Халык аңа «Ак Чишмә» дигән исем биргән. Кызлар, алмалы көянтәләрен асып, Ак Чишмәгә суга килерләр, сөйгән егетләре белән шунда очрашырлар иде. Һәр чишмәнең үз тәме, үз исеме булган. Чишмәләр турында халык күпме җыр чыгарган. Тукайга ияреп, «авылыбызның ямен, суы тәмен беләм» дип әйтүләре дә ни тора!.. Бөтен өметләре Кама-Исмәгыйль җәйләвендә иде бит, авылга шуннан торба сузарга дип план корган иделәр. Нишләп соң болай булган әле?!

— Гел нефтьчеләргә генә сылтамыйк, гаепнең бер өлешен үзебезгә дә алырга кирәк, — диде Алмаз Минһаҗетдинов, күңелендә йөргән борчуларын чыгарып,— чүп үләннәргә, корткыч бөҗәкләргә каршы көрәшәбез дип, кырларга элекке елларда күпме агу тондырдык. Кая киткән дисең алар? Чамасын белмәдек. Күп ашасаң, бал да әче була.

Алмаз сүзен бераз көлемсерәбрәк дәвам итте:

— Күрше авыл бригадасыннан кичә бер егет гербицид сорап килгән. Бакча артында шайтан таягы үсә, ди. Шуны агуларга, янәсе.

Баш агрономның тирәннән карый торган соргылт күзләрендә кызыксыну чаткысы кабынды:

— Нәрсә дидең соң?

— Тамыры белән йолкып ташла, энем,—дидем.

— Хәзерге кайбер яшьләр чүп утауның ни икәнен белми шул. Анысына сүз юк. Мөгаен, химиягә күбрәк салынабыздыр.

Алар идарәгә кайтып кергәндә, ике катлы таш бина янында әллә ничә ят машина тезелеп тора иде. Ярты көнем нефтьчеләр белән уза дип уйлап куйды Минһаҗетдинов, кабинет ишеге янында аны көтеп торган төркемне күреп. Алар белән ул ачык йөз күрсәтеп исәнләште. Арадан берсе, озынрак буйлысы, аңа таныш иде. Әлмәт бораулау эшләре идарәсеннән.

— Бусагаңны күпме таптарга мөмкин, Алмаз Гыйльфанович? — диде бораулау вәкиле, председательнең законлы креслога барып утырганын да көтеп тормыйча. — Бригада бер атна трай тибеп йөри. Аларга простой өчен акча түлибез. Анысы бер хәл, бораулау планы өзелә бит, неушто шуны аңламыйсыз?

— Бер атнадан бодайны урып алабыз, шуннан соң вышкагызны рәхәтләнеп сөйрәтерсез, — диде колхоз председателе тыныч кына.

Бораулау идарәсе вәкиле, бу юлы да уртак тел таба алмасын аңлап, ахры, һөҗүмгә күчте:

— Җирле караш көчле сездә. Ун гектар бодай җире бозыла икән — йөз центнер уңыш югала. Ә скважина ун көнгә соңгарып борауланса, илгә ничәмә мең тонна «кара алтын» бирү тоткарлана! Дәүләт интересларын чүпкә дә санамыйсыз. Китергән зыянны артыгы белән түлибез бит.

— Кем кесәсеннән? — диде Алмаз Гыйльфанович, нефтьче-инженерның йөзенә текәлеп. — Быел «Зәй» колхозы басуларында иллеләп яңа скважина бораулана. Һәр бригада бодай, кукуруз чәчүлекләрен таптатып керә башласа, эшләр кая китә аннары?

Колхоз председателе уң кулда торган тумбочка өстендәге микрофон кнопкасына басты:

— Газизулла абый, кер әле.

— Хәзер! — дигән тавыш ишетелде микрофоннан.

Күп тә үтмәде, чаларган башлы Газизулла Абдуллин председатель янына килеп утырды. Алмаз сүзен дәвам итте:

— Сез материаль ягын гына исәплисез, ә аның мораль ягын кая куясың? Менә баш агроном ни әйтер?

Ул Абдуллин ягына карап, «нык тор» дигән сыман, сизелер-сизелмәс кенә күз кысып куйды. Газизулла абзыйга бу мәсьәлә таныш, аңлатып торасы юк. Ул инде икмәкнең кадерен белә дә белә. Егерме беренче елгы ачлыкны да ул үз башыннан кичергән. Ачтан тәгәрәп үлгән сабыйларны күргән. Ә илгә сугыш афәте килгәч, күпме игеннәр, күпме җирләр янып, көеп харап булдылар. Кешене кеше иткән, ил терәгы булган шул уңдырышлы җирләр өчен утка-суга керде батарея командиры Газизулла.

— Әйе шул, мораль ягын кая куясың, — дип, председатель фикерен куәтләде баш агроном да. Ул нотыгын шактый озынга сузып, бораулау идарәсе вәкиленә шактый күпне сөйләп китте:

— Быелгы ел егерме беренче елгыдан да хәтәррәк килде, — диләр авыл картлары. Бодай басуларына чыгалар да, түбәтәйләрен салып, башларын чайкап торалар. «Сука заманы булса, күрер идең мондый уңышны», диләр. Бөтен кырларны билчән, алабута басар иде. Аллага ышанган картлар хәзер агротехникага табына башлады. Инде җыеп аласы дигәндә, шул күкрәп утырган алтын бодайлар өстеннән нефть вышкасы өстерәтеп узыйк, ди. Бу, энем, игенче хезмәтен мыскыл итү була түгелмә соң? Ил агалары ни әйтер? Берниндн акча белән дә юа алмассың моның гөнаһысын. Берәр ай алдан әйтсәгез иде, ичмасам. Яшел азыкка чабып алыр идек тә, малларга ашатыр идек. Итәккә ут капкач кына чәбәләнеп йөрисез.

Бораулаучылар вәкиле актык чиккә кадәр түзеп, тыныч кына тыңлап утырырга булды. Председатель әле соңгы сүзен әйтеп бетермәгән шикелле тоелды аңа. Әйтте председатель. Алмаз Минһаҗетдинов бу сөйләшүгә шунда нокта куярга ниятләнеп, болай диде:

— Киләчәктә, аңлашылмау чыкмасын өчен, кайда, кайчан һәм нинди скважина бораулаячагыгызны күрсәтеп, график төзегез.

— Рөхсәт сорап килдегезме? — диде нефтьче-инженер кинәт кабынып китеп. — Сез инде, Алмаз Гыйльфанович, нефть белгечләренә, бораулаучыларга күрсәтмәләр бирә башладыгыз түгелме?

— Хет ничек аңлагыз,— диде җавабында колхоз председателе,— графикны бергәләп төзербез, алайса. Ел тәүлегенең өч яшел аен безгә калдырыгыз. Калган тугыз ае сезнеке. Тугыз айда скважина гына түгел, бала туа дөньяга. Аннары гел иген җирләренә керергә дә димәгән. Әнә элекке ком карьеры урынын нигә файдаланмыйсыз, шуннан кыйгачлап бораулрга да мөмкин ич.

Колхоз председателенең бораулаучылар эшенә «кысылуы» чыгырыннан чыгарды нефтьче-инженерны, ул:

— Өстегездән жалоба белән барачакбыз, — дип янады да тиз-тиз генә кабинеттан чыгып китте.

Алмазның моңа әллә ни исе китмәде. Халык сайлап куйган аны.

Алмаз моннан берничә ел элек булган вакыйганы күз алдына китерде. «Зәй» колхозы җирләренә, яу сыман булып, әллә никадәрле машиналар, ят кешеләр килеп керде. Куәтле экскаваторлар иген кырларын актарырга тотынды. Минһаҗетдинов, колхоз активын җыеп, җир турындагы законнар белән коралланып, шулар каршысына китте.

— Партия съезды директиваларын укымагансыз, ахры, — диделәр тегеләр, дәрәҗәләрен саклап кына. — Самотлор нефть ташкыны «Дуслык» магистраленә кушыла бит, егетләр.

Начальниклары телефон трубкасына ук үрелде:

— Дәгъваларыгыз булса, менә Косыгинны тоташтырам, сөйләшегез үзегез.

Колхоз председателе дәүләт башлыгы белән ничек телләшеп торсын инде. Себер тикле Себердән эченә башмак бозау кереп йөрерлек юан торбалар сузып киләләр. Туктатырсың син аларны. Самотлор нефть ташкынын океанга агызсыннармыни хәзер?

Самотлор — Усть-Балык — Әлмәт нефть магистраленең үз колхозы территориясеннән үтүенә ул хәтта горурланып та куйды. Менә, ичмасам, моны дәүләт интересы дисәң дә ярый. Андый чакта авылыңны кучереп куйсалар да, авызыңа су кабып торырсың...

Берәм-берәм йомышларын йомышлап озата торгач, ахырга кадәр тыныч кына тыңлап утырган таза гәүдәле, бик чиста, ыспай киемле соңгы «клиент» калды. Ул, председатель каршына килеп, ихтирамлы тон белән сүз башлады:

— Сезгә җир тапшырырга дип килгән идек, Алмаз Гыйльфанович,— диде ул һәм үзе белән таныштырды:

— РИТС начальнигы Черножуков Виктор Алексеевич.

— Күңелле хәл. Ничә гектар?


— Өч.

— Әйдә, Газизулла абый, кабул итеп алыйк.

Алар комиссия членнарын утыртып, ике җиңел машинага төялеп, тантаналы төстә авылдан чыгып киттеләр.

Җирләребез үзебезгә кайта, дип уйланып барды Алмаз Минһаҗетдинов, соңгы дүрт ел эчендә нефтьчеләр «Зәй» колхозына җиде йөз гектар чәчүлекләрне кире бирделәр. Моның нәрсә исәбенә эшләнүен яхшы белә ул. Скважиналар янында урын биләп утырган мерникларны, нефть чаннарын күрмәссең хәзер. Девон куеныннан күтәрелгән җир мае җир аслап кына туп-туры җыю пунктына озатыла. Кыргыч будкалары да алынды, тарихка китте. Чөнки скважина торбалары эчтән махсус пыяла белән капланган хәзер — парафин утырып йөдәтми, чистартасы юк. Алмаз барысын белеп тора. Нефтьчеләр белән бергә «янәшә тыныч яшәү» өчен андагы хәлләрне аларның үзләреннән күбрәк белергә кирәк. «Бер казанга ике тәкә башы сыймый» дип йөрсәң, берни майтара алмассың.

— Газизулла абый, кара, ничек кысрыкланган монысы, — диде Минһаҗетдинов, ак күбектәй карабодайлар арасында утырган сиртмәле скважинага күз төшереп. — Кая, тиешле утыз алты сотых та калмаган ич монда?!



*Әнисе белән.*

*М. Хәеретдинов рәсеме.*

Баш агроном көлеп кенә куйды. Элек нефть бирә торган бер скважина гектар ярым җир били иде. Ә хәзер ул норма биш мәртәбәгә якын киметелде. Шул мерниклар, ак чаннар, кыргыч будкаларыннан арыну исәбенә. Нефть рәтләре буендагы трассаларның, юлларның да кирәге калмады. Чүп ояларын сөреп, иген чәчтеләр. Кырдагы багана урманнары гел сирәгәеп бара. Җир астыннан кабельләр суза башлагач, баганалар исәбенә, быел колхозга тагын сигез гектар җир кире кайтты. Әйе, адәм башы уйлана, фәнни фикер шәп эшли хәзер. Җиргә дә җиңеллек, нефтьчеләрнең үзләренә дә. Оператор скважинадан скважинага чаж-чож чабып йөрисе урында, автоматлар идарә итә. Нефть түгелүдән, һавага ачык чаннардан бензин исе таралып утырудан котыла барабыз.

Кабул итәсе участокка килеп җитүгә, машинадан иң беренче булып РИТС начальнигы сикереп төште. Ул унбиш ел буе кысыр яткан гектарларны тизрәк хуҗаларына күрсәтергә, аларны сөендерергә ашыга иде. Комиссия членнары элекке бораулау конторасы җиһазларыннан арынган мәйданны аркылысын-буена йөреп, тикшереп чыктылар. Баш агроном учына туфрак алып, аны угалап карады. «Кызыл балчык белән аралашкан». Колхоз председателе тутыккан тимер-томырлар табып китерде. Комиссия членнарының һәркайсының кулында таш кисәкләре...

РИТС начальнигы әллә миңа һөҗүм итәргә җыеналармы дигән сыман каушый калды.

Алмаз Минһаҗетдинов:

— Нишлибез, иптәшләр? — диюгә, авторитетлы сүзне баш агроном әйтте:

— Чистартырга кирәк, аннары бульдозерлар белән тигезләп чыгарга. Ферма ягыннан тирес черемәсе ташысыннар.

Начальник бернинди каршылык күрсәтмәде, һәммәсен блокнотына яза барды:

— Үтәлер!

Эшне коры тоттылар. Көн үзәгендә кайнар кояш кызуыннан шыбыр тиргә баткан ирләр, машиналарга утырып, яңадан кайтыр юлга чыктылар.

— Корырак сөйләшмәдекме? — диде Минһаҗетдинов, шофер янындагы утыргычтан артына, Газизулла абый ягына борылып. — Рәнҗеп китмәс микән?

— Заманында безнең белән бик исәпләшмәделәр, Алмаз Гыйльфанович. Исеңә төшер әле...

Алар икесе дә уйга калды. Абдуллин да, Минһаҗетдинов та шушы Нәдер авылында туып үскәннәр. Яшь чактан ук кендекләре җиргә берекәән. Үзгәрешләр, яңарышлар алар күз алдында булды. Бик болама заманнар бар иде. Җирләрне басулары белән генә алдылар. Топограф килеп, кайда таягын болгаса, шунда төзелеш башлана. Бораулаучылар вахтага барганда трактор вагоннарына төялеп йөриләр, кырларны таптаталар. Асфальт юллар салынмаган. Торба күмелгән траншеялар еллар буена тәртипкә китерелми, тигезләнмичә ята. Чөнки бульдозерлар, машиналар җитешми. Ә басулардагы нефть амбарлары?.. Аларны җыештыру өчен дә техника кирәк. Бер елны колхозның өч баш сыеры нефтькә батып үлде. Дөнья шаулатып, судлашып йөрдек. Ак казларны күрмәссең дә. Агы да, аласы да карага әйләнеп калды. Итеннән нефть тәме килеп тора.

Элеккегә чагыштырганда аерма зур хәзер. Скважина тирәсендә сабый бала борын очына буярлык та нефть табы күрмәссең. Рөхсәтсез траншея казулар бетте. Казыганда да кара туфракны кадерләп кенә аерым өяләр. Нефтьчеләр дә, төзүчеләр дә кем җиренә аяк басып йөргәннәрен нык тоялар хәзер.

— Зәйдә балык чиртә башлаган, Алмаз Гыйльфанович,— диде баш агроном, уйларыннан бераз арынып.— Акчарлаклар күренә.

— Сөенечле хәл. Бака да калмаган иде бит.

Артына борылып, сүзен дәвам итте Алмаз:

— Әлмәткә үткән баруда химлабораториягә сугылган идем. Зәй суының минеральләшүе узган ел белән чагыштырганда бермә-бер кимегән, диделәр. Зәебез чистара бит, егетләр.

Газизулла абзый малай чагында балык тотарга, куян куарга яраткан. Кемнең башыннан үтмәгән инде андый хәлләр. Истәлекләргә бирелде ул:

— Зәйдә, Алмаз Гыйльфанович, без яшь вакытларда нинди генә балыклар юк иде. Корбан, алдакай, кушбаш, кызыл канат, җумба... Менә мо-о-ндый чуртаннар. Кармак салган саен ялт берне. Ә Зәй әрәмәсендә куяннар, ул куяннар... Кем әйтмешли, сарык көтүе кебек иде.

— Куяннар турында бераз шыттырасың түгелме, Газизулла абый? — диде Минһаҗетдинов, ягымлы елмаеп. — Ачуланма тагын.

— Зәй элекке хәленә кайтачак, балык күп булачак. Әнә, Карабаш сусаклагычын гына мисалга алыйк. Балыкчылар, ял итүчеләр гел шунда гына ята хәзер, — диде председатель якты бер өмет белән, — табигатьне саклау эшенә бөтен халык тотынса, башкача булмый хәле юк.

*

* *

Дәрәҗәле актив җыелышында «Татнефть» берләшмәсе начальнигы Әгъзәм Вәлиханов залдагыларны уйландырырлык саннар әйткән иде:

— Татарстан нефтьчеләре соңгы дүрт ел эчендә егерме мең гектар җир мәйданын элекке хуҗаларына кайтарып бирделәр. Шуның 17 513 гектары авыл хуҗалыгына караган җир,— диде ул.— Никадәрле бай резервлар!

Һөҗүмгә барган гаскәр киңрәк плацдармны иңнәргә тырыша. Ә казарма тормышына күчкәч, «кысылып» кала. Татарстан нефтьчеләре һөҗүмгә барудан туктады дип әйтеп булмый, әлбәттә. Шулай да итәкләрен җыеп йөрергә өйрәнделәр. «Кара алтын» өчен көрәш кыза, катлаулана баруга да карамастан, тормыш биредә шактый стабильләште, үз ярларына төште.

«Рекультивация» термины хәзер еш кулланыла: ягъни промышленностьтан бушаган җирләрне дөрес файдалану, уңдырышлы хәлгә кайтару. Нефтьчеләр инде моңа күнегеп бара. Җир тапшырганда, җир кабул иткәндә, Татарстанның атказанган агрономы Газизулла ага Абдуллин куйган сыман кырыс таләпләрне рияланмыйча үтиләр. Әмма төзүчеләрнең эшләре катлаулырак. Ком, таш карьерларын ничек элекке хәленә кайтарырга? Украинлылар үрнәгендә күл ясап, балык үрчетергәме? Яки урман үстерергәме? Уйланырга, баш ватарга кирәк.

Әлмәт районы территориясендә ташландык карьерлар мәйданы 167 гектар исәпләнә. Исеме дилбегә озынлыгы булган «Татнефтьстройматериалы» дигән трест бу

уентыкларны куптән тәртипкә китереп, инде элекке хуҗаларына тапшырырга тиеш иде. Файдасын күр, үзеңә кергән ал да бозып ташла, имеш. Егетлек түгел бит. Моның өчен берәүне дә гафу итмиләр. Сүз ата-бабалардан калган мәңгелек җир — халык байлыгы турында бара.

Без «Татнефть» берләшмәсендә әңгәмә корып утырабыз. Каршыбызда фәнни эшчәнлеге, белеме ягыннан галимнәр белән ярышырлык белгеч, берләшмә начальнигы урынбасарларының берсе. Ул баштанаяк нефтькә гашыйк.

«Нефтьне бүгенге көнкүрештән чыгарып ташладык дип фараз кылсак, нәрсә булыр иде? Илдә хәрәкәт туктар, моторлар ягулыксыз, машиналар тәгәрмәчсез, кешеләр ялангач калыр иде», кебек сүзләрне еш ишетәсең аның авызыннан. «Зәй» колхозында алган кайбер тәэсирләрем белән уртаклашып, табигатьне саклау чаралары турында сүз кузгаткач, ул моңа тулысынча теләктәшлек белдерде:

— Әйе, табигатьне саклау эше узып китә торган кампания гына түгел. Бик тормышчан, мөһим мәсьәлә. Шуңа күрә партиябез, хөкүмәтебез аңа зур әһәмият бирә дә. Без барыбыз да табигать балалары.

Инженер минем алдыма берничә документ китереп салды.

— Кайбер каләм өһелләрен саннар кызыксындырмый, поэзиясен тапмыйлар, — диде ул, дусларча елмаеп.— Менә бер сан әйтәм сезгә, үзебезнең техник телдә.— «Татнефть» берләшмәсе, игътибар итегез, 1975 ел башына 9289 скважинаны герметизацияле нефть җыю системасына тоташтырган. Ни дигән сүз бу?

Ул, утыргычыннан кузгалып, ишекле-түрле йөрергә тотынды, сүзен дәвам итте:

— Тугыз мең скважинада нефть түгелү очраклары тулысынча бетерелгән, ачык чаннардан хәзер бензин парлары очып, һаваны сасытмый дигән сүз бу. Кырлар, агым сулар пычранмый, болыннарда чәчәк исләре генә аңкып тора! Менә кайда аның поэзиясе. Ә тугыз мең скважинадан елына 90 миллион тонна нефть алына. Бу саннар бит кеше хезмәте, иҗади уйланулар, йокысыз төннәр турында сөйли. Аннары килеп, Әлмәт янында зур плотина төзү күздә тотыла, Зәй диңгезе... Шәһәр тирәсе яшеллек зонасына әйләнәчәк. Табигать белән дуслык та менә шуннан башлана инде.

Берләшмә начальнигы кинәт җанлана төште, тарихка чигенеш ясап алды:

— Петр I нең кызык кына указлары булган. Нева елгасына чүп ташлаган солдатларны чыбык белән суктырырга кушкан, ә офицерларны чиннан мәхрүм иткән...

Ишектән киң күкрәкле, ачык йөзле бер ир килеп керүгә, безнең әңгәмә бүленеп калды. Алар сүзне кызу тоттылар. Сүз ниндидер великан-отстойник турында барды. Авырлыгы алтмыш өч тонна. Аны Туймаза станциясеннән алып кайтырга кирәк икән.

— Ике трактор алдан тартса, өченчесе арттан этеп барса...

— Күперләр чыдамас шул.

— Әллә соң кышны көтәбезме? Юлсыз урыннан, кардан чана белән өстерәтүе җиңелрәк булыр.

— Кышка калдырырга ярамый, — диде берләшмә начальнигы урынбасары. Ул телефон трубкасын күтәрде:

— Кызлар, Мәскәүне тоташтырыгыз әле...

Шунда ук Мәскәү белән сөйләшеп алдылар. Ахырдан... «Ярый, була»... кебек сүзләр ишетелде. Теге кеше рәхмәт әйтеп, хушлашып, кабинеттан чыгуга, каршымдагы белгеч мәсьәләгә ачыклык кертте.

— «Лениногорскнефть» идарәсеннән бу иптәш,— диде ул, папиросын еш-еш суырып, — эшләре килеп терәлде. Тапкан нефтьләрен моңарчы сулы килеш Миңлебайдагы чистарту корылмасына озатып тордылар. Хәзер Миңлебай мәйданының үзен су басып бара. Табылган нефтьнең алтмыш проценты су. Уйлап карагыз, ул мәйданнан гайрәсе 182 миллион тонна сыек ягулык алынган. Ә шуны өскә күтәрү өчен ике өлеш күбрәк су кудырылган катламга. Чистарту корылмаларын үзләрендә, Лениногорск тирәсендә төзергә кирәк була хәзер. Ашыгыч чарасын күрмәсәң, аска су китә.

Уйласаң, борчылырлык нәрсәләр шактый. Миллионлаган кубометр саф сулар кудырылды җир куенына. Күп еллар буена. Кая китә дисең аны? Төрле-төрле тозлар иартеп, нефть белән бергә яңадан өскә күтәрелә. Аны ялгыш кына бакчага сипсәң —

яшелчәләрне яндыра. Елгага кушылса, андагы бөтен тереклек үлә. Җиргә акса... Бөз моның аяныч нәтиҗәсен «Зәй» колхозында күреп киттек. Реактив снаряд ярылган урындагы сыман, андый мәйдан озак елларга яшеллектән мәхрүм булып кала. Элегрәк су нефтьчеләрнең «союзнигы» иде. Девон куенында яшеренеп каласы ничәмә йөз миллионлаган тонна хәзинәне өскә күтәрештә ул, күпме файда китерде илгә. Әйтеп бетергесез. Ә соңыннан дошманнарына әйләнә язып калды шул ук су.

Ничек котылырга ул «дошман»нан?

Нефтьче-галимнәр бик әйбәт чарасын таптылар. Җир маеннан аерылган агулы суны махсус корылмаларда чистартып эшкә җигәргә — яңадан девонга кудырырга киңәш бирделәр. Камадан, Зәйдән килгән «төче» су ташкынының күп өлеше янга калачак. Моның өчен чистарту корылмалары төзергә кирәк. Берничә урында инде төзелгән. Әмма алар гына җитми.

Сөйләве җиңел дә, эшләве кыен. Күпме яңа мәшәкать, күрелмәгән чыгымнар. Җитмәсә, бик мәкерле икән ул тозлы су дигәне. Мәрхәмәтсез рәвештә металлны ашый, торбалар гомерен кыскарта.

— Җир асты коммуникацияләребез меңнәрчә чакрымга сузылган, — диде берләшмә начальнигы урынбасары хәвефле тонда. — Көн саен биш-алты мәйданда, бишалты урында торбалар шартламас дип кем гарантия бирә ала? Коррозиягә каршы каты көрәш бара. Шуның турында дистәләрчә фәнни хезмәтләр языла, практик чаралар күрелә. Әйе, торбалар ашала, шартлый тора. Берәү яшел болын уртасында яңа чишмә таптым дип сөенә. Тәмен татып караса — төкеренә башлый. Җир астында, ике метр тирәнлектә яткан торбадан көчле басым астында тозлы су бәреп чыга икән, ул грунтка сеңә, чишмә юлларына барып кушыла.

Баш агроном Газизулла абзый Кама-Исмәгыйль, Ак Чишмә болыннарындагы чишмәләр суын кәҗәгә эчереп карау турында (уены-чыны бергә) сүз чыгарган иде. Белмим, химлабораторияләр, санэпидстанцияләр агым суларны, чишмәләрне көндәлек күзәтү астына алмасалар, монда кәҗәләр сиземе генә ярдәм итәр микән?

Нефть якларындагы чишмәләрнең табигый тәме югала баруы сәбәпләрен бәлки үткәннәрдән дә эзләргә кирәктер. «Татнефть» берләшмәсе бүген моннан егерме еллар элек борауланган скважиналарны цементлау чарасына керешә. Ни өчен? Заманында ашыгыч кына борауланган, ашыгыч кына колонналар төшерелгән. Ә торба кырыйларын цементларга «онытканнар». Нәтиҗәдә, төрле катлам сулары иркенләп, торбалар буйлап бер-берсенә «кунакка» йөрешәләр. Өлгеррәкләре өске катламнарга да менеп җитә. Тикшереп карасаң, минеральлы, тозлы сулар икән алар. Ничәмә еллар рәттән, ничәмә йөзләгән нефть скважиналары грунт, туфрак суларын агулап, чишмәләрне тәмсезләп ятканнар лабаса.

Соң булса да уң булсын, ди. Нефтьчеләр хәзер табигый суларны тозланудан саклау буенча ашыгыч чаралар күрәләр. Моңа акчаны да, көчне дә кызганмыйлар. Чөнки табигать — безнең уртак байлыгыбыз, күмәк шатлыгыбыз.

— «Яшьлек хаталары»н төзәтү «Татнефть» берләшмәсенә күпмегә төшә соң?» — дигән сорауга таныш инженерыбыз болай дип җавап кайтарды:

— Шуңа тотыласы суммага йөз мең халкы булган Әлмәт кадәр яңа бер шәһәр салып булыр иде. Табигатьне саклау чараларын безгә үткәндәге ялгышларны төзәтүдән башларга туры килә.

*

* *

Мин яңадан «Зәй» колхозында булдым. Бодайлар җыеп алынган, басулар такыраеп калган. Вышка төзүчеләр чөлтәрле манараларын, алан-йолан каранмыйча, иркенләп камыллар өстеннән сөйрәткәннәр. Ак Чишмә буйларында буровой гөрләп утыра. Колхоз председателе Алмаз Минһаҗетдиновны мин шул буровой тирәсендә очраттым. Өстендә яңа костюм, түшендә «Татарстан Верховный Советы депутаты» билгесе. «Жалоба бирәм» дигән, янап чыгып киткән бораулау инженеры белән дусларча сөйләшеп тора иде ул.

— Хәлләр ничек соң? — дип сорауга, алар икесе дә берьюлы:

— Бораулыйбыз, — дип җавап бирделәр. Гүя моңа Алмазның да бәйләнеше бар. Хәер, ник булмасын, колхоз җирләрендә бораулыйлар ич. Алар тапканы да, без үстергәне дә — уртак байлык.

Минһаҗетдинов мине машинасы янына чакырды.

— Әйдәгез, кукуруз плантацияләреннән уратып алып кайтам, — диде ул, шифалы яңгырлар явып узуына чиксез сөенүен белдереп, — ә шулай да сугарулы җирләр турында хыялланам. Нефтьчеләрдә өмет. Кама суыннан бәлки безгә дә өлеш чыгарырлар. Бер юлдан йөрибез, бер икмәктән авыз итәбез бит.

Колхоз председателе аннары хәйләкәр генә елмаеп куйды:

— Ә тозлы суларын өнә үз кирәк-яракларына тотсыннар.

Машина асфальт юлдан чаба. «Зәй» колхозы унлап авылны берләштерә. Кызыл Кичү, Бакча-сарай, Гөлбакча, Ак Чишмә... Гаҗәеп матур исемнәр. Ак Чишмә болыннары... Ерактан зәңгәр урман күренә. Яшь үрентеләр, яшь наратлар күтәрелеп килә. Никадәрле хуш ис, сафлык чыганагы. Уртача зурлыктагы бер агач тәүлегенә өч кешегә җитәрлек кислород бүлеп чыгара икән. Кешене яшәрткән дә, терелткән дә табигать. Бер акыллы баш әйткән бит: «Урманга кергәндә эшләпәңне салып, аягыңны чишенеп кер», дигән.

Ак Чишмә. Тизрәк кайтсын иде аның элекке даны. Һәм аннары — сукмакларын һичкайчан үлән басмасын.

**Салкын чишмәләрдән су алдым да**
**Кояш нурларыннан нур алдым...**

— дип, юкка гына җырламый халык.

Үзбәк Саттаров

# «КАРА АЛТЫН» ХИКӘЯЛӘРЕ

*«Татнефть» берләшмәсе начальнигы урынбасары, нефтьче-инженер Үзбәк Саттаров нефть тарихы, аның гаҗәеп сыйфатлары һәм «кара алтын»ның халык хуҗалыгында тоткан гаять зур әһәмияте турында фәнни-популяр китап яза. Шуннан кыскартып алынган берничә өзек тәкъдим итәбез.*

## Нефтьнең кадере кайчан беленә башлаган?

Нефть тә, газ да кешеләргә күптәннән билгеле булган. Әмма «күптәннән» дип әйтү «кайчаннан бирле?» дигән сорауга төгәл җавап бирү түгел.

Без яши торган геологик эра кайнозой дип атала. Ул моннан җитмеш миллион ел элек башланган. Иң кыска гомерле геологик чор — антропогенга барлыгы бер миллион гына «яшь». Без менә шушы антропогенда яшибез дә инде. Бу чор эчендә геологик вакыйгалар бик аз: җир өсте боз белән капланырга исәпкә алмаганда, хәзерге көн рельефы урнашып беткән, хәзерге көндәге җан иясе җанварлар һәм кыргый үсемлекләрнең инде туган чагы. Дөньяда кеше барлыкка килгән. «Бабаларыбыз» нефть һәм газ белән кайчан очрашкан соң?

Нефть тә, газ да бик күп урыннарда турыдан-туры җир өстенә чыга. Димәк, кеше аларны һәр вакыт күрә алган дигән сүз. Әмма кеше бит һәрбер күргән әйбереn файдалана белми әле. Аңа үзе күргән-белгән һәрнәрсәнең нинди дә булса файдасын аңлап-белеп алырга кирәк. Моннан йөз мең ел элек берәр кыргый бабабызның битумлы таш кисәге берәр җәнлекне бәреп үтергәне билгеле дә булды, ди. Аңа карап, кешеләр битумны моннан йөз мең ел элек куллана башлаган дигән нәтиҗә ясап булмый әле.

Нефтьнең кешеләргә кайчан билгеле булуы турында беренче чыганак — борынгы язмалар. Әмма борынгы язмаларда, беренчедән, барысы турында да язылмаган, икенчедән, яза башлау үзе исә кешелек тормышының чагыштырмача соңгы казанышларыннан берсе. Монда безгә археологик казылмалар ярдәмгә килә.

Евфрат елгасы буендагы археологик казылмалар моннан алты мең еллар элек нефтьнең ягулык итеп файдаланылуын күрсәтте.

Геродот (безнең эрага кадәр V гасыр), Өлкән Плиний, Марк Витрубий (безнең эрага кадәр I гасыр) хезмәтләрендә һәм башка укымышлыларның язмаларында Һиндстан, Иран, Сүрия, Урта диңгез утраулары, Малая архипелагы, Кытай һәм башка урыннардагы нефть турында сүзләр очрый. Александр Македонский походларын тасвирлаган борынгы грек язучысы Плутарх Каспий диңгезе ярларында һәм Аму-Дәрья елгасы буенда чыга торган нефтьне дә телгә ала. Аның язуы буенча, мәшһүр полководец гаскәрләре белән Задракарт янында (Ирандагы хәзерге Астрабад шәһәре) лагерь ясап урнаша. Кичен ул лагерь палаткаларының берсендә нурланып яна



*Фронт язы.*

*М. Хәеретдинов рәсеме.*

торган лампа күрә. Бу аны кызыксындыра: лампада сары сыек май яна. Май исә керамик трубка эченә тутырылган җепләр буйлап утка күтәрелә. Лампа үзе дә, җепле трубка кебек үк, керамикадан ясалган. Исеме — «чирак», ә яна торган майныкы — «нафата» (җир мае). «Нафата»ны Каспийның көнбатыш ярларында, җир өстенә үзе агып чыга торган урыннан алалар, дип аңлаталар полководецка. Күрәсең, монда сүз хәзерге көндә дә нефть чыга торган Апшерон ярым атавы турында баргандыр.

Бүгенге медицинаның атасы дип исәпләнгән Гиппократ (безнең эрага кадәр V—IV гасырлар) бик күп даруларын ясаганда шул ук нефтьне кулланган.

Борынгы грек укымышлылары язмаларында сицилия мае турында да мәгълүматлар еш очрый. Күрәсең, монда да «сицилия мае» дип нефтьне атаганнардыр. Ничек дип исемләсәләр дә, (тау сумаласы, тау мае, нафата, җир мае, сицилия мае һ. б.) аның безнең эрага кадәр кешеләргә билгеле булуы шиксез.

Әйткәнебезчә, нефтьне тау токымнарының җир өстенә чыккан урыннарында еш күзәтеп була. Мисал өчен Татарстанның хәзерге Лениногорск районындагы Шөгер тавын гына алыйк. Ул тау барлыкка килгән чорда ук, геологларның билгеләве буенча, нефть ятмалары булган токымнар җир өстенә күтәрелеп чыккан. Шөгер кешеләре әлекке ата-бабалары шул тау яныннан капчык-капчык сумала җыюлары турында хәзер дә сөйлиләр.

Сумаланың, кайбер очракларда сумала белән күкерт кушымтасының хәрби эштә кулланылуы хакында фикерләр борынгы язмаларда бик еш очрый. Өлкән Плиний римлеләрнең походларын яктырткан язмаларының берсендә Лукул шәһәрен саклаучылар атакага ташланучы гаскәрләр өстенә шәһәр стенасы аша нефть катыш күкерт тутырган утлы чүлмәкләр ыргытулары турында сөйли.

Фарсылар һәм грекларның яна торган уклар атуы турында да язмалар бар. Ул укларның очына күкертле нефтькә батырылган чукмарлар беркетелгән булган. Суга төшкәч тә яна торган «грек уты» нефть, күкерт һәм селитра катнашмасыннан тора.

Константинопольне саклаучылар (VII гасыр) гарәп корабларын үз шәһәрләренә бик якынга җибәрәләр икән дә, диңгезгә нәкъ шул рецепт белән ясалган измәне таратып, аңа ут төртәләр. «Грек уты» бик күп корабларны яндыра.

Нефтькә манчылган чүпрәкле укларны рус гаскәрләре половец князе Кончакка каршы сугышта кулланалар. Бу турыда безгә «Ипатьевская летопись» сөйли. Анда нефть «җир сумаласы» дип аталган.

Моннан мең еллар элек Гарәбстаннан Бакуга килгән географ А. Масуди язмалары Апшерон ярым утравында нефть чыгару эшләренең күләме турында фикер йөртергә юл ача. Шул чакта ук инде Баку мәшһүр шәһәрләрнең берсе була. Анда Иран, Һиндстан, Гарәбстан һәм Сүриядән сәүдәгәрләр килә. Шунсы кызык: арада нефть алырга килүчеләр дә күп була. Ул вакытта нефтьне күн капчыкларга салып, дөяләргә төяп ташыганнар. А. Масуди Баку нефть промыселларын карап йөргән, аларның күпме нефть бирә алуы белән дә кызыксынган — Бакудан чыга торган юлларда утырып, читкә һәм якын-тирәгә күпме нефть ташылуын исәпләп караган. Аныңча, Бакуда нефть чыганаклары күп, әмма төп чыганаклары икәү генә булган: берсеннән ак һәм сары нефть, икенчесеннән кара һәм зәңгәр нефть табылган икән.

Ә бу эш асылда кайчан башланган соң? Ул сорауга җавапны Гамань култыгында археологик казынулар вакытында нефть салынган унбиш метрлы амфорлар табылуы җиңеләйтә. Археологлар ул амфорлар VI гасырда ясалган диләр.

## Нәрсә соң ул нефть?

Моңа ничегрәк дип җавап бирергә? Бик тә гади-гадәти итеп, һәркемгә билгеле булганча: «нефть ул кара төстәге сыек бер матдә!» дипме?

Бу җавап бик үк дөрес булмаячак, әлбәттә. Чөнки нефтьнең кара төстәгесе була, әмма дөньяда ак һәм сары нефть тә бар. Ак, сары һәм кара буяу төсләрен төрле күләмнәрдә кушудан нинди яңа төсләр чыгару мөмкин булса, нефтьләрнең төсе дә шул кадәр күп.

Тәҗрибәләр һәм тикшеренүләр нефтьнең су өстенә җәелергә иң һәвәс май икәнен исбатлады. Бер грамм нефть өч квадрат метр чамасы өслекне каплый ала! Бу элпәнең калынлыгы нефть составына кергән молекулаларның бер кат тезмәсеннән дә калын түгел.

Нефть сыекча булмаска да мөмкин. Казагыстандагы Маңгышлак ярым утравында чыга торган нефтьне, шешәгә салып, Әлмәткә алып кайттылар. Ләкин аны бүлмә температурасында шешәдән агызып алып булмады. Казагыстанда җәйге эссе вакытларда да төннәр салкынча тора. Төнлә суынган нефть күле өстендә кешеләр иртәнге якта иркенләп атлап йөри алалар. Дөньяда моннан куерак нефтьләр дә бар. Шулай булгач, «нефть ул сыекча» дип әйтеп буламы?

Нефтьнең нинди матдә икәнен аңлату өчен аны безгә бик таныш булган су белән чагыштырып карыйк.

Дөньяда суның ниндиләре генә булмый. Диңгез суы, күл суы, елга суы, кар суы, яңгыр суы, чишмә суы һәм башка төрле сулар. Чишмә сулары үзләре генә дә бик күп төрле. Күпме чишмә бар — шул кадәр үк күп төрле су аларда. Һәр чишмәнең үз тәме. Елга, күл сулары, мәсәлән, үзләрендә күпме кислород һәм башка газлар, нинди органик матдәләр, нинди бактерияләр булуы белән дә бер-берсеннән аерыла. Һәрбер суның үзенә хас катылыгы була. Аларның һәркайсында төрле тозлар һәм төрле микъдарда эри. Диңгез суларында тозлар бигрәк тә күп. Шуңа карап суның тыгызлыгы да арта. Чиста суның тыгызлыгы 1,0 дип алсак, кеше тәненең уртача тыгызлыгы 1,05 чамасы. Артык күп тозлы диңгез суларында кеше батмый. Химиклар диңгез суында алтмыштан артык элемент барлыгын таптылар. Шуларның иң күбесе — безнең аш тозы. Су — матдә. Һәр матдәнең үзенә генә хас физик һәм химик сыйфатлары — аның химик формуласы —( ул молекуланы төзүче атомнарның төрләре, саннары, аларның үзара бәйләнеше) бар.

Ә нефтьнең химик формуласы юк. Аның булуы да мөмкин түгел. Чөнки без нефть дип бер-берсенә бик күп төрле физик һәм физик-химик бәйләнешләре булган берничә мең (әйе, мең!) исемдәге матдәләрнең катнашмасын атыйбыз. Бу инде су белән чагыштырганда күп тапкырлар катлаулырак.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

## ЯНВАРЬ, 1975 ЕЛ

1974 ел совет халкының коммунистлар төзелештә зур уңышлары, эчке һәм тышкы политикада Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең генераль курсын тормышка ашыруда яңа казанышлар белән билгеләнеп үтелде. Тугызынчы бишьеллыкның билгеләүче елында КПССның XXIV съезды тарихи карарларын тормышка ашыруга илебезнең комсомол оешмалары да үз өлешләрен керттеләр.

Мәскәүлеләр башлаган «Бишьеллыкка — удар финиш» хәрәкәте илебездә көчәйгәннән-көчәя. Бишьеллыкның яшь гвардиячеләре инициативасына йөз меңнәрчә егетләр һәм кызлар кушылды — алар стахановчыларның удар вахтасына бастылар.

Республика, край һәм өлкә комсомол оешмаларының 1974 елдагы эшен караганнан соң, ВЛКСМ Үзәк Комитеты карар чыгарды:

— Фидакарь хезмәт, уку-белем алуда уңышлары, 1974 елда, бишьеллыкның билгеләүче елында, ирешелгән казанышлары өчен Татарстан АССР Чаллы шәһәре комсомол оешмасын ВЛКСМ Үзәк Комитетының космоста булып кайткан Кызыл байрагы белән бүләкләргә.

**«Комсомольская правда», Мәскәү.**

Кама автомобиль комплексын төзүчеләр тугызынчы бишьеллыкның билгеләүче елы дәүләт планын вакытыннан элек үтәүләре турындагы хәбәр миндә зур шатлык тудырды. Чөнки мин сезнең белән берничә ел инде якын дуслык мөнәсәбәтендә.

Ватаныбыз индустриясенең яңа гигантын төзүдәге сезнең темпка, яшь төзүчеләр, гаҗәпләнмәскә мөмкин түгел. Әле күптән түгел генә бер төзелеш мәйданында тәүлегенә бер миллион сум акча тотыла диген сүзгә беркем дә ышанмас иде. Хәзер инде бу күрсәткеч тә артты. Кама буйларында көн саен төзелеш-монтаж эшләренә миллион ярым сум акча тотыла. Мондый хәлнең моңа кадәр дөньяда беркайда да булганы юк әле.

Дөньяны рекордлар белән гаҗәпләндерергә без күнектек инде. Безнең совет чынбарлыгына хас бу.

**(Социалистик Хезмәт Герое Алексей Григорьевич Стахановның КамАЗга язган хатыннан.)**

1975 елның беренче кварталында ял йортларына, пансионатларга, санаторийларга, курортларга путевкалар алу өчен 60 мең сумнан артык акча бүленде. Быел социаль страхование комиссиясе алдына шундый бурыч куелды: барлык Бөек Ватан сугышы инвалидларына ял итү һәм дәвалану өчен путевкалар бирергә.

Март аенда Венгриягә һәм Румыниягә туристик сәяхәткә бару күз алдында тотыла. Эшчеләр өчен путевка акчасының яртысын предприятиеләр түли. Җәй һәм көз айларында КамАЗ төзүчеләр ГДРга, Болгариягә, Чехословакиягә, Польшага һәм башка илләргә сәяхәткә барачаклар.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

Чаллыга СССР Министрлар Советы Председателе урынбасары В. Н. Новиков килде.

Аның белән бергә СССР автомобиль промышленносте министры урынбасары П. Я. Лисняк, СССР энергетика һәм электрификация министры урынбасары

Н. М. Иванцов һәм СССР монтаж һәм махсус төзелеш министры урынбасары К. К. Липодат бар иде.

В. Н. Новиков һәм аның белән килгән иптәшләр заводлар төзелешен, шәһәрнең торак массивларын карадылар, эшлекле киңәшмәләр үткәрделәр.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

ВЛКСМ Үзәк Комитетының беренче секретаре Е. М. Тяжельников Чаллы комсомол оешмасына ВЛКСМ Үзәк Комитетының космоста булып кайткан Кызыл байрагын тапшырды.

Яшь төзүчеләр исеменнән комсомол-яшьләр бригадасы җитәкчесе Виктор Шатунов бу югары бүләк өчен ВЛКСМ Үзәк Комитетына зур рәхмәт белдерде һәм бишьеллыкның тәгәлләү елында Бөтенсоюз комсомол удар төзелеше яшьләре дәүләт заданиеләрен үтәүдә барлык көчләрен куячагын әйтте.

«Комсомолец Татарии», Казан.

Күптән түгел Чаллыга капиталистик илләрнең берсеннән КамАЗга җиһазлар әзерләүче фирма эшләре белән бер бизнесмен килгән иде. Аңа комплексның корпусларын, ялан кыр өстендә үсеп чыккан яңа, хәзерге заман шәһәрен күрсәттеләр.

— Бу — колоссаль! Минем мондыйны күргәнем юк иде, — диде чит илдән килгән кунак гаҗәпләнеп. Аның бу сүзләре нәзакәтлелек күрсәтү генә түгел иде.

Монда промышленность төзелеше белән бергә, торак йортлар салу да киң колач белән бара. КамАЗ төзүчеләр узган елда 365 мең квадрат метр торак мәйдан белән тәэмин ителде. Бу — тугыз катлы 70 йорт эксплуатациягә тапшырылган дигән сүз. Тагын дүрт мәктәп, тугыз балалар бакчасы, ике универсам эшли башлады.

КамАЗ төзүчеләрнең, шәһәр коручыларның алда эшләре күп әле. Быел корпусларда массовый төстә җиһазларны монтажлау башлана, Чаллыда яңа күп катлы йортлар, кибетләр, мәктәпләр салына.

«Труд», Мәскәү.

Главмосстройның КамАЗдагы подразделениесе төзелеш башланган көннән бирле эшли. Шуңа күрә Чаллы урамнары, проспектлары, микрорайоннары Мәскәүне хәтерләтә. Яңа шәһәрне башлыча мәскәүлеләр проектлады һәм аны төзергә дә алар булыша: инде 150 мең квадрат метр мәйданлы 20 торак йорт салдылар. Коллектив социалистик йөкләмәләрне һәм каршылау планын вакытыннан элек үтәде.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

Чаллыдагы производство-бизәү мастерское хезмәткәрләре яңа салынган балалар бакчасын бизәкләү эшен тәмамладылар. Художниклар Л. Шаһиев һәм Н. Бобошко «Чебурашка» бакчасында, Г. Миргалимов, С. Слесарский һәм Э. Саманов «Алтын балык» бакчасында мозаика белән матур композиция эшләде.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

«Есенин — мәңгелек» — Николай Тихоновның бу сүзләре шагыйрьнең иҗатына багышланган әдәби кичәнең эпиграфы булды. Аны 4—15А тулай торагында эшләүчеләр оештырдылар. Кичәгә катнашучылар Есенинның тормышы, аның Ватанга, туган җир табигатенә мәхәббәте турында сөйләделәр.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

# *М. Е. САЛТЫКОВ-ЩЕДРИННЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ*

## РЕВОЛЮЦИОН САТИРА КЛАССИГЫ

Без әкиятләр китабы укыйбыз. Әмма кызыклы маҗара, фантастик вакыйгалар әкияте генә түгел алар. Персонажлары берсеннән-берсе катлаулырак, сәеррәк һәм мәзәгрәк: менә түрә булган Аю... Менә акыллы баш Комкорсак... менә үзен аямаучы Куян... менә Ат... Ләкин ул персонажлар да аллегория итеп кенә алынмаганнар. Алар һәммәсе — социаль сатира образлары, гомумиләштерелгән характерлар. Язучы шулар ярдәмендә социаль-политик идеяләрне алга сөрә, көйдергеч тәнкыйть утына алып, теге яки бу кимчелекне фаш итә.

Сүз тууына быел 150 ел тулган (1826—1889) бөек рус сатиригы Михаил Евграфович Салтыков-Щедринның үлемсез иҗаты турында бара. Искелек калдыкларына каршы безнең бүгенге көрәшебез өчен дә «бүгенге Щедриннар һәм Гогольләр кирәк» булганга үлемсез иҗат ул! Либераль тактикалы һәртөрле оппортунистларга каршы көрәштә Ленин аннан үрнәкләрне бик еш һәм оста кулланган.

Булачак язучының балалык еллары караңгы бер алпавыт утарында үтә. Ул гаделсезлек һәм эксплуатациянең ачы картиналарын, барин белән крестьяннар арасындагы каршылыкны үз күзләре белән күрә. Бу тормышны соңыннан ул үзенең «Пошехонская старина» исемле атаклы әсәрендә оста тасвирлый. Салтыков-Щедрин Пушкин укыган лицейда укый, революцион хисле яшьләр белән бик иртә аралаша, Белинский тавышын яшьли ишетә, тормышта гаделлек, кешелеклелек куерергә омтыла. «Каршылыклар» һәм «Буталчык эш» исемле беренче повестьларында ук бик ачык чагылган бу омтылышы өчен аны Вятка сөргенендә сигез ел чамасы газаплыйлар. Аның «губерна очерклары», бик күп сатирик цикллары һәм хикәяләрендә, җирне яңарта алучы көч буларак, халык массаларына ышану тавышы яңгырый. «Мин безнең гүзәл халыкны гомумән яратам...» дигән онытылмас сүзләрне ул горур әйтә.

Классик әдәбиятка Салтыков-Щедрин калдырган мирас гаять бай һәм үзенчәлекле мирас ул. «Помпадурлар һәм помпадуршалар», «Бер шәһәрнең тарихы», «Господа Головлевлар», ниһаять, искиткеч үткен сатирик әкиятләр миллионнар кулыннан хәзер дә төшми һәм төшмәячәк.

Аның илебездәге милли әдәбиятларда сатира жанры үсешенә дә йогынтысы көчле. Моны, мәсәлән, безнең Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Габдулла Тукай, Шакир Мөхәммәдов, Мәҗит Гафури, Шәриф Камал һ. б. иҗатыннан үрнәкләр белән бик нигезле расларга мөмкин. Бу мәктәп шәкертләренең безнең хәзерге әдәбиятта да күбрәк булуы өчен тырышу дәвам итә.

Салтыков-Щедрин әсәрләренең кайберләре әле Октябрь революциясенә чаклы ук татар теленә тәрҗемә ителгәнлеге билгеле. Аның шактый зур күләмле «Әкиятләр» китабы исә 1953 елда Казанда күренекле әдибебез Ибраһим Гази тәрҗемәсендә чыкты. Шуларның берсе хөрмәтле укучыларыбыз игътибарына тәкъдим ителә.

# М. Е. Салтыков-Щедрин

# ҮЗЕН АЯМАУЧЫ КУЯН



Шулай бер тапкыр куян бүре алдында гаепкә калды. Бүре оясыннан ерак та түгел бер җирдән чабып узган вакытта, бүре аны күрде дә: «Куянкай! Туктале, җанкисәгем!» — дип кычкырды аңа. Ә куян, кая ул туктау, тагын да катырак җилдертә башлады. Бүре аны өч сикерүдә тотты да әйтте: беренче кычкыру белән үк туктамаган өчен, менә сиңа минем карарым: мин сине үлем җәзасына хөкем итәм. Ләкин хәзергә мин тук, хатыным да тук, бер биш көнлек запасыбыз да бар, шул сәбәпле, син менә шушы куак астында үзеңнең чиратыңны көтеп утыр. Бәлки әле мин сине... ха-ха... гафу да итәрмен!

Куак астында арт тәпиләрендә утыра куян, селкенми дә. Бары тик бер генә нәрсә турында уйлый: ничә тәүлек һәм ничә сәгатьтән соң үләрмен икән, ди. Бүре оясына таба карап куйгалый, ә аннан бүре күзе, ялт-йолт итеп, аңа карап тора. Ә кайвакытларда тагын да яманрак: бүре үзенең хатыны белән килеп чыга да алан буйлап куян янынннан арлы-бирле йөри башлый. Куянга карап алалар да, бүре үзенең хатынына бүре телендә нәрсәдер әйтә, һәм икесе дә хахылдап көлешә башлыйлар. Балалары да аларга тагылып йөри; шаярышып, куян янына чабып киләләр дә аңа сарылалар, тешләрен шалт-шолт шакылдаталар... Ә куянның җаны уч төбенә кача!

Хәзерге шикелле бервакытта да тормышны яратканы юк иде аның. Йорт җанлы куян иде ул, бер тол куян хатынының кызына күз салган иде, өйләнергә теләгән иде. Бүре аның җилкәсеннән китереп тотканда, нәкъ әнә шул үзенең кәләше янына чабып барган чагы иде аның. Зарыгып көтә булыр инде ул аны, хыянәт итте миңа юньсез, дип уйлый булыр. Бәлки көткәндер, көткәндер дә бүтән берәү белән... яратыша башлагандыр. Бәлки куаклар арасында күңел ачып йөргәндә, бүре тырнагына эләккәндер...

Мескен куян шулай дип уйлый да күзләреннән мөлдерәп-мөлдерәп яшьләр ага. Барып чыкмады куянның хыяллары. Өйләнергә исәп итеп, самавар алды, яшь хатын белән бергә шикәрләп чәй эчү турында хыялланды һәм шуларның бөтенесе урынына — менә кая килеп капты! Үләргә ничә сәгать калды икән соң әле?

Шулай бер тапкыр төнлә белән йокымсырап утырганда, төш күрде ул: имештер, бүре аны махсус эшләр буенча түрә итеп үз янына алган, ә үзе, куян ревизияләр ясап йөргән арада, аның хатыны янына кунакка килә... Кинәт кемдер кабыргасына төрткән кебек булды аның. Борылып караса, ике китте — кәләшенең энесе килгән.

— Кәләшең үлем түшәгендә ята, — ди ул аңа. — Синең нинди бәлагә эләгүеңне ишетүгә сәгате-минуты белән авыруга сапты. Хәзер бөтен уе бер генә нәрсәдә: шулай ук үземнең бәгырь кисәгем белән бәхилләшмичә үлеп китәрменме икәнни! — ди.

Бу сүзләрне тыңлаган чакта, торкындагы куянның йөрәге телем-телем телгәләнде. Ник болай булды әле? Нинди эшләре өчен мондый аяныч язмышка тап булды ул? Яшеренеп яшәмәде, революцияләр ясап маташмады, корал күтәреп чыкмады, үз эше белән генә

бара иде бит — шуның өчен уларга тиешме? Үлем! Уйлап кына карагыз, сүзе дә аның нинди! Үзе генә үлсә әле бер хәер, кәләше дә бит. Аның гаебе нәрсәдә инде? Мин юньсезне җаны-тәне белән яратуында гына. Хәзер аның янына атылып кайтып керәсе иде дә, алгы тәпиләрең белән колакларыннан тотып, башыннан сыйпый-сыйпый, иркәлисе иде үзен. Кәләшенең энесе әйтте шул вакыт:

— Әйдә качабыз!

Бу сүзне ишеткәч, тоткындагы куян бөтенләй үзгәреп китте. Чабырга әзерләнгәндәй, йомарланып, колакларын аркасына салды. Менә хәзер-хәзер атылып китәр дә, эзен дә күрми калырсың кебек. Бу минутта аңа бүре оясына карамаска кирәк иде, ә ул карады. Йөрәге өзелеп төште куянның.

— Кача алмыйм, — диде ул, — бүре кушмады.

Ә бүре исә моның бөтенесен дә күреп, ишетеп торды һәм үзенең хатыны белән бүре телендә пышын-пышын сөйләште: куянны яхшылыгы өчен мактады булса кирәк. Кәләшенең энесе тагын:

— Әйдә качыйк! — диде.

— Кача алмыйм, — дип кабатлады куян.

Кинәт бүре җикереп җибәрде:

— Нәрсә анда сез чыштын-пыштын киләсез, нинди явызлык корасыз?

Куяннарның котлары очты. Каенесе дә килеп капты бит! Часовойларны качарга димләгән өчен, кагыйдә буенча, нинди җәза тиеш әле? Ах, куян кызы, куян кызы, кияүсез дә, энесез дә каласың бит, — бүре белән бүре хатыны икесен дә тотып ашыйлар бит!

Аңнарына килделәр куяннар, ә бүре белән бүре хатыны аларның каршында тешләрен шак-шак иттереп торалар, караңгыда икесенең дә күзләре фонарь шикелле яна.

— Без, ваше благородие, ни, болай гына... Үзара гына... якташ килгән, хәлемне белергә! — диде тоткындагы куян, ә үзенең куркудан коты алынды.

— Болай гына, имеш! Беләм мин сезне! Авызыгызга бармак каптырсаң, тешләп өзәрсез! Сөйләп бирегез, эш нәрсәдә?

— Эш шунда, ваше благородие, — дип, сүзгә кәләшенең энесе кысылды, — минем сеңелем, ә аның кәләше, үлем түшәгендә ята, үтенә синнән, бәхилләшергә җибәрә алмассыңмы аны?

— Һм... Кәләш үзенең егетен ярата икән, бу бик яхшы, — диде бүре хатыны. — Димәк, куян балалары күбрәк булачак, бүреләргә азык артачак. Без дә менә ирем белән яратышып торабыз, безнең дә балаларыбыз күп. Нихәтлесе читтә йөри, ә дүртесе хәзер дә үзебез белән тора. Бүре, сиңа әйтәм! Җибәрәбезме әллә кияүне, кәләше белән бәхилләшеп килсен.

— Аны бит берсекөнгә ашарга билгеләгән идек...

— Ваше благородие, мин килеп җитәрмен... Мин ялт итеп әйләнеп кайтырмын... мин бит... валлаһи менә, килеп җитәм! — дип, куян кабаланып сөйли башлады һәм, ялт әйләнеп кайтачагына бүре шик тотмасын өчен, шундый егетләр төсенә керде, бүре булып бүре аңа сокланып карап куйды һәм болай дип уйлады: «Солдатларым менә шундый булса иде минем!»

Ә бүре хатыны, уйга калып, әйтте:

— Кара син аны! Куян булып куян үзенең хатынын ярата!

Нишләмәк кирәк, куянны җибәрергә риза булды бүре, ләкин нәкъ вакытына кайтып җитүне шарт итеп куйды. Ә кәләшенең энесен үзендә залог калдырды.

— Әгәр ике тәүлектән соң иртән сәгать алтыга кайтып җитмәсәң, — диде ул, — синең өчен аны тотып ашармын, ә кайтып җитсәң, икегезне дә ашармын, бәлки... ха-ха... гафу итеп тә куярмын!

Атылган ук шикелле, очты гына куян. Шундый чаба, күз иярми үзенә. Тау очраса — тауны ике генә сикерә; елга очраса, сайрак урынны да эзләп тормый, туп-туры йөзеп кереп китә; сазлык очраса — түмгәктән түмгәккә генә элдертә. Уен түгел. Нихәтле җир кайтырга кирәк бит, кайтып мунча керергә, өйләнергә («әлбәттә, өйләнәм!» дип уйлап кайта ул), аннары, бүренең иртәнге ашына өлгерү өчен, кире чабып кайтырга кирәк...

Аның тиз чабуына хәтта кошлар да таңга калдылар — үзара сөйләшәләр: «Московские ведомости»[1] газетасында әнә язалар, янәсе, куяннарның җаны юк, җан урынына пар, диләр, — ә ул әнә ничек... элдертә.

Ахырда кайтып җитте ул. Шул вакыттагы шатлыкны күрсәң — язып та, сөйләп тә бетерерлек түгел. Кәләше, үзенең бәгырькәен күреп алгач, авыруын да онытты. Арткы тәпиләренә басып, барабан киеп алды да алгы тәпиләре белән «Атлы гаскәр маршы» көенә барабан кага башлады — егетенә шундый сюрприз хәзерләгән иде ул. Кәләшенең әнкәсе бөтенләй чуалып калды: кияүне кая утыртырга, ничек сыйларга белмәде. Төрле кардәш-ыруглар, туган-тумачалар килеп тулды — барысының да кияүне күрәселәре, кунакта тәмләрәк аштан авыз иттерәселәре килде.

Кияү генә бик борчулы утырды. Кәләше белән иркәләнешеп тә туймады, әйтә дә башлады:

— Мунчага кереп чыгасы иде дә тизрәк өйләнәсе иде!

— Ник алай бик кабаландырасың? — дип шаярткан булды кәләшенең анасы.

— Кире китәсем бар. Бүре тик бер генә тәүлеккә дип җибәрде.

Ул шунда сөйләп бирде эшнең ничеклеген. Үзе сөйли, үзенең күзләреннән мөлдер-мөлдер яшь ага. Китәсе дә килми, китмичә дә мөмкин түгел. Сүз бирде бит, ә куян үз сүзенә хуҗа. Туган-тумачалары, кардәш-ыруглары сүзгә катыштылар — алар да барысы беравыздан: дөрес сөйлисең кияүкәй, диделәр: әйткән сүз — аткан ук! Алдау дигән нәрсәнең куяннар токымында гомердә дә булганы юк!

Әкият бик тиз сөйләнә, ә куяннар арасында эш аңардан да тизрәк эшләнә. Иртә белән никах укыттылар, ә кич булыр алдыннан кияү үзенең яшь бикәче белән саубуллашты.

— Бүре мине, әлбәттә, ашаячак, — диде ул. — Син миңа тугрылыклы бул инде. Балаларың була калса, әйбәтләп тәрбиялә. Иң яхшысы, син аларны циркка бир: аларны анда барабан кагарга гына түгел, туптан борчак атарга да өйрәтерләр.

Һәм кинәт, онытылып китеп (тагын бүре исенә төште булса кирәк), өстәп куйды:

— Бәлки әле бүре мине... ха-ха... гафу да итәр!

Куянны син күр дә мин күр.

Ул рәхәтләнеп туйда типтереп йөргән вакытта, бүре оясы белән куянның туган иле арасындагы җирләрдә зур бәлаләр булып алды. Бер урында бик каты яңгырлар явып, моннан бер генә тәүлек элек куян мәшәкатьсез йөзеп чыккан елга, ташып, тугыз чакрымга җәелде. Икенче урында король Андрон король Никитага сугыш игълан итте, нәкъ куян барасы юлда сугыш кайный. Өченче урында үләт йөри башлады — карантинны әйләнеп үтү өчен, йөз чакрымлап чабарга кирәк. Аннары бүреләр, төлкеләр, ябалаклар адым саен сагалап кына торалар.

Акыллы иде куян, өч сәгать запаска калдырып, алдан ук исәпләп куйган иде ул; ләкин бер-бер артлы тоткарлыклар очрый башлагач, аның йөрәге «жу» итте. Кич буе чапты ул, төн буе чапты,

[1] Патша Россиясендә чыгып килгән газета.

тәпиләре ташка киселеп бетте, корсак йоннары, чәнечкеле агачларда йолкынып, салынып-салынып төште; күзләреннән нур качты, авыз кырыйларыннан канлы күбек акты, ә аның әле тагын әллә никадәр чабасы бар! Бүре алып калган дусы һич кенә дә күз алдыннан китмәде аның. Бүре янында постта басып торган килеш уйлый бугай инде: кияүкәебез, җанкисәгем, ничә сәгатьтән мине коткарырга килеп җитәр икән? ди бугай. Шул исенә төшкәч, тагын да катырак элдертә башлады ул. Тауларны, уйсу җирләрне, урманнарны, сазлыкларны — берсен дә санга сукмады. Ничә тапкыр инде йөрәге ярылам-ярылам дигәндә генә калды, ләкин йөрәген дә җиңде ул, буш тойгыларга үзен төп максаттан читкә борырга ирек бирмәде. Кайгыру, яшь түгү вакыты түгел. Барлык тойгылар тынсын, тик дусны гына бүре авызыннан тартып алып булсын!

Менә таң да ата башлады. Ябалаклар, ярканатлар йокыга талды. Салкын һава исеп куйды, һәм тирә-юньдәге барлык нәрсә тынды, әйтерсең лә үлделәр. Ә безнең куян чаба да чаба, ә үзе: шулай ук дустымны коткара алмам микәнни? дип, һаман бер уйны уйлый.

Кояш чыгышы кызара башлады; иң элек ерак горизонттагы ак болытлар өстенә аз гына ут сибелде, аннары күбрәк күбрәк һәм кинәт — ялкын! Үләндәге чык ялт-йолт итә башлады. Көндезге кошлар уянды, кырмыскалар, кортлар, бөҗәкләр килеп чыктылар; төтен исе борынга бәрелде; арышлар, солылар кыштырдашырга тотынды, кыштырдау көчәйгәннән-көчәя барды... Ә куян берни күрми, берни ишетми, һаман бер сүзне кабатлый: харап иттем дустымны, харап иттем!

Ниһаять, менә тау. Тау артында — сазлык һәм шул сазлыкта бүре оясы... Соңардың, куян, соңардың!

Тау башына менеп җиту өчен, соңгы көчләрен җыйды ул... менеп тә җитте. Ләкин ул инде чаба алмады, хәлдән таеп егылды... шулай ук барып җитә алмас микәнни?

Аның алдында бүре оясы уч төбендәге кебек күренә. Кайдадыр еракта, чиркәү манарасында, сәгать алтыны сукты, һәм һәр чаңның тавышы алҗып беткән куянның йөрәгенә чүкеч белән бәргән кебек итте. Алтынчы тапкыр сукканда, бүре үзенең оясыннан күтәрелде, киерелде һәм рәхәтеннән койрыгын болгап куйды. Менә ул куян энесе янына килде, аяклары белән эләктереп алды да тырнакларын аның корсагына батырды: икегә аерып ташламакчы булды — берсе үзе өчен, икенчесе хатыны өчен. Балалары да шунда: эти-әниләре тирәсенә утырганнар да тешләрен шалт-шолт иттерәләр, янәсе өйрәнәләр.

— Мин монда! Монда! — дип, куян кычкырып җибәрде, аның тавышы йөз мең куян тавышы кебек яңгырады. Һәм ул таудан сазлыкка атылып барып төште.

Бүре аны шунда мактап куйды:

— Күрәм, — диде ул, — куяннарга ышанырга мөмкин икән. Менә сезгә минем резолюциям: вакыт җиткәнче икегез дә менә шушы куак төбендә утырып торыгыз, соңыннан мин сезне ха-ха... гафу итәрмен.

# ТУКАЙНЫҢ ЯҢА ТАБЫЛГАН ШИГЫРЬЛӘРЕ

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның 1976 ел апрелендә тулачак 90 еллыгына аның дүрт томлык әсәрләр җыелмасы басылып чыгачагы турында хәбәр ителгән иде. СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты хәзерләгән бу дүрт томлык — үзенең фәнни эшләнеше, тулылыгы белән бөтенләй яңа басма. Анда кертелгән әсәрләргә шагыйрьнең үзе исән чакта чыккан барлык басмалары буенча яңадан текстологик тикшерү үткәрелде, элекке басмаларда киткән текст хаталары, урынсызга үзгәртү-кыскартулар, «редакцияләү»ләр төзәтелде. Беренчел чыганакларның күп өлеше үзгәрде, әсәрләрнең язылу һәм басылу даталары дөресләнде.

Яңа дүрт томлыкта Г. Тукайның моңа кадәрге басмаларына кертелмәгән әсәрләре дә урын алган. Журналыбызның бу санында укучыларыбызны шагыйрьнең яңа табылган шигырьләреннән кайберләре белән таныштырабыз. Безгә аларны институтның фәнни хезмәткәре, Тукай томнары төзүче һәм әсәрләренә искәрмәләр һәм аңлатмалар бирүче Рашат Гайнанов тапшырды.

## 1

**«Яз»**. Бу шигырь Уральск шәһәрендә 1906 елның 15 гыйнвареннан 1907 елның 15 маена кадәр (барлыгы 17 сан) Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин (1883—1940) редакторлыгында һәм Г. Тукайның актив катнашлыгы белән чыккан «Әлгасрел-җәдит» («Яңа гасыр») исемле әдәби, фәнни һәм иҗтимагый журналның 1907 елгы 4 нче (15 апрель) санында «Г. Тукаев» имзасы белән басылган. «Ахыры бар» дип куелган булса да, ахыры күренмәде.

Шигырь Тукайның үзе исән чакта чыккан җыентыкларында да, шулай ук бүгенгә кадәрге бүтән җыентыкларында да юк. Бу хәл әсәрнең язылып бетмәгән булуы яисә «Әлгасрел-җәдит»нең шушы 4 нче саны илнең бер генә китапханәсендә дә булмавы белән аңлатылса кирәк. Бу санны узган ел гына институтның фәнни хезмәткәре М. Гайнетдинов Алма-Ата китапханәсеннән табып кайтты, икенче данәсен пенсионерка Бадыйкшанова иптәш институтка бүләк итте.

### Яз

Тыныч торма, каләм, дәртеңне яз, яз!
Тагын җитте мөнәүвәр [1] яз, аяз яз.

Яза күр, и каләм, яз, гәрчә аз-аз,
Дәһ булсын, әйләсен дил иһтизаз[2], яз.

Эрергә башлады бозлар вә карлар,
Томаннар чыктылар җирдән вә парлар.

Төшерә искә язның бу томаны
Дөханы ахыр[3], — ахыр заманы.

[1] Мөнәүвәр — нурлы, якты.
[2] Әйләсен дил иһтизаз — күңел дулкынлансын.
[3] Дөханы ахыр — ахыр заманы — заман ахыры житүен белдергән актыкка ут-төтен,

Кисәктән җанланып, бозлар агалар;
Чабалар, берсен-берсе кагалар;

Белерсең син боларның мәхшәре[1] дип,
Бу бозларны — үлекләр гаскәре дип;

Өрелмеш дип белерсең санки[2] мөгез,
Вә яки мөгезен селкеткән үгез [3].

Болар әллә бара дәһшәтле судка[4],
Беленми: кайсы — җәннәт, кайсы — утка.

Бу галәмне тота бертөрле каушау,
Бөтенләй болганадыр, килә шау-шау.

Бөтен сахра гарип төсләр аладыр,
Болыт төсле ала булып каладыр.

Бераздан күрсәтәдер чын төсен җир,
Чәч орлык, сөр сабан инде, бу — чын җир.

Кояш та җып-җылы нурлар сачадыр,
Күңелсез җир йөзе күңелен ачадыр.

Китә, саубуллаша кыш зәмһәрире[5],
Чыга җиргә яшел чирәм хәрире[6].

Терелә, җанланадыр халкы галәм [7],
Яңара халкы Хаува, халкы Адәм [8].

Шулай шул: уйлата яз төрле якны,
Димәк ки — бер мәматны [9], бер хәятны [10].



## 2

«*** (Кыямәт якын килде...)» Уральск шәһәрендә 1906 елның 15 июненнән 15 ноябрена кадәр (барлыгы 6 сан) К. Мотыйгыйның — рәсми, Г. Тукайның фактик редакторлыгында чыккан демократик юнәлештәге, татар телендә беренче рәсемле сатирик «Уклар» журналының 5 нче (15 октябрь) санында «Хәсрәт» псевдонимы белән басылган «Куркыничлы хәбәр. Кыямәт» исемле юмористик парча ахырына урнаштырылган. Бу парчасында Тукай демократик юнәлештәге «Азад халык» (Казанда 1906 елның 4 июненнән 12 сентябренә кадәр — барлыгы 15 сан — Галиәсгар Камал редакторлыгында чыга) газетасының либераль-буржуаз «Йолдыз» (Казанда 1906 елның 15 гыйнварыннан 1918 елның 21 июненә кадәр — барлыгы 1900 сан — Һади Максуди (1868—1941) редакторлыгында чыга) газетасы белән кушылуын һәм Г. Камалның «Йолдыз»га эшкә керүен тәнкыйтьли.

---

[1] Мәхшәр — динчеләр уенча кыямәт (дөнья беткән) көндә яңадан терелгән кешеләрнең җыелу урыны һәм вакыты.

[2] Өрелмеш дип белерсең санки мөгез — дини мифология буенча, заман ахыры җиткәч, алла тарафыннан махсус билгеләнгән Исрафил фәрештә сур (мөгез, быргы) өрәчәк (кычкыртачак) һәм барлык үлекләр кубарылып чыгачак, имеш. Монда Тукай Коръәнгә ирониялн. Санки — әйтерсең лә, гүя.

[3] ...Вә яки мөгезен селкеткән үгез — дини мифология буенча, җир үгез мөгезләре өстендә, үгез исә диңгездәге өч балык өстендә тора; үгез мөгезен селкетсә, җир тетри яки дөнья бетә, имеш.

[4] Болар әллә бара дәһшәтле судка — Исрафил суры белән кубарылып чыккан барлык җан ияләре алла каршына хөкемгә барачаклар, имеш.

[5] Зәмһәрир — суыклык.

[6] Хәрир — ефәк.

[7] Халкы галәм — дөнья халкы.

[8] Яңара халкы Хаува, халкы Адәм — алла гөнаһлыларны, имансызларны аерып алып җәһәннәмгә, гөнаһсыз һәм иманлыларны оҗмахка җибәрәчәк, имеш.

[9] Мәмат — үлем.

[10] Хәят — тормыш, тереклек, яшәү.

Г. Камалның бу адымын һич тә кичерә алмаган Тукай «Дөнья бу, йа!» («Уклар», 1906, 5 нче, 15 октябрь) дигән сатирик шигырендә дә:

**Социал «Азад халык»ны черносотенный ясап,**
**Һади абзый мәсләгән мәсләк дидерткән дөньядыр,**

— дигән юллар белән тагын бер тәнкыйть уты астына ала.

Ниһаять, Казанга килеп, Г. Камал белән бергә «Яшен» исемле сатирик журналын чыгара башлагач та Тукай, журналның 1908 елгы 6 нчы (31 январь) санында «Гәмбертт» псевдонимы белән басылган «Актык сүзләр» исемле кечкенә фельетонында бу темага янә бер кагылып, түбәндәгечә «тешләп ала»: «Азад» гәзитәсе: «Хифзы[1] сыйххәт кирәк, сәламәт булырга кирәк, үләргә ярамый», — диде дә үзе назад китте дә барды, ди».

«Азад халык» газетасының «Йолдыз»га кушылуын тәнкыйть итү өчен Тукай кызыклы форма сайлый: «Куркынычлы хәбәр. Кыямәт» парчасында башта ул мәгърифәтче галим Шәмсетдин Күлтәсинең (1857—1932) астрономия буенча китаплары («һәйьәте җәдидә ысулыны носусе шәргыйә татбикъ», Казан, 1896; «һәйьәте җәдидә», Казан, 1899, «Мөфассал һәйьәте җәдидә», Казан, Университет матбагасы, 1899 һ. б.) турында юмор белән фикер әйткән була, аннары газетаның тукталуын һәм аның редакторы буржуаз газета редакциясенә эшкә керүен Ш. Күлтәси китапларында сөйләнгән йолдызлар бәрелеше нәтиҗәсе итеп сурәтли.

●

Кыямәт якын килде — җир сораучы ярылды[2];
Галимнәр тәүбә кыйлды — аллаһ дигел бәдәвам[3].

Замана ахры булды — хәятлар мәмат булды[4];
Көлгәннәр йөз түбән китте — аллаһ дигел бәдәвам.

«Фикер»дән көлгән иде һич сәбәпсез бер «Азад»[5];
Инде ул китте назад — аллаһ дигел бәдәвам.

### 3

**«Ахырзаман галәмәте».** Уральскида 1905 елның 26 ноябреннан 1907 елның май урталарына кадәр К. Мотыйгый редакторлыгында, Г. Тукайның актив катнашлыгы белән чыккан демократик юнәлештәге «Фикер» газетасының 1907 елгы 12 январь (2) санында «Мөәррих» («Тарихчы») псевдонимы белән басылган.

Г. Тукай XII йөз Урта Азия суфи шагыйре Сөләйман Бакыргани шигыре белән ачылган «Бакырган китабы» (беренче тапкыр Казанда 1846 елда чыга) җыентыгындагы төрле шигырьләрнең стиленә һәм формасына (ритм, рифмасын файдалачып) ияреп «Хатирәи «Бакырган», «Дөнья бу, йа!», «Тотса мәскәүләр якаң» һ. б. сатирик-юмористик әсәрләрен яза. Бу «Ахырзаман галәмәте» шигыре дә шулар рәтеннән. Ул «Бакырган китабы»ндагы «Килең, дустлар, бу дөнья кичде — ахыр булдия» дип башланган шигырь калыбына салынган.

Әсәр югарыда китерелгән «*** (Кыямәт якын килде...)» һәм бүтән байтак шигырьләре белән аваздаш икәнлеге һәркемгә ачык. Бу сатирасы белән Тукай ишаннардан көлә.

---

[1] Хифзы сыйххәт — сәламәтлек, сәламәт булу.
[2] ...Җир сораучы ярылды — «Азад халык» һәр санында диярлек «Җир һәм ирек!» лозунгысын күтәрә. Монда шуңа ишарә.
[3] Аллаһ дигел бәдәвам — «дәвамлы рәвештә, гел алла исемен кабатлап тор» дигән мәгънәдә. Шигырь «Бәдәвам китабы» (Болгар дәүләте чорында язылган, авторы билгесез көйле әсәр. Беренче тапкыр Казанда Университет матбагасында 1846 елда басылган) шигырьләре стиленә һәм формасына ияреп язылган.
[4] Хәятлар мәмат булды — тереклек, тормыш бетте, барысы да үлде.
[5] «Азад» — «Азад халык» газетасы («Азад» газетасы белән бутарга ярамый). Китте назад — артка китте, яшәүдән туктады.

## Ахырзаман галәмәте

Яэҗүҗ вә мәэҗүҗ[1] тугай,
Озын чапаннан булгай;
Җир йөзе фетнә тулгай
Шомлыгыннан тидия.

Нәфесле булгай үзе,
Үтемле булгай сүзе;
Корсагы гәр туйса[2] да,
Туймагай һич тә күзе.

Ашагай җирне-суны,
Әтәч, күркә һәм куйны;
Бик калын булгай муйны, —
Камыт сыймас тидия.

Ашагайлар һәм адәм,
Тешләре булгай һәп дәм[3];
Мисалларыдыр әм-әм[4],—
Орышырлар[5] тидия.

Милләтеңне белмәсләр,
Гыйлләтене[6] күрмәсләр;
Җилкә, корсак симертеп
Тик ятырлар тидия.



### 4

**[Бакирә җыры.]** «Әлгасрел-җәдит»нең 1907 елгы 3 нче (15 март) санында басылган «Ай, бат» исемле тәрҗемә хикәясендә Бакирә исемле кыз җыры буларак бирелгән. «Ай, бат!» хикәясе Кавказ халыклары арасындагы элекке кан үчлеге йоласына каршы язылган.

Төтен чыккан йөрәкләрдән — чокырларны томан алган;
Бөтен кырлар гөнаһсызлардан чыккан канлә[7] алланган.

Җылаңыз, валидәт[8]: хәсрәт илән йөзләр чокырлансын;
Бу вәхшәтләрне күргәнче әбәд[9] күзләр сукырлансын.

Сези[10] чын кызганып, һәрдәмдә[11] сез агъларга[12] башларда
Бәрабәр агълайур[13] кырлар, агачлар берлә ташлар да.

---

[1] Яэҗүҗ вә мәэҗүҗ — мифик ике халык. Дини мифология буенча, Зөлкарнәйн (Александр Македонский), Бөек кытай стенасын корып, аларны башка халыклардан аерган; дөнья бетәр алдыннан стенаны җимереп чыгып, алар җир өстендәге барлык нәрсәне ашап бетерея барачаклар, имеш. Русларда Гог-Магог.
[2] Гәр туйса да — әгәр туйса да.
[3] Һәп дәм — гел канлы.
[4] Мисалларыдыр әм-әм (ям-ям) — кеше ашаучылар кебек.
[5] Орышырлар — талашыр-сугышырлар.
[6] Гыйлләт — авыру.
[7] Канлә — кан белән.
[8] Валидәт — ата-ана.
[9] Әбәд — мәңгегә.
[10] Сези — сезне.
[11] Һәрдәм — һәр вакыт.
[12] Агъларга — еларга.
[13] Бәрабәр агълайур — шулай ук елыйлар.

**[Бакирәнең икенче жыры.]** «Әлгасрел-җәдит»нең шул ук санында басылган.

Бу ямьсез тауның өстеннән каһәрле нинди җил исте?
Исеп аңсыздан [1] ул безнең йөрәкләрне кисеп кичте.

Нә яшьне-картны белде, кыз-егетләрне нә фәркъ [2] итте:
Тоташтан екты, якты, атты, хәсрәтләргә гаркъ [3] итте.

Исеркәп[4] хәлебезне, кычкырып егълый хәҗәрләр дә[5];
Салынды, башларын бөкте, иелделәр шәҗәрләр дә [6].

Әгәр сахрага чыксаң, файдасыз,— тик хәсрәтең артыр;
Хәяттан [7] биздереп, сиреңүлмәгә мәйлеңә тартыр [8].

Кием кимеш кызылдан һәр чәчкәләр, лаләләр, гөлләр;
Кубармыш аһ вә фөрьяды [9] алар өстендә былбыллар.

Киемнәрне кызыл берлән кара төстән киендек без;
Күңелле туйны туйларга җыелдык һәм өелдек без.

Вә егъладык ачы күз яшь белән безләр тын алмастан;
Вәликин дилдәге [10] хәсрәтне егълап чыгармастан.

Исеркәп хәлебезне, кычкырып егълый хәҗәрләр дә;
Салынды, башларын бөкте, иелделәр шәҗәрләр дә.

«Бакирә жыры» һәм «Бакирәнең икенче жыры» үлчәвен Тукай соңыннан А. С. Пушкинның «Золотой петушок» поэмасыннан тәрҗемә булган «Алтын әтәч»ендә куллана, хәтта аерым строфаларны да файдалана. Чагыштырыгыз:

Исеркәп хәлебезне, кычкырып егълый хәҗәрләр дә;
Салынды, башларын бөкте, иелделәр шәҗәрләр дә.

**«Бакирәнең икенче жыры».**

Исеркәп ушбу хәлне, кычкырып егълый хәҗәрләр дә;
Салынды, башларын бөкте, иелделәр шәҗәрләр дә.

**«Алтын әтәч».**

[1] Аңсыздан — кинәттән.
[2] Фәркъ итү — аеру.
[3] Гаркъ итү — күмү.
[4] Исеркәп — сизенеп.
[5] Хәҗәр — таш.
[6] Шәҗәр — агач.
[7] Хәят — тормыш.
[8] Сиреңүлмәгә мәйлеңә тартыр — үләсеңне генә китерер.
[9] Фөрьяд — аһ-зар.
[10] Дил — күңел.

**Люциан Климович,**
филология фәннәре докторы

# ФАТИХ ӘМИРХАН ИҖАТЫ

XIX йөзнең соңгы чирегендә һәм XX йөз башында татарның алдынгы әдипләре, иҗатта урта гасырлар шартлылыгыннан тәмам арынып, зур күләмле реалистик әсәрләр тудыра башлыйлар. 1905—1907 еллар революциясе һәм шул чордагы милли-азатлык хәрәкәте тәэсирендә критик реализм җиңеп чыга.

Фатих Әмирхан әнә шул яңа агым татар әдәбиятының күренекле бер вәкиле була. Зур чәчмә әсәрләре, пьесалары, публицистикасы, рус һәм дөнья әдәбияты турындагы мәкаләләре, төрле тәрҗемәләре аша аның исеме халыкка таныла. Ф. Әмирханның иң көчле әсәрләре яшьләргә, киләчәккә зур ышаныч белән язылган һәм аларда заман каршылыклары ачык чагыла, киләчәк буын кешесенең мораль йөзе чалымлана.

* * *

Фатих Әмирхан 1886 елда Казанда мулла семьясында туа. Әтисе аны үзе кебек улын дин әһеле итәргә тели һәм шул ният белән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга бирә. Ләкин яшь Фатих тиз арада әдәбият белән мавыгып китә, мәдрәсәдә ачылган рус классларына укырга йөри, зур тырышлык белән рус телен һәм рус әдәбиятын өйрәнә. Мәдрәсәдәге укыту-тәрбия тәртипләре белән килешә алмыйча, ул шәкертләр арасындагы ислахчылар хәрәкәтенә кушыла һәм озакламый бу хәрәкәтнең җитәкчеләреннән берсенә әверелә...

Шәкертләр хәрәкәтенең үзәгендә кайнаган Фатих Әмирхан 1905 елның көзендә, 2 шәкерт белән бергә, мәдрәсәне ташлап чыга. Шуннан соң, үзлегеннән хәзерләнеп, гимназиянең тулы курсына имтихан бирә.

1905 елда Казанда яшерен рәвештә «Әльислах» газетасы чыга башлый. Фатих Әмирхан анда да төп җитәкчеләрнең берсе була.

1906 елда шәкертләр хәрәкәте ихтыяҗлары белән ул Мәскәүгә, Петербургка бара. Бирередә ул, белемен тирәнәйтү максаты белән, тарих һәм рус әдәбияты буенча лекцияләр тыңлый, Париж коммунасы тарихыннан зур мәкалә тәрҗемә итеп, аны «Әлгасрел-җәдит» журналында бастыра. Бу елларда Фатих Әмирхан большевик студент С. Н. Гассардан дәресләр ала. Аның революцион көрәш тарихы белән кызыксынуы, ихтимал, Гассар йогынтысында уянгандыр.

Шушы ук чорда аның күк җисемнәре, җир тетрәү күренешләре, Менделеев хезмәтләре турында популяр очерклары басылып чыга. Ул матур әдәбият әсәрләре тәрҗемә итеп тә каләм сынап карый. Аның тәрҗемәсендә Андерсен әкиятләре һәм

Бу мәкалә Ф. Әмирханның узган ел «Художественная литература» нәшриятында чыккан «Сайланма әсәрләр»енә «Кереш» рәвешендә язылган. Журналда бераз кыскартып басыла.

аеруча «Мәхәббәтсез үрдәк баласы» әкияте хәзерге көнгәчә яшь тәрҗемәчеләр өчен өлге булып торырлык.

1907 елда «Әльислах» газетасы ачык рәвештә чыга башлый. Фатих Әмирхан бу газетаның секретаре саналса да, чынлыкта, аның редакторы була. Биредә ул шул чорның иң алдынгы кешеләре — Хөсәен Ямашев, Габдулла Тукай, Гафур Коләхметов, Галиәсгар Камал белән якынлаша. Бу әдипләр «Әльислах» битләрендә еш-еш басылып торалар. Галимҗан Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемле хикәясе дә беренче кат шунда дөнья күрә. Фатих Әмирханның беренче әдәби әсәрләре шулай ук «Әльислах»та чыга.

Композиция төзеклеге, психологик тирәнлек һәм көчле гражданлык хисе — Фатих Әмирхан иҗатына хас төп сыйфатлар.

1909 елда басылган «Танымаганлыктан таныштык» хикәясендә яшь әдип тыштан ялтырап та эчке дөньясы гаять фәкыйрь булган берьяклы кешеләрдән көлә, белемгә, яктылыкка омтылучы киң карашлы яшьләрне аларга каршы куя. Европача тегелгән ялтыравык киемнәргә төренеп тә бөтен уй-хыяллары байлык туплаудан ары китә алмаган ялганчы һәм надан бай малае Гайса, аның гайбәтче әнисе, шундый ук гайбәтче һәм вакчыл Казан сәүдәгәрләре — бу хикәянең тискәре образлар галереясен тәшкил итәләр. Болар арасыннан тик Гайсаның сеңелесе Разия генә кешеләр белән мөнәсәбәттә үзенең сафлыгын, самимилеген югалтмаган. Дөрес, әлегә аның карашлары да шактый тар, шактый чикләнгән, әмма аның яктылыкка, мәгърифәткә омтылуы сизелеп тора һәм бу омтылышында Разия кайчак тәвәккәл генә адымнар ясаудан да курыкмый.

Казанда Идел пристанендә ул танышкан рус һәм татар егетләре, гимназияне тәмамлап, Мәскәү курсларына укырга китеп баручы татар студентлары — болары хикәянең уңай геройлары. Аларда шул чор яшьләренең уртак теләкләре, уртак фикерләре чагыла.

Язучы үз әсәрләрендә Печән базары карагруһчыларын һәм шулар кебек үк сөрсегән карашлы татар буржуазиясен каты тәнкыйть итә. «Бәйрәмнәр» хикәясендәге Вәли бай һәм аның улы Габделгаллэм нәкъ әнә шундыйлардан. Дини фанатизм белән агуланган бу кешеләр хатын-кызга кимсетеп, мыскыллап карыйлар, әмма үзләре фәхишәләрдән, җенси азгынлыктан бер дә чирканмыйлар. Ләкин иҗтимагый үсеш процессы аларны үзеннән-үзе башка көчләр, башка агымнар белән бәрелештерә. Түбән катлаудан чыккан алдынгы яшьләр хатын-кыз азатлыгы, дөньяви белем алу иреге, чын фән, реалистик сәнгать өчен көннән-көн кыюрак сүз ачалар. «Бәйрәмнәр» хикәясендәге Габделмәҗит — кара көчләргә каршы баш күтәргән әнә шундый яшьләрнең берсе. Габделмәҗитне һәм аның кунакларын Вәли бай дәһрилектә, азгынлык һәм оятсызлыкта гаепли. Әмма яшьләр аның йөзенә бәреп үз фикерләрен әйтәләр:

«— Оят дигән нәрсә бик кызык бит ул, — ди кунаклардан берәү, — сез хатын-кызның качмавын оятсызлык дисез. Ә, минемчә, кеше булып кешенең, башкаларыннан качып, башына әллә нинди кыяфәтсез чапаннар, эсседә шәлләр бөркәнеп йөрүе оятсызлык. Сез менә минем бу озын чәчемне оятсызлык саный торгансыз, ә мин башны ялтыратып алдырып йөрергә бик оялам...»

Вәли бай кебекләрнең гайбәтеннән һәм янауларыннан курыкмыйча, яшьләр әдәби кичәгә китәләр. Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк: 1907 елдан соң яшьләр өчен әдәби-музыкаль кичәләр оештыруда Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан кебек әдипләр һәрчак башлап йөргәннәр.

Ул елларда татар буржуазиясе аерым партияләргә берләшә башлый һәм үзенең съездларын уздыра. Әйтик, «Мөселман иттифакы» һәм «Сират-әлмөстәкыйм» («Тугры юл») партияләре. Дини һәм буржуаз-реформистик бу партияләр асылды бер үк фикердә, бер үк платформада торсалар да, еш кына үзара тарткалашалар, бер-берсен дәһрилектә, имансызлыкта, «кяфер»лектә гаеплиләр. Шундый партияләр оештырып йөрүче милләтчеләрнең һәм буржуаз филантропларның кайчак ни дәрәҗәдә вакчыл һәм көлке булулары Фатих Әмирханның 1908 елда басылган «Милләт тәрәккыйы итерү» исемле хикәясендә ачык чагыла.

«Габделбасыйр гыйшкы» исемле әсәрендә язучы инде үзен тәмам ныгып, өлгереп җиткән каләм остасы итеп таныта. Бу әсәрендә ул шәкертләр тормышын тирәнтен белеп, җиңелчә ирония белән Габделбасыйрның хыялый гыйшкыннан көлә. Габдел-

басыйр үзе уйлап чыгарган хыялый мәхәббәткә тора-бара үзе үк ышана башлый һәм һәм хәтта кайбер дусларын да ышандыра. Бу шәкерт образы аша әдип иске мәдрәсәнең күзгә артык ташланмый торган тагын бер әшәке ягын — кешене физик һәм рухи яктан гарипләндерә баруын сурәтли.

Соңра бу әсәр таҗик язучысы Садретдин Айнинең дә игътибарын җәлеп итә. «Бохара» исемле китабының «Шагыйрьнең өйләнүе» исемле бүлегендә ул да нәкъ шуңа охшашлы вакыйгалар турында сөйли.

Фатих Әмирхан үз халкының язмышы өчен тирәнтен борчылып яши. Шуңа күрә яшьләргә бернинди хезмәт күнекмәләре бирмәгән, аларны эшлексез буш башлар, коры куык, мактанчыклар итеп тәрбияләгән иске мәдрәсә кануннарына каршы чыга.

Искиткеч үткен юмор белән язылган «Сәмигулла абзый» исемле җыйнак кына хикәясендә язучы татар тормышындагы үтә вакчыл мещанлык күренешләрен тәнкыйтьли. Язучы саран гына буяулар белән бөтен гомерен чәй, шикәр турында сөйләшеп утыручы эшлексез, мыжык карт образын тудыра. Шикәрне чәйгә салып эчәргәме, әллә кабып кынамы — Сәмигулла картның бөтен кайгысы әнә шул. Әмма Сәмигулла образын аның гаиләсеннән башка күз алдына китереп булмый. Беренче карашка үтә юаш күренеп тә, чынлыкта исә йорт башы булган Маһитап абыстай да, аларның кызлары да рухи үсешләре ягыннан Сәмигулладан әллә ни ерак китмәгәннәр.

Мәкәрҗә ярминкәсенә сәфәр чыкканда күпме чәй, күпме шикәр алу хакында алар арасында бетмәс-төкәнмәс кирәксез бәхәс бара. Шуның аркасында Сәмигулла белән улы Хәкимулла пароходка соңгаралар. Гаилә членнарыннан бер Хәкимулла гына йорттагы шундый тәртипләрдән, вакчыллыктан риза түгел. Димәк, биредә заман сулышын тою ягыннан бала атадан өстен чыга. Ләкин әле яшьләрне электән басып килгән баш ию, өлкәннәргә буйсыну гадәтләре тыеп тора. Бу яктан караганда, язучының 1912 елда басылып чыккан «Хәзрәт үгетләргә килде» хикәясе дә шактый гыйбрәтле.

Үгет-нәсихәт бирү өчен, шәһәрдә укучы баласы янына берәр мулланы яки берәр диндар картны яллап җибәрү татарларда элек-электән бер гадәт булып килгән. «Хәзрәт үгетләргә килде» хикәясендә Фатих Әмирхан әнә шул искергән юлдан көлә. Мәдрәсә тәмамлаган Закир өлгергәнлек аттестатына имтихан бирергә җыенып йөри. Шул чак, аны үгетләргә дип, заманында кадими Бохара мәдрәсәсендә укып, соңра Каргалы мәдрәсәсендә мөдәррислек иткән хәзрәт килеп чыга. Ләкин бу юлы ул үзенең элекке шәкерте алдында акыл сата алмый. Иске мәдрәсә тәрбиясеннән ваз кичкән алдынгы яшьләр белән бәрелештә аның фикерләренең үтә көчсез булуы гына түгел, хәтта хәзерге көндә бөтенләй көлке икәнлеге ачыклана.

Фатих Әмирхан һәр әсәрендә диярлек күпмедер дәрәҗәдә хатын-кыз иреге мәсьәләсенә кагыла. Әле 1909 елда ук «Татар кызы» исемле хикәясендә ул зур социаль әһәмияткә ия булган шушы теманы күтәреп чыга. Корьәннең сиксән беренче аятендә борынгы мәҗүсилек йолалары телгә алына. Ул йортлар буенча, имештер, гаиләдә беренче булып кыз бала туса, тереләтә җиргә күмелергә тиеш булган. Кыямәт көнендә ул баладан, янәсе: «Ни гөнаһларың өчен тереләтә күмелдең?» — дип сораячаклар икән. Фатих Әмирхан үз заманының хатын-кызларына да корьән-шәрифтәге шул сорау белән мөрәҗәгать итә... Әйе, алар да, борынгы мәҗүсилек чорындагы кебек үк, тереләтә җиргә күмеләләр. Чөнки алар алты яшьтән алып соңгы көннәренә кадәр бернинди хокуксыз хәлдә, кара чадра астына ябылып яшәргә мәҗбүрләр. Шуңа күрә Фатих Әмирхан үз иҗатында бу темага кат-кат әйләнеп кайта, хатын-кыз азатлыгы өчен, татар кызларына дөньяви белем бирү өчен гомере буе көрәшеп килә. 1910 елда ул «Рәхәт көн» исемле хикәясендә дин-шәригать изүе астында бичара хәлгә калган татар хатын-кызлары — Мөхип карчык һәм Гайниҗамал образларын иҗат итә. Шунда ук без яшь татар егете Закир белән янә очрашабыз. Хәзер инде ул — студент. Аның бәйрәм көнне рус кызы белән көймәдә йөрүе, аннары, берәүдән дә куркып тормыйча, кибеткә керүе Мөхип белән Гайниҗамалга искиткеч инсафсызлык, зур гөнаһ булып күренә.

1911 елда Фатих Әмирхан «Хәят» повестен яза. Лирик җылылык белән сугарылган бу әсәрендә әдип үз йөрәгендә туган якты хисләр өчен көрәшә алмаган, дин, шәригать һәм иске йолалар тарафыннан рухи зәгыйфьләндерелгән татар кызының тирән фаҗигасен ачып бирә. Хәят үзенә яшьтән үк таныш булган студент егеткә

ташыйк була, әмма үзе хисләрен белдерүдән курка. Егет тә аның бу халәтен яхшы аңлый. «Сез бәлки мине рус булганга күрә үзегезгә муафыйк күрмәссез, — дип яза ул Хәятка,— ләкин, дускаем, сөю дигән нәрсә миллләт аермаларын белми торган көчле нәрсә икән ул...»

Фатих Әмирхан ирләр һәм хатын-кызлар арасында яңача мөнәсәбәтләр урнаша башлавын да күрмичә узмый. 1912 елда Рашат исемле яшь егетнең бераз сентиментать, әмма үтә саф мәхәббәт мажаралары турында берничә хикәя иҗат итә. Бу хикәяләрдән тирән оптимизм, тормышны, кешеләрне ярату, мәхәббәткә, ирекә, азатлыкка омтылу хисе бөркелеп тора.

«— Я рабби, нинди шәп нәрсә бу тереклек! — ди Рашат «Кадерле минутлар» хикәясендә.— Аның һәрбер минуты үзенә бер төрле чәчәк ата!»

«Рәхәт көн», «Хәят», «Кадерле минутлар», «Татар кызы» хикәяләрен укыгач, аларның бай тел белән язылган матур әдәбият әсәрләре генә түгел, бәлки үзенчәлекле тарихи документлар икәнен аңлыйсың. Аларда Ф. Әмирхан революциягә кадәрге чынбарлыкка хас булган гаять зур тарихи материалны гомумиләштергән. Ә инде шул ук хикәяләрне тагын бер кат укысаң, ирексездән уйга каласың: әнә бит ничек — чагыштырмача зур булмаган бер вакыт эчендә Татарстан хатын-кызлары нинди зур үсеш юлы узганнар, тугандаш халыклар белән бер сафта нинди зур сикереш ясаганнар.

«Рәхәт көн» һәм «Хәзрәт үгетләргә килде» хикәяләрендә Закир исеменең кабатлануы очраклы хәл түгел, әлбәттә. Биредә, бер үк исемнең кабатлануыннан бигрәк, тәмамланган сюжетлы ике мөстәкыйль хикәядәге характерларның тәңгәл килүе уйландыра. Бу хикәяләр ниндидер зур бер әсәр өчен хәзерләнгән фрагментлар булса кирәк, дигән фикер туа.

Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп китик: Ф. Әмирханның әдәби мирасында тәмамланмый калган әсәрләр берничә. Алар арасында иң зурысы — «Урталыкта» романы.

Аның төп персонажларыннан Хәсән Арсланов, Саматов, Мария, Габдрахман образлары, гомумиләштерелгән әдәби характер буларак, әле формалашып җитмәсәләр дә, аларда шул чорга хас карашлар шактый ачык чагыла. Мәдрәсәне тәмамлаган Хәсән Арсланов хәзергә әле тормышта үз юлын тапмаган. Ләкин ул инде кайбер нәрсәләрне төшенә, иске мәдрәсә биргән белемнең генә җитәрлек булмавын, милли чикләнгәнлек, дини схоластика заманнарының узып баруын абайлый, русның алдынгы кешеләре белән аралашу кирәклеген аңлый башлаган. Тик шулай да әле ул патша хөкүмәтенә, социаль коллыкка каршы көрәшкә күтәрелгән кешеләрдән читләшә, революциядән курка, үз язмышын куркыныч астына куймыйча гына рәхәт тормышка, байлык-муллыкка ирешергә тели. Кыскасы, аңарда әле вак буржуаз карашлар өстенлек итә.

Хәсән образында Закир шәкерткә хас күп кенә сыйфатларны чалымларга мөмкин. Әмма, әйткәнебезчә, роман тәмамланмый калган. Шунлыктан, Хәсән һәм башка геройларның язмышы нәрсә белән, ничек тәгәлләнәсен әйтү кыен.

Фатих Әмирхан иҗатында аерым урын тоткан иң зур, иң әһәмиятле әсәрләрнең берсе — «Фәтхулла хәзрәт» повесте һәм аңа кереш рәвешендә басылып чыккан «Минем тәрҗемәи хәлем» хикәясе. Бу хикәядә, чыннан да, язучының үз тормышыннан алынган автобиографик материаллар шактый. Әмма шул ук вакытта гомумиләштерелгән урыннар да бар. «Фәтхулла хәзрәт» повесте үзе исә гади фантастика гына түгел, бер үк вакытта сатирик әсәр дә.

Дини-схоластик караш җимерелә барган, фән һәм техника үсеше алга киткән шартларда фантастика жанрына мөрәҗәгать итү — барлык халыклар әдәбиятына диярлек хас нәрсә. Бу очракта язучы үз чорындагы иҗтимагый каршылыкларны хыялында туган фантастик җәмгыятькә күчерә һәм, биниһая зур көзгедә чагылган кебек итеп, үз заманы кешеләренә күрсәтә. «Фәтхулла хәзрәт» повестенда мондый бурыч тагын да катлаулана. Чөнки язучы әсәрдә, кайбер прототиплар итеп, үз чоры кешеләрен ала һәм хәтта шул заманның аерым партияләрен, аерым җәмгыятьләрен сатира утында көйдерә. Фатих Әмирханның тәнкыйть уклары иң элек реакцион динчеләргә һәм аларның матбугат органы булган «Дин вә мәгыйшәт» журналына барып кадала. Оренбургта миллионер Гани Хөсәенов акчасына 1905 елдан 1917 елга кадәр чыгып

килгән бу журнал кадимчеләрнең төп штабы була. «Минем тәрҗемәи хәлем» хикәясендә Фатих Әмирхан бу журнал редакторларының мин-минлеген һәм наданлыгын тәнкыйть итә.

Икенчедән, «Фәтхулла хәзрәт» повестеның әче сатирасы буржуаз реформачыларга китереп суга. Үзләрен чын демократлар, ысул җәдитчеләр дип, купшы сүз бәйләп йөргән бу кешеләр чынбарлыкта шәкерт хәрәкәтенең колач җәюеннән куркалар, тора-бара хәтта үз сүзләреннән үзләре үк шүрли башлыйлар. Вак-төяк, ярым-йорты үзгәрешләр аларга чын демократик тәртипләр урнаштыру булып күренә.

«Фәтхулла хәзрәт» повестеның сюжеты артык катлаулы түгел. Казан университетының медицина профессоры Мөслимов һәм 1908 елда үлгән Фәтхулла хәзрәтнең улы Әхмәт, фәннең яңа казанышларына таянып, мулланы кырык ике елдан соң яңадан терелтәләр. Үзе «йоклаган» арада дөньяда булган үзгәрешләрне күреп, Фәтхулла бик гаҗәпсенә. Гаҗәпсенеп кенә дә калмый, җиң сызганып, иске тәртипләрне яңадан урнаштыру чарасына керешә. Хәтта шул мәсьәлә буенча халык алдында вәгазь дә сөйли. Әмма яңа заман кешеләре Фәтхулланы аңламыйлар һәм аңларга да теләмиләр.

Фатих Әмирхан бу әсәрендә татар халкының киләчәк язмышы турында күрәзәчелек итәргә алынмый. Ул бары яңа Казандагы кайбер үзгәрешләрне һәм Әхмәт ганләсендәге яңача көнкүрешне тасвирлый. Әсәрдә фәнни фантастика элементлары артык күп түгел. Ә шулай да кырык ике ел эчендә дөнья шактый үзгәргән. Кешеләр рухи яктан баеганнар, зур белемгә, мәгърифәткә ирешкәннәр. Алар сугышка, дини ызгыш-талашка каршы; фанатизм, төрле хорафатлар, милли кәпренүләр алар өчен бөтенләй ят нәрсә. Шул ук вакытта алар җәмгыять тәртибен, әхлак нормаларын бозуга юл куймыйлар. Җәмгыять тәртибенә буйсынырга теләмәүчеләр тиешле җәзасын ала. Фәтхулла хәзрәт театрда утырганда артистларны бүлеп кычкыра башлагач, шунда ук тәртип саклаучы егет килеп җитә һәм хәзрәткә залдан чыгып китәргә куша. Биредә фән-техника яңалыклары да шактый кызыклы. Кешеләр шәһәр буйлап автомобильдә чабалар, канатлар куеп очып йөриләр, оча торган көймәләргә утырып, болытларга кадәр күтәреләләр, шул очкычлары белән турыдан-туры үз йортларының балконнарына килеп төшәләр... Югары катларга лифт-эскалаторларга охшаган күтәргечләр йөреп тора, һәр бүлмәдә көзгеле телефон эшли, телефоннан сөйләшүчеләр бер-берләрен ачык күреп торалар... Әмма боларны тасвирлау язучы өчен төп максат түгел. Аның үзалдына куйган иң зур бурычы — яңа заман кешесен, аның рухи дөньясын ачу. Чыннан да, бу әсәрдәге яңа заман кешеләре, Фәтхулла хәзрәт белән чагыштырганда, бөтенләй башка, моннан кырык ике ел элек дөньяның кендегә булып, дини йолаларны саклап, халыкны акылга өйрәтеп йөргән Фәтхулла хәзрәт хәзер алар алдында көлке булып күренә...

Әсәрдә яңа заман кешеләренең социаль мөнәсәбәтләре бик аз күренә. Әмма андый мөнәсәбәтләр чагылып киткән урыннарда хикәяләү тагын да отышлырак яңгырый. Әйтик, хатын-кызның зур белемгә ия булуы, файдалы иҗтимагый эшкә ирләр белән берлектә катнашуы повестьта шактый уңышлы күрсәтелгән. Биредә, контраст буларак, Фәтхулла хәзрәтнең театрда уйлаган уйлары гыйбрәтле. «Хатын-кыз» адвокат булгач, чапан бөркәнеп йөрми шул инде ул!» — дип кычкырырга тели Фәтхулла.

«Фәтхулла хәзрәт» повесте үз заманында татар җәмәгатьчелегенең төрле катлауларында шактый шау-шу тудыра. Чөнки, әйткәнебезчә, аның уклары реакцион диниләргә, кадимчеләргә генә түгел, үзләрен ысул җәдитче дип йөрткән буржуаз милләтчеләргә дә кадала.

«...Син «тар балаклар» дип йөртә торган кешеләрнең һәммәсе синең шикелле үк надан, синең шикелле үк мотагассыйп...— ди Әхмәт әтисенә.— Барыгыз да бер булган инде: ул гыйлемхаль язучы ысул җәдитче, «Мөхтәсар»дан дәрес бирүче ысул кадимче, барысы да миләре бертөрле чүпләр белән тутырылган кешеләр булганнар. Бер-берегезне аңлашмый гына сүгешеп йөргәнсез тик...»

1908 елда, «Фәтхулла хәзрәт» повестеның беренче бүлекләре басылып чыкканнан соң, Казан ахуны Йосыф Сәгыйтов, указлы ун мулла белән берлектә, «Әльислах» газетасын ябтыруны сорап, губернаторга прошение бирә. Күрәсең, бу очраклы хәл булмагандыр. Чөнки Фатих Әмирхан иҗатын өйрәнүче галимнәрдән кайберәүләр Йосыф ахунны Фәтхулла хәзрәтнең прототибы дип саныйлар.

*
* *

Билгеле булганча, бер генә язучының да һәр язганы бертигез дәрәҗәдә булмый. Фатих Әмирхан әсәрләренә карата да шуны ук әйтергә мөмкин. Әмма аның әдәби мирасын тирәнтен өйрәнгәннән соң язучының үткер акылына, күзәтү сәләтенә, рухи байлыгына сокланасың. Бигрәк тә аның әсәрләреннән бөркелеп торган көрәш дәрте, яшәү шатлыгы таң калдыра. Ә бит, карасаң, язучының тормышында кешене сыгып төшерерлек авырлыклар да шактый булган.

1907 елда егерме бер яшендә паралич авыруыннан аның ике аягы да хәрәкәтсез кала. Шуннан соң гомере буе ул коляскага утырып кына йөри. Әмма болар ялкынлы әдипнең рухи ныклыгын сындыра алмыйлар. Һәм үзенең иң зур, иң катлаулы әсәре булган «Фәтхулла хәзрәт» повестен әдип егерме дүрт яшендә яза.

Фатих Әмирхан 1926 елның 9 мартында вафат була.

Яшь Татарстан республикасында һәм бөтен совет илендә барган бөек төзелешне күреп, гомеренең соңгы елларында әдип Ленинга, Кызыл Армиягә, иҗади хезмәткә дан җырлый. Бу уңайдан «Чәчәкләр китерегез миңа» исемле кыска гына нәсергә игътибар итми булмый. Нәсер 1921 елда язылган... Татарстанда һәм бөтен Идел буенда ачлык, ялангачлык, тиф, саранча... Илдә гражданнар сугышы китергән бөлгенлек хөкем сөрә. Һәм шул хәлләрдә дә язучы үз иҗатына тугры булып кала, халыкка күтәренке рухлы, якты эчтәлекле әсәрләр кирәклеген яхшы аңлый. Үтә таләпчән каләм остасы буларак, ул яңа җәмгыятьтән, тормыштан, табигатьтән иҗат өчен яңа буяулар эзли.

Фатих Әмирхан үзенең бөтен язмышын халык язмышы белән бәйләгән какшамас рухлы язучы була. Шуңа күрә аның иҗаты татар әдәбиятын киң колачлы реалистик әсәрләр белән баетты һәм СССР халыклары әдәбиятының алтын фондына кереп калды.

Г. САБИТОВ тәрҗемәсе.

## Мөхәммәт Мәһдиев

# ФАТИХ ӘМИРХАН ЖАНДАРМЕРИЯ КҮЗӘТҮЕ АСТЫНДА

Милләтләрнең күзе ачылу — дөньяви белемнәргә, рус демократик культурасына тартылу һәм, ахыр чиктә, пролетариат идеологиясенә таба борылу дигән сүз. Моны патша хөкүмәте дә бик яхшы аңлаган. Һәм, яңа революцион күтәрелеш елларында азчылык милләтләр арасында кабат хөррият дулкыны кузгалмасын өчен, күп төрле чаралар күргән. Арадан берсе — 1910 елда Эчке эшләр министрлыгы янында дини эшләр департаменты председательлегендә оештырылган махсус киңәшмә. Бу киңәшмәгә Православие дини идарәсеннән, Эчке эшләр министрлыгыннан, шулай ук халык мәгарифе органнарыннан үзәктәге һәм урыннардагы вәкилләр катнаша.

Махсус киңәшмәдә, төп мәсьәләләрнең берсе төсендә, Россия империясенә кергән мөселманнарга мөнәсәбәт мәсьәләсе карала. Патша чиновниклары, барыннан да бигрәк, Россия мөселманнарының үзара берләшү ихтималы куркыта. Һәм алар, шул хәлне булдырмас өчен, конкрет чаралар күрергә булалар. Төп һөҗүм татарлар арасындагы революцион азатлык хәрәкәтенә каршы юнәлтелә. Бу көрәш жандармерия тарафыннан панисламизмны әзерләклəү флагы астында алып барыла. Панисламизм

эзләү битлеге астында татарларның белем учаклары, мәгърифәт үзәкләре — уку йортлары, китапханәләр, нәшриятлар туздырыла, язучылар эзәрлекләнә, матбугат кысрыклана. Казан губернасын тентүләр, доносләр басып китә. Царизмның бу политикасын кадимче татар байлары, мулла һәм ишаннар үз мәнфәгатьләре өчен файдаланалар. Яңалык тарафдарлары булган һәр кеше өстеннән жандармериягә аноним әләкләр җибәрелә. Шул әләкләр нигезендә Г. Камал, Г. Тукай, Г. Коләхметов, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ф. Кәрими, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, Ш. Әхмәдиев, Ә. Хәсәни һәм башкалар күзәтү астына алына. Күренекле татар язучысы Фатих Әмирхан жандармерия күзәтүе астына әнә шул шаукым тәэсирендә килеп керә.

Жандармерия чиновникларына Ф. Әмирханның әтисе Зариф хәзрәт тә яхшы таныш була. 1905 елның 16 ноябрендә «Сарай» номерларында Казандагы сәяси партияләрнең программаларын ачыклау җыелышы уздырыла. Җыелышта эсерлар, социал-демократлар, «халык иреге» партиясе вәкилләре һ. б. катнаша. Социал-демократлар, буржуй белән пролетарийның бер партиягә сыешуы мөмкин түгел дип, милләтчеләрне кискен тәнкыйтьләп чыгалар. Әлеге җыелышка Галиәсгар белән Зариф Әмирхан да килгән була. Бу хәл жандармериягә барып ирешә [1]. Шул көннән башлап, Әмирхановлар турында жандармериядә кәгазьләр туплана башлый.

Зариф Әмирханның иҗтимагый эшчәнлеге өстеннән күзәтү 1908—1909 елларда тагы да көчәя. 1908 елда жандармериянең бер «ышанычлы кешесе» (татар) махсус задание буенча бөтен Казан губернасын йөреп чыга һәм белешмә төзи. Бу белешмәдә татарлар арасында панисламизм хәрәкәте барлыгы, бу хәрәкәтнең төп максаты хөкүмәтнең миссионерлык политикасына каршы көрәш икәнлеге әйтелә. Моның башында торучылардан берсе итеп Зариф Әмирхан исеме атала [2]. Казан фабриканты Якуп Козлов жандармериягә биргән әләгендә З. Әмирханны «соң чиктәге сул карашлы кеше» дип бәяли [3]. Жандармериянең ышанычлы әләкчесе, Казан шәһәренең хәрби мулласы Фасыйх Мөхетдинов та З. Әмирханны «сәяси яктан ышанычсыз шәхес» дип күрсәтә. Зариф Әмирханов, ди ул үзенең әләгендә, «бик сак һәм бик яшерен рәвештә хөкүмәткә каршы пропаганда алып бара» [4].

Шул ук елда Казан шәһәренең 12 мулласы, «хөкүмәткә каршы эш алып баралар» дип, З. Әмирхан һәм Ш. Шәрәф өстеннән Эчке эшләр министрлыгы канцеляриясенә әләк язып җибәрәләр. Бу мәсьәлә буенча шактый озак языш алып барыла. һәм 1910 елның 12 июнендә Казан губерна жандармерия идарәсе (КГЖУ) начальнигы З. Әмирхан белән Ш. Шәрәф өстеннән яшерен күзәтү алып барырга дигән карар чыгара [5].

1911 елның 27 январенда Казанның Галиев мәчетендә мәүлид бәйрәме уздырыла. Шымчы мулла Сираҗетдин Зәбиров Россия эчке эшләр министры Макаровка язган әләгендә бу бәйрәмдә Зариф Әмирханов һәм тагын берничә кешенең патшага бәддогага укыганлыкларын әйтә. Бу мәсьәлә буенча тикшеренүләр Зариф Әмирхановның патшага түгел, ә әләкчеләргә бәддога кылганлыгын раслый [6].

Ф. Әмирхан әнә шундый «политик ышанычсыз» семьяда тәрбияләнеп үсә. Әмирханнар семьясына кагылышлы документларда Әхмәтгәрәй Хәсәни исеме дә еш очраганлыктан, аның белән дә танышып үтик (Матбугатта Ә. Хәсәни дип тә, Г. Хәсәни дип тә йөртелә).

Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы Хәсәнев 1883 елда Әтнә авылында крестьян семьясында туа. Аңа алты яшь тулганда әтисе Казанга күчеп килә, сәүдәгәрлек итә башлый. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлагач, әтисе Гәрәйне дә сәүдә эшенә тарта. Ләкин Гәрәй әдәбиятны сайлый. 1906 елдан ул матбугат эшенә күчә. Кирәк кадәр акча туплаган, Казан шәһәрендә «Гасыр көтепханәсе вә ширкәте» ачып җибәрә. «Гасыр»ның китапларын Харитонов баса. Гәрәй Хәсәни шул чорда Г. Коләхметов, Х. Ямашев, С. Рахманколый, Г. Кәрам кебек алдынгы карашлы яшьләр белән очраша [7].

---

[1] Татарстан дәүләт архивы (ТДА). I фонд, I тасвирлама, 633 эш, 36 документ.
[2] Шунда ук. 199 фонд, I тасвирлама, 1729 эш, 11 һәм 13 документлар.
[3] Шунда ук, 39 документ.
[4] Шунда ук, 42 документ.
[5] Шунда ук, 1715 эш, 156 документ.
[6] Шунда ук, 2269 эш, 189 һәм 199 документлар.
[7] 1912 елның 13 мартында кич сәгать 8 дә Х. Ямашев нәкъ менә шул китапханәдә үлә. Г. Коләхметов белән китапханәгә килеп кергәч, Ямашев кинәт кенә үзен начар хис итә, башы әйләнә. «Это первый раз в жизни» дип әйтә дә, озак та үтми үлә. Бу истәлекләрне авторга Зәйнәп Хәсәни сөйләгән иде.

1912 елның 15 декабренда Зәйнәп һәм Гәрәй Хәсәниләр акчасына «Аң» журналы чыга башлый. Зәйнәп Хәсәнинең сөйләвенә караганда, журналның исемен Тукай тәкъдим итә. И. Рәми бу журналны шул чордагы «нәфис әдәбият белән тулып чыккан, художествоны эченә алган бердәнбер, чын мәгънәсе белән әдәби журнал» дип атый [1]. Журнал Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Ш. Камал, К. Тинчурин, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Газиз, Г. Рәхим, С. Рахманколый, Г. Кәрам, Г. Алпаров, М. Гали, Н. Думави, Г. Сөнгати, Г. Харис, Гыйффәт туташ, З. Нуркин кебек язучы һәм журналистларның иҗатларына киң урын бирә.

Мулланур Вахитов реальный училищеда укыган вакытта Хәсәниләр семьясының якын дусты була. Гәрәй Хәсәнинең энесе Барый Хәсәнев белән Мулланур Вахитов еш очрашалар. Музыка училищесы тәмамлаган Барый үзенең дусты Мулланурны флейтада, скрипкада уйнарга өйрәтә [2].

Хәсәниләрнең эшчәнлеге татар әдәбияты тарихында махсус өйрәнергә лаек. Аларның әтисе, ихтимал, типик татар сәүдәгәре булгандыр. Документлар аның ике төрле фикер уртасында — искелек һәм яңалык уртасында — торганлыгын күрсәтәләр. Бер карасаң, Сибгатулла Хәсәнев — Казанның абруйлы купецы, мөселман агай-эне арасында да, дәүләт учреждениеләре каршында да билгеле бер урын тоткан кеше. Кадимче Фәтхулла хәзрәт тә, яңалык өчен көрәшүче дә түгел. Фатих Әмирханның «Тигезсезләр» драмасына нигез итеп шулар семьясы алынмаганмы? Документлар Ф. Әмирханның шул семья белән бик нык аралашкан булуын раслыйлар.

Шул ук семьяда Х. Ямашев, М. Вахитов, Ф. Әмирхан, Г. Коләхметов, Г. Тукай, С. Рахманколый һ. б. кебек иң алдынгы яшьләр белән дус булган ике егет үсә. Әхмәтгәрәй һәм Барый Хәсәниләр, мәсәлән, Х. Ямашев үлгәч, аның исемен мәңгеләштерергә дип төзелгән комиссиянең эшен, отчетын таләп итеп матбугатка чыгаралар [3]. Жандармерия идарәсендәге Әмирханнарга кагылышлы документларда менә шушы ышанычсыз Хәсәниләр исеме бик еш телгә алына.

Инде турыдан-туры Ф. Әмирханга кагылышлы документларга күчик.

1912 елның 13 ноябрендә Казан губернаторы Стрижевский Казан полицмейстерына җибәргән хатында болай ди:

«Миңа килеп кергән мәгълүматларга караганда, Казанда Төркия «Һилал Әхмәр» җәмгыятенә иганә җыю белән Фатих Әмирханов шөгыльләнә һәм инде 200 сум чамасы җыйган да. Иганәне җыю өчен Әмирхановның имзалы листы юк, бөтен керемне ул үзенең куен дәфтәренә язып бара. Күрсәтелгән сумманың бер өлеше Хәсәневләрнең бер ир туганы тарафыннан җыйналган һәм Әмирхановка тапшырылган. Бу максатка иганә җыю рөхсәт ителмәгән генә түгел, ә бәлки тыелганын да игътибарга алып, сезгә... гаепләләрдән һич кичекмәстән сорау алырга һәм, законнан тыш акча җыюда гаепләп, аларны җавапка тартырга тәкъдим итәм... Җыелган акчалар конфискацияләнергә тиеш. Мондый иганә җыюлар турысында моңарчы миңа бернинди дә хәбәр язмавыгыз, бу иганәләрне җыюны булдырмау турындагы минем кисәтүемнең полиция тарафыннан үтәлмәвен күрсәтә. Моңа мин сезнең җитди игътибарыгызны юнәлтергә һәм киләчәктә югарыдан килгән күрсәтмәләргә мондый битарафлык күрсәткән хезмәт кешеләре бик нык җавапка тартылачагын исегезгә төшерергә мәҗбүр булам» [4].

Шушы кәгазь нигезендә Казан шәһәренең полиция участоклары эшкә тотына. Әйтергә кирәк, жандармерия, полиция машинасы бик төгәл эшли. Иң башта Казан приставлары эшкә керешә.

«Полицмейстер әфәндегә. Казанның 2 нче часть приставыннан.

Сез Высокородиенең миңа турыдан-туры тапшырган эше буенча сезгә хәбәр итәм: миңа ышандырылган частьта бертуган Хәсәневләр — Гәрәй Сибгатуллович һәм Барый Сибгатулловичлар Евангелистлар урамында үз әтиләренең йортында яшиләр,

---

[1] И. Рәми. Вакытлы татар матбугаты. Казан, 1926 ел, 50 бит.

[2] З. Хәсәнинең безгә сөйләгән истәлекләренә караганда, Әхмәтгәрәй Хәсәни заманының укымышлы, эрудицияле кешесе булган. Ул 1910 елда Швейцария, Германия, Франция, Польшада сәяхәттә йөргән, 1913 елда Астраханьда һәм 1915 елда Уфада Сәгыйт Рәмиевтә кунакта булган. Аларның Юдино янындагы дачасына Г. Тукай, Г. Коләхметов, Ф. Әмирхан барып йөргәнлеге мәгълүм. 1918 елның җәендә М. Вахитов конспирация юлы белән Казаннан чыгарга омтылыш ясаганда Барый Хәсәневкә киемнәр сорап записка белән бер кызны җибәрә. Ләкин Барый өйдә булмый. Октябрь революциясеннән соң Әхмәтгәрәй Хәсәни татар совет язучыларының махсус кибетендә, тәрҗемә бүлегендә һ. б. урыннарда эшли. Ул 1934 елда Свердловск шәһәрендә үлә.

[3] «Кояш» газетасы, 1912 ел, 8 сан.

[4] ТДА, 149 документ.

• Фатих Әмирханов, миндә булган мәгълүматларга караганда, Яңа бистәнең 5 нче часть районында үз йортында яши» [1].

6 нчы часть приставы хәбәр итә:

«...Миндә табылган мәгълүматларга караганда, Яңа бистә мулласы Зариф Әмирхановның Фатих Әмирханов дигән улы бар: аның аяклары авырый, параличланган, ул әтисе янында үз йортларында яши һәм өлгергәнлек аттестатына хәзерләнә...» [2].

Шул ук нәрсәләрне 5 нче часть приставы да куәтли:

«Сез Высокородиегә хәбәр итәм: Фатих Әмирханов мулла малае, Яңа бистәдә яши, аяклары зәгыйфь...»[3].

Казан полицмейстеры ярдәмчесе үзенең начальнигына шул ук көнне (13-XI) рапорт яза.

«Казан мещаны Фатих Әмирханов алты елдан бирле аяк параличы белән авырый, йөри алмый һәм даими рәвештә өендә Мөхәммәт динендәгеләр өчен татар телендә үзенең романнарын, хикәяләрен, әкиятләрен язу белән шөгыльләнә. Бу әсәрләр «Гасыр» нәшрияты тарафыннан басыла, һәм ул «Юл» газетасына[4] мәкаләләр дә яза, алар өчен гонорар ала.

Кинәт кереп, мин Әмирхановның татарча хикәя язып утырган вакытына туры килдем. Үзенең алган гонорарларын Әмирханов ел саен куен дәфтәренә язып бара. «Юл» һәм «Гасыр»дан биш ай эчендә аның тарафыннан 161 сум акча алынган. Бу куен дәфтәренә күп еллардан бирле язылса, анда башка төрле язмалар юк.

Хәсәневләр шактый бай яшәүчеләр, үзләренең китап кибетләре бар, квартиралары да һәм кибетләре дә минем тарафтан кинәт кереп тикшерелде. Әмирхановлар һәм Хәсәневләр квартирасына кинәт кереп ясалган тентүләрдән һәм аларның үзләрен тотуларыннан алган тәэссоратыма караганда, алардан законнан тыш игanә җыялар дип шөбһәләнү, мөгаен, урынсыз булыр. Минем кинәт килеп керүем алар өчен көтелмәгән хәл иде һәм иганә җыюда үзләрен гаепләрлек әйберне алар яшерергә өлгермәгән булырлар иде» [5].

Хәзер «көтелмәгән тентү»нең кайбер детальләре белән танышыйк. Ф. Әмирханнар йортында тентүне Казан полицмейстеры ярдәмчесе вазифасын вакытлы башкаручы Шершнев ясый. Аның янында 5 нче часть приставы Разумов, шаһитлардан Галәветдин Мөхетдинов, Габделнасыйр Гафуровлар катнаша. Тентүнең максаты Төркиягә ярдәм йөзеннән җыелган акчаларның эзенә төшү була. Алда әйтелгәнчә, тентү бернинди дә нәтиҗә бирми. «Әмирхановның үзе янында, пиджак кесәсендәге кул кошелокта 60 сум 50 тиен (бишәр сумлык өч кәгазь, ике унар сумлык һәм дүрт данә бишәр сумлык алтын акча һәм көмеш белән 5 сум 50 тиен)» акча табыла. Шершнев бу акчаларның каян килгәнлеге белән кызыксынгач, Ф. Әмирхан протокол ахырында болай дип язып куя: «Алтмыш сум акчаны мин «Гасыр» китап нәшриятыннан үземнең китабым өчен алдым».

Полиция чиновнигы ахырдан моны да ачыклый. Ә. Хәсәни: «Әмирханов, чыннан да, безнең нәшриятка үзенең әсәрләрен сатты һәм шушы елның 10 ноябрендә алар өчен 50 сум акча алды. Мин аның белән даими рәвештә эш йөртәм һәм аның әсәрен сатып алганда ул миннән акчаны алдан түләтә» [6], дип күрсәтмә бирә.

Хәсәниләрнең өендә шул ук көнне, шул ук чиновник тарафыннан ясалган тентүнең дә протоколы сакланган. Төркиягә ярдәм итү өчен акча җыелганны расларлык «бернинди язулар, квитанцияләр, хатлар табылмады», диелә протоколда. Кибеттә тентү дә берни дә бирми. «Әхмәтгәрәй Хәсәневнең өстәл тартмасында Идел-Кама коммерческий банкысының чек кенәгәсеннән башка әйбер күренми».

Бу тентүләрдән соң полиция-жандармерия аппараты үзенең ялган әләк буенча эш йөрткәнен аңлый.

«Мин сезнең хәбәрегез буенча Фатих Әмирхановны һәм Хәсәневләрне тикшерүгә тарттырган идем,— дип яза губернатор Стрижевский Казан жандарм идарәсенә

[1] ТДА. 151 документ.
[2] Шунда ук, 152 документ.
[3] Шунда ук, 150 документ.
[4] Чиновник ялгыша. Сүз «Юл» нәшрияты турында бара.
[5] Шунда ук, 146 документ.
[6] Шунда ук, 153 документ.

яшерен рәвештә язган кәгазендә.— Тикшерү нәтиҗәсендә аларның бу эштә гаепсез икәнлеге танылды. Казан полицмейстерының күрсәтүенә караганда, «Һилал Әхмәр» җәмгыятенә почтадан бернинди акча җибәрелмәгән. Полиция чиновниклары полицмейстерга Казанда андый акча җыю бөтенләй булганы юк дип белдергәннәр»[1].

Һәм, ниһаять, бер атнадан соң жандарм идарәсе начальнигы полковник Калинин, акланып, губернаторга болай дип хәбәр итә:

«Фатих Әмирхан һәм бертуган Хәсәневләр турындагы кәгазьләрне кире кайтару уңае белән, Сезгә түбәндәгеләрне белдерергә җөрьәт итәм: минем 10 сентябрьдә 713-санлы язмамда Ф. Әмирханов Төркия «Һилал Әхмәр» җәмгыятенә акча җыя дигән мәгълүматларым формаль тәртип белән тикшерелгән мәгълүмат түгел иде. Күрсәтелгән Әмирханов, гәрчә аяклары паралич белән авырса да һәм местәкыйль рәвештә йөри алмаса да, «Шәрык клубы»на һәм үзенең якын танышларына мәҗлесләргә йөри»[2].

Тентүләрнең беренче дулкыны, шулай итеп, Ф. Әмирхан язмышына артык зур зарар салмыйча гына узып китә.

1913 елда, Романовлар династиясенең 300 еллыгын билгеләгән көннәрдә, татар демократ язучыларының иҗтимагый-политик эшчәнлеге тагын да активлаша. Шуннан чыгып, охранка күзәтүе дә көчәйтелә. Агентура мәгълүматларына таянып, КГЖУ татар язучыларын ике лагерьга бүлеп өйрәнә. Беренче группа «ультранационалистлар» дип атала һәм бу группаның башында Ф. Әмирхан тора дип күрсәтелә. Агентура Ф. Әмирхан һәм Г. Коләхметовларның яшерен мәҗлесләрдә татар уку йортлары, көндәлек матбугат һәм татар әдәбияты турында сөйләшүләр алып барганлыгын хәбәр итә[3].

Ул арада беренче империалистик сугыш башланып китә. Охранка мөселманнар яши торган окраиналарда үзенең эшчәнлеген көчәйтә. Патша администрациясе моңарчы, татар язучылары Төркиягә ярдәм итмиләрме, дип шикләнгән булса, сугыш вакытында аның шиге конкретлаша төшә: хәзерге кыен ситуацияне мөселманнарның алдынгы карашлы яшьләре үз максатларында файдаланылмыйлармы?[4] Охранканы бигрәк тә Ф. Әмирхан һәм Г. Ибраһимов исемнәре кызыксындыра. Жандарм идарәсенең таләбе буенча, татарча матбугат органнарына ватанпәрвәрлек хисе пропагандалау эше йөкләтелә. Документларга караганда, Ф. Әмирхан эшләгән «Кояш» газетасы мондый басымнан аеруча нык җәфа чигә. Ахыр чиктә «Кояш»ның редакторы Зәкәрия Садретдиновны патриотик эчтәлекле материаллар урнаштырырга мәҗбүр итәләр. Шул уңайдан Ф. Әмирхан өстеннән күзәтү көчәйтелә. Аның белән Казан губернаторы үзе кызыксына. Жандарм идарәсенең губернаторга биргән җавабында Ф. Әмирхан «бик сак эш итүче кеше буларак игътибарга лаек» дип характерлана. Аның яшьләр арасында зур авторитетка ия булуы һәм, секретарь гына булса да, «Кояш»та тәэсире зур икәнлеге күрсәтелә. Жандармерия газета идарәсенең «хәйләкәр»леген ача. «Вакыт» кебек нинди прогрессив газетага кадәр, диелә документта, бу сугышта Төркиягә симпатиясен белдерми түзә алмый, ә менә «Кояш» газетасы «бары тик Ф. Әмирхан тәэсирендә генә мондый мәсьәләләрне дәшмичә уза. Патриотик эчтәлекле мәкаләләрне исә алар бары тик цензура комиссиясенең басымы астында гына урнаштыралар»[5]. Жандармерия Ф. Әмирхан турында губернатор өчен «бик яшерен» белешмәлек төзеп бирә.

«Соңгы вакытта, 1914 елгы сугыш башланганнан бирле, — диелә бу белешмәлектә,— Ф. Әмирханов бу сугышның нәтиҗәләренә мөнәсәбәтен кешедән яшерми. Ул, Россия, тегеләйме, болаймы, сугышта җиңеп чыкса, көчле реакция башланачак, бу реакция инородецларга, бигрәк тә мөселманнарга кагылачак, дип фикер йөртә һәм мөселманнар өчен файдалы булачак, дип, бу сугышта Россиянең җиңелүен тели»[6].

Губернатор, үз чиратында, «бик яшерен» грифы белән 1914 елның 15 декабрендә жандармерия идарәсенә кәгазь җибәрә. Бу кәгазьдә «Фатих Әмирхан эшчәнлегенә бик нык игътибарлы булырга һәм аның өстеннән бик көчле күзәтү алып барырга»[7] куша.

[1] ТДА, 148 документ.
[2] Шунда ук, 147 документ.
[3] Шунда ук, 3610 эш, 57 документ.
[4] Шунда ук, 2348 эш, 43 документ.
[5] Шунда ук, 3620 эш, 163 документ.
[6] Шунда ук, 165 документ.
[7] Шунда ук, 185 документ.

*
* *

Февраль революциясе булып, патша бәреп төшерелүгә, Ф. Әмирхан патша ялчылары — әләкчеләр, кара көчләргә нәфрәт белән тулы «Богаулар өзелделәр» дигән мәкалә язып чыга. Бу мәкалә шул вакыттагы татар интеллигенциясенең гомуми фикерен чагылдыра.

«Берничә ун көннәр генә моннан әүвәл, — ди Ф. Әмирхан, — ...җәмгыятьләребезнең гомуми җыелышларында ана телендә сөйләшүне, мәмләкәткә бер уңайсызлык вөҗүткә китерү төсле, бер кысынкылык белән куркынып эшләргә мәҗбүр хәлдә калдырылган, хәзергә кадәр иң саклык белән уйлый торган фикерләребезне язганда да безнең хөррияте фикриябезне вә хөррияте матбугатыбызны буарга куелган бер мөстәшрикъ яхут бер кодсиятсез, сатлык татар үлчәве аркылы үткәреп торырга, бөтен театр, әдәбиятыбызны Смирнов шикелле бер кара вә ахмак психопатның зәһәрле карашы аркылы уздырырга мәҗбүр булган бөтен тәрәккыяте миллиябез өчен кара хөкүмәтнең кара агентларына сатылган доносчы Ишмөхәммәт вә Сабир муллалардан куркынып хәрәкәтләнергә мәхкүм хәлдә булган без... киң мәдәни вә гыймрани мәйдан вә имкяннар алдына килеп чыктык»[1].

Халыкның нәфрәтенә дучар булган көчләр Ф. Әмирханның күз алдында эшләгән эшләренең җәзасын алалар: газеталарда татар провокаторлары фаш ителә. Татар язучылары өстеннән бик кабахәт рәвештә әләк язган Тымытык мулласы Шәһиморат Гаделевкә 1917 елның 26 мартында халык суды ясала. Судта аның әләгән үз кулына тоттырып кычкырып укыталар, ул бөтен халык алдында халыктан гафу үтенә[2]. 1918 елның январенда учительская семинариянең дин мөгаллиме провокатор мулла Фасыйх Мөхетдиневне (Ф. Әмирхан өстеннән жандармериягә әләк язган кеше) укучылар таләбе буенча эшеннән куалар. Провокатор Ишми ишан да үзенең табигый финалына килә: ул Колчакка хезмәткә күчә һәм ахырдан тиешле җәзасын ала.

Ф. Әмирхан исә бу вакытта үзенең яшьлек дусты булган Мулланур Вахитовны сагынып мәкалә яза («Мулланур иптәш»), «гражданнар сугышын галәбәле тәмам итеп, хезмәт мәйданына кайта торган иптәшләргә» багышлап, «Чәчәкләр китерегез миңа!» исемле нәсерен иҗат итә, Октябрь казанышларын яклау өчен аңлы көрәш юлына баса.

Тарих, һәр чактагыча, монда да эзлекле хәрәкәт итә һәм һәркемнең барыр юлы ачыклана: кара эчле, мәкерле әләкчеләр революция дошманнары ягында калалар, пакь күңелләләр исә күптән көтелгән бөек борылыш — Октябрь революциясе казанышларын саклаучылар сафына баса. Фатих Әмирхан пакь күңелләләр арасында була. Чөнки ул моңа бөтен тормышы, бөтен иҗаты белән хәзерләнгән иде.

---

[1] Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. II том, 491—492 битләр. Сүзлек: мөстәшрикъ — көнчыгыш телләре белгечe; гыймрани — төзек; имкян — мөмкинлек.
[2] «Вакыт» газетасы, 1917 ел, 2204 сан.

# ДУСЛАР ИҖАТЫ

*Сугыштан соң Татарстан язучылар союзы каршында рус секциясе оештырылган иде. Хәзерге вакытта бу секция рус телендә яза торган 17 авторны берләштерә. Аның җитәкчесе — күренекле язучы Тихон Журавлев.*

*Соңгы елларда рус секциясенең С. Радзиевская, Г. Паушкин, Р. Кутуй, М. Скороходов, М. Зарипов, Ю. Белостоцкий, Н. Орешина, Н. Беляев кебек членнары аеруча актив иҗат иттеләр.*

*Шуларның берсе — Михаил Скороходовка быел 50 яшь тулды.*

*М. Скороходов озак еллар төньякта эшләгән, төрле сәяхәтләргә катнашкан.*

*Казан һәм Мәскәү нәшриятларында басылып чыккан дистәдән артык китап авторы М. Скороходовның «Текә таулар» һәм «Ал җилкәннәр астында» исемле проза әсәрләре Татарстан укучыларына да яхшы таныш.*

*Бу санда без Михаил Скороходовның берничә шигырен урнаштырабыз.*

## Михаил Скороходов

### Тирән тыл

Яумаса да өстән бомбалар,
Тирә-юньдә фронт сулышы.
Төне-көне тынмый моторлар,
Һәркайсыбыз безнең сугышчы.
Минем сменадаш егетнең
Ачылды да кинәт ярасы,
Больницага алып киттеләр..
Тагын цехта куна каласы.
Мастер әйтә иртән: — Түз инде
Тагын өч-дүрт сәгать булса да.
— Сменадаш терелеп чыкмыйча
Цехтан китмәм, мастер, үлсәм дә.
Станогым тынмас бер минут,
Сынатмабыз, мастер, көенмә.
Өйрәнчек кыз гына кызганыч,
Яшь бит әле, кайтсын өенә.
Яшь кыз әйтә: — Юк, мин өйрәнәм
Рәнҗетәсез алай сез мине...
Егетләргә мохтаҗ цехларда
Егетлекнең һич тә юк чиге...
Сменадан соң да йокы юк.
Шатланабыз: дошман кыйнала...
Болытларны тишеп ай оча,
Охшаган ул көмеш минага.

Ал байраклар горур җилферди,
Аларның зур, данлы юлы бар...
Җиңелү белмәс герой-шәһәрләр
Тылда да күп, бик күп булдылар.

## «Кара урман»

Җырлады ул сугыш алдыннан:
— Караңгы төн, кара гына урман...
— Нинди җыр бу? — диде дусты аңа, —
Үзәкләрне өзеп-өзеп ала.
Татар телен белмим, әйтче зинһар...
— Сугыштан соң, хәзер вакыт бик тар.

Бу сугышта дошман алды сабак.
Сугыштан соң җыр терелде кабат,
Яңгырады җыр җирдә яңадан:
— Караңгы төн, кара гына урман...
— Сөйлә инде, нинди җыр бу, туган?
— Тыңла, сөйлим.
Дөм-караңгы урман...

Сүз өзелде шунда,
Приказ булды...
Кайталмады алар тик бу юлы...

Батальонга яңа комбат килде,
Төркем-төркем яшь-яшь солдат килде.
Учак янды төнлә,
Төште томан.
Бер җыр барды алдан:
— Кара урма-ан...

Ф. ШӘФИГУЛЛИН тәрҗемәләре.

## *ЛЕНИНГРАД ШАГЫЙРЬЛӘРЕННӘН*

### Георгий Некрасов

#### Чишмәләр

Зур суларның юлы зур була...
Ә кайдадыр үлән төбендә
Вак чишмәләр агып яталар
Күзенә чалынмыйча кемнең дә.

Ашыкмыйлар, узып бер-берсен,
Дулкыннарын ярга кагарга.
Камышларның сизелер-сизелмәс
Пышылдавы сердәш аларга.

Шушы нәни сулар тынсалар,
Болыннарны тирән моң баса...
Шәрәләнеп калыр җир өсте,
Шушы вак инешләр булмаса.

Гөл-чәчәкләр корыр тамырында...
Уйланырлык нәрсә бар монда.

### Николай Кутов

#### Туган ягым минем, Төньягым

Поезд чаба... Чуен юл тирәли
Баганалар тезелеп киткәннәр...
Күздән кичә яшь-яшь наратлыклар,
Күлдә йөзгән ап-ак җилкәннәр.

Давыл сөрлектергән төз агачлар,
Яктылыкны җыйган аланнар;
Телемачталар һәм телеэкраннар
Урман буйлап озата баралар.

Бөтерелеп очкан яфракларның
Күңелләрне үзенә тартуы;
Күккә ашкан яңа биналарның
Кояш нурларында балкуы,

Заводларның дәртле гөрелтесе,
Мең-мең төскә кергән болыннар —
Барысы-барысы җанга шундый якын,
Әй, Төньягым! Газиз урыннар!..

## Узган юлын бизәп нурларга

Бу җирне син иксез-чиксез итеп
Китерәсең һәрчак уеңа.
Аның буйлап узар юлың озын,
Гомер генә кыска тоела.

Тик Ватаным белми картаюны,
Мәңге язлар иле булганга.
Ул һәр вакыт алга карап атлый,
Узган юлын бизәп нурларга.

Күнеккән ул туар таңы белән
Гадәтенчә алдан котларга:
Иртәгесе аның — төзелешләрдә,
Бүген балкып янган утларда.

Һәм тели ул барлык дәүләтләрнең
Тату яшәүләрен үзара.
Океан, чүлләр аша һәркайсына
Дуслык кулын әзер сузарга.

Җил-давыллар кубып, һичбер кайда
Шом салмасын тыныч өйләргә.
Юккамыни илләр батырлыкка
Һәм хөрлеккә аннан өйрәнә?!

## Сергей Макаров

### Таң

Таң уяна кызгылт нурын җәеп,
Үзенә йотып көмеш чыкларны.
Бал кортлары ширбәт эчәр өчен
Көтеп ала кояш чыкканны.

Оя-оя куе өрекмәннәр
Йокымсырый читән артында.
Көнбагыш, чаң кагып, хәбәр бирә
Яңа көн тууы хакында.

Әкияттәге коштай канат җилпеп,
Кояш күренә офык читеннән.
Һәм үзенең кауры нуры белән
Сыйпап ала җирнең битеннән.

Мөлдерәмә тулып менәр өчен
Ак чиләкләр төшә коега...
Игеннәрнең кырда баш кысуы
Изге бәйрәм булып тоела.

## Песнәкләр

Таң сулышы көнне җылыта алмый,
Ирек куя салкын җилләргә.
Ә песнәкләр барыбер иртә саен
Каеннарга кунып тирбәлә.

Күңелемә алар җылы хисләр
Китерәләр миңа таңнарда.
Каеннарның, ахры, тамыры буйлап
Җир җылысы үрли аларга.

## Татар әдипләренә

Татар әдипләре, сезгә
Әйтмәк булам шушы сүзне:
Бер үк зәңгәр, саф иртәләр
Иркәли һәм назлый безне.

Назлый тук башаклар шавы,
Көмеш чыклар, күксел томан...
Без бит гомерлеккә бергә —
Идел белән Казан сыман.

# Сергей Каширин

## Очышта

Очам гүя пуля тизлегендә,
Куып җитә алмас тавыш та...
Җирне дә мин чак-чак кына шәйлим
Янып торган кояш баешта.

Кош мамыгы белән чорнагандай,
Термометр бәскә күмелде.
Кеше түзәлмәслек салкынлыкны
Күрсәтә ул, борчып күңелне.

Тик шулай да мине һич өркетми
Текә борылышлары юлымның.
Тоташ траектория буйлап очам
Көчен тоеп мотор җырының.

Күнегелгән эшем шушы минем,
Кайгым да шул, тормыш ямем дә.
...Утырам. Дәшмим. Ә тир тамчылары
Битем буйлап ага тәнемә.

## Йокысызлык

Тормыштан без чиксез канәгать,
Бар кайгылар гүя онтылган.
Ә нигә соң һаман төннәрен
Куркып уянабыз йокыдан?

Баш калкытып йомшак мендәрдән
Һәм онытып юрган җылысын, —
Хәвефләнеп кат-кат тыңлыйбыз
Балаларның тирән сулышын.

Йокысызлык иңә бүлмәгә,
Мамык мендәрләргә сарылып.
Көтмәгәндә аннан бу тынлык
Шартлый кебек туптай ярылып.

Тәрәз өлгеләре кисешкән,
Хәтерләтеп прицел ноктасын...
Үрелеп шунда радиоалгычка
Соңгы хәбәрләрне тотасың.

Сәгать теле салмак текелди,
Җир әйләнә... сүнмәс иярчен.
Шундый тыныч... Шундый сөйкемле...
Йокыга талган сылу диярсең...

**РӘШИТ ГӘРӘЙ** тәрҗемәләре.

И. Бутылкин

# МУСА ЯНЫНДА БЕРНИЧӘ КӨН

*Икенче удар армия составында сугышканда Мясной Бор авылы янында чолганышта калдым. 1942 елның җәе иде. Соңыннан әдәбиятта бу урынны «Үлем үзәне» дип йөртә башладылар.*

*Июнь башында безнең артиллерия дивизионын укчы бригадага куштылар. Мин хезмәт иткән батарея шул бригаданың бер батальонына бирелде.*

*Батальонга һәлак булган командир урынына калган өлкән политрук Муса Җәлил җитәкчелек итә иде.*

*Мин батальонда дүрт көн булдым, дүрт көн Муса белән бергә яшәдек*[1].

## Беренче көн

Майның соңгы көне. Эссе.

Атларны күптән ашап бетердек. Тиреләрен кайната башладык. Чирек сохари алабыз. Кузгалак ашыйбыз. Махорка да, тоз да юк. Эч поша, күңелсез. Сугыш әле бер хәл! Ә чолганышта калган кешенең эше барыннан да яманрак.

— Иптәш командир! Замполитка!

Ял итәргә туры килмәс, ахры. Разведчикларыма, элемтәчеләремә һәм минем үземә дә хәрби задание бирергә чакыралардыр.

Шулай булып чыкты да.

— Дивизионны укчы бригадага куштылар. Батарея командиры инде анда, штабта,— диде замполит, аннары аягын бөкләп йокымсырап утырган үзбәк егетенә күрсәтте дә,— менә бу батальонның элемтәчесе. Ул сезне озатып куяр,— диде.

...Төш җитеп килә. Үңда да, сулда да, артта һәм алда да туплар ата. Мясной Борга таба кара «юнкерс»лар очып үтә. Күбәү алар — өчәр самолеттан алты төркем. Алардан аста, нарат башларына тияр-тимәс кенә, безнең штурмовиклар оча. Күп түгел, дүртәү генә.

— Батальон командирыгыз кем сезнең? — дип сорыйм элемтәчедән.

— Муса — политрук.

— Нинди кеше ул? Усалмы?

Солдат ияген тиз-тиз ышкып алды да, хәйләкәр карап, кулын селтәде.

---

[1] Материал «Дружба народов» журналының 1975 елгы 7 нче саныннан алынды.

— Белмим.

— Әйт, курыкма. Әлеге түгел мин.

Ул тагын күз кырые белән карап:

— Бераз кызурак. Әтәч,— дип куйды.

— Нишләп алай?

— Йоклап киткәнмен. Ул автоматымны алып яшергән. Үземне чокырга утыртты.

— Дөрес эшләгән. Автоматсыз сакчы буламыни?

— Була! — диде элемтәче, кулы белән һаваны кисеп.— Төн йокламадым, көн йокламадым, тагын төн йокламадым, җир казыдым. Арылган. Үлгән кеше кебек...

— Барыбер. Автоматсыз солдат кеше түгел, корт.

Элемтәче үләр дәрәҗәгә җитеп гарьләнде, юлыма аркылы төште дә противогаз сумкасыннан башта бер түгәрәк граната, аннары икенчесен, өченчесен алды.

— Бу нәрсә? Кортмы бу? — дип ярсыды.

Гранаталары күп иде аның, сигез данә.

— О-о! Корт түгел. Бу бик яхшы. Хәйләкәр солдат син,— дидем.

— Рәшид — совет солдаты! — диде ул. Ачу белән карап алды да:— Аңлыйсыңмы, совет солдаты! — дип өстәде.

Юлыбыз түбән таба төшә, сазлык өстенә салган киртәләрдән киң яланга чыгабыз. Якындагы урман аланына әле генә сугышта булган авыр тупларны күчергәннәр. Ут сызыгы һәм аннан алдагы ачыклык бомба, снаряд чокырлары белән казылып беткән. Җимерелгән бер туп тәгәрмәчләре өскә әйләнгән килеш ята.

Әле күптән түгел генә Вдицко авылы янындагы шундый аланнарның берсендә безнең дивизион сугышта катнашты. Дошманның өч атакасын кире кактык. Немецлар окопларга яшеренергә мәҗбүр булдылар.

Ә төнлә безнең батальон чигенергә приказ алды. Хәзер армия Мясной Бор авылына таба чигенә. Ул авыл үзе юк инде. Исеме генә калган.

Алан бетүгә нарат урманы башлана. Урман эченә таба өч йөз метрлап ара окоплар, траншеялар, хәбәрләшү юллары белән казылып беткән. Юлны танкка каршы ике туп саклый. Елга аркылы салынган күпер сүтелгән.

Арырак землянкалар күренә. Күбәү алар. Кыш көне биредә партизаннар базасы булган, ахры, анда немецлар авылларыннан сөргән халык та яшәгәндер. Солдатлар күренми, каядыр ышыкланып йоклыйлар булса кирәк. Каен ботакларына эленгән фляга һәм котелоклар гына биредә кеше күплеген күрсәтә. Ул савытларга каен суы җыела — ач кеше өчен кирәк нәрсә.

Команда пункты янындагы бүкәндә өлкән политрук безне көтеп утыра иде. Тезендә ачык дәфтәр, үзе әкрен генә көйли:

— Утыр әле яннарыма, нигәдер йоклый алмыйм. Мәскәүдәге дустыма хат язым...

Рәшид якын килеп кулын пилоткасына куйды да:

— Приказ үтәлде! — диде.

— Яхшы. Бар, ял ит.

Өлкән политрук карандаш белән дәфтәрен планшетына салды, җитез генә торып басты, бил каешын рәтләде дә сөйкемле итеп елмайды. Кырынган, өс-башы пөхтә, урта буйлы, кара чәчле кеше иде ул. Иреннәре бераз күперәп тора. Зур коңгырт күзләре ышаныч белдереп төбәп карыйлар.

Мин кемлегемне әйткәч, ул кулымны кысты һәм:

— Өлкән политрук Муса Җәлил. Батальон командиры вазифаларын башкарам,— диде һәм шунда ук,— ә тупларыгыз кайда? — дип сорады.

Мин, картамны җәеп, туплар торган урынны күрсәттем:

— Менә, биредә.

Комбат, борчылып, сызгырып куйды:

— Миңа алар биредә кирәк. Биредә,— дип кабатлап әйтте.— Нихәтле тизрәк килсәләр, шул хәтле яхшы булачак. Сизәсезме, нинди эшләр бара?! — ул, канонада ягына баш кагып өстәде:— Сигез чакрымда гына. Безнең дә яшисе килә бит!

— Аңлыйм. Хәзер донесение язып ашыктырырмын.

— Снарядларыгыз бармы?

— Күп түгел. Туп башына кырык сигезәр.

— Ашыгыгыз. Соңыннан туп-туры миңа килерсез.

Шулай диде дә землянкага кереп китте.

Егерме минуттан эшемне бетердем.

— Әйдә әле, тупларны кая куярга икәнен күрсәтим,— диде батальон командиры.

Ничек шулай булгандыр, дөресрәге, комбат телемне ничек чишкәндер, юлда барганда мин аңа кайда, кайчан туумымны, әтием-әнием кем булуын, кайда укуымны, кайларда сугышып йөрүемне, гомеремнең иң истәлекле көннәрен — барын да сөйләп бирдем.

— Кәләшең бармы соң? — диде батальон командиры.

Кәләшем юк иде әле. Хәтта таныш кызларым белән дә хат алышмый идем. Ләкин араларыннан берсенең миңа бик ошавын командирдан яшермәдем.

Өлкән политрук көлемсерәп куйды:

— Син болай ярыйсы егет үзең,— диде ул.— Минә нәрсә, мине исемем белән генә ата әле. Официальлекне, купшылыкны яратмыйм. Обстановкасы ул түгел. Ә мин сиңа Сергей дип дәшәрмен. Фамилияң әллә ничек бит...— ул тагын көлемсерәде.

Минем хәтерем калды.

— Бик гади фамилия. Руснкы. Атаклы Бутылкиннар фамилиясе. Лука Андреевич илебездә целлюлоза-кәгазь промышленностеның беренче карлыгачы — Сясьский комбинатын төзегән кеше. Егерме алтынчы елны беренче нигез ташларын салалар, ә егерме сигезенче елда илебезнең үзенең целлюлозасы һәм газет кәгазе эшләнә башлый. Совет дәүләте чит илләргә алтын түләүдән котыла. Менә шулай ул.

Муса уңайсызланды.

— Зинһар гафу ит. Ләкин, дөресен әйтим, андый фамилияне беренче ишетүем.

Юлыбызда еш кына туктаталар иде. Комбатка исеме белән дәшәләр. Ләкин үз кеше булып кылану, түбәнсенүнең эзе дә юк, зур хөрмәт белән мөрәҗәгать итәләр.

Шунысы гаҗәпләндерде. Муса кем белән генә сөйләшсә дә, аның исемен, фамилиясен, аны борчыган уйларны белә.

Сазлык читендә өч-дүрт туп куярлык урын сайлагач, разведчикларымның берсен батареяны каршыларга җибәрдем.

Наратлыкта каршыбызга рота командиры очрады. Сакал-мыек баскан, тирләп беткән, бил каешын чишеп, маузерын күн итек куныычына кыстырган өлкән яшьтәге бу лейтенантка Муса Степан дип дәште.

— Йөзеңне җон баскан, күзеңне дә күреп булмый, бик шәп үрнәк күрсәтәсең солдатларыңа,— диде аңа Муса.

— Китте инде, китте... Шулай булыр дип уйлаган идем. Банкетта түгел бу мин. Кая бассаң шунда су. Күрәсең бит ничек интегәбез.

Агачлыкта һәм сазлыктагы барлык ут нокталары — пулеметлар, танкка каршы ике туп, автоматчыларның оялары — өеп куелган кызыл балчык артына яшеренгәннәр. Балчык өстенә чирәм ябылган. Казыган чокырга, чирәме киселгән җирләргә пычрак кара су җыелган.

«Иң яхшы рота булса кирәк», дип уйладым.

— Дивизия тубын кая куясың? — дип сорады Муса рота командирыннан.

— Танкка каршы туп яхшы булыр иде, ул кечкенәрәк.

— Юк, Степан Федорович, теләсәң нишлә. Авыр туп кирәк.

— Алайса, әнә тегендә, кәкре нарат янына куярмын,— диде дә лейтенант миннән:— Броняга каршы снарядлар белән картечь бармы? — дип сорады.

— Ник булмасын, барысы да бар,— дидем мин.

Без ерактагы аланлыкка киттек. Муса танковый пулемет янына туктады. Кырыс йөзле карт солдат гимнастерка ямап утыра иде. Кайчандыр өзелеп калган сүзләрен дәвам итеп, Муса аңардан:

— Уйламадыңмы, Петр Игнатьич? — дип сорады.

Солдат башын күтәрми генә:

— Юк, иптәш өлкән политрук,— диде.

Муса авыр сулап куйды.

— Үземә генә авыр миңа, ышанасыңмы? Бертуктаусыз чабам. Ярдәмче кирәк.

Солдат энәсен кадап куйды, командирның хәленә кереп, ягымлы итеп карады. Ләкин сүзе катгый булды:

— Булмый, Муса. Мәктәбем, укучыларым, гаиләм фашист кулында. Ә мин кәгазь сырлап землянкада утырыйммы? Үзең уйла... Укытучы булгач миңа ярый дип беләсеңме? Ярамый. Нигә дип миңа каныктың соң әле? Югары белемле кешеләр азмыни бездә? Еремеев, Абушвили, Чаурс... Барысы да партия әгъзалары. Булдыра алмыйм, аңла.

— Ярый, Петр Игнатьич,— диде Муса.— Ярый. Яшермим, үпкәләттең син мине. Синдә өметем бар иде.

— Гафу ит.

Без штабка кайттык.

Батареялар әле килеп җитмәгән.

Кояш байый башлады, җиргә озын күләгәләр ятты. Атыш тавышлары тынды.

## Икенче көн

Сандугач сайравына уянып киттем. Землянкадан чыктым. Сакчы, сержант Крылов:

— Тынычлык, иптәш командир,— дип хәбәр итте,— менә сандугач кына... Гаҗәп!

Агач арасын томан баскан. Ул хәвефне арттыра. Сакчыдан:

— Лейтенант белән замполит кайда? — дип сорадым.

— Сазлыкта,— диде Крылов.— Төркемнәргә бүленеп туплар янына киттеләр. Батарея командиры икенче туп янында. Сезгә өлкән политрук белән бергә булырга куштылар. Элемтә өчен.

Сазлык ягыннан ату тавышлары ишетелүгә, «Барыгыз да урыннарыгызга!» дигән команда яңгырады. Автоматымны алып Муса янына йөгердем.

Муса телефон янында утыра иде. Рота командирын тыңлый:

— Дозорлар чигенде... Танклар килә. Автоматлары күп...

— Танклары ничә?

— Берни күреп булмый. Туптан чыккан ялкыннарга карап атабыз. Нәрсәдер яна да инде... Шулай да киләләр. Ишетмисезме әллә?

Шул вакыт элемтә өзелә.

Муса икенче трубканы алып кычкыра:

— Федоров!.. Взводны флангтан алып бар. Тиз бул! Әйдә!

Сугыш кыза бара. Миналар сызгыра. Мотор тавышлары торган саен ачыграк ишетелә.

— Сугышлы разведкага күтәрелделәр. Хәзер безнең хәлне чамалап карыйлар, аннары һөҗүм башларлар.

Элемтә һаман юк.

Сугышка Федоровның автоматчылары керә. Аларның атакасы кискен, ярсулы була, немецлар яна торган танкларына таба чигенәләр. Чытырдап шартлаган тавыш моторлар авазын баса, һавага ялкын күтәрелә.

Урман өстенә кояш күтәрелә. Сирәгәя башлаган томан эченнән агачлар калкып чыга.

Без тупны күчереп куюга сугыш тәмамлана. Немецлар кире чигенә. Шулай да урман эчендәге күршеләр атышудан туктамый әле. Анда да дошманның чигенә баруы сизелә. Сазлыкта немецларның ике танкы, өч машинасы янып ята.

— «Музыкант»лар күренгәнче тупны агачлыкка кертегез,— дип, Муса команда бирә,— житезрәк булыгыз, егетләр.

Немецларның бер моторлы сары бомбардировщикларын «музыкантлар» дип йөртә идек. Түбән төшкәндә алар халыкны куркыту өчен сиреналарын кычкырталар.

Елга аръягыннан Федоров автоматчылары кайта. Взводта үлгәннәр юк, ләкин өч солдат авыр яраланган икән. Ә ротада югалтулар шактый. Муса үлгәннәрне агачлыкка күмәргә, бер наратны юнып, кызган тимер белән фамилияләрен язарга кушты.

...Кояшлы, җылы иртә иде. Кошлар сайрый, чикерткәләр чырылдый. Сазлыктан салкын бәреп тора. Сугышлар еракта, бездән уңда да, сулда да бара.

— Бүген артык авыр хәлләр булмас кебек,— диде Муса,— дошманның пехотасы һәм техникалары аз булса кирәк. Китереп җиткерә алмаганнар, күрәсең. Атна арасында шактый какшаттык бит үзләрен. Ләкин һөҗүм булачак! Каты һөҗүм. Мясной Бор янында чолганышны өзүебездән куркалар алар.

Үлгәннәрне туганнар каберлегенә күмдек. Озын сүзләр һәм салютлар булмады. Исән калганнар исеменнән батальон командиры әйтте:

— Бәхил булыгыз, сугышчан иптәшләр! Сезнең өчен үч алырбыз! Бик нык үч алырбыз. Ант итәбез!

Шунда булганнар барысы да аның сүзен кабатлады:

— Ант итәбез!

Ун минуттан бар да тәмамланды.

Өлкән политрук, калку җиргә утырып, тез өстенә дәфтәрен салды. Вакыты белән аның шулай ялгыз калу гадәтен батальонда беләләр иде булса кирәк. Андый чакта Мусаны юк-бар белән йодәтмиләр.

Ике сәгать үтүгә лейтенант Мотылев Муса янына бер төркем сугышчыны алып килде. Партиягә керергә телиләр икән. Муса башта аңламады, Мотылев кулындагы кәгазьләрне алып, тиз генә күз йөртеп чыкты. Шуннан соң гына эшне аңлап:

— Сез нәрсә, сүз берләштегезме әллә? — дип сорады.— Кем өйрәтте? Кем котырткы?

— Кем дә өйрәтмәде. Сүз дә куешмадык.

— Ә замполит кая?

— Килмәде. Шикләнде. Сезнең төпченергә яратуыгызны белә бит ул. Бу эшне миңа тапшырды. Монда минем гаризам да бар.

Муса кашын җыерып дәфтәрен планшеткасына салды.

— Сержант Карпов, гаризагызга өстәп ни әйтәсез?

Карпов иңбашларын җыерып куйды.

— Нәрсә әйтергә?.. Мин үзем Мордовиядән. Беләсезме? Саранскида эшләдем. Махорка ясый идек. Бөтен Кызыл Армиягә җитәрлек булгандыр. Полтаваныкыннан ким түгел иде. Ә кайда ул хәзер бу махорка? Бөтен сүзем шул.

— Аңлашыла... Гаризаларыгызны бүген карарбыз,— диде Муса һәм адъютантын (батальонда штаб начальнигын шулай дип йөртәләр иде) чакырып алды.— Көн азагына коммунистларны җый. Карарны өзерләп куй. Алырга кирәк булыр, әйбәт егетләр.

Штаб начальнигы гаризаларны алып китеп барды.

Өлкән политрук яшел урман эчендә тагын ялгыз калды. Тагын дәфтәренә иелде. Ул кызу-кызу яза иде. Аннан кинәт кенә кашын җыерып уйланып торды. Әле карандаш башын, әле иренен тешләштереп утырды да тагын яза башлады.

Эссе һәм бөркү иде.

Түзә алмадым, Муса янына килеп әкрен генә сорадым:

— Һаман, һаман нәрсә язасың син?

Килеп туктавымны сизмәгән икән, тавышымны ишеткәч, сискәнеп китте. Яндырып ала торган карашын күрдем мин аның шунда, уйлары белән әллә кайларда йөргәнен сиздем. Менә ул айнып киткәндәй булды, дәфтәрен ябып куйды. Таныш булмаган хәрефләр белән язылган дәфтәр битен күреп калдым.

— Нәрсә язасың? — дип кабатлап сорадым.

— Шигырьләр.

Мин аны уйнап әйтә дип уйладым, тапкан шаярыр вакыт, дип хәтерем дә калган иде. Ләкин Муса бик җитди итеп:

— Шигырьләр язам, йөрәгемнең ярсуын һәм нәфрәтемне,— диде.

Янына утырдым да:

— Мөмкин булса укы әле,— дип үтендем.

— Тыңла,— диде Муса.

Хәйләкәр итеп карады да тирән итеп сулады.

**Умом Россию не понять.**
**Аршином общим не измерить.**
**У ней особенная стать.**
**В Россию можно только верить.**

— Муса, искиткеч шәп шигырь бит бу! Бик дөрес сүзләр!— дидем мин, ул туктагач.

Ул елмаеп башын чайкады.

— Эх, Сергеич! Яшел шул әле син! Әйе, әйе. Бу шигырьне инде әллә кайчан ук Федор Иванович Тютчев язган. Онытма: Тютчев!

— Ә мин Тютчевны беләм. Алай ук надан дип уйлама син мине. Менә тыңла: «Люблю грозу в начале мая, когда весенний первый гром...»

Муса аркамнан кагып куйды.

— Моны барыбыз да беләбез. Мәктәптә күңелдән ятлаталар иде.

Шулай итеп, өлкән политрук Муса Җәлилнең танылган татар шагыйре булуын, туган телендә бик күп китаплар чыгаруын, рус телендә дә тәрҗемәләр барлыгын белдем.

Аңа хөрмәтем тагын да артты: тере язучыны күргәнем юк иде әле. Искитмәле бит, ике көн буе янында йөрдем, шагыйрь икәне башыма да килмәде! Шушы бәхетле очрак булмаса, белми дә калыр идем. Ә батальонда беләләр икән. Хәзер генә аңладым. Үземнең генә хәбәрсез булуымнан уңайсызланып:

— Гафу ит, Муса, Мин белмәдем бит. Китим әле...— дидем.

## Өченче көн

Иртән иртүк, куе томан таралып та өлгермәгән иде әле, немецлар нәратлыкка авыр снарядлар яудыра башлады. Төбәп атмагач зур зыян китерә алмады үзе, шулай да сугышчыларны тынычсызлап, борчып торырга ярады.

Мин Муса землянкасына кердем. Анда йокламыйлар инде.

Кояш чыгуга урман өстеннән безнең сигез штурмовик үтеп китте. Немецлар шунда ук тупка тотудан туктадылар. Безнең самолетларның килүе аларны аяз көнне яшен суккандай итте, ахры, бер каршылык күрсәтми тынып калдылар.

Озакламый елга аръягыннан көек исе килә башлады.

Муса телефоннан Степанны чакырды:

— Степан Федорович, бомбага тоту башланганчы кешеләрнең беразын немецларның яндырылган танклары белән машиналары тирәсенә күчерсәк ничек булыр? Үзләре белән ике-өч пулемет та алсалар? Бераз сирәкләнер идек, өелеп ятып булмас бит. Ничек уйлыйсың?

— Яхшы фикер,— диде рота командиры.

— Алайса, башладык. Кемне алырга, кемне калдырырга икәнен үзең беләсең. Син тәҗрибәлерәк.

Бераздан лейтенант:

— Приказыгыз үтәлде! — дип хәбәр итте. Йөткергәләп алды да,— Муса, мин бит яхшы аңлыйм... Борчылма,— дип өстәде.

— Менә яхшы. Яхшы, Степан Федорович.

Һавадан мотор тавышы ишетелде. Күп тә үтмәде, агачлык өстендә сары тәреле унбер пар бомбардировщик күренде. Әкренләп түбәнәя-түбәнәя, алар ике төркемгә бүленделәр. Алтысы Степан группасы өстендә, уналтысы батальон урнашкан җирдә әйләнә башлады.

Сазлыктан зенит автоматлары атарга тотынды. Алар шул хәтле төз аталар иде, беренче обоймадан ук өч самолетны бәреп төшерделәр.

Безгә дә чират җитте.

Степанны инде бомбага тоталар. Иң эре, авыр бомбалар шартламый. Чапылдап, сазлыкка төшеп бата. Туп һәм пулемет тавышларын басып сиреналар үкерә. Агачлыкта ике дистәләп кенә нарат утырып калды. Шулар өстендә самолетлар әйләнә дә әйләнә. Бер бомба җирне изеп керә, икенчесе күккә күтәрелә.

Ниһаять, самолетлар китте. Батальон төп позициягә күчте. Яшь каеннарны сытып-изеп, Степан ротасы өстенә биш җиңел танк килә башлады. Ара кыскарганнан-кыскара. Рота тын тора. Әллә инде Степан дошманның якынрак килгәнен көтә, әллә инде каршы торырлык көче юк...

Муса, алгы сызыкны таный алмыйча, хәрәкәтсез катып калды. Күзләренә ышанасы килми иде аның. Җир казылып, актарылып беткән. Танкка каршы ата торган ике туп җимерелеп сулыкта ята. Хәер, дивизиянең авыр туплары төзек иде әле.

Шул вакыт Мусага Степан шалтыратты:

— Бер взводны сезнең карамакка бирергә була. Хәзергә соң түгел әле, Муса.

— Кирәк булса, хәбәр итәрбез,— диде батальон командиры.— Җимерек машиналар яныннан чигенмәгез. Алар немецларның флангасында торалар. Шуннан кузгалмагыз. Аңлашылдымы?!

Бу тынлык та озакка сузылмады. Ике моторлы «юнкерслар» югарыдан бомба яудыра башлады.

Муса йөгереп килде. Чалбары белән гимнастеркасы балчыкка буялган, сул колагыннан кан ага, планшеткасының бер читен бомба кыйпылчыгы кисеп алган, пилоткасы кайдадыр төшеп калган.

— Барыгыз да исәнме? — дип сорады ул карлыккан тавыш белән.— Мин дә исән әле.

Җирнең асты-өскә килә. Солдатлар кайсы кайда ятып яшеренгән, йөзләреннән эре салкын тир ага. Тирә-якта — бомба сызгырган, шартлаган тавышлар.

Һәм кинәт — тынлык.

Дошман самолетлары наратлык өстеннән бер очып әйләнделәр дә базаларына китеп бардылар.

Тегеннән дә, моннан да солдат башлары күренә, корал шалтырый, бер-беренә дәшкән тавышлар килә башлады.

Мусаның команда биргәне ишетелде:

— Лутиков, командирга! Мотылев взводы бирегә... Ике винтовка, бер пулемет минем белән!

Ике сугышчы элемтәне ялгарга йөгерде.

Мин Мусага карап куйдым. Ул түземсезлегемне күреп читкә борылды да күңелсез тавыш белән:

— Туплар юк. Һәлак булдылар,— диде.— Исән калган тупчылар минометларда. Батарея командиры исән. Исән иде әле...— дип кабатлап әйтте ул.— Күңелеңне төшермә. Туп юк икән, ике танк килә. Инде юлда. Утыз дүртләләр.

Мотылев взводы оборонага ятарга да өлгермәде, тапалган нарат агачлары артында танклар һәм автоматчылар күренде. Аларны якын җибәреп, каршы ут ачтылар. Автоматчылар җиргә сыенды, ике танк, инеш аша чыгып, безнең позицияләргә таба килә башлады. Алар күп зыян китергән булырлар иде, әмма безнең утыз дүртле танкларны күреп, юлларыннан борылдылар да урманга кереп качтылар. Башка танклар да чигенергә тотынды.

Дошманның атакасы барып чыкмады.

— Карагыз әле, качалар! Без җиңдек! — дип кычкырды Муса.

Разведка немецларның янган авылга таба чигенүен хәбәр итте. Безнең югалтулар да зур иде. Исән калганнарның да өчтән бере яралы булып чыкты.

Муса үз янына Степан ротасыннан бер отделение солдат алды.

— Авыр көн булды. Никадәр кан коелды...— диде ул күңелсезләнеп.— Коточарлык! Синең дә, минем дә үлеп калуым бик мөмкин иде.— Ул, ярсудан тешләрен шыкырдатып, ачу белән өстәп куйды.— Үтерүләре мөмкин иде, тик җиңүләре түгел. Җиңә алмаслар. Без фашизмны тар-мар итәрбез. Шулай булырга тиеш!

## Соңгы көн

Наратлыкта тукран тукылдый.

Өч солдат батальон өчен аш әзерли.

Лейтенант Мотылев бер төркем сугышчылар белән төнлә, безнең штурмовикларның бомбага тоту нәтиҗәсен белергә дип, инеш аръягына чыккан иде. Җимерелгән туплар һәм янган машиналар арасында пуля тишкән кухняларга очраганнар. Шуларның берсеннән ике чиләк пешеп җитмәгән ботка белән итле бәрәңге, икенчесеннән ярты чиләк кофе тутырып алганнар. Хәзер шуны пешереп, җылытып яталар.

Муса үзенең адъютанты белән бергә бүләкләү кәгазьләре тутырып утыра. Язганнарны кабат укый-укый, авыз эченнән генә көйләп бара:

— Утыр әле яннарыма, нигәдер йоклый алмыйм. Мәскәүдәге дустыма мин бит тутырып хат яздым...

Сәгать уннарда, без бераз тамак ялгап алганнан соң, бригада штабыннан элемтә офицеры лейтенант Семенов килде. Ул пакет китергән. Муса пакетның эчтәлеген адъютантына әйткәч, бүләкләү кәгазьләрен политбүлеккә алып бару өчен Семеновка бирергә булды.

Кәгазьләрнең әзер булганын көтеп торган арада Семеновны батальон командирлары чолгап алды. Штабтан килгән лейтенант аларны бер-ике мәзәк сөйләп көлдерде дә немецлардан кулга төшерелгән уен картасын күрсәтте. Картадагы оятсыз рәсемнәрне карагач, командирларның кайберләре елмаеп куйды, икенчеләре чирканып баш чайкады, өченчеләре уңайсызланып читкә борылды.

— Мондый карталар белән теләмәсәң дә уйнарсың,— диде Семенов. Карталарны бутады-бутады да ком өстенә йөз сум акча куйды.— Кем тели?

Командирлар бер-беренә карашып алдылар.

— Ә Муса белсә? — дип куйды берсе шикләнеп.

— Ул язып утыра,— диде Мотылев.

Уйный башладылар.

Семеновның кесәләре һәм кыр сумкасы акча белән тулы иде. Карта уйнарга бик ярата һәм беркайчан да оттырмый торган кеше икәне әллә кайдан күренеп тора.

Мотылевның да уенга катнашасы килә. Ләкин аның акчасы юк. Әҗәткә сорарга да уңайсыз. Егет аптырамады, алтын сәгатен кесәсеннән чыгарып Семеновка күрсәтте:

— Күпме бирәсең?

Семенов сәгатьне әйләндергәләп карады, колагына куеп тыңлады, капкачын шартлатып ачты да:

— Мең сум,— диде.

— Тиле дип белдеңме әллә син мине! Китер монда!

Уен Мотылевсыз гына дәвам итте.

Алар янына сиздермичә генә Муса килеп басты. Банкта мең ярымлап акча бар иде. Муса берничә минут карап торды да әкрен генә:

— Семенов! — диде.

Семенов каушап картасын чәчте. Өлкән политрукның шелтәсен көтеп, уенчылар да күңелсезләнеп калды. Муса алар янына утырып карталарны бутады, берсен үзенә алды, икенчесен Семеновка тоттырды да:

— Күпмегә барасың? — диде.

— Барсына да,— диде лейтенант.

Семенов отты.

Муса, карталарны кесәсенә салып:

— Тагын килеп, кешеләрне карта уйнарга котыртып йөрсәң, взвод командиры итеп батальонда калдырам. Аңладыңмы? — диде.

— Аңладым. Шулай эшләгез әле, иптәш өлкән политрук. Шат булыр идем. Миңа рәхәт дип беләсеңме әллә? Семенов ротага, Семенов складка, Семенов тегендә бар... Үзең соң нигә газетадан качтың?

— Сүзеңне уйлап сөйлә, лейтенант Семенов,— диде Муса кырыс итеп.— Минем батальонда күпме торуымны командование хәл итә. Ә хәзер тай моннан! — Ә үзенең командирларына Муса болай диде:— Оят белмәсәгез, сезнең өчен мин оялам.

Шулай диде дә штабка таба китте, юлында кинәт нидер исенә төшеп туктап калды, йөгереп кире килде. Командирлар таралып өлгермәгән иде әле.

— Кара әле, Иван Петрович, шул хәтле күп акчаны кая куясың син? — диде Муса Семеновка.

— Кая куйыйм. Тозлап булмый инде, бәлки мин аларны бүген үк туздырып бетерермен,— диде егет аптырап.

— Юләр син! Утын агачы!

Семенов сагая калды.

— Синең урында булсам, артиллеристларга туп сатып алыр идем мин. Бер батарея!

Лейтенантның күзләре ялтырап китте:

— Алырга мөмкинме соң? Бирегә килгәндә егерме сигез мең акчам бар иде, хәзер күбрәк. Җитәрме?

— Җитмәсә, өстәрбез,— диде Муса.— Әйдә, киттек.

Барысы да штаб урнашкан землянкага юнәлде. Акча җыю турындагы хәбәр шунда ук батальонга таралды. Адъютант акча китергән кешеләрне язып өлгерә алмый башлады.

Муса бригадага шалтыратып начфинны чакырды.

— Оборона фондына акча җыябыз. Машинаңа утыр да кил. Көтәбез!

Лейтенант Мотылев уңайсызланып:

— Муса, минем хәзергә акчам юк. Үзең беләсең бит... Менә сәгатемне бирсәм ярармы? — диде.

— Нигә ярамасын. Мөмкин. Шулай дип язый та: алтын сәгать, өч капкачлы, шәп йөри.

Начфин килгәндә илле өч мең сум акча җыелган иде инде. Акчага ияртеп биргән язуда бу средстволарның сигез йөз туксан дүртенче артиллерия полкының бишенче батареясе өчен туплар сатып алырга дип җыелган булуы аерып әйтелгән иде.

— Зур рәхмәт, дуслар. Ышанычыгызны акларбыз. Юмартлыгыгыз аяк астына салынмас, дошманны аяусыз кыйнарбыз,— диде батарея командиры нык дулкынланып.

Төзек калган бердәнбер тупны һәм артиллеристларны алып китәргә дип көндезге икедә машина килде.

— Төнлә без дә чигенәбез. Приказ бар,— диде Муса.

Без кочаклашып саубуллаштык.

Машинага утыргач Мусага:

— Волховта очрашырга язсын,— дип кычкырдым.

— Волхов нәрсә ул! Берлинда дип әйт син!..

Без шулай аерылыштык.

Берлинга барып җиту миңа насыйп булмады.

Ә Муса Берлинда батырларча үлеме белән батырлык яулап алды.

ЛӘБИБӘ ИХСАНОВА тәрҗемәсе.

# ВАТАН ӨЧЕН ЯШӘРГӘ ӨНДӘДЕ

**1944** елның 25 августы иде. Шул көнне немец фашистларының Плетцензее төрмәсендә, Берлин вакыты белән 12 сәгать 06 минуттан 12 сәгать 36 минутка кадәр, тәп-төгәл ярты сәгать дәвамында, патриот шагыйрь Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең башлары киселде. Шушы олы фаҗигага 30 елдан артып китте. Ләкин бу зур югалтуның тетрәткеч әрнүе халкыбыз йөрәгендә йөз еллар дәвамында да сүрелмәс.

Гадәттә, шагыйрь яшәгән һәм иҗат иткән урыннар аның кадерле исеме белән бәйләнеп олылана. Ә Моабит?.. Ул немец халкының бөек улы Эрнст Тельман, ут йөрәкле шагыйрь Муса Җәлил кебек көрәшчеләргә читлек, таш капчык булды.

Әсирлектә дә фашистларга үлем карары укыган татар халкының баһадир улы янында Үзбәкстан җирендә туып-үскән көрәштәшләре дә булган. Без алар турында берничә мәртәбә язган да идек инде. Әле соңгы араларда гына афишаларда каһарман шагыйрьнең тагын бер көрәштәше—Үзбәкстан улы Хәбибулла Фәйзуллаев исеме күренде.

Бөек Ватан сугышы кырларында авыр яраланып, әсир төшкән Хәбибулла Фәйзуллаев чәнечкеле тимер чыбык артындагы җәһәннәм газапларын татыган, җәлилчеләр сафында торып ул да көрәшкә омтылыш, җиңүгә ышаныч тойгысы кичергән.

Фашист басып алучылары, чигенгән саен, тоткыннарны бер концлагерьдан икенчесенә күчереп торалар: Львов, Кельце, Вустрау...

— Бер белдерү хәзергәчә күз алдымнан китми, — дип искә төшерә Хәбибулла ага. — Барлык концлагерьларда очрады ул. Шул ук вакытта фашист ерткычларының үз-үзләре өстеннән язган гаепләү акты да иде бу белдерү. Анда болай дип язылган иде: «Белдерү. Кем дә кем мәетләр гәүдәсеннән ит кисеп алса һәм аның бу эше сизелсә, ул үлем җәзасына тартылачак. Лагерь администрациясе».

Мондый вәхши манзараны тарих моңарчы да күрмәгән, мин ышанам, моннан соң да күрмәс.

...Хәбибулла Фәйзуллаев әнә шундый вәхшәт тырнагында, Вустрауда чакта Муса Җәлил белән очраша. Аның күңелендә каһарман шагыйрь белән аралашкан ул көннәр гомеренең иң кара һәм иң якты мизгелләре булып урнаша. Шушы көннәрнең караңгы пәрдәсенә Муса Җәлил якты нур булып сирпелә.

— Шагыйрьнең лагерьдагы фамилиясе Гумеров иде, — дип искә төшерә Хәбибулла Фәйзуллаев. — Тәбәнәк кенә буйлы, башына һәр вакыт татарча чигелгән кызыл түбәтәй киеп йөргән Муса аз сүзле һәм үтә уйчан иде. Ул чагында Муса Җәлилнең күренекле татар шагыйре икәнлеген белмәсәк тә, аның гади кеше булмавын сизендек. Эшкә чыккан чакларда, хәлсезлектән артка кала башласа, мин аны тизрәк култыклап алырга, аңа таяныч булырга тырыша идем. Ул миңа һәр вакыт: «Энем, кеше чебен шикелле үлеп китмәскә тиеш. Аның туган җире бар. Моны онытма!» — ди торган иде. Караңгы кичләрдә аның тирәсенә шигырь яратучылар җыела һәм алар бу хәлсезләнгән, әмма корыч рухын саклаган кеше янынннан дәртләнеп таралышалар иде. «Кеше чебен шикелле үлеп китәргә тиеш түгел!..» — Бу сүзләр без тоткыннарның сугышчан девизына әверелде. Шушы девиз безне иң авыр хәлләрдә дә Ватаныбыз һәм халкыбыз өчен тормышыбызны саклап калырга өндәп торды. Без Муса Җәлил белән ике ай чамасы гына бергә булдык. 1943 елның апрель башларында Муса безнең белән хушлашты. Аны каядыр алып киттеләр.

Очраклы рәвештә нәкъ шушы вакытларда Хәбибулла Фәйзуллаев үзе дә шигырьләр язгалаган. Бу җәһәттән дә ул каһарман шагыйрьдән күп нәрсәгә өйрәнгән. Муса кулында булган, аның киңәше белән кат-кат эшләнгән шигъри тәҗрибәләрен ул иң кадерле ядкарь итеп саклый. Бигрәк тә аның 1943 елда, февраль аенда язылган «Дошманга» дигән шигыре ялкынлы шагыйрь Муса Җәлил шигырьләренең рухына якын тора, алар белән аваздаш яңгырый:

**Көлмә, әй, дошман!**
**Озакка бармас**
**Башыма төшкән**
**бәхетсез көннәр.**
**Хакыйкать өстен**
**чыкмыйча калмас.**
**Таңнарым атар,**
**узар бу төннәр.**

Совет кешеләренең ышанычына нигезләнгән әнә шундый батырлык рухы сугышта җиңүче булды.

Хәбибулла Фәйзуллаев хәзер дә иң удар вахтада — Карши төзелеш идарәсендә эшли. Кешелек дөньясының киләчәгенә булган зур ышаныч аның күңелен нәкъ әнә шул көннәрдә биләп алган.

Тормышта яшен шикелле ялтыраган Муса Җәлил һәм аның Моабит шигырьләре исә, тынычлык символы булган ап-ак күгәрченнәр кебек, җиһан күгендә, биектә-биектә канат җилпиләр.

**ИСХАК ЗӘБИРОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**
Үзбәкчәдән АБДУЛЛА СӘЛАХЕТДИНОВ тәрҗемәсе.

9*

**Идмас Үтәгәнов,**
театр белгече

# СӘХНӘ КАҺАРМАНЫ

*Мөхтәр Мутинның 90 еллыгына*

Кешелекнең азатлык өчен көрәшен, якты һәм саф идеалларын театр сәхнәсендә маяк итеп күтәргән, зур актерлык талантын, гаять көчле темпераментын шул изге максатка хезмәт итүгә багышлаган Мөхтәр Мутин иҗаты татар театр сәнгатендә җуелмаслык эз калдырды.

Мондый көрәшче актер-гражданинны, халыкның тирән катлауларын төптән кузгатып, азатлык, социаль гаделлек һәм бәхет өчен көрәшкә күтәргән революция генә тудыра ала иде. Шуңа күрә дә Беренче рус революциясе һәм аннан соңгы яңа революцион күтәрелеш елларында сәхнәне ялкынлы идеаллар өчен дау мәйданы итеп, хөр фикерләр дөрләтү өчен файдаланган Мутин кебек кешеләрнең театр сәхнәләренә күтәрелә башлавы гаять мөһим һәм зарури күренеш булды.

Мөхтәр Мутин хәзерге Татарстан АССРның ямьле төбәкләреннән берсе саналган Актаныш районы Такталачык авылында 1885 елның (иске стиль белән) 20 декабрендә крестьян гаиләсендә туган.

Булачак артистның әнисе Мәрьям апа яхшы белем һәм тәрбия алган хатын була. Ул иренең дуамаллыгына түзеп, буйсынып яшәргә теләми; аның иске тормыш-яшәеш тәртипләренә баш бирмичә, биш яшьлек малаен алып, авылдан чыгып китәргә йөрәге җитә. Бәләбәйгә, туган йортына кайтып, ул бөтен гомерен баласын тәрбияләүгә багышлый, көн-төн чигү чигә, акча җыеп, Мөхтәрне гимназиягә урнаштыруга ирешә.

Малайда укуга сәләт иртә уяна, ул аеруча әдәбиятны ярата, төннәр буе шигырь китапларын мавыгып укый. Гимназиядә укыганда ук классташ дуслары белән бергә әдәби түгәрәкләргә йөри, укучылар куйган спектакльләрдә катнаша. Укуын тәмамлап, Уфадагы үзәк мөселман дини идарәсендә бухгалтер булып эшләгәндә Мутинның театрга мәхәббәте тагын да ачыграк юнәлеш ала. Шәһәр приказчиклары белән бергә, алар төрле вак концертлар, соңрак кечкенә спектакльләр куя башлыйлар. Яшь Мутинның мәгълүм җырчы Фәттах Латыйпов белән оештырган концертлардагы ялкынлы чыгышларын Оренбург һәм Уфа шәһәрләрендә яшәүчеләр бик җылы кабул итәләр.

Рус телен яхшы үзләштергән Мөхтәр тиздән Уфада һәм башка шәһәрләрдә революцион рухлы рус яшьләре белән таныша. Русның революциягә кадәрге күренекле тел осталарыннан берсе Дарьялов концертларында катнашуы, алдынгы провинциаль интеллигенция вәкилләре белән элемтәдә булуы аны, әлбәттә, Уфаның дин әһелләре белән бәрелештерми калмый. 1906 елда Мутин дини идарәдәге эшеннән куыла. Беренче рус революциясе дулкыннары тынгысыз йөрәкле, әзләнүчән егетне үз эченә бөтереп ала. Уфа сәүдәгәрләренең берсе Шәмгуновта ревизор һәм приказчик булып эшли башлагач, шәһәр приказчиклары забастовкасында катнашуы өчен, ул ике ай ча-

масы охранка төрмәсендә утыра, полиция күзәтүе астына эләгә. М. Мутинның революцион хәрәкәттә якыннан торып катнашуын без икенче бер документтан да беләбез. Күптән түгел Башкортстан дәүләт архивында Уфа социалист-революционерлар оешмасы буенча агентура мәгълүматлары көндәлегеннән 1909 ел 23 ноябрьда алынган бер күчермә табылды. «Уфада (берләштерелгән социал-демократ һәм социал-революционер) татар типографиясен оештыруда,— диелә күчермәдә,— Шәмгунов магазинының конторщигы, Уфада яшәүче Мөхтәр Мутин катнашырга тиеш (материаль ярдәм һәм тарату)»[1]. Шунда ук Мутин артыннан күзәтү оештырылуы хакында да әйтелгән.



Партия эшләре буенча Уфага килгәндә беренче татар большевигы Хөсәен Ямашев сәүдәгәр Кәримов йортында, үзенең туганы Хәдичәгә туктый торган булган. Ә ул йорт М. Мутин эшләгән Шәмгунов кибете белән янәшә генә урнашкан. Х. Ямашев белән Мутин очрашканнармы-юкмы — хәзергә монысын әйтүе кыен. Әмма Хөсәен Ямашев кебек театр сөюче кешенең ул вакытта ук инде таныла башлаган талантлы артист Мутинны күрмәве мөмкин түгел. Тагын менә шул кадәресе дә бар: «Урал» газетасы ябылганнан соң Х. Ямашев большевистик газета чыгаруны җайга салу өчен яңа мөмкинлекләр эзли. Аңа бу ниятен тормышка ашыруда патша охранкасының күзәтеп торуы нык комачаулый. Югарыда телгә алынган агентура хәбәре, ихтимал, нәкъ менә Х. Ямашев эшчәнлеге белән бәйләнештә булгандыр.

Мөхтәр Мутинның охранка каршында ышанычсыз һәм шикле кеше булуы анык беренче тапкыр Казанга килүеннән соң да күренә. Рус театрына артист Мутин килү хәбәре ишетелү белән полициядан унтер Сафа килеп, аны пароход белән кире Уфага озата. Әмма Мутин тиздән шулай да Казан тамашачылары белән очрашкан. 1909 елның язында хәзерге М. Горький исемендәге культура һәм ял паркында «Халыкара күргәзмә» дип исемләнгән бер күргәзмә барган көннәрдә анда Габитов җитәкчелегендәге һәвәскәр труппа чыгыш ясый. «Алдым-бирдем» спектаклендә Уфадан чакырылган Мутин Әхмәди ролен уйнап уңыш казана.

Татарлар арасында үзенә күрә сәнгать меценаты саналган сәүдәгәр Шәмгуновта эшләгән елларда Мутинга Урал һәм Себер шәһәрләрендә еш булырга туры килгән. Пермьдә яки Чиләбедәме, Оренбург яки Троицкидамы — кайда гына булмасын — Мутин театр сөюче татар яшьләрен эзләп таба, спектакльләр оештыра һәм әдәби концертларда чыгышлар ясый.

Мутин татар сәхнәсенә әдәби концерт жанрын алып килде, киң аудитория алдында, беренчеләрдән булып, халык шагыйре Габдулла Тукай, Сәгыйт Рәмиев поэзиясен пропагандалады. М. Мутин үзенең табигый таланты белән Тукай, Рәмиев шигырьләрендәге тирән эчке мәгънәне ача, алар иҗатындагы социаль азатлык, шәхес иреге, мәгърифәт өчен көрәшкә чакыру мотивларын киң яңгырашы белән халыкка җиткерә. Апухтин һәм Корецкий кебек рус шагыйрьләренең әсәрләре, Чехов хикәяләре дә актер репертуарында күренекле урын тота. Аларны ул рус һәм татар телләрендә башкара. Әлеге чыгышларында ук Мутин вак тормыш-көнкүреш, мещанлык сазлыгыннан котылу юлын эзләп бәргәләнүче шәхеснең киеренке эчке кичерешләрен тирәнтен ача һәм сурәтли белгән. Николай Корецкийның «Караңгылык эченнән» дип аталган шигъри циклын аеруча яратып башкарган.

---

[1] БАССР Үзәк дәүләт архивы, ф. 187, I тасвирлама, 331 эш, 141—142 битләр.

1912 елның язы Мутинның тормышы һәм иҗатына зур яңалык алып килә. С. Гыйззәтуллина-Волжская, Фәттах Латыйпов белән бергә, алар Уфада «Нур» труппасын оештыралар. Шулай итеп, аның иҗаты яңа баскычка күтәрелә, ул профессиональ актер булып китә. Мөхтәр Мутин үзенең тормышын инде театрдан, тамашачы белән даими бәйләнештән башка күз алдына китерә алмый.

Моннан илле еллар элек К. С. Станиславский чын театрда «үзләренең югары миссияләрен аңлаган һәм шул миссияне өстәмә алкышлар, үзенең бәләкәй генә актерлык шөһрәтен канәгатьләндерү өчен түгел, ә милли патриотизм һәм гомум кешелек идеясе хакына үтәүче кешеләр булырга тиеш», дип язган иде. Мөхтәр Мутин татар сәхнәсендә актерның югары гражданлылык вазифасын нәкъ әнә шулай аңлый торган шәхес буларак танылды. Профессиональ сәхнәдәге беренче адымнарыннан алып аның иҗатына тойгы һәм хисләр дөреслеге хас булды. Геройларының һәр гамәлен ул ышандырырлык итеп гәүдәләндерә белә, чөнки болар аның үз иманының ныклыгына, тирән интеллектуаль сыйфатларына, философик фикер йөртү, ышанганлык көченә нигезләнәләр. Кайнар темперамент, үзенең эмоциональ халәтен тамашачыга күчерә алу сәләте Мутинга тормыш мәгънәсе, революцион фидакарьлек, рухи батырлык хакында тамашачы белән ачыктан-ачык сөйләшергә мөмкинлек бирә. Тамашачы үзен актерның дусты, сурәтләнгән вакыйгаларда катнашучы көрәштәше итеп сизә, бөтен күңеле белән аңа ышана, аңа иярә.

1912—1917 елларда «Нур» һәм Сигрәк тә «Ширкәт» труппасында эшләгәндә М. Мутин иҗатының әнә шушы төп сыйфатлары формалаша башлый. «Ширкәт»не (1915—1917 еллар) Мутин үзе «нык профессиональ татар театрының башлангычы» дип атый. Бу труппа, чынлап та, тулысы белән профессиональ актерлардан торган, ул ике дистәләп артистны берләштергән. «Сәйяр» һәм «Нур»да исә әле андый состав булмый. «Ширкәт»тә ул елларда, М. Мутиннан башка, С. Гыйззәтуллина-Волжская, яшь актриса Ф. Ахмерова-Ильская, Мортазин-Иманский, Камал I, Казанский, Мангушев кебек актерлар уйнаган. Репертуарга кергән әсәр авторлары арасында без, Г. Камал һәм Ф. Әмирханнан башка, Мольер, Шиллер, Гогольне күрәбез. Шиллерның Мутин тарафыннан 1916 елда куелган «Юлбасарлар» трагедиясе труппа эшчәнлегендә зур бер этапны тәшкил итә. Карл Моорны Мутин үзе уйный. Ул тиздән актерның иң яраткан образы булып китә һәм Мутин репертуарында соңыннан үзәк урыннарның берсен алып тора. Революция алды чорында тудырылган бу образ социаль әһәмияте белән бөтен татар театры үсешенә зур өлеш кертте.

Октябрь революциясен Мөхтәр Мутин әнә шулай каршылый. Революциягә ул бөтен иҗат ялкынын багышлый, иске җәмгыять тәртипләрен нигезенә кадәр җимерү, яңаны тудыру өчен каһарманнарча көрәш пафосы Мөхтәр Мутин иҗатында революциянең беренче елларыннан ук ниндидер аеруча күтәренке һәм ярсулы яңгыраш ала. Революция актерның трагик таланты ачылып китү һәм үсүгә куәтле этәргеч бирде. Мутин сәхнәдә зур уңыш белән Карл Моорны башкара, Әлмансур (Г. Гейне), Надиршаһ (Н. Нариманов әсәре) образлары да аның уены аша сәхнәдә яңа көч белән яңгырый башлый. Актер буларак, шушы чорда ук инде ул тирән фикерләүгә, трагик хис-тойгы үткенлегенә ирешә. Трагик актер үзенең тавышы, мимика, хәрәкәтләр, актерлык техникасының бөтен бай арсеналы белән гаять дәрәҗәдә төгәл идарә итә белергә тиеш. Бу яктан ул чор татар сәхнәсендә Мутинга беркем дә тиңләшә алмый. Актерлык осталыгын үстерү өстендә ул көн саен һәм гомере буе эшли.

1918 елның язында Мөселман комиссариаты Мутинны театр труппасы төзү өчен Әстерханга җибәрә. Зәйни Солтанов белән бергә оештырган яңа труппада, иң беренче спектакль итеп, Шиллерның «Юлбасарлар»ы уйнала. Мутинның Карл Мооры тамашачыларны сокландыра. Пьеса каһарманы революцияне яклап сугышучы чынбарлыктагы каһарманнар белән әйтерсең бергә яши; «Тираннарга каршы!» дигән ялкынлы чакыруы белән акгвардиячеләр һөҗүменнән шәһәрне саклаучы кызылармеецларны җиңүгә рухландыра. Әстерханда чыга торган «Сарай» газетасы Мутинның сәхнәдәге уенын бөек әзербәйҗан трагик актеры Араблинский белән тиңләштерә. Ике милли театр культурасының бу гигантлары классик драматургияне массалар арасында пропагандалаулары белән дә, тирән социаль эчтәлекле әсәрләр куюга омтылышлары белән дә бер-берсенә якын, охшаш иделәр.

Революциядән соңгы елларда татар театрын тирән эчтәлекле һәм житди темаларга юнәлдерү, бигрәк тә классик репертуарны баету һәм үстерүдә М. Мутинның роле зур булды. Ул Казан Мөселман хәрби комиссариатының театр секциясендә эшли, эшчеләр арасында театр труппалары оештыра, спектакльләрдә катнаша, хәрби частьларда концертлар бирә. Татарстан АССР төзелгәннән соң, Мутин Мәгариф халык комиссариатының театр бүлеге мөдире итеп билгеләнә. һәм ул яңа татар совет театрын оештыру эшенә җиң сызганып керешә. Төрле шәһәрләрдән, эрелевaклы труппалардан сәләтле артистларны чакыртып, талантлы һәм булдыклы коллектив туплый, яңа театрның юнәлешен билгели торган тотрыклы репертуар булдырырга тырыша. Әнә шулай итеп, тиз арада «Беренче татар дәүләт күргәзмә театры» оешып җитә, утыздан артык актерны берләштергән иҗади коллектив туа.

Әмма Октябрьдан соң театр нинди булырга, аның идея юнәлешен, иҗат йөзен нәрсә билгеләргә тиеш соң? Яшь театр әнә шундый сорауларга җавап эзли. Шушы чорда татар театры сәхнәсендә героик-романтик стильнең өстенлек алуы турыдан-туры М. Мутин эшчәнлегенә бәйле. Ул яшь татар совет театры өчен революцион репертуар булдыру, революция һәм производство темаларына багышланган пьесаларга конкурс оештыру мәсьәләсен алга куя. Шәрык халыклары арасында революцион аң таратуда татар театры гаять зур роль уйнарга тиеш дип саный. Революция тудырган яңа кеше, бөек идеаллар белән рухланган көрәшче образы Мутинның үз иҗатында да үзәк урынны ала. Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» әсәреннән Батырхан, Горький пьесаларыннан Сатин һәм Нил образлары Мутинның бу чордагы иҗатында яуланган яңа үрләр булып тора.

Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр», М. Горькийның «Дошманнар», «Тормыш төбендә», «Мещаннар», Шиллерның «Юлбасарлар» кебек әсәрләрнең егерменче еллар башы репертуарында зур урын биләве театрның үсеше өчен принципиаль әһәмияткә ия була. Чөнки нәкъ менә героик-революцион жанр аның киләчәк казанышларын, иҗат юнәлешен билгеләүче тенденцияләрне чагылдыра.

Совет театрлары үткән юлны ил күләмендә күздән кичерсәк, театр сәнгатендә социалистик реализм методының героик драма аша үз-үзен раславын күрербез. Героик-революцион тема театрларга эпоханың төп конфликтларын сурәтләү һәм шулар аша яңа тормышны төзүчеләрнең эре типик характерын тудыру, тарихи оптимизмны раслап, партиячел ялкын белән яңалык өчен көрәшү юлларын ачты. Классик драматургия әсәрләренә мөнәсәбәт егерменче еллар башы татар театрында менә шушы позициядән чыгып билгеләнә, сәхнәдә алар, табигый рәвештә, героик репертуарның аерылгысыз бер өлеше булып китәләр. Шекспирның «Отелло» һәм «Гамлет» трагедияләренең беренче тапкыр татар сәхнәсенә менүе, хаклы рәвештә, театрның бу еллардагы иң зур казанышларыннан берсе санала. Мөхтәр Мутин «Отелло»ны 1921 елда сәхнәгә куя һәм баш рольдә үзе уйный. Актерның трагик таланты монда бар куәтенә ачылып китә. «Отелло-Мутин, — дип яза тәнкыйтьче Гали Рәхим, — шәрык улы булып күз алдына баса. Аңардагы изге күңеллелек, акыл, энергия һәм кыюлык күзгә бәрелеп тора... Әмма ул гаҗәеп беркатлы, тиз ышанучан. Бу мәрхәмәтле кешенең намусы һәм вөҗданы саф. Аның өчен иң бөек принцип — җәмгыять һәм үз-үзең алдында тугрылыклы булу»[1].

Отелло образының чишелеше күп кенә провинциаль театрлар спектакльләрендә гаилә конфликты чикләреннән чыга алмаган булса, Мутин башкаруында зур социаль һәм гуманистик яңгыраш алды, ул — бөек идеалларга тугры булырга, гаделлеккә чакыру иде. Актер үзенең уены белән тамашачылар күңелендә шул давыллы чорга авазлаш булган җанлы ассоциацияләр уятты, революциянең хаклыгына тирән ышанычны раслады. НЭП чорына аяк атлаганда, мещанлык идеологиясенә каршы көрәш көчәйгән елларда бу бигрәк тә зур әһәмияткә ия иде. Спектакльнең конфликты үзен иректә итеп сизгән, хаклыгына һәм бәхетенә нык ышанган Отеллоның шул җәмгыятьтәге барлык кара көчләр белән котылгысыз бәрелешүендә гәүдәләнә: Яголар дөньясы шәрык улының ирекле һәм бәхетле булуы белән килешә алмый.

---

[1] «Татарстан хәбәрләре», 1921 ел. 85 сан.

Конфликтның шушы рәвешчә хәл ителүе егерменче еллар тамашачысына якын һәм аңлаешлы була, спектакльнең җитди уңыш казануына ярдәм итә.

Шул ук елны Шекспирның тагын бер әсәре — «Гамлет» тәрҗемә ителә. Гали Рәхимнең проза белән эшләнгән бу тәрҗемәсе матбугатта уңай бәя ала. Җәй һәм көз айларында М. Мутин Гамлетның сәхнәдә уйналу тарихына караган күп төрле материалларны өйрәнә. Спектакльне әзерләүдә аңа күптән түгел Казанга килгән күренекле режиссер һәм театр тәнкыйтьчесе Ю. Соболев зур ярдәм күрсәтә. Премьера 1922 елның 21 апрелендә уза.

Режиссер Ю. Соболев һәм башкаручы М. Мутин Гамлет образын героик планда хәл итәләр. Тамашачы алдына Гамлет һәртөрле ялган һәм алдаулар, куркаклык һәм хыянәт белән килешә алмый торган кыю йөрәкле, зирәк кеше булып килеп баса. Мутинның Гамлеты үзенең бөтен акыл һәм рухи көчен хакыйкатьне ачуга багышлый. Күңел күзе алдында хакыйкать үзенең барлык явызлыгы һәм куркыныч яклары белән ачылып киткәч тә, ул коелып төшми, рәхимсез чынбарлык алдында чигенми, ә шул чынбарлыкны үзгәртү өчен көрәш юлына баса. Бары тик яңа тип актер, тамашачыны героик эпоха рухында тәрбияләү максатын беренче планга куйган актер гына бу бөек образны шулай уйный ала иде. Чыннан да, сәхнәдә элек Гамлетның эчке хискичерешләре, шикләнү-икеләнүләре, җан газаплары һәм пессимизм өстенлек алып торса, режиссер һәм актер бу спектакльдә төп игътибарны икенче якка юнәлтәләр. Үзәккә бөтен явызлык һәм мәкерлекнең башы — замок куела. Шул замок эчендә хөкем сөргән тәртипләргә каршы көрәшергә кирәк. Бу аяусыз көрәштә Гамлет үзен шәхес буларак раслый. Мутинның Гамлеты шул ук вакытта интеллектуаль сыйфатларын, философик уйлануларының тирәнлеген дә югалтмаган. Гадел Кутуй билгеләп үткәнчә, Мутин Гамлеттагы эчке ярсуны, үчлелек тойгысын, аның үткерлеген, акыл тирәнлеген, гадилеген һәм образның шигърияттен калку итеп гәүдәләндерә алган.

Мөхтәр Мутинның Шекспир образларын җанландыруда ирешкән уңышы аның зур талантының нурланышы гына түгел иде. Аның әдәбият, шул җөмләдән, драматургия һәм поэзия өлкәләрендә зур белем туплаган, Гегель, Фейербахны өйрәнгән, марксизм классикларының әсәрләрен үзләштергән, хәтта һинд философиясе белән мавыккан киң колачлы шәхес булуын да онытмаска кирәк. Ул Шекспирның материалистик философиясенә тирән үтеп керә.

«Гамлет» спектакле яңа туган театр — совет театрының зур иҗади җиңүе булып тарихка керде. Ул НЭП елларында сәт өстендәге күбектәй өскә күтәрелгән буржуазия калдыкларына, мещанлыкка, пессимизмга нәфрәт авазы булып яңгырады. Спектакль гаять зур уңыш казанды һәм 1927 елга кадәр театр репертуарыннан төшмәде.

Мөхтәр Мутин 1923—1924 елларда Уфада татар-башкорт труппасын оештыра. Монда да «Отелло», «Гамлет», «Мәкер һәм мәхәббәт», «Юлбасарлар» труппа репертуарының үзәгендә була. 1925 елда ул яңадан Казанга, Татар дәүләт академия театрына кайта. Гамлетны уйный, Д. Юлтый әсәре буенча куелган «Карагол» спектаклендә Карагол, К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр»ендә Батырхан образларын иҗат итә. Батырханны ул тирән психологик образ итеп гәүдәләндерә, үткән көннәрне кайтарырга хыялланучы буржуаз милләтче тибын үткен сатирик чаралар белән күз алдына бастыра. Театр сәнгате өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен актерга республиканың атказанган артисты дигән исем бирелә.

1927 елда Гыйльми үзәк М. Мутинны Мәскәүгә, кино режиссерлары курсына укырга җибәрә. Чөнки нәфис фильмнар киностудиясе өчен кадрлар хәзерләү мәсьәләсе алга килеп баса. Ә бу идея Мутинның исә бөтен күңелен биләп ала. Ул Мулланур Вахитовның татар киносын булдыру турындагы хыялын тормышка ашырырга тели. Кино курсларын тәмамлаганнан соң Мутин берничә ел Уфада, Башкорт дәүләт театрында эшли, спектакльләрдә беренче тапкыр кино эффектларыннан файдалана.

1930 елда ул Татар дәүләт академия театрына кайта һәм тормышының соңгы көннәренә кадәр аңардан аерылмый. Актер өчен яңа иҗади эзләнүләр, яңа табышлар чоры башлана.

Ул К. Тинчуринның «Кандыр буе» спектаклендә Минһаҗ, А. Афиногеновның «Курку» әсәре буенча куелган спектакльдә профессор Бородин образларын зур уңыш белән башкара. Бу чорда М. Мутинның иҗаты яңа төсмерләр белән баый, граж-

данлылык һәм әхлакый идеал хакында ул күп уйлана, замандашларының күңел хәзинәсен, чын характер сыйфатларын калку итеп чагылдырырдай яңа чаралар эзли. Сәхнәдә ул яңа кешене характерлый торган билгеләрне гәүдәләндерергә омтыла, социаль күренешләрне җанландыра алырлык буяулар таба. Актерның ул эзләнүләре «Кандыр буе»нда, «Бронепоезд 14-69» (Вершинин), Ф. Вольфның «Профессор Мамлок» (Гендель), «Дошманнар» (Захар Бардин), «Тартюф» кебек спектакльләрдә башкарган рольләрендә чагылыш таба.

М. Мутин — комедик талантка да ия булган актер. Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясе буенча куелган спектакльдәге Хаҗи роле, мәсәлән, аның бу сәләтен бик ачык күрсәтә. Ә Нәкый Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу» драмасын сәхнәләштергән чорда ул иҗат иткән Гыйфрай образы тирән трагик яңгырашы белән хәтердә кала. Соңгы елларда М. Мутин Шекспирның «Король Лир», «Ричард III» әсәрләрен өйрәнә, аларны сәхнәдә уйнау өчен җитди әзерлек алып бара. Әмма бу теләгән тормышка ашырырга өлгерә алмый. М. Горькийның «Дошманнар» әсәрендәге Захар Бардин — Мутинның театр сәхнәсендә уйнаган соңгы роле була. Иҗат эшчәнлеге һәм талантының чәчәк аткан чорында аның гомере трагик рәвештә өзелә.

Мөхтәр Мутинның сәхнә мирасы зур, аның таланты һәм иҗат куәте белән тудырылган бик күп образлар татар театр сәнгатенең алтын фондына керде. Бу мирас җентекләп өйрәнелергә һәм үзләштерелергә тиеш. Бүген — театр сәнгате эшлекләреннән без чын гражданлылык хисләре белән сугарылган тирән идеяле спектакльләр көткән чорда — татар театрының өлкән буын осталары калдырган гүзәл традицияләргә әледән-әле әйләнеп карыйбыз. Сәхнәгә үзе белән зур фикерләр алып килә торган актерга бүгенге театрда да ихтыяҗ зур. Утыз еллык иҗат гомерендә Мөхтәр Мутин революцион идеаллар һәм югары гражданлылык өчен ялкынлы көрәш үрнәкләре бирде. Халкыбызның художестволы фикерләү куәтен, аның яктылыкка, гүзәллеккә омтылышын гәүдәләндергән бу иҗат татар театрында киләчәктә дә бик күп яшь буын актерларын рухландырыр, маяктай балкып, алга дәшеп торыр, кыю эшләргә чакырыр.

# ГАМИР НАСРЫЙНЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

## КҮРЕНЕКЛЕ ДРАМАТУРГ



Күп санлы сәхнә әсәрләре белән кырыгынчы-илленче елларда татар совет драматургиясендә тирән эз калдырган, театр сәнгате үсешенә сизелерлек өлеш керткән күренекле драматург Гамир Насрыйның тууына 60 ел тулды.

Гамир Гариф улы Насретдинов 1916 елның 3 январенда Башкортстан АССРның Кызыл Кама районы, Иске Янҗегет авылында крестьян семьясында туа. Яшүсмер чорыннан ук ул хезмәт юлына аяк баса, үз колхозларында хисапчы, район җир бүлегендә секретарь булып эшли.

Гамир Насрый бик яшьли каләм тибрәтә, әдәби иҗатын поэзиядән, я булмаса прозадан да түгел, ә туп-туры драматургия кебек катлаулы жанрдан башлый, уналты яшендә үк аның «Ялкау Бикмөхәммәт» исемле дүрт пәрдәлек пьесасы матбугатта күренә. Утызынчы елларда Г. Насрый кече күләмле драматургия өлкәсендә тырышып эшли, инсценировкалар, драматик этюдлар яза, шуларның бер өлешен туплап, 1934 елда «Колхоз театры» исемле җыентыкта бастырып чыгара. Яшь драматург өчен ул еллар тәҗрибә туплау, тормышны өйрәнү, иҗади җитлегү чоры була. Танылган драматург булып җитешкәч тә, Г. Насрый кече күләмле сәхнә әсәрләре язуын ташламый, авыл һәм район һәвәскәрләре өчен тормышның үткен, актуаль мәсьәләләрен күтәргән күп кенә скетчлар, этюдлар, бер-ике пәрдәлек пьесалар иҗат итә.

Утызынчы елларның икенче яртысыннан драматург иҗади каләмен акрынлап эре күләмле әсәрләр язу эшенә җигә, «Делегат» исемле дүрт пәрдәлек пьеса, «Ил чигендә» дигән драмасын дөньяга чыгара.

Гамир Насрый ун елга якын Совет Армиясендә хезмәт итә, ак финнарга каршы сугышта һәм Бөек Ватан сугышында катнаша. Фронтта күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены, күп кенә медальләр белән бүләкләнә. Ватан сугышының соңгы чорында ул фронт газетасының хәрби корреспонденты булып эшли, «Фронт хакыйкате» газетасы (соңыннан «Җиңү байрагы») битләрендә совет сугышчыларының батырлыкларын, алгы сызыктагы тормыш-көнкүрешен сурәтләгән дистәләрчә очеркхикәяләр, күп кенә җыр-шигырьләр бастырып чыгара.

Гамир Насрый үзенең иң уңышлы сәхнә әсәрләрен сугыштан соңгы елларда иҗат итте. Бер-бер артлы аның «Күңел дәфтәре», «Без капчыкта ятмый», «Идел буенда» исемле комедияләре туа. Г. Насрый пьесаларына материалны һәрчак үз чорыннан сайлап алырга, иҗатында чын тормыш проблемаларын яктыртырга омтыл-

ды. Аның иҗатына хас бу сыйфат алга таба тагын да көчәйде, үсте һәм язучы чынбарлыкны сәнгать биеклегеннән торып сурәтләүдә үргә күтәрелә барды. «Туган авылым», «Кушнарат», «Кадерле минутлар», «Яшел эшләпә» кебек колхоз авылы һәм завод-фабрика тормышыннан алынып язылган әсәрләре тамашачыларда аеруча зур популярлык казанды. Алар республикабызның профессиональ һәм үзешчән театрлары репертуарында күренекле урын алдылар.

Гамир Насрыйның сәхнә әсәрләренә һәм аерым җыр текстларына композиторларыбыз С. Сәйдәшев, З. Хәбибуллин, Җ. Фәйзи, Р. Яхин һ. б. тарафыннан музыка һәм күп җырлар иҗат ителгән. «Алтын көз» («Идел буенда») музыкаль комедиясе (Җ. Фәйзи музыкасы) Татар дәүләт опера һәм балет театрында куелды. «Совет солдаты», «Сайра син, тургай», «Зәңгәр», «Күңелемдә яз», «Яз шатлыгы», «Хак булса әгәр» һ. б. җырлары бүген дә концертларда яңгырый, халык арасында яратып җырлана.

Гамир Насрый «Әшнәкәй», «Дилбәр» һ. б. поэмалар, күп кенә шигырь һәм хикәяләр, очерк-фельетоннар авторы да. Язучының архивында дөнья күрмәгән янсә төгәлләнми калган сәхнә әсәрләре, поэма һәм шигырьләр, тәнкыйть мәкаләләре саклана. Укучыларга бу санда шулар арасыннан «Бикмулла хәзрәтнең биш нәсихәте» дигән скетч һәм «Җиңү байрагы» исемле фронт газетасында басылган (1 январь, 1946 ел) бер хикәя тәкъдим ителә.

**Гамир Насрый**

# РӘХМӘТУЛЛА АБЗЫЙ ӘКИЯТЕ

ХИКӘЯ



Рәхмәтулла абзыйның йомры сөякле җиңел гәүдәсе, җыерчыксыз шома йөзе, борын астындагы тырпайган мыегы, көйдереп алырдай үткен күз карашлары әле дә булса хәтеремдә ачык саклана-лар.

Мин аны беренче һәм соңгы тапкыр Берлин шәһәрендә очраттым. Ул, рейхстагның җимерек стенасын пәке очы белән чукый-чукый, нәрсәдер язып маташа иде. Мин аңа таба якынрак бардым һәм соры таш өстенә кәкре-бөкре зур хәрефләр белән: «Гвардия ефрейторы Рәхмәтулла Гыйләҗетдинов» дип язылган сүзләрне укыдым.

— Нихәл, якташ? — дип дәштем мин аңа. Ул кинәт миңа таба борылды да, шатлыклы елмаеп, көр тавыш белән җавап кайтарды:

— Хәлләр изге, туган.

Без, күптәнге танышлар шикелле, кул кысышып күрештек, хәлөхвәлне сораштык, һәм Рәхмәтулла абзый, чыннан да, минем якташ булып чыкты. Туган-үскән илләрне сагынып, сугышта күргән газапмихнәтләрне искә төшереп, бераз вакыт сөйләшеп торганнан соң, ул башы белән стенага таба ымлап алды да:

— Күрәсеңме, туган? Үземнең исемне тарихка кертеп калдырырга исәп,— дип кәефләнеп көлеп җибәрде. Ул тагын нәрсәдер әйтмәкче булган иде, ләкин шул вакыт безгә таба якынаеп килгән генералны күреп, без икебез дә сүзсез катып калдык һәм, гәүдәләребезне шәмдәй турайтып, генералга сәлам бирергә хәзерләндек. Генерал безнең яныбыздан үтеп барганда, Рәхмәтулла абзыйның йөзе кинәт яктырып китте, һәм ул, үзенең иң якын дустын очраткан кеше сыман, тешләрен генә түгел, бөтен уртын күрсәтеп елмайды да, үз-үзен тыя алмыйча:

— Исәнлек телибез, иптәш генерал! — дип җилкенеп кычкырырга да өлгерде. Бу хәлдән мин аптырап калдым. Рәхмәтулла абзыйның үзен шулай чамасыз иркен тотуына күңелем әрнеде, ачуым килде. «Ах, әдәпсез! Ни кылана бит. Әйтерсең колхоз председателе белән сөйләшә», дип уйладым мин. Ләкин мәсьәлә бөтенләй мин көтмәгәнчә булып чыкты.

Минем якташның тавышын ишетү белән, генерал аңа таба салмак кына әйләнеп карады һәм:

— Я, эшләр ничек, иптәш Гыйләҗетдинов? — дип, дусларча елмайды. Рәхмәтулла абзый, очып китәргә җыенган кош сыман, генерал артыннан тагын талпынып-талпынып кычкыра калды:

— Эшләр яхшы, иптәш генерал!

Якташның бу кыланышы башта бик сәер булып тоелса да, соңыннан үземә дә ошап куйды.

— Нәрсә, таныш генералыңмы әллә? — дип сорадым мин. Рәхмәтулла абзый, үзенең бәхетле елмаюыннан әле һаман айный алмыйча:

— Ничек кенә таныш әле! Менә дигән дус! Үзеңә бер кызыклы вакыйга сөйлимме? — диде һәм, ияген бераз күтәрә төшеп, күзләрен яртылаш йомды да, куллары белән мыегын еш-еш сыпыргалап, ашыкмыйча, җайлап кына хикәят итәргә кереште:

— Бервакыт шулай кыш көне оборонада торабыз. Ә мин үзем, туган, оборона дигән сүзне яратмыйм. Әрләп кебек җир тишегендә томаланып ятканчы, бугаз киереп «урра» кычкыра-кычкыра, атакага бару мең өлеш артык. Әле монысын сүз уңае чыкканда гына әйтүем. Хикмәт анда түгел. Менә шулай оборонада яткан көннәрнең берендә рота старшинасы мине сугыш припаслары алып кайтырга җибәрде. Ничек барганны, ничә ящик патрон төягәнне сөйләп тормыйм. Чөнки хикмәт анда түгел.

Шулай мин үземә кушылган эшне җиренә җиткердем дә кире кайтырга дип юлга чыктым.

Кайта-кайта бер заман кич булды. Караңгы төште. Кар ява башлады. Әй, ява, мин сиңа әйтим, ишелеп-ишелеп ява...

Шулай кар бураны белән тарткалашып кайтып килгәндә, чана кырыенда ниндидер бер кеше шәүләсе күземә чалынып китте. «Әй, кем ул?» — дип кычкырып җибәрдем. Ә үзем тиз генә автоматны эләктереп алдым. «Үзебезнекеләр», — дип җавап кайтарды әлеге шәүлә. «Солдатмы?» — дип кычкырдым мин, тагын да катырак итеп. «Әйе, әйе, солдатлар», — диде ул. Шәйләбрәк карасам, чыннан да, ул берүзе генә түгел икән. Минем чананы өчме-дүртме кеше уратып алганнар. «Әйдәгез, утырыгыз», — дип әйтүем булды, алар дәррәү чанага менеп бастылар. Ә берсе минем яныма ук килеп утырды. Мин аңа таба борылып карадым. Аның өстендәге шинеленә, башындагы тубал хәтле зур бүрегенә, хәтта кашына һәм мыегына да берилле кар сырышкан иде. Мин аның инде олы яшьтәге кеше булуын шунда ук сизеп алдым. Әмма аның генерал икәнлеге

һич кенә дә башыма кереп чыкмады. Үзем шикелле бер гади солдаттыр дип уйладым мин аны. Менә бөтен хикмәт тә шунда, туганкай.

Ул үзе бик көр күңелле кеше булып чыкты. «Их, браток, ниләр генә күрми солдат башы», дип, дусларча гына аркасына кундырып алган идем, ул шаркылдап көлеп җибәрде. Ә мин үзем, туган, шат күңелле кешеләрне яратам.

Шулай без аның белән бик тиз дуслашып киттек. Мин бер сүз әйткән саен, үземнең гадәт буенча, «их, браток!» дип, йомшак кына итеп аның аркасына кундырып алам, ә ул шаркылдап көлә бирә. Менә шул ягы белән ул миңа гаҗәп ошады инде. Ә мин үзем, туган, күңелгә ятыш кешеләрне сыйларга яратам. Аракы салынган флягany бил каешыннан ычкындырып алдым да аның кулына тоттырмакчы булдым. «Мә, эч, солдат, азрак сөякләрең йомшарыр», мин әйтәм. Ә ул: «Эчмим»,— ди. «Әйдә, әйдә, эч,— мин әйтәм.— Нарком нормасы. Хәләл аракы!» «Юк, эчмим,— ди ул кырт кисеп,— үз нормагызны үзегез эчегез»,— ди. «Үзе болай инсафлы кеше икән», дип уйлыйм эчемнән генә.

Шуннан соң флягадагы аракыны тоттым да үзем кәгеп җибәрдем. Кәеф килеп китте бит бер заман. Телем тәмам ачылды. Бер туктамыйча сөйлим дә сөйлим: сугыш башыннан бирле фронтта йөрүемне, дүрт тапкыр яралануымны, ничәмә тапкыр атакага баруымны, бөтенесен тезеп киттем. Ә ул тын да алмыйча тыңлый. Ә мин туган авыл турында, хатын һәм бала-чагалар хакында сөйләргә тотындым. «Их, браток,— мин әйтәм,— берәр генә көнгә булса да авылга кайтып киләсе иде, ә? Балалар бик сагындырды бит». Ә ул минем сагышны уртаклаша: «Командирыңа рапорт язып бир, бәлки кайтарырлар»,— ди. «Юк, ярамый, браток, ярамый»,— дим мин аңа, ә үзем йомшак кына итеп тагын аркасына кундырып алам: «Сугыш вакытында отпуск теләнеп йөрүе оят нәрсә, ә сугыш беткәч, болай да кайтып китәрбез»,— мин әйтәм.

Шулай без аның белән озак гәп корып кайттык. Ике юл чатына килеп җиткәч, ул үз иптәшләре белән чанадан төшеп калды, ә мин урманга таба борылдым...

Икенче көнне, иртәнге аш вакытында, старшина мине очратты да: «Сезне дивизия командиры чакыра», — диде. Шул сүзне ишетү белән тәмам каушадым. Маңгаемнан салкын тир бәреп чыкты. Дивизия командирына, генералның үзе янына бару уен эш түгел бит. Генерал тикле генерал минем кебек гади солдатны тиктомалга гына чакырамы соң?!

Өс-башымны рәтләдем дә, башыма тулган кырык төрле уй белән бутала-бутала, генерал янына киттем. Барып кергәндә тез буыннарым дер-дер калтырый башлады, әмма үземнең каушаганлыгымны сиздермәскә тырышам. Генерал каршына барып бастым да нәкъ уставта язылганча итеп рапорт бирдем.

Генерал башын күтәреп миңа туп-туры карады һәм шундый ягымлы итеп елмайды, куанычымнан эреп китәмме дип торам. «Иптәш Гыйләҗетдинов, батыр солдат булуыгыз өчен, мин сезне бер айга отпускага кайтарам»,— диде ул. Генералның таныш тавышын ишетеп, мин бөтенләй телсез калдым. Күз алдым караңгыланып китте. Ә генерал минем яныма килеп басты да: «Зарар юк. Сугышта төрле хәлләр булгалый. Их, браток!» — дип, йомшак кына итеп аркама кундырып алды һәм гел менә теге чакта чанада барган вакыттагы шикелле, шаркылдап көлеп җибәрде.

# БИКМУЛЛА ХӘЗРӘТНЕҢ БИШ НӘСИХӘТЕ

СКЕТЧ

Сөйләүчесе: Бикмулла хәзрәт үзе.
Җөпләп торучысы: Зәйнетдин мөәзин.
Тыңлаучылар: Сарысакал, Карасакал, Аксакал.

Түгәрәк табында аш-су мәҗлесе тәмамланган. Таралышырга вакыт. Ләкин Бикмулла хәзрәтнең кыймылдарга нияте юк. Ул җиңелчә генә тамак кырып ала да картларга мөрәҗәгать итә.

Бикмулла. Авылыбызның могтәбәр картлары, хак мөселманнар! *(«Мөселман» сүзен ишетү белән Зәйнетдин мөәзин елмаеп җибәрә, авызы чак кына колагына җитмичә кала.)* Аллаһ тәгалә адәм баласын биш бармаклы итеп яраткан... Әйе, хуш, шулай. Аннан китереп, ходай тәгалә адәм балаларына күктән биш китап иңдергән...

Аксакал. Дүртәү генә түгелме соң, хәзрәт?

Карасакал. Бәхәскә кермә, кордаш, хәзрәт әйткәч, биш була инде ул. Бармак саен бер китап дигән сүз.

Сарысакал. Алайса, ун булырга тиеш. Әгәр инде аяк бармакларын да өстәсәк...

Зәйнетдин. Әй, син, кем, китап сүзенә аякларыңны тыкма! Тәһарәт тә алмыйча килгәнсеңдер әле.

Бикмулла. Инде дәхи рәсүлемез Мөхәммәтгаләйһессәлам биш вакыт намазны безгә фарыз итеп калдырган. Ишетәсезме, фарыз, ягъни мәҗбүри дигән сүз! Аннан китереп, тагын... *(Нәрсә әйтергә белмичә, аптырашта кала.)*

Сарысакал. Аннан китереп, хәзрәт, хәтерем ялгышмаса, 1947 елны булса кирәк, колхозның биш капчык солысын урлаган өчен синең улың Сәйфелмөлекне биш елга төрмәгә утыртканнар иде бугай...

Зәйнетдин. Әй, син, кем, Сарысакал, җомга көнне дөнья сүзләрен кыстырып сөйләшмә! Гөнаһсын кая куярсың?

Сарысакал. Бетте, алайса, бетте. Әле тик хәзрәткә конкрет примерлар кирәк булса гына дип әйтүем иде.

Бикмулла. Бәндә хатадан хали түгел, дигән китап. Әйе, хуш, шулай. Инде хәзер мин сезгә, могтәбәр картлар... *(Сарысакалга җен ачуы белән карый. Бераз тотлыгып тора.)* Мин бүген сезгә озын итеп вәгазь укырга җыенмыйм. Әмма ләкин шулай да үземнең биш үгет-нәсихәтемне әйтеп үтмәкче булам, аллаһ боерса. *(Бармакларын бәрәмләп бөгә-бөгә.)* Беренче нәсихәтем — милләт турында булыр, җәмәгать. Икенчесе — хәмер эчүнең гөнаһсы, өченчесе — гаилә татулыгы, дүртенчесе — балаларны дөрес тәрбия кылу һәм дәхи бишенчесе — мөселманнарның үзара яхшы мөнәсәбәттә булулары турында. Әйе, хуш, шулай, башладык. *(Йомарланган кулын күтәреп һәм бераз кызыбрак та китеп.)* Җәмәгать, сез беләсезме үзегезнең кайсы өммәттән, ягъни, мәсәлән, кайсы милләттән икәнегезне?

Аксакал. Бик беләбез, хәзрәт, татар милләтеннән.

Бикмулла. «Татар» дигән милләт юк, җәмәгать! Китап әйтә...

Сарысакал. Тукта әле, хәзрәт, татар милләте нишләп булмасын ди?

Карасакал. Хәзрәт әйткәч, юк инде, юк!

Сарысакал. Как туес юк!

Бикмулла. Сабыр итегез, җәмәгать, хәзер аңлатып бирәм. Мәгълүмдер ки, 1939 елны халык саны исәпкә алынды. Шул елны мин, ходай тәгаләнең әмере буенча...

Сарысакал. Әйе, әйе, хәзрәт, төрмәдә утыра идегез. Теге, ни өчен... Бакалы базарында алыш-биреш ясап...

Зәйнетдин. Әй, әй, син, кем, Сарысакал, җомга көнне базар сүзләрен калдырып тор! Алла сакласын, авызыңнан иманың качар.

Сарысакал. Ярый, алайса, дәшмим. Әле тик хәзрәтнең хәтереннән чыккандыр дип кенә әйтүем иде.

Бикмулла. Тәкъдирдә язылганны күрмичә, гүргә кереп булмыйдыр, дигән китап. Шулай итеп, 1939 елны мин, «Кайсы милләттән?» дигән сорауга: «Мөхәммәт өммәтеннән, мөселман милләтеннән», дип чатнатып җавап кайтардым. Быел гыйнвар аенда, үзегезгә мәгълүм булганча, янә бер тапкыр халык саны исәпкә алынды. Милләт мәсьәләсе, әгәр онытмаган булсагыз, җәмәгать, көннәрнең берендә, җомга намазыннан соң, мәчеттә махсус рәвештә тикшерелгән иде, әйе. Авылыбызның могтәбәр картларыннан унбишләп кеше үзләрен «мөселман» дип яздырырга вәгъдә дә биргәннәр иде. Ләкин, көне килеп җиткәч, бу картларның барысы да, гөнаһ шомлыгына каршы, үзләрен «татар» дип яздырганнар.

Зәйнетдин *(хәзрәтнең күзләренә тилмереп карап, сабырсызланып).* Ә мин соң, хәзрәт, мин?!.

Бикмулла. Арабыздан бары тик Зәйнетдин мөәзин генә, тәңренең әмере һәм минем кушуым буенча...

Зәйнетдин *(бу юлы инде авызы тәмам колагына җитеп).* «Динем — исламныкы, туган телем — мөселманныкы» дип, күз дә йоммый җавап бирдем, хәзрәт!

Бикмулла. Һәм бик дөрес эшләгәнсең, кем, Зәйнетдин. Мөхәммәт өммәтендә торган адәм балалары үзләрен «хак мөселман» дип йөртергә тиешләр. Афәрин.

Аксакал. Афәрин диюен диден дә, хәзрәт, ләкин аңлашылып җитмәде бит. Зәйнетдин мөәзин әйтә: «Туган телем — мөселманныкы», ди. Алайса, нигә ул гел безнеңчә сөйләшә? Әйтик, нигә үз телендә сөйләшми икән?

Бикмулла. Андый тел юк, җәмәгать, корьән теле генә бар.

Сарысакал. Как туес юк, хәзрәт?.. Милләте булгач, аның, әбәзәтелне, теле дә булырга тиеш.

Бикмулла. «Әбәзәтелне» дигән кяфер сүзе китапка язылмаган, җәмәгать. Әйе, хуш, шулай. Милләт турындагы үгет-нәсихәтем шуның белән тәмам. Инде хәзер, җәмәгать, мин сезгә хәмер эчүнең гөнаһсы турында да әйтмәкче булам.

Сарысакал. Гөнаһсына караганда аның зарары күбрәктер, хәзрәт. Кичәгенәк клубта...

Зәйнетдин. Әй, әй, бу сиңа клуб түгел, вәгазь мәҗлесе!

Бикмулла. Мөәзин бик дөрес әйтә. Әйе, хуш. Шулай. Безнең һәркайсыбызның, аллага шөкер, тамагы тук, өсте бөтен. Кибетебездә кәнфит-шикәр кебек ләззәтле тәгамнәр дә тулып ята. Моның өчен дә без фәкать аллага шөкерана кылабыз. Шулай булгач, без, хак

мөселманнар, аллаһ тәгалә тарафыннан бирелгән байлыкны, ягъни арпа, богдай, шәкәр, бал кебек ризыкларны исраф итеп, көмешкә коярга яки бал әчетергә тиешме, юкмы?

Аксакал. Тиешен-тиеш түгелдер дә, хәзрәт. Әмма да ләкин остабикәң шикәрдән бал коярга бик остарып киткән икән, дип сөйлиләр. Килешми бит, хәзрәт, авыл картлары синең бал әчүеңнән һич разый түгелләр. *(Сарысакал мыек астыннан гына елмая, Карасакал җилкәсен кашый, мөәзиннең башы түбән иелә.)*

Бикмулла. Колмаксыз гына әчетелгән татлы бал хәрам әчемлек булып исәпләнмидер вә аның гөнаһсы да юктыр ди, китап әйтә... Әйе, хуш, шулай. Инде хәзер, җәмәгать, гаилә татулыгы турында берничә сүз әйтеп узыйм. Син, кем, Карасакал, авылыбызның иң өлкән, иң гакыллы мәчет картларыннан саналасың. Ә үзең аллаһ тәгалә алдында бик зур хилафлык эшләгәнсең...

Сарысакал. Әллә хатын-кызлар белән чуала башлаганмы, хәзрәт?

Бикмулла. Үзе түгел, малае. Бер гаепсезгә хәләл җефетен аерып җибәргән, бәдбәхет! *(Карасакалга.)* Ә син, ата буларак, бу эшкә юл куймаска тиеш идең. Шәригатькә дә, законга да сыя торган хәл түгел бу.

Карасакал. Әйттем инде, хәзрәт, бик әйттем... нишлисең бит, тыңламады.

Зәйнетдин *(иелгән башын кинәт югары күтәреп, үз гомерендә беренче тапкыр мулладан узып сөйли).* Тыңлата белмәгәнсең, гөнаһ шомлыгы! Әнә, безнең хәзрәттән үрнәк алырга кирәк иде. Хәзрәт үзенең улына бер генә тапкыр әйткән: хатының дин тотмый, ата-бабаларыбыздан калган гадәт-йолалардан йөз чөерә, дигән. Хатынының әтисе Зариф шулай ук алладан җаяүләп качкан кеше, муллаларны мәсхәрә кылып, кәмит уйнап йөри, дигән. Миңа мондый киленнең кирәге юк дип, кискән дә салган. Хәзрәтнең әйтүе булган, Сәйфелмөлек бер гөнаһсызга Нәфисәне аерган да җибәргән, вәссәлам. *(Бикмулла ачудан бик каты итеп тамак кыра. Ләкин мөәзин моны үзенчә аңлап, дәвам итә.)* Ә бит Нәфисә Сәйфелмөлекнең өченчеме, дүртенчеме хатыны иде... Нишләсен бит, ата әмере — тәңре әмере, дигәндәй, ата үз баласын тыңлата белергә тиеш. Дөрес сөйлимме, хәзрәт?

Бикмулла *(карлыккан зәһәр тавыш белән).* Китап сүзен сөйләмисең син, мөә-зин!.. *(Мөәзин телен аркылы тешли.)* Китап әйтә: кушылмак бар, ди, аерылмак юк, ди. Әгәр ир заты үзенең хәләл җефетеннән разый түгел икән, ди китап, ул, ягъни ир заты, өч шаһит алдында өч тапкыр «талак» дип тәкърарларга тиеш буладыр, ди. Шуннан соң ир белән хатын арасында никах бозылган булып исәпләнәдер, ди.

Сарысакал. Әгәр хатыны иреннән разый булмаса, ничегрәк инде, хәзрәт?..

Бикмулла. Анысы китапта язылмаган, әйе. Алладан узып сөйләр хәлем юк. Ярый, хуш, бу нәсихәтне дә шушының белән мохтасар кылдык. Инде хәзер, җәмәгать, балаларыбызны дөрес тәрбия кылу турында берничә сүзем бар. Без, хак мөселманнар, үз балаларыбызның тәрбияле булып үсүләре өчен аллаһ тәгалә алдында җаваплыбыз. Мөселман балалары намуслы, әдәпле вә итәгатьле булырга тиешләр. Аннан китереп...

Сарысакал. Аннан китереп, хәзрәт, урлашмаска тиешләр. Анысын да әйтергә онытма.

Бикмулла *(мәчет картларыннан гафу үтенгән сыман, күзлә-*

*рен чылт-чылт йома-йома).* Урлашуны китап мактамый, җәмәгать. Фараз итик, мин үзем кешенең инәсенә кагылырга да куркам, әйе.

А к с а к а л. Улың Сәйфелмөлек совхоз бүрәнәләрен урлап тотылган икән, дип ишеттек, хәзрәт. Дөрес хәбәрме?

Б и к м у л л а. Балаларыбыз азындылар, җәмәгать, шайтан коткысына бирелделәр. Китап әйтә, дин тотучылар азайган саен, шайтаннар күбәя барыр, ди. Шайтан котырта безнең балаларыбызны.

С а р ы с а к а л. Шайтан котырта, дисең дә бит, хәзрәт, мулла инәдән курка, бүрәнәне йота дигәндәй, урланган бүрәнәләрне синең ишегалдыннан тапканнар түгелме соң?

Б и к м у л л а *(ишетмәгәнгә салыша).* Я, хуш, җәмәгать, дога кылыйк та таралышыйк. Ахшам намазына барыр вакыт җитә. Тәһарәтләрегезне яңартып килергә онытмагыз.

А к с а к а л. Бишенче нәсихәтеңне әйтмәдең бит әле, хәзрәт.

К а р а с а к а л. Әйе, әйе, хәзрәт, мөселманнарның үзара яхшы мөнәсәбәттә булулары турында сөйләмәкче идең.

С а р ы с а к а л. Сөйлә, хәзрәт, сөйлә. Күңелләребез тәмам түгәрәкләнсен инде.

Б и к м у л л а. Бишенче нәсихәтемне, җәмәгать, ахшам намазыннан соң сөйләрмен. Ә син, кем, Сарысакал, бүген мәчеткә барып йөрмә, әйе. Вәгазь тыңлаганда үзеңне мөселманнарча тота белмисең. Алла йортында дөнья сүзләре ычкындырып, гөнаһлы булуың бар.

С а р ы с а к а л. Алайса, хәзрәт, мәчеттә әйтәсе сүзләремне шушында гына әйтеп китим инде. Түбән оч Фәрхетдин картны беләсеңдер?.. Шул карт, сильсәвиткә барып, синең өстән жалу биргән, ди. «Бикмулла хәзрәт мәчеттә, авыл картлары алдында мине эт урынына сукте, «дуңгыз» дип мәсхәрә итте», дип әйткән ди. Күр инде, хәзрәт, мөселманнар арасындагы яхшы мөнәсәбәтне бозарга тырышу була бит бу. Алла йортында әйтелә торган изге сүзләрне ни хаҗәтемә дип халыкка чыгарырга кирәк. Дөресме, хәзрәт?

(Бикмулла хәзрәт дәшми. Зәйнетдин мөәзин телен аркылы тешләгән. Аксакал аптырашта. Карасакал яңадан җилкәсен кашый башлый. Сарысакал, гадәтенчә, мыек астыннан гына елмая.)

# ҖЫР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

**Илбарис Надиров**

## ИЛ ЯШӘВЕ — ҖЫР БЕЛӘН

Безнең халыкта җыр, көй, моң, шулай ук җыр осталары хакында бик тапкыр һәм тиргән мәгънәле итеп әйтелгән канатлы сүзләр бар. Җырларның үзләрендә үк: җыр ул — сабак һәм нәсихәт, сердәш һәм юлдаш, диелә. «Ил яшәве — җыр белән», «Илнең җыры бар, күңелнең моңы бар» дигәннәр борынгылар. Шагыйрьләр дә еш кына поэзияне, үз иҗатларын җырга тиңлиләр. «Җырлап торам, торган җирем тар булса да», — дип горурланып әйткән бөек Тукай. Патриот шагыйрь Муса Җәлил үзе өчен чын мәгънәсендә юлдаш һәм көрәш коралы булган җыр турында: «Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә һәм үләргә кыю ир булып», — дигән ялкынлы сүзләр язып калдырган.

Чыннан да, халкыбызның үлемсез җыркөйләре белән бергә, татар шагыйрьләре һәм композиторларының бик күп гүзәл әсәрләре халык һәм ил язмышы, гомер һәм яшәү кадере, чал тарих һәм бүгенге матур тормыш турында уйландыралар, күңелдә дәрт һәм нәфислек тойгысы уяталар. Җыр — тетрәтә дә, елата да, көлдерә дә, сөендерә дә, моңландыра да ала торган кодрәт иясе. Чөнки ул үзенә күрә бер тылсымлы жанр, анда ике сәнгать чишмәсе — шигырь белән музыка бергә кушыла. Бу бердәмлек җырга гаҗәеп бер эмоциональ көч-куәт бирә.

Әнә шуңа күрә хисләр дөньясын тәрбияләү һәм баетуда гаять тә әһәмиятле урын тоткан бу хәрәкәтчән һәм өлгер жанр турында әллә нидә бер генә түгел, ә ешрак сөйләшәсе, фикер алышасы килү табигый.

Җыр ул — шагыйрь белән композиторның уртак иҗади эзләнүләре нәтиҗәсе. Композитор белән шагыйрьнең бер-берсен шәхес буларак белүләре, бергәләп, уртак хисләр кичереп иҗат итүләре җырның сыйфатына, һичшиксез, уңай тәэсир ясый. Сибгат Хәким «Җыр язмышы» дигән мәкаләсендә: «Һәр шагыйрьнең аралашкан композиторы була. Минем андый композиторым — Җәүдәт Фәйзи. Без менә унбиш ел инде бергә эшлибез», — дип язган иде. Моның өстенә җырның таралуы, халыкчалашуында өченче бер кешенең — җырны башкаручы артистның да роле кечкенә түгел. Җырга багышланган бер кичәдә танылган җырчы Илһам Шакировның әсәрне сәхнәдә башкарганчы, композитор белән алдан каткат уйнап-җырлап каравы, җырны камилләштерү өстендә эзләнүләре, бәхәсләшүләре турында сөйләгәне истә калган. Җырның башкару үзенчәлеге, халыкчан яңгырашы, милли колориты, телдәге интонация, аваз һәм басымнарны дөрес куллану, артистның репертуар сайлавы һ. б. шуның кебек хосусый булып күренгән мәсьәләләрнең һәммәсе дә — җырның табигате, яшәеше белән тыгыз бәйләнгән.

Җыр шигырьдән башлана. Көй — аның канаты. Артист җырны халыкка җиткерә. Бу өч өлкәнең өчесе турында аерым-аерым сөйләшү дә кирәк. Бу мәкаләдә сүз бүгенге җырларның шигъри ягы, тематикасы, мәгънәви һәм поэтик үзенчәлекләре турында барачак.

Иң әүвәл — сан ягыннан берничә мәгълүмат [1]. Соңгы унбиш ел эчендә татар шагыйрьләренең 730 җырына композиторлар тарафыннан көй язылган. Шул исәптән, ял-

[1] Мәгълүматлар татар шагыйрьләренең сугыштан соңгы җырлары турында фәнни хезмәт язучы Флюра Яркимбаева тарафыннан тупланган материалларга таянып китерелә.

гыз башкару өчен язылган җырлар — 510, дуэтлар өчен — 21, хор өчен — 46, романслар — 64, балалар өчен язылган җырлар — 89. Боларга шушы вакыт эчендә үзешчән композиторлар, һәвәскәрләр тарафыннан язылган тагын йөздән артык җырны өстәсәк, барлыгы сигез йөз утыздан артык җыр җыела. Уртача алганда, елына 55—56 җыр туры килә.

Микъдар ягы, әлбәттә, жанрның төп күрсәткече түгел. Ләкин, мәгълүм булуынча, микъдар сыйфатка илтә торган юлларның берсе. Шуның белән бергә, китерелгән саннар жанрның елдан-ел үсә, төрләнә баруын, халык ихтыяҗына бәйле рәвештә, җыр өлкәсендә эшләүче авторларның иҗаты киң колач алуын сөйлиләр. Бер үк вакытта бу саннар уйга да калдыра.

Әгәр без соңгы унбиш елда халык арасында уңыш казанган, башкаручылар яратып җырлый торган әсәрләрне көнүлдән барлый башласак, аларның саны шактый аз булып чыга. Сигез йөздән артык җырның күп булса бер йөзе, тормыш, вакыт сынауларын үтеп, яңа яшәеш алды яисә алуы мөмкин дисәк, хата булмас. Ә калганнары соң ник бик тиз онытылган? Нигә алар бер яисә ике тапкыр яңгырау белән тынсыз калып архив материалына әйләнәләр? Бу сорауга берьяклы гына, ансат кына җавап бирү кыен. Чөнки җыр, алда әйткәнчә, ике төрле сәнгать оеткысында тугыланган, ике авторның хезмәте кергән жанр.

Җырны шигъри яктан бәяләүгә килгәндә, монда ике фикер, ике төрле караш яши. Берәүләр, җырның текстына мөстәкыйльлек зарури түгел, чөнки ул көй белән бергә генә яшәүче жанр, шул көйгә ярашлы булса, музыканың эмоциональ якларын ачарга ярдәм итсә, аңа шул җиткән, диләр. Бу фикер тарафдарлары җырның көй-музыкасына төп урынны биреп, аның сүзләренә иярчен, икенчел нәрсә итеп карыйлар.

Икенче берәүләр, җырның сүзләре дә чын шигырь, мәгънәле һәм матур эшләнгән поэзия әсәре булырга тиеш, диләр. Музыкага ябышып, музыка канатына сыенып яшәүче сыек эчтәлекле зәгыйфь юл-тезмәләрне танкыйть итәргә кирәк, чөнки җыр белән көй, шигырь белән музыка арасында гармония, аһәңдәшлек булганда гына чын мәгънәсендә сәнгать әсәре туа ала, диләр. Соңгы карашны яклаучылар, әлбәттә, күп мәртәбә хаклы.

Әгәр без Х. Туфанның «Әйткән идең», С. Хәкимнең «Кайда да йөрәктә», Н. Арслановның «Унике батыр турында баллада», И. Юзеевның «Яшь наратлар», Ш. Галиевның «Тамчылар тамар чаклар», Роберт Әхмәтҗановның «Солдатлар», Р. Фәйзуллинның «Аккошлар», Зөлфәтнең «Һаман яратам» кебек мәгълүм җырларын берәм-берәм күңелдән үткәрә башласак, аларның чын мәгънәсендә шигърият әсәрләре булуын күрәбез. Алар музыкадан аерым да укучылар күңеленә тәэсир итәрлек камил һәм нәфис эшләнгән. Җырда, барыннан да элек, чор рухына авазданш тирән шигъри хис-фикер, кеше язмышына якын тормышчан сюжет булырга тиеш. Җыр композициясе җыйнаклык сорый, күләме артык зураеп китсә, аны истә калдыру, башкару кыенлаша. Сурәтләрнең халыкчан, әмма тапталмаган булуы, сүзләрнең музыкальлеге, табигый нәфислеге — җыр өчен зарури шарт. Заман сынавын үткән җырлардан «Урман кызы» (Һ. Такташ), «Без кабызган утлар» (К. Тинчурин), «Сагыну» (М. Җәлил), «Яшь егетләр, яшь кызлар» (Ә. Ерикәй) һ. б. — жанрның шул таләпләренә туры килгәнгә күрә бүген дә сафта, бүген дә яңгырыйлар. Әмма хәзер бездә озын гомерле җырлар, вакыйга булырлык, онытылмаслык җырлар аз. Жанрның бүгенге торышына хас кимчелекләр тематика өлкәсендә дә, поэтика өлкәсендә дә, сурәтләр, сүзләр белән эш итүдә дә күренә. 1971—1975 еллар арасында язылган ике йөз кырыкка якын җырның, мәсәлән, ике йөз сигезе мәхәббәт темасына багышланган, аларда сөйгән ярның күз-кашы, буйсыны мактала, җавапсыз калган мәхәббәт газабы, оныта алмау, очрашасы килү һәм аерылу сагышы турында сөйләнелә. Җырның интим хисләрне сурәтләве, әлбәттә, табигый күренеш, мәхәббәт темасы поэзиядә мәңгелек темаларның берсе ул. Ләкин мәхәббәт турындагы җырларның байтагына бертөрлелек хас, алар бер-берсен кабатлыйлар. Х. Туфанның «Әйткән идең» җыры ни өчен күңелдә уелып кала? Чөнки анда шәхеснең характеры бар, тормыш драмасы, фәлсәфә бар. Н. Гайсинның «Кайт, сөеклем» дигән җыры да драматик хәлне сурәтли. Җыр сагышлы сүзләр, моңсу юллар белән тулы. Ләкин ул күңелне тетрәтми, киресенчә, елмаю тойгысы уята.

Ташлап киттең мине,
Моңсулатып өйне.
Бер дә юкка, иркәм, үпкәләп,
Син булмагач янда,
Күңел юксынганда,
Кем ятыр мине иркәләп.

Кеше хисләрен шулай рәвешчә ясалма сурәтләгән, төче сентиментальлеккә корылган җырлар бездә аз түгел.

Соңгы елларда шагыйрьләр илебезне, партия һәм Ленинны, хезмәт кешеләрен

олылый торган, чын гражданлык тойгылары белән сугарылган матур гына җырлар иҗат иттеләр. Алай да заман рухына аваздаш киң колачлы публицистик җырлар, героик җырлар бик аз әле. Дөрес, язылмый түгел алар, ел саен язылып торалар. Бишьеллык флагманы булып саналган тиңсез КамАЗ турында, мәсәлән, уннан артык җыр иҗат ителгән. Арада көе белән күңелгә ятышлы тик бер генә җырны күрсәтергә мөмкин. Ул Р. Биләлов тарафыннан «Ак кала» җырына язылган көй. Әмма җыр үзе шигъри яктан (авторы М. Хөсәен) КамАЗга багышланган башка җырлардан ерак китмәгән. Ул җырларда машиналар гөрелтесе, лозунг бар, ялтыравык эпитетлар бар, тик эшченең хезмәтен, аның күңел хәзинәсен сурәтләүдә эчке җылылык юк. К. Тинчуринның һәм С. Сәйдәшевның бүген дә яратып җырлана торган «Без кабызган утлар»ына хас дәрт, ялкын юк. Алар, ничектер, илһамсыз гына, салкын акыл белән генә тудырылганнар сымак.

Шаблонга ияру, сурәт ярлылыгы — күп кенә публицистик җырларның төп кимчелеге. Мөнир Мазуновның «Игенче җыры»на күз салыйк.

Хезмәт җимеше — бәхет билгесе.
Күкрәп үсә куе игеннәр.
Кая баксаң — күркәм тормыш яме,
Йөзләр көләч, көйле күңелләр...

Калган строфаларда сүз «чиксез кырлар», «яшел болыннар» ,«якты уйлар» «балку ма-«яшел болыннар», «якты уйлар», «балку мамәт шатлыгын, бәйрәм тантанасын сурәтләргә омтыла. Беренче карашка барысы да дөрес, игенчене мактарга кирәк, ул моңа бик лаек. Ләкин җыр тәэсирле түгел, күңелгә үтми, аның тукымасына эстетик фальшь катнашкан. Җырда ник бер генә тапталмаган сурәт, таушалмаган образ булсын! Һәммәсе дә электән таныш, һәммәсе дә әллә кайчан кат-кат әйтелгән. М. Садриның «Без хокуклы барсына да», М. Таҗетдиновның «Дуслык каласы», М. Газарның «Чаллыдан хат», М. Хөсәеннең «Хуш киләсез», Г. Зәйнашеваның «Уңыш бәйрәме», Б. Камаловның «Илдә илле дустың булсын», Х. Вахитның «Безнең авыл» кебек соңгы елларда язылган җырларында да теге яки бу күләмдә шул кимчелек күзгә ташлана: яңа бер образ, җырны башка җырлардан аерып торган шигъри фикер, сурәт юк. Х. Вахит хәзерге авылны менә ничек тасвирлый:

Хезмәт сөя авыл халкы,
Мул уңыш ала ел да;
Тракторлар, комбайннар
Гөрләп эшлиләр кырда.

Бакыр биш тиен кебек шомарып беткән шундый сүзләр җыелмасына, салкын тезмәләргә көй язучы композиторларга үпкә белдерәсе килә. Нигә алар чын поэзиядән ерак торган, бер җырдан икенчесенә күчеп йөрүче әзер сурәтләр, блоклар ярдәмендә төзелгән строфаларга музыка язып вакыт һәм энергия әрәм итәләр икән?

Үз вакытында «Социалистик Татарстан» газетасында (9. 01. 1966) Алмаз Әхмәтовның хезмәт темасына караган һәм радиодан яңгырый торган аерым җырлары турында тәнкыйть фикерләре әйтелгән иде. Шуңа карамастан, А. Әхмәтов үзенең зәгыйфь текстларын «Таң егете» дигән исем астында матур тышлык һәм ноталары белән бастырып чыгарды. Бу гаҗәпләндерә. Чөнки мондый бәхеткә җыр жанрында танылган кайбер шагыйрьләрнең дә ирешә алганы юк әле. Чын поэзия күзлегеннән карасаң, «Таң егете» җыентыгындагы җырлар тәнкыйтьне гомумән күтәрми. Соңгы вакытта А. Әхмәтов исеме күренми һәм ишетелми. Күрәсең, ул үзенең бу өлкәдә очраклы кеше булуын аңлагандыр. Ләкин аның урыны буш тормый, чиле-пешле тезмәләрен таләпчәнлек тойгылары үтмәсләнгән аерым композиторлар белән берлектә җырга әйләндереп эфирга озатучы, матбугатта бастыручы авторлар һаман мәйданга чыга тора.

Мәгълүм булганча, туган ил, туган як, аның табигате, җире-суы турында татар халкының берсеннән-берсе матур җыр-көйләре бар. 1972 елда чыккан «Җырлар китабы»нда бу темага алтмыштан артык җыр урнәге бирелгән. Арада халык җырларының борынгылары да, яңараклары да, шагыйрьләр һәм үзешчәннәр иҗат иткән җырлар да бар. Байтагы аерым төбәкләргә, район һәм авылларга багышланган. Соңгы төркем җырлар безнең халык иҗатына хас күркәм милли традиция булып санала ала. Шул традицияне дәвам итеп, аерым авторлар, теге яки бу район хезмәт ияләренең теләкләрен канәгатьләндерү йөзеннән, матур гына җырлар да яздылар. Алай да халык иҗатындагы билгеле бер төбәк исеме белән мәгълүм җыр-көйләргә тиңләшерлек үрнәкләр әле бик тә аз дияргә кирәк (sic: дисе килә).

Җентекли башласаң, монда бер төрле калыплар, әзер өлгеләр белән эш итү аеручa еш очрый. Менә шуның мисаллары:

Чылтырап ага тау буеннан
Салкын чишмә сулары;
Бигрәк матур, бигрәк уңган
Ютазының кызлары.

(«Ютазы», Г. Насрый сүзләре.)

Яңгырап торсын җырларга
Баулының урамнары;
Яшь кызларның, егетләрнең
Баулыда уңганнары.

(«Баулылар». Н. Арсланов сүзләре.)

Һаман күбрәк муллык яулый
Безнең ил батырлары;
Күпләрне гашыйк итәрлек
Азнакай матурлары.

(«Безнең Азнакаебыз». Г. Моталлапов сүзләре.)

Борылып ага Зәя суы,
Соклангыч урманнары;
Яшьләрнең эштә ярсулы,
Чибәре, уңганнары.

(«Апас ягы». Б. Камалов сүзләре.)

Инкубатордан чыккан чебешләрмени? Барлык районнарның да кызлары, егетләре бер-берләренә ике тамчы су кебек охшашлар — бер үк эпитетлар, чагыштырулар, сыйфатламалар... Кайбер җырлар өчен аерым эпитетлар гына түгел, шигырь юллары да уртак. Мәсәлән, «Саба» җырындагы:

Диңгез кебек дулкынланып
Кырда чайкала иген,—

тезмәсе «Ямьле безнең Минзәләбез» җырында:

Диңгез кебек дулкынлана
Киң басуларда иген,—

дип бирелгән.

Кабатлану образны төссезләндерә, эстетик яктан вагайта, торгынлыкка китерә. Бездә үзенә атап җыр чыгарылмаган район хәзер сирәктер. Кайбер шагыйрьләр бу өлкәдә рекорд та куйдылар кебек. Мостафа Ногманның «Актаныш таңнары»на, «Арча кичләре»нә, «Салагыш болыннары»на, «Шәйморза утлары»на, «Сөн буендагы бөдрә урман»га, «Ямьле Тол буе»на, яшьлек каласы Түбән Камага багышлап язган җырлары бар. Болардан тыш Чирмешән, Исәнбай, Чынлы, Мөслимнекеләр дә музыкага салынган. М. Ногман — җыр өлкәсендә тәҗрибәле шагыйрьләрнең берсе. Ул бигрәк тә Р. Яхин һәм С. Садыйкова белән якын иҗади дуслыкта эшләп килә. Рөстәм Яхин белән 25 елга сузылган хезмәттәшлек нәтиҗәсендә, «Татбригада сугышчылары җыры», «Бәхтияр батыр», «Каеннар шаулый», «Онытa алмыйм», «Болгар кызы Айсолтан» кебек танылган җырлар туды. Ләкин М. Ногман кайвакыт үз-үзен кабатлый, бер үк мотивны, интонацияне, сурәтләрне алмаш-тилмәш төрле җирдә куллана. Еракта калган мәхәббәтне, яшьлекне сагыну мотивы, фольклор поэтикасыннан алынып, җыр эчендә эретелмәгән традицион сурәтләр аның җырларында еш очрый. Шагыйрь зәңгәр төсенә гашыйк. Аның дүрт җырында «зәңгәр» сүзе, мәсәлән, алты тапкыр кабатлана: Идел дә зәңгәр, киңлек тә зәңгәр, сукмак та зәңгәр, урам да зәңгәр, кич тә зәңгәр булып күренә аңа. «Зифа» эпитетын да ул кайвакыт урынсызга куллана. «Чирмешән» җырында тал чыбыктай зифа буйлы кыз турында сүз бара икән, бусы әле халыкчан, традицион образ. Ә менә батыр солдатны зифа буйлы итеп сурәтләү —бусы инде ясалма, күңелгә ятышсыз.

Үз вакытында радиода кабул ителеп тә, тиз арада онытылуга дучар булган җырлар арасында без Н. Зариф, Н. Ибәтов, Р. Байтимиров, Ф. Тахтамышев, Ю. Әминев, М. Латыйфуллин, Б. Камалов, Р. Хисмәтуллин сүзләренә язылган җырларны очратабыз. Менә Р. Хисмәтуллинның «Мин яратам җилләрне» җырыннан бер өзек:

Җилләр уйный кырларда
Кушылып минем җырларга,
Җил тауларны сикерә,
Җил яңгырлар китерә,
Җил иркәли гөлләрне,
Мин яратам җилләрне.
Йолдызларга җил исми,
Җилсез яшәү килешми.

Су белән уйнауның, гамьсез рифмалаштыруның типик бер мисалы бу.

Без җырга поэзиянең югары формасы дип карыйбыз. Ә ни өчен бу өлкәдә һәвәскәр шигырьчеләр, кәсепчеләр күбәеп китте соң әле? Адәм куанырлык бер шигырь яза алмаган кеше ни өчен җыр өлкәсендә эшләп була дип саный икән? Бүгенге җырлар турында уйланганда күңелгә әнә шундый сораулар килә.

Юморны кеше характерының гүзәл сыйфаты диләр. Шаян җыр кеше күңелендә әнә шул сыйфатны тәрбияләүгә ярдәм итә. Андый җырларга мохтаҗлыкның беркайчан да беткәне юк һәм бетмәячәк.

Үзенең юморга бай таланты белән аерылып торган Ш. Галиевнең «Утыр әле янарыма», «Шалт, Мөхәммәтҗан», «Янып көясем килә» кебек шаян җырлары, Н. Арсланов, Г. Зәйнашева, Г. Афзал, М. Хөсәеннең аерым җырлары үз вакытында популярлык казандылар, әмма хәзер искереп баралар дисәк, хата булмас.

Күп кенә җырларның, шул исәптән шаян җырның да, мода белән бәйле икәнлеген онытмаска кирәк. Модага бәйләнгән булу шаян җырлар өчен аеруча хас. Алар тизрәк искерәләр, тизрәк онытылалар. Моннан биш-ун ел элек яратып тыңланган мондый җырлар хәзер радиодан да әллә нигә бер генә яңгырый. Ә алар урынына яңалары бик тә аз иҗат ителә. Бу өлкәдәге кытлыкны Г. Зәйнашеваның «Турысын әйтик» дигән

җыры да, Ә. Исхакның «Кичке җиләс җил исә»се дә, Ә. Камалның «Әштер-Өштеревкә сәлам» дигән җыры да бетерә алмый, гәрчә шаян рухта язылган булсалар да, аларның күп кенә уңышсыз яклары бар.

Г. Зәйнашева — җыр сөючеләргә яхшы таныш. Ул — «Китмә, сандугач», «Бураналар», «Яшь гомер» кебек популяр җырлар авторы. Ләкин ул кайчак өлгермәгән текстларын композиторларга илтергә ашыга. «Турысын әйтик» җыры — шуның бер мисалы. Ул кызлар өчен чәнечкеле такмаклар дип тәкъдим ителә. Берничә юлына күз төшерик:

Егетләр матур булалар
Эчмәгән чакларында,
Мәхәббәтсез күренәләр
Пивной чатларында.

Кызлар күзләп йөрмәсен дә,
Исерек безгә яр түгел.
Исерек егет ялкау була,
Ялкау безгә пар түгел.

Автор, әлбәттә, җырны изге, тәрбияви максаттан чыгып язган. Ләкин бу такмакларның сәнгатьчән юмор белән уртаклыгы шикле. Татар кызларының тормышта һәм җырларда макталган ягымлы, күркәм образы белән алар ярашмыйлар. Әхлакый матурлык тойгысы югалмаган бер генә кыз да мондый тәмсез, йөгәнсез такмакларны җырламаячагын автор уйламады микәннни? Аларның музыкага салынып меңнәрчә экземплярда таратылуы — җыр өлкәсендәге җавапсызлыкка бер дәлил.

Әхмәт Исхак — танылган шагыйребез. Аның берничә җырын халык яратып кабул итте. Ә менә «Кичке җиләс җил исә» уңышсыз чыккан. Формасы да табылган кебек, тик җырга табигыйлек, такт, зәвык җитеп бетми. Үткән кичтә янына чыкмаган өчен егет кызга үпкә белдерә. Ә кыз аңа:

Дөрес булса көткәнең,
Нигә хәбәр итмәдең?
Килгәнеңне белдереп
Нигә тәрәз чиртмәдең?

Әгәр дә булсаң егет,
Икенче йөрмә җебеп;
Кыз баланы көттермә
Кичә көттергән кебек,—

дип өздереп җавап бирә. Егет, мескен, нишләсен, ахырдан үз гаебен таный һәм кызның сүзләренә кушылып:

Әгәр дә булсам егет,
Икенче йөрмәм җебеп;
Кыз баланы көттермәм
Кичә көттергән кебек,—

дип, үзара аңлашута нокта куя.

Мондый диалог 30 нчы елларда үзешчәннәр башкаруында яңгыраса әле бер хәл иде. Ә җыр бит хәзерге заман егетләренә, кызларына багышланган. Күренүенчә, җырга халыкчан шаянлык җитми, ул схема булудан узмаган.

Халык җырларына ияреп, фольклор сюжетларына һәм образларына таянып җыр язылган икән, ул халык җырыннан калышмаска тиеш, яңалыгы белән, үзенчәлекле сыйфатлары белән аерылып торырга тиеш. Шушы җәһәттән, татар халык көйләренә язылган җырлар турында кайбер фикерләр әйтәсе килә.

Мәгълүм ки, татар халкының күчмә текстлар — кыска җырлар белән яши торган күп кенә көйләре бар. Шул көйләр рухына туры килгән яңа шигъри текст — сюжетлы җыр язу — мактаулы бурыч, чөнки ул көйнең гомерен озынайта, аңа талмас канатлар бирә. Бу өлкәдә күркәм мисал итеп бөек шагыйребез Г. Тукайны күрсәтергә була. Г. Тукай яшьтән үк халык җырын яраткан, җырлар җыйган, җыр турында гаҗәеп тирән фәнни фикерләрен әйткән, ниһаять, халык көйләренә «Туган тел», «Зиләйлүк», «Әллүки» кебек сокландыргыч җырларын язган. Халык әдәбиятына багышланган бай фикерле лекциясендә Тукай «халыкның үз көе, үз вәзене, үз формасына» ияреп язылган һәм җырларга әйләнгән шигырьләрне бүтән «шигырьләрдән хис, мәгънә, тасвир ягыннан һич тә ким түгел» дип саный. Бу төр җырларның русларда инде күптән яшәвен, аның үрнәкләре Кольцов, Пушкин иҗатларында булуын күрсәтеп үтә. Бездә дә мондый җырлар нигезенә «берничәшәр булса да, кирпеч салучылар булуын» әйтеп, М. Укмасыйны, С. Рәмиевне телгә ала, үзенең дә халык көйләренә язган кайбер җырлары турында мәгълүмат бирә [1].

Тукай җырлары халыклашкан җырларның беренче карлыгачлары булды. Халык көйләренә җыр язу безнең поэзиядә соңрак традиция төсен алды һәм хәзер дә дәвам итә. Бу өлкәдә сөенечләр дә, көенечләр дә бар. Башта сөенечләргә багыйк. Иң элек Ә. Фәйзинең «Ком бураны», «Аккош», «Умырзая»сы, Ә. Ерикәйнең «Сәрвиназ»ы, С. Хәкимнең «Таң атканда» һәм «Фазыл чишмәсе» дигән мәгълүм җырлары искә төшә. Алар халыкның борынгы һәм яңа көйләре белән үрелеп күңел хәзинәсенә әверелделәр һәм җыр сәнгатенең алтын фондына керделәр. З. Мансурның «Яшьлек», Г. Зәйнашеваның «Уйна тальян гармуныңны» җырлары да халык көйләре ярдәмендә уңыш казанды. Ниһаять, Н. Исәнбәтнең яшь

[1] Г. Тукай. Әсәрләр. Дүрт томда. 2 том, 1955 ел, 265—269 битләр.

чагында язган һәм көй сорап торган «Туган ил», «Син сазыңны уйнадың» җырлары соңгы елларда зур популярлык алды. Соңгы ике көйнең киң яңгыравына һәм тиз таралуына Илһам Шакиров та сәбәпче булды. Аерым шагыйрьләрнең халык көйләренә яңа гомер биргән җырлары моннан башка да бар. Ләкин күп түгел. Байтак җырлар, кызганычка каршы, халык күңеленә юл табалмадылар. Бусы традициянең көенечле ягы.

Халык көенә җыр язарга алынган кайбер шагыйрьләр бу эшкә җиңелчәрәк карыйлар. М. Садри «Каз канаты» дигән мәгълүм көйгә өч строфадан торган җыр язган. Алар халыкның шул көй белән таралган җырлары стилендә, андагы сурәтләрне файдаланып язылганнар. Ә бер строфа халык җырының варианты булып чыккан. Чагыштырып китик:

**Халык җыры:**

Каз канатларын санадым
Тезелеп кагынганда;
Инде кемнәргә карармын
Өзелеп сагынганда.

**М. Садрида:**

Каз канатларын санадым
Тезелеп кагынганда;
Тулган айларга карадым
Өзелеп сагынганда.

Җырда строфаларны бәйләүче хис, кичереш бәрдәмлеге сизелми. М. Садри җыр өлкәсендә күптән эшли. Уңышлы җырлары да күп. Шуның белән бергә, халык көйләренә язган һәм үз вакытында «Халык җырлый» җыентыгында басылып чыккан «Бәхетле хезмәт», «Батырларга дан», «Чибәр егетләр» кебек җырлары чын мәгънәсендәге җыр булып китә алмадылар.

Халык көенә җыр язган шагыйрьнең сурәтле фикерләве халык күңеленә аеруча якын булырга тиеш. Шулай булмаганда, җыр тексты халык көенә үрелә алмый, гармония җимерелә, ясалмалылык барлыкка килә.

Татар халкының «Дулкын» дигән кыска көе бар. Композитор М. Яруллин аны музыкаль яктан эшкәрткән, ә яшь шагыйрь Разил Вәлиев сүзләр язган. Әмма ул сүзләрне аңлавы кыен. Текст дүрт строфадан тора. Менә беренчесе:

Чем-кара карлыгачлары,
Гөнаһсыз иде яры...
Нигә соң шунда калмады,
Ник дулкын китте ары?

Шагыйрь елга ярын калдырып диңгезгә хушылган дулкынны кызгана, моның белән нидер әйтмәкче була. Ләкин шигырь — абстракция, табышмак булып кала.

Җырны ниндидер серле мәгънәгә төрү, тиз генә төшенеп булмый торган катлаулы метафорик әйләнмәләр куллануның мондый мисаллары бирәү генә түгел. М. Таһированың «Тик мин яшим синең яныңда» җырында (Р. Яхинның «Бу җырым тик сиңа» дигән җыентыгында басылган) сөйгән яр диңгез белән чагыштырыла:

Синең холкың — ачык диңгез өсте:
Бервакыт та булмый бертөсле —
Кайчагында назлы, шундый тыныч,
Күп вакытта уттай куркыныч.

. . . . . . . . . . . . . . .

Табигатьнең нинди көче синдә,
Мин таш кебек диңгез ярында.
Ялкыннардан алып сал суларга,
Тик мин яшим синең яныңда.

Монда һәр строфа диярлек уйга калдыра, лирик геройның халәтен, теләген баш ватмыйча гына аңларлык түгел. Баштагы юллар белән соңгы ике юл арасында логика җитми, эзлеклелек югала. Ә җыр бит халык өчен языла, халык аны аңламаса, ул кемгә кирәк?

Ренат Харисның Фасил Әхмәтов музыкага салган «Күрешербез әле» дигән җыры бар. Популяр лирик җыр. Аның көе заманча, яңа интонацияләргә бай. Ләкин җырда Р. Хариска хас катлаулы тел, метафорик фикер йөртү сизелеп тора. «Хисләремә ялкын кабынган, өметләрем канат кагына» янсә «Эзебезне еллар күммәгән, буран узган — ялкын сүнмәгән» кебек хикмәтле тезмәләрдә күңелгә хуш килердәй гади матурлык, мәгънәви ачыклык җитми. Бу җырның кушымтасы да ниндидер билгесезлек томанына төрелгән. Сүз анда кайчан да булса, кайда да булса бер күрешү турында бара. Тыңлаучыны серле киная белән нигә пошаманга калдыру кирәк соң әле? дигән сорау туа. Р. Харисның «Җирдә бер кояш», «Татарстаным минем» кебек җырларының поэтик теле дә катлаулырак. Яшьләр турындагы беренче җырда, мәсәлән, шундый юллар бар:

Һава сафлыгы яшьләр кулында —
Әйдәгез, җырлыйк һава турында,
Һава шул ук миңа,
Һава шул ук сиңа,
Һава шул ук безгә, дуслар!

Соңгы юллар грамматик яктан да дөрес корылмаган.

М. Горькийның, әгәр шигырь көмеш булса, җыр алтынга тиң булырга тиеш, дигән сүзләре искә төшә. Җыр өчен сүзләр сайлау — ул букет өчен чәчәкләр сайлау кебек.

Җыр осталарының иҗатына нечкәләп игътибар итсәң, аларның сүзне мәгънәви яктан сыйдырышлы итеп, музыкасын тыңлап, тоеп язуларын күрәсең. Ә. Ерикәй, С. Хәким җырларында бу ачык сизелә. И. Юзеев,

Р. Фәйзуллин да моны беләләр. Соңгы елларда Р. Фәйзуллинның берничә җыры халыклашып китте: «Бу дөньяда», «Сагыш», «Аккошлар», «Без дә үсеп җиттек, әни». Аларның үз моңы, үз дулкыны, үз поэтикасы сизелеп тора.

Сүзнең үз музыкасы бар. Ләкин ул музыка авазлар инструментовкасы белән, рифмалар, ассонанслар, аллитерацияләр белән оста эш итүгә кайтып калмый. М. Хөсәеннең «Зөһрә» исемле җырын алыйк. (А. Монасыйпов музыкасы.) Ул сыер савучы кызга багышланган.

Ак халатын киеп,
Сөенеп һәм сөеп,
Сыерларын сава чибәркәй;
Уйный-уйный-уйный,
Ак тамчылар ургый,
Күбекләнеп тула чиләккәй.
Ля-ля-ля-ля-ля,
Күбекләнеп тула чиләккәй.

Чиләге дә ап-ак,
Беләге дә ап-ак,
Теләге дә ак сөт шикелле;
Энҗеләрдәй вак-вак
Тешләре дә ап-ак,
Күз карашы да, һай, сөйкемле!
Ля-ля-ля-ля-ля,
Күз карашы да, һай, сөйкемле!

«Чибәркәйгә» рифма өчен автор сөт чиләгенә назлап «чиләккәй» дип дәшә яисә теләкне сөт аклыгы белән чагыштыра икән — анысы бер хәл. Күренүенчә, шигырь әчке рифмаларга шактый бай, ритмик яктан да үзенчәлекле. Әмма болар тышкы бизәкләр белән мавыгу, сүз белән жонглерлык итү булып чыкканнар.

Соңгы елларда татар композиторлары бай поэзиябез тарихы битләрендәге кайбер шигъри әсәрләргә дә музыка яздылар. Г. Тукайның бер төркем шигырьләре җыр яки романс буларак яңгырады. Һ. Такташ, М. Фәйзинең берничә шигыренә дә көй язылды. 20 нче еллар башында романтик рухлы шигырьләре белән поэзиядә эз калдырган Ярлы Кәримнең «Назлы гөлкәем» шигыренә сәләтле композитор Ф. Әхмәтов музыка язды. Көйне җырчы Рабига Сибгатуллина башкаруында халык яратып кабул итте, көйгә ияреп аның урта кул тексты да таралды. Композитор бу шигырьдәге кимчелекләргә игътибар итмәгән. Шигырь заманча яңгырамый, анда ниндидер мелодраматик төчелек бар. «Былбыллар кебек гөр-гөр гөрләшик» дигән юлларны ишеткәч, былбыллар да гөрләшә микәнни? дигән сорау туа. «Күрсәм үзеңне, һич тә мин туймыйм, иркә баладай килче, кил, уйныйк» юллары да уңышлы түгел.

Поэзия бакчасы мондый шигырьләрдән генә тормый бит.

Композиторларның җыр язуын көтеп яткан, фикере, хисе, поэтикасы белән көйгә салуны сорый торган бер дигән шигырьләр бар. Аларны Фатих Кәримдә дә, Хәсән Туфанда да, Нури Арслановта да, Шәүкәт Галиевтә дә, башка күренекле шагыйрьләрдә дә табарга була. Кайбер композиторлар, күрәсең, үзләренә тәкъдим ителгән текстлар белән генә эш итәләр, ә шигырь китапларына сирәк күз салалар дигән фикер туа. Татарстан китап нәшрияты ел саен композиторларның җиде-сигез җыр җыентыгын чыгарып бара. Алар арасында яхшы җырлар белән бергә, шигырь әлифбасына туры китереп язылган, әмма йөрәкне кузгатмый, күңелгә кагылмый торган тумыштан ямаулы текстлар да очрый. Композитор үзе язган көйнең нинди җыр тексты белән яңгыравына, таралуына бармак аша гына карарга, талымсызлык, зәвыксызлык күрсәтергә тиеш түгел.

Аерым композиторларның җыентыкларында җыр текстлары ике телдә — татарча һәм русча бирелә. Соңгы биш елда тәрҗемәле алты җыентык басылган. Моның максаты изге. Сүз — яңа җыр-көйләрне бөтен союз тыңлаучысына һәм тугандаш халыкларга җиткерү турында бара. Яхшы музыкаль-поэтик әсәрләрне пропагандалауның, культура өлкәсендәге дуслык бәйләнешләрен ныгытуның әйбәт юлы бу. Ләкин монда үзеннән-үзе ике проблема килеп баса. Беренчедән, тәрҗемәләр сайлап эшләнми, әйбәт җырлар белән бергә, шигъри яктан өлгермәгән, тәнкыйтькә мохтаҗ булган текстлар да тәрҗемә ителә. Икенчедән, тәрҗемәләрнең сыйфаты җитди борчылуга урын калдыра, аларның шактый өлеше мәгънәви яктан якынча гына итеп, ашык-пошык эшләнгән, ритмик яктан кытыршы чыккан. А. Монасыйповның 1970 елда басылган «Дуслар җыры» китабына күз салабыз. Андагы күпчелек җырларны М. Таҗетдинов тәрҗемә иткән. Аның байтак тәрҗемәләрендә үзеннән өстәлгән сүзләр, юллар, сурәтләр күп җыела. Мондый кимчелекләрне Г. Әхмәтҗанов, Р. Хәкимов, Н. Беляев, Б. Дубровин тәрҗемәләрендә дә табарга мөмкин.

Балалар өчен язылган җырлар хакында да кайбер фикерләр әйтәсе килә. «Ялкын» журналы, «Яшь ленинчы» газетасы ел саен яңа җырлар биреп бара. Китап нәшриятында узган ел А. Батыршинның З. Нури сүзләренә «Бик яраткан төсләрем» дигән җырлар бәйләме, Ә. Бакировның «Ленин оныклары», Ф. Әхмәтовның «Туган җир» җыентыклары чыкты. Радиодан атна саен балалар өчен

язылган җырлар яңгырый. Арада истә кала торган матур гына җыр-көйләр бар. Алай да балалык рухы бөркелеп торган, бала күңелен җәлеп иткән аһәңле, сурәтле җырларга кытлык сизелә. М. Садриның «Нәни балыкчы җыры», Г. Латыйпның «Сакта тора сизгер абыйлар», Салих Хәкимнең «Китап турында җыр», С. Шакирның «Яшь Володя» кебек җырларында сурәт ярлылыгы, тел кытыршылыгы, үгетләүгә корылган өндәмәләр, сюжетсызлык күзгә ташлана.

Яхшы җыр-көйләр азрак булганга, балалар еш кына зурлар өчен язылган мәхәббәт җырларыннан юаныч эзләргә мәҗбүрләр. Бу — күңелле хәл түгел.

Җыр жанрының киләчәген талантлы яшьләр билгеләргә тиеш. Яшь шагыйрьләрнең, яшь композиторларның иҗади дуслыгы, безнең поэзиядә һәм музыкада урнашкан күркәм традицияләрне дәвам итү — жанрның үсүе, баюы өчен нигез шартларның берсе.

Яшьләр исемлегендә Роберт һәм Рәшит Әхмәтҗановларны, Рөстәм Мингалимовны, Зөлфәтне, Гәрәй Рәхимне дә санарга була. Аларның һәркайсысы — берничә матур җыр авторы һәм ул җырларның һәркайсысы үзенчәлекле ритмикасы, сурәтләре, яңа тибрәнешләре белән истә кала.

Яшьләр турында сүз чыккач, татар халкының милли җыр традицияләрен кабат-кабат өйрәнү кирәклеген искә төшерәсе килә. Г. Тукай да, М. Җәлил дә фольклорга бетмәс-төкәнмәс шигъри фикерләр, бәһасез хәзинәләр чыганагы дип караганнар. Без шагыйрьләрне, әлбәттә, милли поэтика эчендә эрергә, архаик формаларны тергезергә чакырмыйбыз. Әмма бүген дә эстетик ләззәт биргән халык җырларының тылсым кодрәтләреннән берсе аларның нәфис поэтикасында түгелмени! Татар халык җырлары тупланган китапларга гына күз төшерик. Анда шагыйрьләр бәяләп җиткермәгән яки файдаланмаган никадәр байлык бар! Ул байлык җырларның ритмик үлчәүләр төрлелегендә, эчке кушымталарында, тел-сурәтләү бизәкләрендә күренә. Халык җырлары белән чагыштырганда, шагыйрьләр язган кайбер җырлар хис-мәгънә тирәнлеге, сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан эчпошыргыч ярлы һәм күңел кайтаргыч бертөрле булып чыгалар. Сүз халык җырларына хас сәнгатьчә сурәтләү чараларын һәм башка үзенчәлекләрне турыдан-туры күчерү турында түгел, ә халыкның образлы фикерләү дөньясын иҗади өйрәнү турында бара. Халык поэзиясендәге әзер өлгеләрне, сурәт һәм образларны күчерү беркайчан да яхшы нәтиҗә бирмәде, җыр жанрын баетырлык яңа әсәр язуга китермәде. Бу — мәгълүм хакыйкать.

Муса Җәлил 1940 елда ук әле җыр жанрын безнең әдәбият өчен яңа жанрларның берсе дип күрсәткән иде. Хәзер җыр жанры безнең бай әдәбиятыбызда үзенә тулы хокук яулаган һәм инде традицияләре булган жанр. Халык күп кенә шагыйрьләрне, композиторларны иң элек җырлары буенча телгә ала, иң таләпчән редактор буларак, аларны барлый, сайлый, шомарта һәм хәзинәсенә кабул итә. Бу хакта С. Хәким бер шигырендә бик тапкыр әйткән:

Халыкның кулында
Иң яхшы җиз иләк.
Үткәрә җырыңны,
Үткәрә йөз иләп.

Халык характерына хас күркәм сыйфатларны, кеше күңелендәге бай хис-тойгыларны тагы да тирәнрәк, тагы да нәфисрәк итеп җыр телендә ачу — һәм шагыйрьләрнең, һәм композиторларның иң олы һәм иң изге бурычларыннан берсе.

# ИҢ ҮТКЕН, ИҢ ҖИТЕЗ ЖАНР

Җыр — музыка сәнгатенең иң демократик, иң үткен, иң җитез жанры. Татар совет музыкасына нигез салган өлкән композиторларыбыз үз иҗатларын җыр язудан башладылар. Аларның революцион пафос белән сугарылып, киң массаларга юнәлдерелгән җырларында яңа җәмгыятьнең иҗади мөмкинлекләренә чиксез ышанганлык, актив көрәшкә чакыру, туган илгә кайнар мәхәббәт яңгырады. Егерменче елларның азагында, утызынчы елларның башында Салих Сәйдәшев иҗат иткән «Комсомол җыры», Мансур Мозаффаровның Һади Такташ шигыренә язылган «Пионерлар маршы», Заһид Хәбибуллинның «Без — яшь көчләр», Нәҗип Җиһановның «Колхоз җыры» бүген дә сафта, бүген дә аларда хезмәткә өндәү,

тормышны сөю ялкыны сүнмәгән. Музыка сәнгатенә соңрак аяк баскан композиторларыбызның һәр буыны үзе белән бергә җырга яңа аһәң, яңа образлар, җыр иҗат итүнең яңа алымнарын алып килде. Җыр бакчабыз үсте һәм киңәйде. Ул бакчада матур гөлләр генә чәчәк атсын, чүп үләннәре басып китмәсен өчен кайгыртучанлык та юк түгел. Республикабызда егерме елдан артык инде иң яхшы җырларга әледән-әле конкурслар уздырылып килә. Язучылар союзында, Композиторлар союзында, Культура министрлыгында җыр турында җыелып сөйләшүләр, булып узган кайнар бәхәсләр хәтердә саклана. 1973 елның декабрендә Татарстан композиторлар союзы үткәргән пленумда да җыр турында сөйләшү булды. Шул пленумда ук инде соңгы елларда җыр жанрындагы хәлләрнең бик куанырлык булмавы, чын мәгънәсендәге югары художестволы, гражданлылык ялкыны бөркелеп торган җырларның азлыгы, бу юнәлештә яшь композиторларның актив эшләмәүләре күрсәтелеп үтелде. 1974 елда язылган җырлар белән танышканнан соң да шул ук фикерне кабатларга туры килә. Тематикасы, эчтәлеге, музыкальлеге белән күңелне җәлеп итәрлек җырларны ишетә алмадык диярлек.

1974 елда, мәсәлән, илледән артык җыр язылган иде. Шуларның гражданлылык темасын күтәргәннәре, туган ягыбызга, яшьлек һәм комсомолга, КамАЗга багышланганнары ун-унбиштән артмый. Композиторларыбыз, шагыйрьләребез халыкка бүген нинди җыр кирәген сиземләп җитмиләр, ахры. Заманыбызның рухын күпкырлы итеп сурәтләгән күтәренке массовый җырлар жанры онытылып бара. Ә иҗат тәҗрибәбездә аның матур үрнәкләре аз түгел бит. Салих Сәйдәшевның «Без кабызган утлар»ы, Мансур Мозаффаровның «Туган ил», Җәүдәт Фәйзинең «Шауласын, гөрләсен безнең җыр», Әнвәр Бакировның «Яшьләр җыры» — әле дә массовый татар җырларының иң яхшылары.

Төзүчеме ул, завод эшчесе яки колхозчымы—яшь кешенең тормышын җырсыз күз алдына китерү мөмкин түгел. Республикабыз — студентлар иле. Әмма бәйрәмнәрдә студентлар колоннасында җырларлык җырларны альбомнардан таба алабызмы?

Кыскасы, массовый җырлар жанрын бик нык җанландыру, аның тематикасын баету, киңәйтү өчен җиң сызганып эшләү кирәк икәнлеге үзеннән-үзе аңлашылып тора.

Җыр өлкәсендә соңгы бер-ике елның җимешләрен барлау халыкның матур йолаларын, күңел ачуларын бизәрлек көнкүреш җырлары да авторларыбыз игътибарыннан бик ерак торалар дигән нәтиҗәгә китерә. Сабан туйларында, яшьләрнең туй мәҗлесләрендә, бәби туйларында, төрле кичәләрдә башкарырлык әсәрләр язылмаганнар.

Халкыбызның тапкырлык, зирәклек кебек күркәм сыйфатларына лаек булган шаян җырлар эстрадада, телевидение, радио концертларында да әле тиешле урынны алмаганнар.

Әсәрнең уңышын тематика гына хәл итми, билгеле. Югары культурага ия булган бүгенге тыңлаучы композитор иҗатына бик игътибарлы, яңа әсәрдәге һәр табышны, яңа яңгырашны бик тиз эләктереп ала. Тик еш кына без аның өметен аклый алмыйбыз. Чөнки күп кенә җырларда бүгенге кешеләрнең йөрәк тибеше тоелмый. Аларда яңа интонацияләр, заман аһәңе аз. Җырлар ритмик яктан да, форма ягыннан да бер төрлерәк.

Композиторларыбыз профессиональ яктан яхшы хәзерлекледәр, иҗат тәҗрибәләре дә зур. Җырларны тикшерә башласаң, форма төзелеше дә дөрес, милли үзенчәлеге, гармониясе дә урынында шикелле. Тик йөрәкне чеметтереп ала торган ниндидер бер элемент, әллә кайларга алып китә торган бер аһәң, бер борылыш, бер бизәк табылмаган, кульминация билгеләнмәгән була. Көйнең драматургиясен тоймыйсың. Әнә шундый иҗади табышы булмаган җыр моңсыз-канатсыз булып дөньяга килә дә җырчының да, тыңлаучының да күңеленә үтеп керә алмый. Мисалга КамАЗ турындагы җырларны алыйк. Бу тиңсез автогигантка, андагы хезмәт батырларына дистәләп җыр багышланган. Әмма аларның берсен дә камазчылар җырламыйлар. Димәк, йөрәккә үтеп керә торган, заманга, замандашларыбызга авазадаш интонацияләр, ритмик бизәкләр табылмаган. Камазчыларга адресланган җырлар арасында без киң колачлы, талгын гына ага торган көйләр белән дә очрашабыз. Күрәсең, ул гына җитми. Җырларга ялкын, җитез динамика да өстәлсен икән. Барлык халыкларга якын, уртак тойгыларны үзебезнең милли телдә, милли формаларда үткен, тапкыр, матур итеп әйтеп бирә алган булсак, аларны КамАЗда да, Мәскәүдә яисә Таллинда да хуплап күтәреп алырлар иде. Республика-

быз яшьләре соңгы елларда Башкортстан композиторы Рим Хәсәновның «Тапшырылмаган хатлар» спектакленә язган Искәндәр җырын яратып тыңлыйлар, җырлыйлар. Нигә? Чөнки бу көйдә заман интонацияләренең актив элементлары, халыкның эпик көйләрендәге бормалары оста тотып алынган. Көйнең ритмы бик актив, омтылышлы. Ә безнең яшьләргә нәкъ әнә шул сыйфатлар: ныклык, сәламәт рух, активлык хас.

Яңа опера, яңа балет турында Опера һәм балет театры кайгырта. Яңа симфония язылуга, ә дөресрәге, язылу процессында ук, дирижер аны күзәтүгә ала. Әсәр куелуы яки башкарылуы белән үк, аның турында иҗади сөйләшү оештырыла, бәхәсләр туа, тиз арада рецензияләр дә языла. Җыр өлкәсендә исә юнәлешне билгели торган, авторларны, башкаручыларны, музыканы пропагандалаучы оешмаларны бер максатка туплаган үзәк юк. Җыр хуҗалыгында—хуҗа, җыр корабының капитаны юк. Ул капитан—Композиторлар союзының җыр секциясе булырга тиеш. Безгә аны оештыру вакыты күптән җиткән. Татарстан радиосы тапшыруларында музыкага көненә ике сәгатькә якын вакыт бирелә. Шул вакытның яртысы гына җыр программасы өчен билгеләнгән тәкъдирдә дә, көненә егерме җыр кирәк була. Татар дәүләт филармониясе эстрада бүлегенең алты бригадасын гына алыйк. Бер кичтә алар тарафыннан ким дигәндә 120 гә якын җыр башкарыла. Димәк, бу оешмалар репертуарларын даими төстә баета барырга, җырчыларның профессиональ осталыкларын күтәрү мәсьәләсен дә игътибар үзәгендә тотарга мәҗбүр булалар. Шагыйрьләр, композиторлар, башкаручылар арасында иҗади хезмәттәшлекне ныгыта һәм үстерә барганда гына аларның үз бурычларын уңышлы үтәячәкләре бик ачык. Күренә ки, бу оешмаларның эшләре катлаулы, киеренке һәм гаять җаваплы.

Радионың музыкаль редакциясе күп еллардан бирле яңа җырлар тудыруда, яшь җырчыларны үстерү, аларның репертуарларына юнәлеш бирүдә алдынгы иҗат төбәге булып килде. Ул—шагыйрь, композитор, җырчының иҗади очрашу урыны. Заһид Хәбибуллинның колхоз кешеләре турындагы гүзәл җырлары — «Сабанчы егетләр», «Комбайнчылар җыры», Җәүдәт Фәйзинең «Яз шатлыгы», Рөстәм Яхин, Мансур Мозаффаровның күп кенә җырлары да радиода тудылар. Эмиль Җәләлетдинов совет җырларын башкаручы буларак радиода танылганнан соң гына эстрадага күчте. Радионың шушы матур традициясен, әлбәттә, сакларга, үстерергә кирәк.

Җырчыларыбыз күп кенә очракларда иҗади ярдәмгә, киңәшкә мохтаҗ. Аларның сүзләрне бозып җырлаулары, дикция кимчелекләренә битараф кала алмыйбыз. Чыннан да, кайбер җырчыларның нинди телдә җырлауларын кайчак аңышмый торасың. Сүзләргә басым дөрес ясалмый. К. С. Станиславскийча әйткәндә, «люблю» һәм «убью» бер үк интонация белән җырлана. Магнитофонга язылганчы җырны башта сәхнәдә, халык алдында башкарырга, камиллеккә ирешкәч кенә тасмада калдырырга кирәклеге көн кебек ачык. Әгәр син микрофон алдында нотага карап кына җырлыйсың һәм студиядән чыгуга нәрсә турында җырлавыңны онытасың икән, әгәр ул җыр синең репертуарыңда урын алмый икән, ул инде чын дәрәҗәсендәге башкару түгел. Телевидение концертларына таләпчәнлек тагы да арта. Монда җырчы нәрсә җырлыйсын һәм ничек җырлыйсын бик ачык аныкларга, музыкаль редактор, режиссер исә һәр очракта җырчыга аның башкару манерасы һәм үзенчәлегенә туры килә торган әсәрне тәкъдим итәргә тиеш. Әгәр репетицияләргә авторлар да чакырылса, нәтиҗә тагын да яхшырак булыр иде. Монда кайбер җырларны иҗат итү һәм эшкәртү тарихын искә төшереп үтү урынлы булыр кебек. Җыр хәзинәсенә кергән әсәрләрдән З. Хәбибуллинның «Сагыну», М. Мозаффаровның «Сайра, сандугач», «Җиләк җыйганда», Ф. Яруллин җырлары Мәскәүдә, опера студиясендә уку чорында, 1933—1938 елларда туганнар. Әдәби бүлек җитәкчесе Муса Җәлил башта шагыйрь белән композиторны очраштырган, аннары аларны җырчы белән кавыштырган. Композитор, шагыйрь, җырчы — өч иҗатчы — бергә эшләгәннәр. Ялкынлы, дәртле массовый җырларны башлап Мөнирә Булатова, Мәрьям Рахманкулова, Усман Әлмиев җырлаганнар. Лирик җырларны Фәхри Насретдиновка биргәннәр. Колоротуралы җиңел, җитез көйләр Сара Садыйкова, Наилә Рәхмәтуллина, Галия Кайбицкая өчен язылганнар. А. Ключаревның «Туган җирем — Татарстан» — җыр-бию ансамбле репетицияләрендә туды. З. Хәбибуллинның «Бормалы су», «Казакъ дустыма», Х. Вәлиуллинның «Бөек дуслык елгасы» җырлары үз матур яңгырашларын шул ансамбльдә тап-

тылар. «Казакъ кызы сөйгәнем»—Илһам Шакировка адресланды. Бу тәҗрибәне киләчәк эшебездә файдалану, мөгаен, җитди өметләр баглаган җырчыларыбыздан Ренат Ибраһимов, Гали Ильясовка да, танылган эстрада артистлары Әлфия Афзалова, Зиннур Нурмөхәммәтовларга да яңа иҗади үрләргә күтәрелергә этәргеч бирер иде.

Җырларның нинди аккомпанемент белән башкарылырга тиешлеге мәсьәләсен дә игътибарсыз калдырырга ярамый. Соңгы елларда төрле ансамбльләргә кушылып җырлау белән артыграк мавыгып китмәдек микән? Вадим Венедиктов, Ренат Биктимеров ансамбле, «Идел», «Дуслык» һәм тагын шундый инструменталь ансамбльләр... Болар аккомпонементы коры ритмнарга, хәзерге джаз алымнарына гына таянып эшлиләр түгелме соң? Алардагы бертөрлелек колакны талдыра, җырның эчтәлеге белән бәйләнеш җитмәве күңелне тырный. А. Монасыйповның образларга бай, яктылык сирпеп торган «Тамчылар» исемле җырын Р. Мифтахова һәм В. Венедиктов ансамбле башкаруында тыңлавыбыз хәтердә калган. Башта җырның нинди телдә башкарылуын аңлый алмыйсың. Аннан оркестровканың бик таушалган алымнар белән шаблон буенча эшләнүе әрнетә. И. Дунаевский, Л. Утесов чит илдән кергән джаз музыкада совет җырларына туры килә торган чын художестволы оркестровка алымнарын таптылар бит. О. Лундстрем да С. Сәйдәшев, И. Шәмсетдинов, А. Ключарев һәм башка авторларның әсәрләрен джаз оркестры өчен эшкәртеп, джазны милли музыка белән бәйләүнең матур үрнәкләрен бирде. Искә алынган «Идел», «Дуслык» һәм башка ансамбльләр өчен әсәрләрен композиторлар үзләре эшкәртеп бирсәләр, әлеге шаблон алымнардан арынырга мөмкин булыр иде.

Зур күләмле әсәрләрнең премьерасы көтеп алына. Җырлар премьерасын, җырчыларның яңа программа премьераларын без исә белмибез диярлек. Шуңа күрәдер, җыр турында рецензия язу гадәте бездә әле урнашмаган. Композиторлар союзында музыка белгечләре секциясе егермедән артык музыка белгечен берләштерә. Сәнгать фәннәре кандидаты Земфира Сәйдәшева җырлар турында монография яза. Җырлар антологиясенең беренче томы да төгәлләнеп килә. Музыка белгечләребез Татарстан китап нәшрияты чыгарып бара торган җыр җыентыкларына рецензияләр дә язуга күнексәләр, бик кирәкле эш эшләнер иде. Республикабызның драма театрлары спектакльләрендә музыкага, җырга зур урын бирелә. Болар да тәнкыйтьчеләр игътибарына мохтаҗлар.

Җыр өлкәсендә утыз елдан артык эшләүче Сара Садыйкова, үзенчәлекле җырлары белән халык игътибарын яулаган Марс Макаров, Ифрат Хисамов әсәрләре профессиональ рецензия ишетергә бик күптән хаклылар. Музыка белгечләребез җырлар турындагы үткен фикерләрен кыюрак әйтсеннәр, җырларны анализлауда профессиональ таләпчәнлекләрен ныграк сиздерсеннәр иде.

Һәвәскәр композиторлар ара-тирә бик матур интонацияләр, образлар табалар. «Бу профессиональ композитор җыры түгел», дип яхшы җырларны игътибарга алмаган, колак салмаган чакларыбыз да була. Җыр секциясе киләчәктә бу мәсьәләдә тиешле сизгерлек күрсәтер дип ышанырга кирәк.

Яхшы җырларны иҗат итүдән тыш, аларны халыкка тиз җиткерүне оештыру да бик әһәмиятле. Аерым композиторлар җырларына багышланган кичәләр үткәрелә башласа, алар зур җаваплылык сизеп, бу кичәгә яңа җырлар белән килерләр, җырчылар белән ныклап эшли башларлар иде дип, һич шикләнмичә әйтергә мөмкин. Автор кичәләре оештыру иҗатка яңа стимул бирер иде.

Әлбәттә, җыр жанрын активлаштыру буенча эшчәнлегебезне башка төрле юнәлешләрдә дә җәелдерергә мөмкин. Әйтик, һәр елны республиканың туган көне — 25 июньдә яңа җырлардан концертлар оештыруны ник традиция итеп әверелдермәскә!

Өч-дүрт минут кына яңгырый торган җырда опера, симфония белән чагыштырырлык тирән хисләр һәм фикерләр әйтелергә мөмкин. Җыр жанры талант, профессиональ осталык, өзлексез эзләнүне, үзенең музыкаль һәм гомуми культураңны күтәрүне таләп итә. Бу таләпләргә җавап бирерлек композиторларыбыз да, шагыйрьләребез, җырчыларыбыз да, аларның иҗатларына киңәшләре белән ярдәм итәргә әзер торучы музыка белгечләребез дә бар. Җырны игътибар үзәгенә алсак, заманга лаек булган, күңелләрне канатландырырлык әсәрләр күп туачагына шик юк.

**ЗӘЙНӘП ХӘЙРУЛЛИНА,**
музыка белгече.

# «МӘХӘББӘТ СЫНАВЫ» СЫНАУ ҮТӘ

Сәҗидә Сөләйманова укучыларга күбрәк лирик шагыйрә буларак таныш. Аның тау чишмәседәй агылып торган, күп төрле нурларны үзенә җыйган лирик шигырьләре укучы күңеленә бик тиз юл таба. Юл таба да мәхәббәт хисе белән иләсләнгән яшьләрнең уена аек акыл өсти, бөреләнеп килгән изге хисләрен яңа дәрт белән уятып җибәрә, мәхәббәтнең мәңгелегенә, илаһилыгына дан җырлый. Әмма шагыйрә тормыштан аерылган, дөньяга кул селтәп, үз хисләренә генә чумган галиҗәнаплар турында җырламый. Ул мәхәббәт темасы белән бүгенге көннең актуаль мәсьәләләрен күтәрә, күңелгә ятышлы шигъри деталь һәм образларны үз йөрәге аша үткәреп, укучы йөрәгенә күпер сала. Ә мондый бәхет сирәк әдипкә эләгә. Сәҗидә Сөләйманова — шуңа ирешкән сәләтле шагыйрәләребезнең берсе.

Баксаң, Сәҗидә Сөләйманова укучылар күңелен биләгән лирик шагыйрә генә түгел, ә чарланган каләмгә ия, тирән психологик кичерешләрне сурәтли алырлык прозаик та икән. Аның соңгы елларда «Казан утлары»нда басылган хикәяләрен укучылар җылы кабул иткән иде. Менә, ниһаять, Сәҗидә Сөләйманованың проза әсәрләрен бергә туплаган «Мәхәббәт сынавы» [1] дигән китабы дөньяга чыкты.

Соңгы еллар тәҗрибәсе шуны күрсәтә: прозага хәзер тормыш тәҗрибәсе туплаган, дөньяның шатлыгын да, әчесен-төчесен дә татыган яңа авторлар килә һәм аларның әсәрләре бүгенге көн укучыларының зәвыкманова хикәяләренең дә уңышы әнә шуннарына тулырак җавап бирә. Сәҗидә Сөләйда — авторның тормыш казанында туктаусыз кайнавында, үз геройлары белән һәр даим аралашып торуында, аларның шатлыгын үз шатлыгы, кайгысын үз кайгысы итеп иңендә күтәрә белүендә. Билгеле булганча, язучы менә егерме ел инде Татарстанның нефть үзәге Әлмәттә яши. Озак еллар КПСС-ның шәһәр комитеты лекторы булу, җирле радио тапшырулар редакциясендә эшләү, кичке нефть техникумында укыту, болардан тыш күп төрле җәмәгать эшләре башкару язучының иҗатына үз эзен салган. Аның барлык әсәрләре диярлек бүгенге көн кешеләренә багышланган, тормышның үзендә туган вакыйгаларга нигезләнгән.

Менә җыентыкка беренче итеп урнаштырылган «Сагы барның сагы ятар» исемле хикәя. Автор үзенә таныш гадәти генә күренешне — нефть районнарындагы китапханәләрнең берсендә «Хәзерге татар әдәбиятында эшче образы» дигән темага укучылар конференциясенең ничек хәзерләнүен һәм ничек үтүен тасвирлый. Хикәя беренче җөмләләрдән күзгә күренмәс җепләр белән укучыны үзенә бәйли, үз артыннан ияртә.

«Әкиятләрдә шулай була: күңеленә ошамаган батырдан котылырга теләгән падиша тегеңә адәм көче җитмәстәй эш бирә. Латәфәткә дә Мөдирә шундыйрак эш кушты, ахрысы».

Әнә шулай башлана бу хикәя. Шушы беренче җөмләләр үк безне хикәя геройлары белән таныштыра, һәм үзең дә сизмисең, син алар белән бергә дулкынлана башлыйсың. Баксаң, «падиша»га ошамаган батырыбыз — Латәфәт бер дә әллә нинди пәһлеван түгел, ә гап-гади, «әле яңа гына китапханәдә эшли башлаган, җил ныграк иссә дә, егылырга торган кыз бала» икән ләбаса. Мөдирә дигәне дә әллә кем булып чыкмый, шушы ук китапханә мөдире, инде мәхәббәт ялкынында янган-көйгән, аның ләззәтен-га-

[1] С. Сөләйманова. Мәхәббәт сынавы. Хикәяләр. Татарстан китап нәшрияты, 1975 ел.

забын тойган Мөнирә дигән кыз. Ул — тәҗрибәле, конференцияне гөрләтеп уздыру өчен барысын да алдан күрергә өйрәнгән. «Сагы барның сагы ятар» принцибы белән эш итә торган кеше. Мөнирә һәркемгә эшне конкрет бүлеп бирә. Латәфәткә дә дүрт сөйләүче әзерләргә куша. Аларның берсе эшче, икенчесе интеллигенция вәкиле, өченчесе җитәкчеләрдән булырга тиеш. Ә дүртенчесе? Дүртенчесе запаска икән. Запассыз яши алмый Мөнирә. «Аның хәтта егете дә икәү диләр...» Менә шушы кыска гына җөмләләр китапханә мөдире Мөнирәнең җанлы образын күз алдына бастыра.

«Падишаһ» кушкан әмерне тормышка ашыру өчен, Латәфәт эшкә керешә. Яшь булса да, үз шәһәрен, аның кешеләрен, китап укучыларын яхшы белә. Конференциядә чыгыш ясаучыларны шунда ук күз алдына китерә. Менә узган ел гына унны бетереп, бораулаучылар мәктәбендә укучы, шагыйрь күңелле Назыйм. Икенчесе — күршеләре, бораулау остасы, Социалистик Хезмәт Герое Әхмәт абыйсы. Өченчесе — РИТС начальнигы Якупов. Болары, бик назландырып булса да, конференциядә чыгыш ясарга ризалык бирәләр. Эзли торгач, дүртенчесен дә таба Латәфәт. Укучы кенәгәләрен актарганда, кызның күзе Талипов Заһит дигән егет фамилиясенә төшә. «Егерме алты яшендә. Югары белемле. Нефть участогы начальнигы. Адресы бар, өенә кереп чыгарга кирәк». Шулай итеп, конференциядә чыгыш ясарга тиешле кешеләрнең дүртесе дә табыла.

Әмма конференция буласы көнне аларның барысының да дип әйтерлек «кичектергесез» эшләре килеп чыга. Ут-су йота Латәфәт. Шул кадәр өзерләнеп, көлкегә каласы көннәрем бар икән, дип аһ ора. Тик юкка гына борчылган икән яшь китапханәче. «Кай ягы беләндер күңел түренә нур булып иңә башлаган» Заһит участокта килеп туган авариядән котылуга конференциягә килә. Эше никадәр генә булмасын, Назыйм да вакыт тапкан.

«Назыйм залны шигърият белән әсир итте. Җир астындагы тәмуг утын чыгарып бетергәч, анда оҗмах кына калуын, элек шәмгә мохтаҗ якларның хәзер Европага нур таратуын тасвирлаган шигырьләрне яттан сөйләде. Бораулаучы дусларына багышланган үз шигырен укып, залдагы бөтен яшь кызларны бердәй гашыйк итте.

Заһит исә, әдәби әсәрләргә караганда, тормыш турында гәп корды бугай, аның чыгышы сорауларга җаваплар төсен алды:

— Герой Әхмәтнең биш чакрымлык скважинасына нигә һаман көч түгәләр, аннан нефть чыкмасы билгеле түгелмени инде?..

— Бораулаучылар Себергә китә, әллә безнең якта нефть бетәме?..»

Әнә шундый четерекле сорауларга, Заһит белән бергә, автор да җавап бирә. Кыскасы, бу хикәядән заман сулышы, үзебезнең кара алтын иле — Әлмәт яклары сулышы бөркелеп тора.

Шулай да, әгәр хикәянең әһәмияте нефть якларының реаль картинасын бирү белән генә чикләнсә, аның турында бу чаклы сүз озайтып тору артык булыр иде. Югарыда әйтелгәнчә, гадәти бер чара — укучылар конференциясенә әзерлек аша язучы тормышның беренче карашка күзгә ташланып тормаган якларын ача. Унҗиде яшьлек кыз баланың мөстәкыйль хезмәт юлына аяк басуы, бу юлның авыр һәм мавыктыргыч булуы әсәрдә ышандырырлык итеп бирелә.

Менә Латәфәт конференциядә чыгыш ясаучы эзләп, Талипов Заһитның квартирасына килә, беренче чиратта, егетнең өстәлендә яткан китапка күз сала: «Сүзне нәкъ шушы китаптан башлап булмасмы? Китапның тышын караута Латәфәт гаҗәпләнү катыш күңел кайту хисе кичерде. Боккаччо. «Декамерон»... Бүтенге эшче образыннан ничаклы ерак...»

Ләкин китапханәче кыз Заһиттан кул селтәми. Киресенчә, кызның, аның белән бергә укучының да әлеге нефтьче белән кызыксынуы арта гына. Менә без Заһитның әнисе өчен әллә кайлардан чишмә суы алып кайтуы, китапханәдән әнисенә татарча китаплар ташуы турында беләбез. Чишмә суы да, Боккаччо да Заһитның төп эшенә комачау итми икән. Автор шуны ышандыргыч детальләр белән күрсәтә.

Эшлекле Мөнирә дә үз хезмәтенә җаваплы карый, һәр эшне наять итеп башкарырга ярата. Әмма ул бүтәнрәк бизәкләр белән сурәтләнә. Конференциянең өзелү куркынычы килеп тугач, Мөнирәнең яшь хезмәткәр белән сөйләшүен искә төшерик. «Кызыл кыналы кул сырты өстәлгә пычак булып төшә, йөзекләре елкылдап-елкылдап куя». Бу юлларны укыганда Латәфәтнең тормышы куркыныч астында дип утырасың. Яшь кыз исә булдыклы Мөнирә алдында җебеп төшми. Мөнирәнең запаста торган егете Заһит икәнен дә сизенгәч, үзенең тормыш принципларын, мәхәббәтен яклап, көрәшкә чыга. «Әйе, Заһит үзенең эшенә гашыйк. Мөдирә конкурентлар сөйми. Өстәвенә, Заһит үзенең әнисен бик ярата дип уйлап ал-

ды Латәфәт... Юк, Мөдиргә бирергә ярамый Заһитның әнисен!»

Бу хикәядән алган гомуми тәэсирне бик ягымлы һәм мөлаем кыз Латәфәт сүзләре белән әйтәсе килә:

«Бүтәннәр конференциядән нәрсә алып киткәннәрдер, җыелышны әзерләгән көннәрдә кыз дөньяда изге әйберләр булуын, аларны тупаслыктан, ваемсызлыктан, купшы сүзләрдән сакларга кирәклеген тойды».

Алдарак Сәҗидә Сөләйманованың педагог булуына ишарә ясаган идек. «Безнең апай королева», «Чур, сызык!» хикәяләре әнә шул тәҗрибәгә таянып язылган.

Университетның тарих-филология факультетын тәмамлаган яшь тарихчы Мәскүрә, башкорт авылына килеп, беренче дәресенә керергә әзерләнә. Дулкынлана, борчыла. Җитмәсә, аны яңа укытучының һәр сүзеннән, хәрәкәтеннән гаеп табып, «безнең Таңсылу апа алай итми иде, безнең апай болай итми иде», дип торучы бишенчеләргә класс җитәкчесе итеп тә куялар. Ә алар арасында кемнәр генә юк! «Бигрәк тә Айрат исемле четерчән малай күз дә ачырмый. Класста аның сүзе үтә, күрәсең, үзен гаскәр башлыгы кебегрәк тота». Бу малайның биргән сорауларына акыллы башка да җавап табуы, ай, авыр. Нинди генә сораулар бирми ул, әмма явыз ният белән түгел, самими, чын бала кызыксынуы аның фантазиясенә минут та тынгылык бирми. Һиндстан темасын узганда, яшь укытучы кызның авызыннан шахмат уены Һиндстаннан чыккан дигән сүз ычкынуга, Айрат:

«— Апай, нишләп шахматта королева корольдән шәбрәк йөри?» — димәсенме. Җавап бир син кеп-кечкенә Айратка, ышанырлык итеп бир. «Белмим» дип авызыңны да ачма, башка класс булса бер хәер, бу бит Мәскүрәнең үз бишенчесе... Кыен хәлдә калды безнең Мәскүрәбез.

Ләкин, тукта, чу!.. Авызын йомып, колак яфракларына кадәр каушап калмады бит әле бу. Айрат әнә каз тәпие кебек кызыл кулларын яңагына таянып ихлас күңел белән тыңлый, инанып тыңлый.

«— Сугыш барганда король күзәтеп, киңәшләр биреп торган,— ди әнә Мәскүрә апасы, Айратның елтыр күзләренә карап.— Гаскәр башлыгы гадәттә корольнең якын кешесе, улы яки энесе булган. Легенда буенча, сугышларның берсендә король дә, гаскәр башлыгы да каты җәрәхәт алганнар. Король белән бергә сугыш барышын күзәткән королева чигенә башлаган солдатларны үзе һөҗүмгә алып киткән. Король янәшәсендәге королева шахматка шулай килеп кергән...»

Ышанмый карасын хәзер Айрат! Үзе уйлап чыгарган бу легендага Мәскүрә хәтта үзе дә ышана. «Нигә, бик табигый хәл. Индира Ганди ил белән идарә итә бит әнә»,— ди.

Әйе, бала күңеленә ачкыч табу җиңел түгел. Мәскүрә моны белә һәм ышандырырлык ситуацияләр аша Айратны: «Безнең апай королева...» дип әйттерер дәрәҗәгә җиткерә.

«Сау булыгыз», «Чәчәкле шәльяулык» хикәяләрендә укучы мәхәббәтнең зурлыгын аңлаучы, аны изге хис итеп саклаучы катлаулы образлар белән очраша. Яшьли ятим калып, кайда бала, кайда өй карап яшәгән, аннары шәһәр больницаларында няня булып эшләгән удмурт кызы Лизаның Петр Палычка булган мәхәббәтен, 40 яшькә җиткәндә кабынган бу мәхәббәт ялкынына җил-яңгыр тидерергә теләмәүче, аны ничек тә сакларга тырышучы палатадашларының Лиза турында, аның киләчәк язмышы турында туганнарча кайгыртуларын автор дулкынландыргыч итеп тасвирлый. Хикәядәге һәр образ үзенчә ачыла һәм алар әсәргә олы мәгънә өстиләр, аның колоритын баеталар.

«Кыйбла» хикәясен укып чыгу белән тирән уйга каласың. Башта күп төрле сораулар туа. Тормыш ыгы-зыгысы белән бәрелештә җиңелгән Илшатка карата күңелдә бер үк вакытта ачу хисләре дә, кызгану хисләре дә уяна. Кәфенләнгән мәет янында Мәйсәрә апасының бәет көйләвен генә тыңлыйк:

> Дуслар җыелган
> урыным түрләрдә.
> Тиздән салырсыз
> салкын гүрләргә...

Тәннәр чымырдап китә, күзгә ирексездән яшь килә. Ә бәет агыла, аңны томалап, бер көйгә дәвам иткән моңлы аваз сине кайгы-хәсрәт дәрьясында әллә кайларга агызып алып китә.

> Үлчәп алыгыз
> зифа буйларым.
> Ашыктырмагыз,
> актык туйларым...

Тик язучының укучыны тетрәндерерлек бу хәлгә үз мөнәсәбәте бар: «Сәнгатькә салгач, үлем кебек иң ачы кайгыга да бүтән төс керә, елау-сыкраута гаҗәеп аһәңнәр өстәлә икән»,— ди ул. Моның белән килеш-

ип булмый. Безнең халык үз башына килгән кайгы-хәсрәтләрне әледән-әле бәетләрдә чагылдырган, шул юл белән күкрәгенә таш булып утырган хәсрәтеннән бушанган.

Әмма хикәяче, үз-үзенә кул салган Илшатны кызганса да, аның бу адымын аклямый. Автор позициясе ярылып ята. Илшатны бүтенге матур киләчәк өчен гомерен биргән әтисе янына җирлиләр. Зират бушап кала. «Җил көчәйде. Карт тирәкнең ботаклары әле бер якка, әле икенче якка егылдылар. Түбәннән тамырлар аша атаның өне ишетелгәндәй булды:

— Мин үлем белән кылычка-кылыч килеп күрештем. Сезгә ирек яуладым, ут бураннары аша үтеп, гаделлек табып бирдем. Әзер ирек әллә кадерсезгә әйләндеме?.. Гаделлектә күрешергә дошман булмас диденме, шуңа үзеңне киряксезгә санадыңмы?»

Гүрдәге ата сүзләре гаделлек өчен көрәшнең әле дә дәвам итүен искәртә һәм, Илшат кебек, көрәшләрдән куркып калучыларны хурлык тамгасы белән тамгалый, ата улын кыйбласын саташтырганы өчен гаепли. Ә «кыйбланың кай якта икәнен саташтырмас өчен, күңел яктылыгы кирәк». Илшатның фаҗигасе әнә шунда — үз кыйбласын үз вакытында таба алмавында, аның өстенә семья низаглары... Сүз җаеннан шул кадәресен дә әйтик: «Кыйбла» — соңгы елларда иҗат ителгән иң әйбәт психологик хикәяләрнең берсе. Темасы, сюжет, композициясе төзеклеге белән ул сәхнә әсәренә тартым булып чыккан.

«Әс-сәләми, Суфият!» — хикәяте дә уңышлы әсәр. Юлъязма буларак, ул шактый кызыклы язылган. Укучыны моңа кадәр аз билгеле булган илләр, халыклар, аларның гореф-гадәтләре, культуралары белән таныштыра, һәр вакыйгага, тарихи фактларга бүгенге совет кешесе күзе белән бәя бирә.

Инде килеп, күңелне борчыган кайбер кимчелекләр турында да әйтик. Алдарак әйтелгәнчә, Саҗидә Сөләймmanagованың прозаик буларак, каләме шома. Әмма урыны-урыны белән каләме түмгәкләргә дә килеп төртелә.

«Февраль аеның кояшлы бер көнендә класс активы белән күрше авылдан йөреп укыган өлгермәүче балаларның өйләренә барырга булдылар. Чаңгыда барасы булгач, активка кермәгәннәре дә активлашып киткән».

«Кирәкле кешене кайчан өйдә очратырга мөмкинлеген сорады да шым гына чыгып китте. Урамга чыккач үкенде: эш телефонын сорамаган, тагын киләсе була инде.

Икенче тапкыр килгәч, әбекәй Латыйфәттән сорыйсы итте...».

Каләм җитәрлек чарламау нәтиҗәсе булган мондый җөмләләр һәр хикәядә диярлек очрый. Аннары авторның геройларының портретларын сурәтләүгә һәм сөйләм телләрен индивидуальләштерүгә игътибарны да көчәйтәсе бар.

Билгеле, болар гына китапның әдәби кыйммәтен төшерми. «Мәхәббәт сынавы» сынауны уңышлы үтте, укучылар аны үзләренең рухи азыгы итеп кабул итте. Ә рухи азыкка сусап торган хәзерге укучыга мондый китап бүләк итү өчен язучының үзенең рухи дөньясы ифрат тирән һәм киң колачлы булуы кирәк! Саҗидә Сөләйманова исә аңа ия һәм укучы аннан, лирик шигырьләр, поэмалар белән бергә, вакыт сынауларын уңышлы үтәрлек яңа проза әсәрләре көтә.

**ХӘНИФ ХӘЙРУЛЛИН.**

# ШАГЫЙРЬНЕҢ ПРОЗАСЫ

Моннан җиде-сигез еллар элек, бер сөйләшеп утырганда, шагыйрь Г. Афзал әйтә куйды:

— Слуши, менә ничә еллар инде миңа бер вакыйга һич тынычлык бирми. Язасы килә шуны, ләкин шигырь дә, поэма да чыкмый аннан. Хикәялек материал ул. Булмаса, син яз әле шуны...

Вакыйга, чыннан да, дулкынландыргыч иде. Больницада ятканда, шагыйрь кызыклы күп кешеләр белән танышкан. Шулардан берсе легендар Чапаевның һәлак булуын үз күзләре белән күргән икән. Шагыйрь сөйләгәннәр күңелне бик кытыклаcа да, мин аны хикәя итеп яза алмадым. Ни генә әйтмә, кеше сөйләгән вакыйгаларга таянып әдәби әсәр язу — кыен эш.

Ул арада «прозада мин чи надан» дип, мескенләнеп йөргән Гамил Афзалыбыз бербер артлы кыска юмористик хикәяләр язарга кереште. Һәрберсе 2—3 кенә битлек шул юморескалар белән каләмен сынап, уч төп-

ләрен җылытып алды да көннәрдән бер көнне ул безгә «Сигезенче палатада» дигән күләмле әсәрен укыды. Бу — шагыйрьгә ничәмә еллар тынгылык бирмәгән һәм кайчандыр миңа сөйләп йөргән вакыйгага нигезләнгән хикәя иде.

Ниһаять, менә шагыйрьнең «Кышкы озын кичләрдә»[1] дигән хикәяләр һәм юморескалар китабы. Җыентыкка кергән хикәяләрнең күбесе кулъязма хәлендә үк таныш булса да, мин китапның һәр битен, чын ләззәт белән рәхәтләнеп, көлә-көлә укыйм.

Гамил Афзал прозасының шулай елмайта-көлдерә һәм уйландыра торган көче нәрсәдә соң? Мондый көч, иң беренче чиратта, аның шигырьләреннән үк килгән бай юморында. Язучы юморның күп төрле сер-хикмәтләрен белә. Менә «Матриархат чорында» исемле хикәя.

«Без, имеш, матриархат чорында яшибез. Дөньяга хатын-кыз баш та хатын-кыз түш. Ә ирләрнең, мескеннәрнең, бернинди хокуклары юк... Хәзер мин өйдә өч бала карап утырам, бер кулым белән бала тирбәтәм, икенче кулым белән камыр басам, «и ходаем, эчеп кайтмаса гына ярар иде», дип теләк телим. Әчсә, бик холыксыз ул Нәфисә, дөньяны кыра... Әле үткән атнада гына: «Шешә саткан акчаны кая куйдың, кирәшен?» — дип бәйләнеп җанымны алды...»

Язучы, әнә шулай, реаль хәлләрне һәм дәверләрне алыштырып куеп, комик ситуация тудыра, шул ситуация аша тормыштагы тискәре күренешләрне тәнкыйтьли. «Чалыш көзге», «Шәһрезадә әкиятләре», «Изгеләр бәянында», «Бер сенсация тарихы» исемле хикәяләрдә дә шундый алым кулланылган.

Г. Афзалның юмор-сатира өлкәсендә яратып куллана торган икенче бер алымы — гипербола. Шул алымнан файдаланып, ул үз геройларының характерындагы берәр тискәре якны калку итеп, көлке итеп күрсәтеп бирә. Гипербола алымы белән «Күрде безнең башлар» хикәясендә һәр төрле мактанчыкларга, «Җаваплылык хисе» хикәясендә хәреф корты-бюрократларга, «Инфаркт» хикәясендә ялган дан артыннан куучыларга үткен сатира угы атыла. Г. Афзалның аткан уклары бик төз барып тия. Укучы, андый хикәяләрне укыгач, рәхәтләнеп бер көлә дә: «Кара әле, бу нәкъ безнең фәлән-фәләнеф икән», дип уйлап куя.

Тагын бер төр хикәяләрендә язучы тормыштагы гап-гади хәлләрне ала да шулар нигезендә мавыгып укырлык кызыклы әсәр яза. Бу яктан «Хәл-әхвәлләр» исемле хикәя бик характерлы.

Нигъмәй төнге сменадан эштән кайтып керә. Өй буш. Хатыны — эштә, малай — бакчада. Юынып алгач, ул кухнядагы савыт-саба капкачларын ачып-ачып карый. Тамак ялгардай берни юк. Кыйммәтле телевизор алып, кесә такырайган чак шул... Нигъмәй тизрәк караватка аву ягын карый. «Кунак-фәлән генә килеп чыкмасын, получкага чаклы күп калмады», дип уйлый ул, йокыга куерып барышлый. Шул чак кинәт ишек шакыйлар. Нигъмәй сукрана-сукрана ишекне барып ачса, авылдан әтисе белән бертуган абыйсы килгән. «А, кемне күрәм мин, әйдүк, әйдүк, түрдән, түрдән!» — ди Нигъмәй. Бер кашык бал капкандай, вак шадраларын нурландырып, кунакларны өйгә алып керә, өстәл янына утырта. Папирос арты папирос белән сыйлый-сыйлый, әй, тотына бу туган-тумачаның, күрше-күләннең хәл-әхвәлләрен сорашырга. Шул рәвешчә, шактый сайрап утыргач: «Их, җиңгине дә алып килсәң, кунак булып китәр идегез»,— дип өзгәләнә ул һәм тагын яңа пачка папирос чыгара. «Җиңгәң папирос тартмый шул ул», — дип, абыйсы урыныннан кузгала.

Бөтен вакыйга бары әнә шуннан гыйбарәт. Ихтимал, мин аны кызыклы итеп сөйли дә алмаганмындыр. Әмма хикәянең үзен укыганда бер генә укучы да елмаймыйкөлми кала алмый. «Кышкы озын кичләрдә», «Бригадир Ахун», «Беренче гонорар» хикәяләрендә дә тормыштагы гап-гади вакыйгалар бәян ителә. Ә үзләрен рәхәтләнеп, елмая-көлә укыйсың. Хикмәт нәрсәдә соң? Бу сорауга, ихтимал, автор үзе дә анык кына җавап бирә алмас иде. Ә хикмәт әдәби талантның сүз белән аңлатып биреп булмый торган сихери көчендә булса кирәк.

Г. Афзал прозасында ягымлы юмор белән нечкә лирика бик матур үрелеп бара. Моның гүзәл үрнәге — югарыда телгә алынган «Сигезенче палатада» хикәясе. Менә бер палатада сигез авыру ята. Сигезенең сигез төрле чире, сигез төрле характеры, сигез төрле язмышы. Әнә шул бер-берсенә һич охшамаган кешеләрнең характерларын ачу, язмышларны тасвирлау өчен, язучы кабатланмас детальләр таба. Шулар өстенә әле, врачларның, сестраларның истә калырдай портретларын бирә бара. Ул детальләр, ул портрет-характеристикалар гаять кыскалар. Ләкин никадәр саллы-үтемле алар. Өстәвенә, лирика һәм юмор никадәр мул булып, икесе берьюлы нурланып балкый алардан.

[1] Г. Афзал. Кышкы озын кичләрдә. Кыска хикәяләр, юморескалар. Казан, 1975 ел.

Салават күпередәй мондый характер-язмышлар балкышына язучы ничек ирешә соң, дигән сорауны мин тагын, баягыча, талантның сихери көче белән генә аңлата алыр идем. Ләкин хикәянең ничек язылуы миңа яхшы ук мәгълүм булганлыктан, ул «талант» дигәннәренең бер сере турында да әйтми китү мөмкин түгел. Беренчедән, язучы ул хикәяне еллар буе күңелендә йөртте. Икенчедән, Г. Афзал аны күпме көч куеп, һич иренмичә кат-кат эшләп чыкты. Менә шунда, ирексездән, П. И. Чайковскийның мәгълүм сүзләре искә төшә: «Хәтта даһилар сәләтенә ия булган кеше дә, әгәр җәһәннәм газаплары кичереп эшләмәсә, бөек әсәрләр генә түгел, урта кул әйберләр дә иҗат итә алмый; илһам бары тик хезмәт процессында һәм хезмәт иткәндә генә туа».

Кемгә-кемгә, бу хакыйкать Гамил Афзалга яхшы таныш. Җыентык «Юл газабы» дигән автобиографик хикәя белән ачыла. Автор анда әдәбиятка килгәндә узган авыр һәм газаплы юлы турында сөйли. Шул авыр юл турында сөйләгәндә дә, ул үзенең юморына тугрылыклы булып кала. Әмма ахырдан җитди итеп әйтә: «Әдәбиятта-сәнгатьтә ансат юллар юк. Шуны әйтергә теләдем. Бу юл газапларының кемнәргәдер гыйбрәтле булуы ихтимал».

Әйе, гыйбрәте тими калмас.

Китапта «Ике ләкин» дигән юмореска бар. Анда Г. Афзал башта күккә чөеп мактап та, «ләкин» дип җиргә салып таптаучы, тагын бер «ләкин» белән сыйлап-сыйпап та куючы бериш тәнкыйтьчеләрдән көлә. Мин тәнкыйтьче түгел. Г. Афзал китабына карата андый «ләкин»нәрем юк. Бик зур теләгем генә бар. Шагыйрьнең беренче проза китабы әле калын түгел. Аның шушындый ук елмаеп, көлеп, уйланып укый торган калын-калын яңа проза китапларын тизрәк укыйсы килә. Укучы моңарчы Гамил Афзалның шигырь китапларын шулай көтеп ала иде. Хәзер аңа таләп икеләтә арта. Поэзияңне дә бир, инде бер ымсындыргач, зинһар, прозаңны да онытма.

**РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИН.**

# КОНКУРСКА КИЛГӘН РЕЦЕНЗИЯЛӘР

*Журналыбызның бишенче санында яшь тәнкыйтьчеләр арасында иң яхшы рецензияләргә конкурс игълан ителгән иде. Яңа чыккан матур әдәбият әсәрләренә һәм яңа китапларга яшь каләмнәребез язган рецензияләр соңгы вакытта редакциягә килә тора. Бу санда шуларның берничәсен урнаштырабыз.*

## САУМЫ, БӘЙРӘМ!

Бәйрәм дигәч, күңел яктырып китә. Бу сүз бигрәк тә бала чакта әкият кебек серле тоела, төрле төсләре белән әйтерсең күңелгә нурын чәчеп тора. Шигырь-җырсыз бәйрәм бәйрәм түгел. Аннан башка шатлык кичәсенең яме, яктысы кимегәндәй.

Май кояшы күктән көлеп карый,
Май кояшы бүген сөенә.
Урамнарда бүген шатлык кына,
Күңелләрдә дәртле көй генә.

**(Разил Вәлиев. «Май кояшы».)**

Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган «Безнең бәйрәмнәр»[1] җыентыгында әнә шундый якты шигъри юлларны күпләп очратабыз. Балалар һәм яшүсмерләр өчен шагыйрьләр Зәки Нури һәм Хәкимҗан Халиков төзегән бу җыентыктагы унбер бүлекчәдә кырыктан артык шагыйрьнең (яшьләрнең дә, өлкәннәрнең дә) даһи Ленинга, Бөек Октябрьга һәм традицион бәйрәмнәргә багышланган йөз утызлап шигыре тупланган.

Беренче бүлекчәнең эпиграфы ук безне тормыш эченә бөтереп алып кереп китә, заманыбызның җаваплы һәм катлаулы мәсьәләләре уртасына куя:

Без узасы, әй, юллар бар,
Зур эшләргә чакырып ил дәшә.

**(Сибгат Хәким. «Күңелем Ленин белән сөйләшә».)**

Әйе, укучылар да кичәләргә фейерверк чөяргә дә, бәйрәм итәргә дип кенә килмиләр. Алар бирелә рухи азык алалар, уйларын киләчәккә төбиләр. Шуңа күрә «Ленин гел исән» (Әнвәр Давыдов), «Бөек якташыбыз» (Нури Арсланов), «Байраклар» (Фәнис Яруллин), «Якты көннәргә» (Зөлфәт) кебек шигырьләрнең зәвыклары үсkәннән-үсә барган яшь укучылар күңеленә хуш киләчәге шиксез.

Бу рәткә яшь шагыйрьләрдән Роберт Миңнуллин һәм Зиннур Насыйбуллин шигырьләрен икеләнмичә өстәргә мөмкин. Шигъри бәйләмнәрдә аларның үз авазлары, поэтик полотноны үзләре тапкан төсләр белән баетырга омтылулары сизелә. Р. Миңнуллинның таң нуры сыман җиңелчә генә шигъри романтика рухы белән сугарылган шигырьләрендә ярсу яшьлек чирәм җирләргә ашкына. КамАЗ төзи, күкләргә күтәрелә. Яшь герой өчен бишьеллыклар да, тормыш үзе дә — көрәш мәйданы, һәм, гомумән, кеше җиргә көрәш өчен килгән шәхес булып күзаллана. Зиннур Насыйбуллинда исә шушы ук төшенчә (көрәш сүзен кулланмыйча гына) тормышчан детальләр аша тагын да киңрәк яңгырашта бирелә.

Мин ышанам:
Үлемнәрне җиңәр бер көч итеп
Җир яраткан безне — улларын.
Шуңа безнең нерв җепләренә
Тоташтырган заман җир шарын!

**(«Безнең буын».)**

Иҗат кайчан да үзең булып калуны таләп итә. Балалар өчен язам дип, бераз гына сүлпәнләнеп кара! Яшь иптәш моны шунда ук «тота», ул һәрдаим олылар белән берргәттән атларга, фикерләргә тырыша. Әйе, бала булып кыланганны өнәми яшь укучыларыбыз. Шуның өчен җыентыкка үтеп кергән кайбер ясалма шигырьләр аларны дулкынландырмаса һәм хәтергә сеңеп калмаса, һич гаҗәп булмас.

[1] Безнең бәйрәмнәр. Казан, 1975 ел.

Мисалга Р. Вәлиеваның «Май җыры»н алыйк.

Быргылар уйнасын,
Барабан тынмасын,
Дәртләнеп яшь йөрәк җилкенсен,

— ди автор. Ләкин «җил исә» диеп кенә Иделдә дулкын купмаган кебек, гомуми сүзләр тезмәсе белән генә укучының йөрәген җилкендереп булмый. Аннары бу җырдагы:

Нурларга төренеп,
Гөлләргә күмелеп,
Кояшлы, чәчәкле май килә...

— кебек юллар белән шушы ук «Май кояшы» бүлекчәсеннән икенче бер шигырьдәге:

Ал байракларга төренеп,
Ал чәчәкләргә күмелеп,
Тагын Май килде,

— дигән юллар арасында нинди аерма бар икән?

Әмма, бәхеткә каршы, мондый әсәрләргә караганда, сәхнәне чыннан да бәйрәмчә яңгыратырлык һәм укучылар репертуарында лаеклы урын алырлык шигырьләр китапта күбрәк. С. Хәким, Н. Арсланов, И. Юзеев, С. Сөләйманова, Р. Гәрәй, Г. Рәхим һ. б. ларның күп кенә шигырь-җырлары нәни дусларыбызга менә дигән бүләк булыр.

Җыентыктагы кайбер шигырьләрне укый торгач, күңелгә тагын шундый уй да килә: күп вакытта без тышкы кыяфәт-күренешләр белән мавыгабыз, бала күңеленә үтеп керә алмыйбыз, ахрысы. Югыйсә, нәниләр күңелендә күпме җорлык, наянлык-шуклык та тулып ята бит әле! Без, олылар, артык җитди-кырыс түгелбезме икән? Әнә бит Шәүкәт Галиев шигырьләре балаларга: «Бу — мин, сезнең дустыгыз — Шәүкәт абыегыз булам!» — дип кычкырып торалар. Шагыйрьнең «Солдат әби», «Нинди була Яңа ел?», «Яңа ел ник картая?», «Май бәйрәмендә» дигән әсәрләре «Безнең бәйрәмнәр»не чын мәгънәсендә бизиләр. Алыйк менә бер уку белән үк хәтердә кала торган «Солдат әби» шигырен:

Алъяпкычын бәйләгән,
Энемне җитәкләгән,
Бидон тоткан кулына,
Урын юк мылтыгына —
Кыстырган култыгына!

Җыентыкта әнә шундый чатнап торган образлы яисә укучыбыз үрнәк алырдай заман геройларын сурәтләгән шигырьләрнең аз булуы алай да үзен нык сиздерә дияр идек. Кайда безнең балалар әдәбиятының «Дядя Степа»лары? Заманында укучылар яратып укыган «Таза Мортаза»лар кайда йөри? Әйтик, ни өчен «Уңыш бәйрәме» бүлекчәсендәге сабан туена багышланган шигырьләрдә заманыбыз каһарманнары җиңнәрен сызгана алмыйлар? Шигырь сөюче мәктәп балалары бәйрәм кичәләрендә пафослы шигырьләр генә сөйләмиләр ич.

Китапка композиторларыбыз көйләр язган шигырьләрнең дә кертелүе матур күренеш. Аларның «Уңыш бәйрәмендә», «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Яшьләр җыры», «Унике батыр турында баллада», «Кояш гомере», «Гайдар — безнең комиссар», «Хәтерлим мин әле бүгенгедәй» кебекләре яшүсмерләр һәм балалар арасында инде популярлашып та өлгерде. Боларга өстәп, тагын «Кыңгыраулы мәктәп еллары» (Шәүкәт Галиев шигыре, Хөснул Вәлиуллин көе), «Иң шатлыклы көнем» (Хәкимҗан Халиков шигыре, Әхмәт Хәйретдинов көе), «Мәктәпкә барасы бар» (Гәрәй Рәхим шигыре, Мирсәет Яруллин көе), «КамАЗда сабан туе» (Рәшит Әхмәтҗанов шигыре, Луиза Хәйретдинова көе) кебек әсәрләрне атарга мөмкин. Әйтергә кирәк ки, китапта музыка әһелләренең игътибарын җәлеп итәрдәй әсәрләр күп әле. Композиторлар, бигрәк тә яшьләр, бу җыентыкны читләтеп узмасыннар иде.

Яңа туган һәрбер уңышлы шигырь — үзе бер бәйрәм ул. Ә биредә күпчелеге матур-матур әсәрләрдән торган яңа китап хакында сүз бара. Аны яшь укучыларыбызның якын дуслары — шагыйрь абыйлары һәм апалары әзерләгән бәйрәм бүләге дип кабул ителәчәгенә ышаныч бар.

**ФӘННУР САФИН.**

# ЧИШМӘ СУЫН УРТЛАГАЧ...

Кемдер әйтер: тагын шул ук «чишмә», шул ук искереп беткән чагыштыру, дияр. Әйе, төшенчә бу-лаарак иске ул, ләкин чишмә суы үзе искерми дә, кабатланмый да. Һәр яшәү мизгелендә — тәүге сафлык, яңа омтылыш аның. Яшь шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның беренче китабын[1] укыганда чишмәнең менә шушы кыйммәтле сыйфаты хакында уйлыйсың.

Чишмәләр табыла тора... һәр яңа табылган чишмә суын татып карыйсы килү таби-

[1] Кадыйр Сибгатуллин. Әманәт. Казан, 1974.

гый нәрсә. Һәркайсыбызның тәмгә «үз тәме» булуын онытмастан, китапның беренче битләрен ачабыз...

Бик җитәрлек минем, җитәрлек
шатлыкларым, кайгым, сагышым.
Иңнәремә төяп барысын,
Ерак юлга чыгып барышым,

— ди шагыйрь «Юл башы» исемле шигырендә. Һәм алга таба ул, шигырьдән-шигырьгә, бүлектән-бүлеккә, шушы «иңнәргә төялгән» йөкнең асыл бәясен ачып бирергә тырыша.

Китапның төп юнәлеше күңелне җәлеп итәрлек ачык билгеләнгән. Кадыйр Сибгатуллин кешелекнең «заманнан-заманга» ничек «ныгый һәм чистара» баруы турында сөйли, мещаннарча «заманга ябышып, сырышып» яшәүчеләрне чын поэзия югарылыгыннан торып хөкем итә, заманны «җилкәңә салып бару»ның олы мәгънәсен шигъри осталык белән ача белә. Шагыйрь үз иҗатын гражданлык бурычыннан аерып карый алмый. Аның индивидуаль-пессимистик фәлсәфәгә каршы көрәштә үзе тапкан позициясе бар.

Мескеннең зары бар,
халыкның — заманы,

— ди ул.

«Әманәт»нең лирик герое бай рухи тормыш белән яши. Киләчәк хисе үткәнне һәм бүгенгене дөрес бәяләү, образлы үзләштерә белү шикелле кыйммәтле сыйфаттан килеп чыкканга күрә, шагыйрьнең тавышы ышанычлы. Ул укучы күңелендә үз сүзе тудырган уй-хисләрне гел ишетеп-сизеп, анализлап тора кебек һәм, шигырьләрне күбрәк укыган саен, шагыйрь белән укучы арасы якыная бара.

Кадыйрның уйлануы, хакыйкатьне эзләү формасы үзенә бер төрле. Кайберәүләр аны кыюсызлык чагылышы дип тә атарлар бәлки. Ә, минемчә, алай әйтү дөрес булмас.

Чынлап торып бер карагыз әле,
каерылып,
борылып карагыз...
Көннәр,
айлар,
еллар үткән саен,
ераклашмый микән арабыз?!

Яки:

Без беләбез инде,
улларыбыз
ипи тәмен менә аңлармы?

Бу юллар «Авылым» дип исемләнгән эскизлардан. Беренче карашка, сорау формалары шигырьгә очраклы килеп кергән сыман. Ә чынлыкта исә алар — авылның авыр үткәнен һәм бүгенге якты көнен йөрәк аша үткәреп тапкан поэтик раслауларның көчен арттыручы «шик»ләр генә. Әйе, улларыбыз да ипи кадерен белсен өчен, шуңа ышанычны ныгытыр өчен кирәк ул шик. Шагыйрь безнең үзебездән дә яшерергә маташкан (әмма бездә булган!) шикне үз фикерен нигезләү өчен куллана. Шулай итеп, ул кешеләрнең күңелен тазарта, чүп-чардан арындыра, яшәү сәләтен арттыра. «Авылым» эскизлары шагыйрьнең юлга максатлы чыгуына матур ишарә.

Кадыйрның лирик герое чыгышы белән җир кешесе. Аның «буыннары ныклыгы» — «учларда уылган арыштан», ул гомер таңында ук кырыс сынауларга очраган.

Җырчы да,
шагыйрь дә булма, ди,
монда ту,
монда үс,
яшә дә!

— ди ул «Кырларым күмелгән рәшәгә» исемле шигырендә. Шагыйрь шушы җирнең кешеләрен, дөньяга үлемсез эшләр калдырыр өчен туган кешеләрне җырлый. Алар туган туфракка тән белән генә түгел, җаннары белән бәйле. Юккамыни шагыйрьнең чит җирдә картаерга мәҗбүр булган бер якташы шундый васыять әйтә:

Авылыгыз зираты ни хәлдә?
Терлектән таптата күрмәгез.
Картайган көнемдә кайталсам,
мине дә кәфенләп күмәрсез.

(«Чит илдән хат».)

Кадыйрның лирик герое өлкән буыннар каршындагы бурычын, киләчәк алдындагы җаваплылыкны үткен тоя. Ул үзе турында да заманнар фикерен ишетергә тели. Заман зур сынау мәйданы ул, без яшибез—димәк, сыналабыз. Сынаулар исә чыныктыра да, кайберәүләрне сындыра да.

Аналардан малай туа, ирләр тумый.
Малайларның туган бере гел ир булмый.
Сабыр итеп һәр мизгелдә заман кәтә:
кыл өстеннән кемнәр үтә,
ничек үтә!

(«Заман көтә».)

Кадыйрның шигъри осталыгы зур күләмле әсәрләрдә тагын да ачыграк сизелә. «Ирләр» дип исемләнгән әсәре безне тормыш дөреслеге белән тетрәндерә. Катлаулы чор проблемаларына, тарихи вакыйгаларга чын иҗади якын килү бу. Кичә генә иген иккән крестьян ил өчен сугышка керә. Бу темага язылган әсәрләр санап бетергесез. Кадыйр Сибгатуллин теманы ачуда үз сүзен тапкан, җир кешесенең рухи ныклыгын, зурлыгын сокландыргыч итеп күрсәтә алган.

Сезгә генә кыен инде, нишләтәсең,
бик борчылма, хафаланма, түз, энкәсе.
Малайга әйт: камыт-дуга исән булсын,
тимер худның кучәрләрен майлый торсын,

Болар җиңүгә үзе ышанган гына түгел, башкаларны да ышандыра белгән совет сугышчысы сүзләре. Шул ук вакытта нинди сөйкемле һәм никадәр милли бу характер!

Шагыйрьнең шәхси лирикасы самими, ул кешенең намусына, кешелеклелегенә мөрәҗәгать итә белә. Шәхес үзенең бөтенлеген актив җирлектә генә, язмышына башкалар актив катнашканда гына таба һәм исбат итә ала. Тик шул чакта гына ул үзендә индивидуаль вакчыллык, мин-минлекне җиңә һәм эшләгән эшләрен чын күңелдән кешеләр хөкеменә бирә. Сибгатуллинның «Әйт әле», «Тәрәзә саен көлтә-көлтә нурлар», «И чабабыз, йөгерәбез» шигырьләрендәге лирик герое шул көрәшсез генә ялганмый торган кешелеклелек сыйфатлары белән күңелгә якын.

Тик, әнә шундый әсәрләр белән беррәттән, китапта шактый гына кытыршылыклар да юк түгел. Мәсәлән, «Киткәннәр әйтсеннәр» исемле шигыренең фикере шактый бәхәсле. Хәерчелектән иза чиккән авыл кешесенең читкә, бәхет эзләргә китү факты каршында, әйтик, бүгенге колхозчының «иленнән-җиреннән китмәве» һич тә мораль өстенлек була алмый.

> Бер түгел микәнни һавалар,
> җирдәме-күктәме аерма?

— дигән сораулар белән үткәндәге мәҗбүри трагик (бу урында: читкә чыгып бәхет эзләү) хәлләргә нигә «авырттырып» якын килергә?

Аннан соң:

> Егет кулы түгел,
> тормыш тотты нәфис куллардан.

Яки:

> Кызлар хисен инде яшьлек түгел,
> дуңгыз фермалары исертте.
>
> («Иргә чыкмый калган апалар».)

— кебек уңышсыз юллар да очраштыргалап куя китапта. Әмма шунысы бәхәссез, «Әманәт»не безгә өметле автор әйтте.

...Сүзне чишмәдән башлаган идек бит әле. Әйе, чишмәгә суга кояш чыкканчы киләләр. Тик бу максатсыз ашыгу түгел, бу — кояшны, яңа туып килгән көнне сәламләү билгесе.

ВЕНЕРА РӘХМӘТУЛЛИНА.

# «ФРОНТОВИКЛАР» РОМАНЫНДА ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЛАРЫ

Соңгы елларда әдәби тәнкыйть тә, киң катлау укучылар массасы да язучы М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романы турында күп кенә җылы сүзләр ишеттерде. Әсәрнең әдәби яктан төзелеше, художество эшләнеше һәм төп образлары хакында байтак фикерләр әйтелде. Ләкин «Фронтовиклар» турында инде әйтәсе сүзләр бетте дип булмый әле. Мисал өчен, романдагы хатын-кыз образлары, андагы моңа кадәр очрамаган аерым үзенчәлекле типлар хакында аз язылды. Мәдинә Маликова «Кайда сез, Нәфисәләр?» дигән мәкаләсендә әсәрдәге хатын-кыз образларына беркадәр тукталып киткән иде[1]. Шуннан ары бу темага сүзне дәвам иттерүче күренмәде кебек.

Роман, белгәнебезчә, сугыштан соңгы елларда авыл интеллигенциясе тормышын сурәтләүгә багышланган. Сугыш беткән ел. Мәктәпләрдә укытучылар җитми. Менә шундый авыр бер вакытта Акбалык урта мәктәбенә элекке диңгезче Рушад Сулимов һәм кыю разведчик Гата Сәләхиев килеп төшә. Фронтовиклар озакламый укытучыларның да, укучыларның да ихтирамын яулыйлар, шат күңелле, тырыш һәм бердәм коллектив туплыйлар.

Һәм нәкъ менә шушы коллектив эчендә, мәктәптә без төрле характерлы, төрле язмышлы хатын-кызлар белән очрашабыз да инде.

Шуларның берсе — мәктәптә «техничка» булып эшләүче Мәсрүрә. Романның алдагы битләрендә үк без аның белән йөзгә-йөз килеп очрашабыз. Аның чыгырыннан чыгардай булып бәрелә-сугыла директор булмәсенә килеп керүе геройның характерындагы бер якны ачып бирә. Ул — тол хатыннарга гына хас күңел ярсуы, күңел ашкынуы. Мәсрүрә ачы язмышын күз яшьләре аркылы үзе менә болай белдерә: «Нишләп мине андый сүз белән мәсхәрә итә ул, ә? Тол хатын дигәч тә. Ирем сугышта үлмәгән булса, мин

[1] «Азат хатын» журналы, 1973 ел, 5 сан.

дә болай кеше артын чистартып йөрмәс иде-е-ем. Уһу-һ-һу-һ-у-у...»[1].

Мәсрүрәнең характерындагы бу сыйфат әсәр барышында үстерелә һәм XII бүлектә югары ноктага җиткерелә. Биредә тол хатынның ярсуы, күңел ашкынулары укучыны тетрәндереп җибәрә. Берничә генә ай ире белән яшәп калган Мәсрүрә ялгыз өйгә яшь егет Рушадны чакыра. Бу очрашудан Мәсрүрәнең эчке кичерешләре, күңел дөньясы шул кадәр кинәт ачылып китә ки, без үзебездә аңа карата бер үк вакытта кызгану да, хөрмәт хисе дә уянганын сизми дә калабыз. Автор берничә җөмлә белән өй эчен сурәтли, ләкин шул кечкенә бер күренештә кеше күңеле чагылыш таба. «Батып бара торган кояшның саргылт нурлары ян тәрәзәдән өйгә үтеп кергән дә мич алдындагы җиз самаварда, бакыр комганда чагылган. Өй эчендә әллә нинди үзәк өзгеч тынлык, саргылт-кызыл нур, әллә нинди ятимлек...»

Язучы безне сугыш һәм кешеләр язмышы, кешеләрнең бәхеткә һәм мәхәббәткә хаклы булулары кебек зур мәсьәләләр турында уйланырга мәҗбүр итә. Тормыш барышын туктатып булмаган кебек, мәхәббәтне дә туктатып булмый. Кешелекне юк итәргә күтәрелгән ерткычлар яшәүне туктата алмадылар. Тормыш дәвам итте. М. Мәһдиев моны Мәсрүрә һәм Мөби образлары, Мостафа һәм Хәлимә кичерешләре белән үстерде һәм Рушад белән Ләйләгөлнең матур, моңлы, саф мәхәббәтләре белән тәмамлап куйды.

Әсәрдә укытучы хатын-кыз образларын сурәтләүгә аеруча зур урын бирелә. Менә Нәркис. Язучы аның турында дәртләнеп-мавыгып сөйли. Нәркис мәктәп коллективындагы бөтен укытучы хатын-кызлардан нык аерылып тора. Мәктәптә ул бердәнбер югары белемле укытучы. Авылга шәһәрдән килгән. Бу турыда автор безгә гел кисәтеп, искәртеп бара. Университетта ук ул онытгысызынчы йөз язучыларының әсәрләрендәге хатын-кыз образлары белән шашынды, ди. «Тургеневның «Накануне» романында Елена Стахова образы» дигән темага диплом яклады, дип тә өстәп куя. Нәркис тирән фикерле торган кеше. Әдәбиятка, дөньяга аның үз карашы бар. Сугыш җиле бу кызга да кагылмый калмый. Нәркис сугышта сөйгән егетен югалта. Бу аның өчен чын мәгънәсендә авыр кичереш. Ул да мәхәббәтен эзли.

Нәркис — хәрәкәттәге образ. Без аны коллектив эчендә дә, коллективтан читтә дә күрәбез. Ул романның төп образлары Рушад һәм Гатаны тулырак күз алдына китерергә дә ярдәм итә.

Нәркиснең яхшы укытучы булуын, балаларда рус әдәбиятына мәхәббәт тәрбияләү өчен бөтен тырышлыгын куюын автор җай килгән саен искәртеп үтә. Яхшы белем бирү өчен көрәштә Нәркис ялгызы гына түгел. Шундыйларның берсе — акыллы һәм әдәпле Бәлкыйс. Уку-укыту бүлеге мөдире ул. Бәлкыйс үзенең гомерен дә, матурлыгын да, бәхетен дә мәктәпкә бәйләгән, шуңа багышлаган, олайган кыз. Бәлкыйс дөреслекне яклый, күз йомып калырга аның көче җитми. Фронтовик егетләрне педсоветта беренче яклап чыгучы да ул була. Аның бүлмәсе дә китапханәгә охшаш. Рушад аңа сокланып: «Бу кеше ник укытучы булмасын? Бу шуның өчен туган, шуның белән яши»,— ди. Бөтен гомерен яшь буынны тәрбияләүгә багышлаган Бәлкыйснең сәер гадәтләре дә бар. Ул да сөюдән, сөелүдән мәхрүм.

«Романда бирелгән һәр образ безне дулкынландыра, көлдерә, кызгандыра. Әйе, кызгандыра, алар үзләренә карата кызгану хисе тудыралар. Чөнки сугыштан соңгы елларда үзләренә тиң яр табып гаилә коруның кыенлыгы аларны бәхетсез итә. Романдагы хатын-кызларның образы шушы мәсьәләдә — гаилә кору, үзләренә тиң яр табу мәсьәләсендә ачыла, шунлыктан берьяклы булып күз алдына килеп баса»[1].

Язучы М. Маликова романдагы хатын-кыз образларына карата шундый фикер әйткән иде. Безнеңчә дә, ул фикердә хаклык бар. Мисалга Миңҗамал образын гына алыйк. Миңҗамал да тол хатын. Ул нечкә күңелле, тиз елаучан. Тормышка чыгып та озак яши алмаган Миңҗамал бүленеп калган бәхетен, ирен сагынып яши. Югары белем дә ала алмый, читтән торып педучилище тәмамлый. Укытучыны без класста укучылары алдында, я булмаса дәрес вакытында күрергә гадәтләнгәнбез. Ә менә Миңҗамал безнең күңелдә укытучы булып түгел, ә күбрәк тол хатын булып кына кала. Без аның белән уку-укыту процессында очраша алмыйбыз. Шундый ук хәл нәзакәтле Нәркис өчен дә хас. Ул да үзен балалар янында күрсәтми. Ә инде тормышка чыккач, әсәрдән бөтенләй югалып калгандай була. Әсәр башында тулы канлы булып күренгән Нәркис образы төссезләнеп китә.

Романда Ләйләгөл зур тормышка, белем-

[1] М. Мәһдиев. Фронтовиклар. Казан, 1973 ел, 25 бит.

[1] «Кайда сез, Нәфисәләр?» «Азат хатын» журналы, 1973 ел, 5 сан.

гә омтыла, кораблар төзүче булу турында хыяллана. Шушы хыялы тормышка ашмыйча торып, ул хәтта мәхәббәтеннән — Рушад белән очрашудан да баш тарта. Кызганычка каршы, без Ләйләгелнең зур тормышка ничек аяк басканын, максатына ирешү юлында очраган киртәләрне ничек кичкәнен күрә алмыйбыз. Бу турыда язучы читләтеп кенә әйтеп үтә. Шулай да Ләйләгел образ буларак әһәмиятен югалтмый.

Югарыда сөйләнгән образларга капмакаршы бер тип итеп автор Гөлчирәне куя. Ул — директор Сабир Ишмуратович хатыны. Укучы күңелендә алсу чәчәкләр арасында үскән шайтан таягы сыманрак бер тәэсир калдыра. Әсәрдә Гөлчирәгә багышланган битләрне укыганда елмаймый калмыйсың. М. Мәһдиев аны нечкә юмор белән язып үтә. Мәсәлән: «...Гөлчирә кадерле яшәде Сабир кулында. Сугыш вакытында авылның хәлле кешеләре арасында кунак-төшем бик еш уйналды. Гөлчирә, Бибисара шундый мәҗлесләрнең түрендә булдылар. Парлап йөрү модада түгел, хәер, аның ире дә шул Гөлчирәдә генә бар иде. Гөлчирә килмичә мәҗлес башланмый иде Акбалыкта. Тавышы авылдагы бер генә гармунга да туры килмәсә дә, Гөлчирә җырчы исәбеннән йөрде. Аңа ияреп уйный алмаучы гармунчылар үзләренең «культурный» итеп уйный белмәүләреннән, кушылып тавышын җайлый алмаучылар шулай ук «Гөлчирәнеке кадәр үк талантлары юклыктан» дип уйлыйлар һәм ышаналар иде».

Гөлчирәдәге көнчелек хисе, буш куык кына булса да, башкалардан үзен өстен куярга омтылуы оста сурәтләнә.

Романдагы хатын-кыз образларының һәрберсенә хас характеры, хәл-фигыльләре, килеш-кыяфәтләре, сөйләмнәре бар. Нәзакәтле Нәркиснең сөйләме үзе кебек үк нәфис. Язучы аның турында: «Кыз тал чыбыгына кунган сандугачтай сайрый иде», — ди.

Мәктәптә җыештыручы булып эшләүче Мәсрүрәнең дә, һавалы Гөлчирәнең дә сөйләмнәре үзләренә гаять тә ятышып тора, характер сыйфатларын ачуга нык ярдәм итә. Мәсәлән, Гөлчирәнең белдекле булып русча сөйләшергә тырышып йөрүе шунда ук аның характерын күз алдына бастыра. Китапта образларның теле, гомумән, ачык һәм төгәл булуы белән аерылып тора. Әсәрне укыганда ул геройлар белән үзең сөйләшкәндәй буласың.

Татар әдәбиятында хатын-кыз образлары бик күптәннән тудырылган. Кол Галинең «Йосыф вә Зөләйха» поэмасында Зөләйха, Г. Кандалыйның «Сәхибҗамал» поэмасында Сәхибҗамал һәм тагын үз заманы өчен гүзәллек идеалы булган бик күп образларны санап булыр иде. Татар совет әдәбиятының казанышлары аеруча зур. Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ындагы Галия, Г. Бәшировның «Намус» романындагы Нәфисә, Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр»ендәге Гөлшаһидә кызларыбызның тормыш идеалына әйләнделәр. «Фронтовиклар» романы белән М. Мәһдиев бу зур һәм матур традицияне дәвам иткән диясе килә.

**РАФИС ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН,**
педагогия институты студенты.

# НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

## Равил Вәлиев

### Теш сызлагач



Әтисе Ләззәткә базардан чикләвекләр алып кайтты.

— Тешең белән ватып ашый күрмә, улым! Сызлап үзәгеңә үтәр! — диде ул, аларны Ләззәтнең чикләвек кадәрле генә нәни учына салып.

Ләззәт әтисенең сүзен тыңлады. Чикләвекләрне чүкеч белән ватып ашый башлады.

Бераздан, үч иткәндәй, әтисенең теше сызларга тотынмасынмы?! Каян күреп өлгергән диген, Ләззәт чүкечен күтәреп әтисе янына килеп тә җитте:

— Нигә тешең белән чикләвек ваттың? — диде һәм: — Мә, чүкеч белән ватып аша, — дип, чүкечен әтисенә сузды.

### Эштән кайтмаган

Телевизорда күп серияле «Лэсси» исемле фильм бара. Әтисе, бар дөньясын онытып, шул фильмның «Адашкан сарык бәтие» дип аталган икенче сериясен карап утыра.

Ә Ләззәтнең әнисе эштән кайтмый да кайтмый. Берәр җыелыш-фәлән килеп чыккан, ахрысы...

Менә телевизор экранында һау-һаулап Лэсси кушаматлы эт өреп җибәрде. Аннан күреп, әнкәсен югалткан сарык бәтие бәэлдәп куйды. Әнисен көтә-көтә көтек булып беткән Ләззәт тә, бер читтә уйнап йөргән җиреннән, әтисенең алдына менеп утырды:

— Кемне эзли алар, әти?

— Әниләрен, дәү сарыкны... — диде әтисе, телевизор экраныннан күзләрен алмый гына.

— Ул да эштән кайтмаганмыни, әти?

### Язны сагыну

Март азагы.

Иртән генә аяк асты кап-каты иде, ә көндезен шәһәр урамнары буйлап гөрләвекләр акты.

Ләззәтнең аягында киез итек. Шуңа күрә әтисе аны балалар бакчасыннан күтәреп алып кайтты.

Иртәгесен тагын суытты. Бакчага барышлый, Ләззәткә кабат әтисе янәшәсеннән теркелдәргә туры килде.

— Әти, кайчан яз килә инде? — дип сорап куйды Ләззәт, балалар бакчасына килеп җитәрәк.

— Чү, улым, апрель керсен... Язны шулай тиз сагынып та өлгердеңмени инде?

— Әйе-е... Яз килсә, син мине бакчага күтәреп илтер идең...

## Табышмак

Бүген Ләззәтләр группасы табышмак чишәргә өйрәнгән, ахрысы... Балалар бакчасыннан кайтышлый, ул әтисен аптыратып бетерде:

— Эленеп тора груша — ашарга ярамый... Ул нәрсә, әтием?

— Ашарга ярамаган нинди груша икән ул? — дип, Ләззәтнең күңелен күрү өчен, әтисе табышмак җавабын юри таба алмый торды.

Ләззәткә мактанырга шул гына кирәк тә:

— Ә мин беләм... Лам-поч-ка!

— Ә-ә-ә, кара син аны, тел очымда гына торган иде ләбаса...

— Дөрес түгел! — дип, янә әтисен уңайсыз хәлдә калдырды Ләззәт. — Тел очында лампочка була димени?

## Кем хаклы?

„Күк лампочкалары» — йолдызлар турында сүз чыккач, Ләззәт әтисеннән артта калып кайта башлады. Ул төнге күк йөзенә озак кына текәлеп карап тора да, йөгереп барып, янә әтисен куып җитә. Аннары тагын артта кала...

— Әти, йолдызлар ник яна? — дип сорап куйды ул бервакыт.

— Минә синең шикелле әтиләрен көттерә-көттерә кайткан малайлар караңгыда калып адашмасын өчен!

Кырыс кына әйтелгән бу сүзләрне Ләззәт колагына нygытып, киртләп куйган икән. Иртәгесен иртән, балалар бакчасына барышлый, ул янә әтисенә сорау бирде:

— Йолдызлар ник сүнгән, әти?

Әти кеше, ни дип әйтергә белмичә, бу юлы иңбашларын гына сикертте:

— ?..

— Ә мин беләм! Малайлар бакчага әтиләрен көттерә-көттерә барсалар да, көндез адашмый ич...

## Бәрәңге төтене

Әнисе бүген кичкә «чикмәнле» бәрәңге пешерде. Ул аның суын сыкты да кайнар кәстрүлне өстәлгә куйды. Капкачын ачты. Ә аннары:

— Суына торсын!.. Әйдә, улым, пеш-ш итә күрмә! — дип, аяк астында чуалып йөргән Ләззәтне дә үзе белән кухнядан алып чыгып китәргә теләде. Ләкин Ләззәт карышып:

— Әни дим... Без чыгып китсәк, бәрәңге янып бетәр ич! Әнә, ничек төтене чыга! — диде ул, кәстрүлдән күтәрелгән парны күрсәтеп.

## Үпкә

Ял көне Ләззәтнең әтисе белән әнисе Кама буеның бөек Шишкин мактап җырлаган нарат урманында йөреп кайттылар. Ләззәтне дә үзләре белән алдылар. Чаңгыда йөрү аларга бик ошады. Киләсе ялга да урманга барырга сүз куештылар.

Өйгә кайткач, һәркем үз эшенә керeште. Ләззәт фоторәсемнәр карарга утырды.

Менә ул бер рәсемгә бик озак текәлеп карап торды. Анда нәкъ ул бүген күреп кайткан кышкы урман сурәтләнгән. Ләззәтнең әтисе белән әнисе шунда чаңгы шуып йөриләр. Аларның яңа өйләнешкән, икәү генә яшәгән чаклары иде ул.

Ләкин кечкенә Ләззәт боларның барысын да каян аңлап бетерсен соң әле?! Аның иреннәре әкренләп турсайды, озын керфекләре астыннан ике бөртек күз яше тәгәрәп чыкты.

— Мин кайда? Нишләп урманга икәү генә бардыгыз? — диде ул, әти-әнисенә үпкәләп. Һәм елап җибәрде.

# ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Мирсәй Әмир

## МЫЖЫК КАРТ ЯЗМАЛАРЫ

### Сүз башы



Радио тыңлый торган кешеләрнең исендәдер, «Хәерле иртә» дигән тапшыруларның берсендә мондый киңәш биргәннәр иде: «Әгәр дә сез тиешсез урында урам аркылы чыгарга уйласагыз, иң элек сулга карагыз, аннары — уңга һәм, якын-тирәдә милиционер-мазар күренмәсә генә, тәвәккәлләп, каршы якка үтегез!»

Шул акыллы киңәшне истә тотып, тротуарда тукталып калдым. Бутлеров урамы иде бугай... Әйе, әйе, галимнәр йортыннан ерак түгел, ә тыкрыктан ерак: тиешсез урыннан чыкмый хәлең юк. Як-ягыма каранырга өлгермәдем, кемдер, ниятемне аңлап, миңа теләктәшлек белдерергә ашыкты.

— Әнә бит, — диде, — үзләре мәҗбүр итәләр кешене урам кагыйдәләрен бозарга...

Әйләнеп карасам — бер карт. Башында кайчандыр затлы булган велюр эшләпә, кулында артыш таяк. Аны яшьрәк чагында үзе юнып алган булса кирәк: ботак урыннары, кыз-курчак күкрәкләренә охшап, калкып-калкып тора. Карт үзе бик җитди күренә. Хәттә кырыс. Әллә кашлары шулай ачулы күрсәтә: озын булып салынып төшкән чал кашлар, койрыкларын өскәрәк күтәреп, әз генә бөтереп җибәрсәң, менә дигән мыекка әйләнергә торалар.

— Бар иде бит! — диде ул ачулы тавыш белән. — Менә шушы тауны менеп җиткәч тә туктала иде трамвай. Хәзер әнә түбән төшүчеләр өчен туктала, ә тауга менүчеләр өчен — юк! Кайда монда логика?!. Моңа бит... — ул, ал ягы озынрак булып салынып төшкән соры пинҗәк чабуларын ачып, балак очлары кайтарып куелган, инде бер кат модадан чыгып, икенче кат модага кереп бара торган киң чалбар кесәсенә тыгылды. Тик теләгәнен эшләргә өлгермәде, аның игътибары очып килгән яшел «күзле» такси машинасына юнәлде. Кесәсеннән газета катыш нинди дер кәгазьләр, дәфтәрләр тартып чы-

гарган уң кулы кинәт югары күтәрелде. Шул ук секундта, аны җилә белән бәреп ега язып, нәкъ алдына машина килеп туктады. Картым, утыртмый китеп бармасын тагы дип курыккандай, кабаланып алгы ишекне ачты, кәгазьләрен кире кесәсенә тыга-тыга, шофер янына кереп тә югалды.

Машина китеп баргач кына абайлап өлгердем: кәгазьләре арасыннан бер дәфтәре төшеп калган икән. Иелеп, кулыма алдым. Кечкенә форматлы, ләкин калынча, кара коленкор тышлы дәфтәр. Нишләтергә инде моны? Машинадан җилләр искән. Язу таныган кеше була торып, ничек ачып карамыйсың? Язу танымаган кеше дә түзә алмас иде, бит араларында акчасы-мазары юк микән дип булса да, актарып карар иде. Мине, әлбәттә, ул ягы кызыксындырмый. Күңелем яхшыда. Әчендә адресы-фәләне язылмаганмы — шуны беләсем килә. Һич югында, исем-фамилиясе булса да ярар иде. Хәерле булсын! Кешегә чишәргә ярамый торган серләрең язылган булса, гафу ит, бабакаем, ачтым дәфтәреңне!..

Тышлык белән беренче бит арасындагы калын саргылт кәгазьнең нәкъ уртасына гарәп хәрефләре белән калын итеп мондый сүзләр язылган:

## «Мыжык карт язмалары»

Китапка охшый ич бу! Беренче битен ачтым. Китап шул. Әнә, «мөкатдимә» дигән. Аның янына, җәяләр эченә алып, «кереш сүз» дип тә язып куйган. Димәк, элекке заман китапларын да күргән кеше, хәзергеләрен дә буш куймый. Карыйк, ни яза икән?

## Мөкатдимә

«Бу китапны язам үзем өчен генә. И вот почему: яратмый башладылар үземне. Өемдәгеләрне әйтәм. Сүләшмиләр. Сүләшмәсеннәр, анысына да түзәм. Тыңламыйлар! Бер кәлимә сүз әйттемме, бетте: «Мыжыма!..» Янәсе, мин хәзер сүләмим, мыжыйм гына.

Мыжыса соң? Ә син тыңла! Мыжымыйча буламыни? Мыжык картлардан башка дөнья алга барамыни? Бик беләсегез килсә, әйтим: мыжу бит ул самокритика. Самокритикадан башка алга барып кара!.. Тыңламасалар да мыжып була булуын. Мин үзем, мәсәлән, ялгыз калган чагымда да теттереп мыжыйм. Даже кыюрак та мыжыйм. Критиканы үзенә алып, үпкәләүче или каты җавап бирүче булмый. Берәр нецензурный сүз ычкындырып җибәрсәң дә, колагын тыгучы юк. Шулай да ялгыз мыжу кызыксыз. Компание юк. Ягъни, әйткәнеңне хуплап торучы юк. Хупләп та тормасын, пусть каршы чыксын, опровергать итсен, и то җанга рәхәтрәк булыр иде. Даже кызыграк та булыр иде әле, телне ача төшәр иде, зиһенне дә. И күңел бушап калыр иде бер. Юк бит андый кеше, юк! Нишләргә? Карчыгым исән булса икән. И-и-и, ул исән булса! Тыңламас җиреннән тыңлар иде, мескенем. Әрләсә ни! Әрләве дә күңелгә хуш килеп кенә торыр иде. Хыт яңадан үлән. Бәлкем табылыр да иде. Мәрхүмәмне алыштырырлык ук булмаса да,

үзем кебек бер мыжык карчык — и то ярар иде. Кая ул андый турыда авыз ачу! Ычкынган бу дияргә генә торалар. Аларча, мин инде бу дөнья белән алыш-биреше беткән кеше. Какой анда үләнү! Берүземне күпсенәләр. Әйтмиләр әйтүен, тамакны да кысмыйлар, гөнаһларына керер хәлем юк (хотя үз пенсиям булмаса, нишләрләр иде әле?). Ирочканың тетелдәвенә караганда... Шундый внучкам бар, рәхмәт төшкере. Тик мона исеме! Әйтергә оят. Шундый матур кыз балага Ир дип кушмасалар! Ира дигән булалар, әлбәттә. Барыбер ир булып ишетелә. Шул рәхмәт төшкере бала гына минем белән сүләштергәли дә бит, нәрсә сүлисең сабый белән? Шул бер көнне сорый миннән.

— Бабай, син, — ди, — кайчан китәсең?

— Кая? — мин әйтәм.

— Әби янына, — ди.

Вот ишетмәсәң ишет!

— Нигә? — Мин әйтәм. — Мин китсәм, сиңа рәхәт буламы?

— Синең бүлмәгә эти пианино алып куя...

Әнә ни турында план коралар бит! Туктале, мин әйтәм, ишеттерсен үзләренә бу сабый: «Юк, мин әйтәм, кызым, әбиең янына ашыкмыйм әле. Әгәр син каршы килмәсәң, бүлмәмә яңа әби алып кайтырга уйлап торам».

Кызыксына калды сабый.

— Апкайт, бабай, миңа әби кирәк, — ди.

Ә бер-ике көннән әйтә бу миңа:

— Син, бабай,— ди,— ычкынган! Сүләшмим синең белән...

Шуннан чамаларга була инде маңгаена тай типмәгән кешегә...

Аптыраганнандыр инде, башка бер идея килде: зарларымны язып куярга булдым. И файдасы тиде. Әйтелмичә эчтә калган зар баш миен агулый дип беләм мин. Йөрәккә төшә, нервларны боза. Ә мона язып куйгач... Пусть берәү дә укымасын, эчтә калмавы әйбәт. Кем белә, язып куйгач, бәлки кайчан да булса, кемнең дә булса күзенә чалыныр. Рус ул белми әйтми: что напишешь пером, не вырубишь топором...

Башта мин аларны нинди кәгазь эләксә, шуңа язып куя идем. Тора-бара шушы дәфтәргә күчерә башладым. Эчемне пошырган нәрсәләрне һаман шушында терки барам. Эчемне иң нык пошырган хәл — яшьләрнең бер нәрсәгә дә эчләре поша белмәве...

Шушындый кереш сүздән соң карт үзенең зарларын язып китә. Зарлары... Ни дип әйтим?.. Артык шәрехләп торуның кирәге юк дип беләм. (Кирәк булса тәнкыйтьче табылыр.) Кызганычка каршы, дәфтәрдә авторның исем-фамилиясе дә, адресы да юк. Шулай да «мыжу»ларын «кайчан да булса, кемгә дә булса» ишеттерү турында хыялланган кеше, мөгаен, рәнҗемәс дип ышанып, язмаларын укучыга тәкъдим итеп карарга булдым.

Шунысын да әйтеп үтим, мин аларны үзгәртмәдем. Тик формасы белән китапка охшый төшсен өчен, кайберләренең урынын алыштырдым һәм һәркайсына номер сугып, исем кушып чыктым. Әгәр бу язмалар басылып чыкса һәм, авторы күзенә чалынып, ул аларның эчтәлегендә нинди дә булса үзгәреш тапса, ялганлаган дип, мине гаепләмәсен: редактор үзгәрткән булыр.

Тәвәккәлләдек!

## 1. Талыйлар!

Тордым йокыдан. Бактым тәрәзәгә. Күзем төште әлеге бинага. Ни арада калкып чыкты диген! Җигерме катлы. Алдым бинокль, санаймын тәрәзәләрен. Юк, барысын да димим, аларын әнә эвеэм санасын, мин исәбенә чыга торган түгел. Югалган күзләрен генә санадым. Кичә сигез күз юк иде, бүген — ун! Көн саен я ике, я өч күз пыяла юкка чыга. Ватылмый бит ул. Бала-чага бәреп ватарга теләсә дә, җигерменче катка таш ыргыта аламыни? Буй җиткән ата хулиган булса да җиткерә алмый. Төзүчеләр арасында орлашу бетми, ди! Менә шунысына эч поша. Урамнардагы телефон будкаларының пыялаларын орлыйлар бит! Ничек шундый кешеләр белән коммунизм төземәк кирәк?!

## 2. Корсагыннан кысма тюбикны!

Чыктым юынырга. Алдым кулыма «Поморин». Врач куйган теш ходай биргән үз тешеңнән кадерлерәк дисәләр, ышанмаган булыр идем яшь чакта. Мона хәзер күрәм: үз тешләрем таза вакытта искә төшкәндә бер генә щеткага тотына торган идем, ә тимер тешләрне көн саен щеткалап, пасталап чистартырга да иренмим. Щеткаларны аерым тотабыз. Паста уртак. Барыбыз да «Поморин»га үч. Файдаланырга яраталар, ә ничек файдалану ысулын белмиләр. Тоталар да тюбикны корсагыннан кысалар. Эчтәге сыекча тюбикның ике башына бүселә. Мин үзем аны, тюбикны, тулы чагында ук төбеннән кысып китерә башлыйм, аннары аның бушаган өлешен нигытып бөкләп куя барам. Сез дә шулай эшләгез, дип, йөз тапкыр гына әйткәнмендер, йөздә генә бетсә әле! Әйтми калган көнем юктыр. Кияүгә дә, кызга да, Ирочкасына да... Кая ул истә тоту, ишетмиләр дә. Тәңренең бирмеш көне тюбик обязательно уртасыннан кысылган, ике якка бүселгән була. Шушы хәлгә тыныч кына карау өчен никадәр гамьсез, никадәр ваемсыз кеше булу кирәк? Алла сакласын!

## 3. Яшәсен безопаска!

Утырдым кырынырга. Безопаска белән. Электр бритвам да бар. Кияү бүләге. Арзанлысы да түгел, «Москва» дигәне. Әйбәт кыра. Тиз дә. Мәгәр бер алама ягы бар: өреп чистартырга кирәк. Төк тузаннарын үзең сулыш ала торган бүлмә һавасына очырырга диган сүз. Бервакыт баскыч коридорына чыгып өреп караган идем, күрше карчык тетмәмне тетеп кертте.

— Оятсыз! — ди. — Синең сакал тузаныңны ни өчен мин сулап үпкәмне черетергә тиеш? — ди. — Ак тузаның белән кешеләргә мондый этлек эшләргә ничек намусың җитә? — ди. (Әйтерсең, кара сакал тузаны булса — файдалы.) — Кешегә ярый, үзеңнекеләргә ярамыймыни? Алланың кашка тәкәләремени сезнекеләр? — ди.

Артыгын тыңлап тормадым, өйгә кереп бикләнгәч тә әллә ни гомер ишетелеп торды зәһәр тавышы. Каршы берни диярең юк, дөресен әйтә. Ә бит кем бинават? Миндә дә гаеп юк түгел. Шулай да таякның юан башы завод өстенә төшә. Неужели шундый машинаны уйлап чыгара алган конструкторның төк тузанын бөтен дөньяга туздырмый гына җыю әмәлен табарга башы җитми?.. Ә кияүнең гамендә дә юк. Кайда туры килсә, шунда кырына бирә, кырынган урыныннан

да ук өреп очыра бирә. Әйтсәң, кешегә яраган безгә ярамыймыни, дип кенә җибәрә. Кырынуы кырыну, очыруы очыру. Аңа, янәсе, тизрәк кенә барып җитәргә кирәк. Икесенең дә эшкә киткәндә җан-фәрман ашыкмаган чаклары юк. Минем өчен иң кызыгы... юк, кызыгы түгел, иң нык эчемне пошырганы, ачуымны китергәне шул: соңгы бер минут кыска тоела аларга. Сәгатьләренең ярты минутка, хәтта берничә секундка алдамы-арттамы икәнлекләрен тикшереп башлары ката. Шул актыккы ярты минут өчен шашар чиккә җитәләр.

— Болай ашыгып, ачлы-туклы, чиле-пешле чыгып киткәнче, мин әйтәм, эшләгән урыныгыз өчен дә, сәламәтлегегез өчен дә хәвефле булган мондый цейтнотка кергәнче, дим, көн саен хотя бы биш кенә минутка алданрак торырга гадәтләнсәгез, ә? Биш минут та булмасын, бер генә минут җитми кала бит сезгә?

Җавап биреп тә тормыйлар. Кайвакыт авыз ачарга бер секундларын җәлләмиләр икән, анда да җавап дигәннәре әлеге дә баягы:

— Я, мыжыма әле!..

Минем ашыгасы юк. Үзләренә булсын электр бритвалары. Яшәсен безопаскам!

## 4. Урынына куй!

Кордым бритваны. Алдым кипиток, күперттем сабын. Яңакка сөртмә келәп, багыйм дисәм, юк куйган урынында көзгем... Егет чакта ук сатып алган бик шәп түгәрәк көзгем бар. Өч аяклы, ике йөзле. Бер ягы гади, икенче ягы зурайтып күрсәтә. Шул зурайтып күрсәтә торганына карамасам, кырына да алмыйм. Кайчак читтә-мазарда мәҗбүрән туры килсә дә, кырынуымның ләззәте булмый. Хикмәт, шул көзгене кияү дә ярата, кыз да. Ирочкасына кадәр шуңа үч. Яратсыннар, карасыннар, рәхәтләнсеннәр иде, сүзем юк, ашала торган нәрсә түгел. Шунысы теңкәгә тия: алгач, кире урынына куя белмиләр. Ә мин, бер әйберем куйган урынында булмаса, бетәм, җенем кузгала, чыгырымнан чыгам. Кайдан эзләргә белмим. Бәлки ул әллә кая да китмәгән буладыр, хәтта күренеп тә тора торгандыр. Ә мин аны күрмим. Күңел күзем сукырая. Бал корты кебек мин, укыганым бар: бал эзләргә чыгып киткән кортның әйләнеп кайтуына умартасын ярты гына метрга булса да урыныннан күчереп куйсаң, ул аны табалмый ди. Мин дә тач шул корт.

Әнә бит, юк бит көзгем үз урынында! Кая киткән, шайтан белсен. Тагын шуны эзләп өйнең астын өскә китерергә туры килер микәнни?.. Шулай да капыл ук кызып китәргә ашыкмадым. Күркәм сабырлык күрсәттем әле. Бәлки ерак китмәгәндер, шунда өстәлемдә үк утырадыр... Тыныч кына күз йөртеп чыктым. Юк, күренми. Сизәм, әллә кайдан, йөрәк төбемнән ярсып ачуым кузгалырга тора. Бирешмәскә тырышам, тыям әле үземне. Сабыр ит, әллә кая китмәгәндер, мөгаен, трюмо тирәсендәдер. Трюмо өстәлен карыйм. Әниләр, җепләр төрле чүпрәк кисәкләре салынган кәнфит тартмасын күрәм. Көзге юк. Тартмаларын ачып карарга тотындым. Беренчесен ачуга, мең төрле әкәмәт өстенә йомарлап тыгылган лифчик сикереп килеп чыкты. Тизрәк кире ябыйм дисәм, ябылмый. Ничек сыеп торган аңа бу тикле чүп-чар? Ничек җитте алай кире ябып, икенче ящикны тарттым, ачылмый. Юк, бикләнмәгән, просто нәрсәдер өске тартмага эләгеп, җибәрми тора. Иң аскы тартма көч-хәл белән булса да ачылды. Туп-тулы бигуди. Эресе кирәкме, вагымы, әллә тагы меңләп!.. Ул төрле-төрле флаконнар, өреле-ваклы тюбиклар, ирен буявы төпчекләре... Бәласеннән башаяк!..

Инде үземнең нәрсә эзләгәнемне дә онытым. Хәзер мине «тагы ни тамаша күрәм» дигән явыз сорау кызыксындыра башлады. Янга таба ачыла торган кечкенә шкаф кебегенең ишеген тарттым. Ачылуы булды, пачка-пачка кәгазьләр: тегү өлгеләре, «Азат хатын», «Работница», «Мода» журналлары, башлары ертып алынган конвертлар, төргәк-төргәк газета киселмәләре актарылып идәнгә ишелде. Ә эчтә тагы-ы-ын... Утыр да ела! Ничек эче пошмый бу Нәфасәтнең?..

Ачуым да килә, кызганып та куям үзем. Күрәсең, замана модасыннан калышасы килмәгән буладыр инде. Ә бизәнеп-киенеп тә, үз артыннан җыеп та өлгерергә вакыты калмый торгандыр. Бигрәк күп эшләтәләр шул инде хәзер бу яшьләрне дә. Кешечә ял итеп, үзара кунакка йөрешергә дә, җыенлап театрга барырга да вакытлары калмый. Кичтән, эшләрен бетереп, йокыга ята алмый азапланалар, иртән йокыларыннан тора алмый җәфаланалар...

Кире сыйдыра алмый азаплана-азаплана, тагы җен ачуларым кузгалды. Тетеп ташладым кызымны. Заочно булгач, бигрәк тә шәп: эчем бушаганчы әйттем әйтәсе сүзләремне. — Юк инде, — дидем, — вакыт тут не причем. Просто ваемсызлык! Тәртипсезлеккә эче пошмаган кешене аңламыйм, валлаһи! Просто хорасанлык. Шушындый квартирада? Утын кистерәсе иде сездән, мичкә яктырасы иде көн саен ике тапкыр. Ипи салдырасы иде мич төбенә! Су ташытасы иде көянтәләп ике квартал ераклыктагы урам колонкасыннан! Помой түктерәсе иде көненә биш кәрра! Мунча чиратына йөртәсе иде атна саен! Өстәвенә, биш бала үстертәсе иде кимендә. Оек-бияләйләр бәйләтәсе иде үзегездән барсына да! Вакыт, имеш. Дуңгыз, хорасан! Яшьрәк чагында катырак тота алмадым шул үзем дә. Хәзер инде ире... Ире генә дә түгел, хөкүмәт үзе узындыра хатын-кызны. Ирләребез катыншага әйләнеп бетеп бара бит инде...

Шулай эчемне бушатып, бераз тынычлангандай булгач, өстәл янына килеп утырган идем, сүнгән сабын күбеген күреп, тагын күзгем исемә төште. Кырыну дәртем дә, сабын күбеге кебек, сүнгән иде инде.

Менә бит, бер гамьсез җанның тоткан әйберен кире урынына куя белмәве аркасында, нервага никадәр көч төште. Торып-торып ачуым килә. Чыннан да, ужас бит ул алган әйбереңне кире үз урынына куя белмәү! Шундыйлар аркасында әйбер эзләүгә әрәм ителгән минутларны, сәгатьләрне барын бергә җыйсаң, валлаһи әгәр, айларга гына сыеп бетмәс, берничә елга тула торгандыр...

Кайчак күлмәк эзләүгә генә дә күпме гомер китә! Бер минем генәме? Шул ук Нәфасәтнең үзенең? Кияүнең? Кайчы эзләүгә дисеңме, пычак, ачкыч, я берәр документ, рецепт яки адрес эзләүгәме киткән вакыт?

Бер мин генә җәфаланаммыни бу чирдән? Азмыни бездә тоткан әйберен урынына куярга онытучылар? Эзләрнең йөрәгенә бәрәмени шундый борчулар?.. Стрес дигән булалар. Атом гасыры дигән булалар. Фәнни-техник революция! Чынлабрак уйлап карасаң, күп кешеләрнең вакытыннан иртә картаюы да, инфаркт дигәннәре дә шул оешмаганлык бәласедер әле. Ягъни, әйберне үз урынына куя белмәүдән килеп чыккан бәладер. Валлаһидыр дип әйтәм, әгәр миннән сорасалар: «Культуралы кеше булуның беренче шарты нәрсә?» — дисәләр, уйлап та тормас идем:

— Тоткан әйбереңне, кирәге беткәч, кабат үз урынына куя белү! — дип җавап бирер идем...

Кич белән табылды табылуын. Әллә кая китмәгән, шул өстәлдә үк бер читкә алып, яткырып куелган да, өстенә кайсыдыр җүнсезе, мыскыл иткәндәй, «Чаян» журналын куйган икән. Я инде, тәпи бастырып куярга ясалган аяклы күзгене кем яткырып куя ди инде?

## 5. Яхшы аш, яман корсак

Кердем кухняга. Килдем аш өстәле янына. Чәй эчәргә кирәк, тамак туйдырырга. Савыт-сабаның юылмаган килеш калуына сүзем юк. Ә мона алларына алган ризыкны ашап бетермичә, сынык-санак калдыруларына эч поша. Калдырганда да ниндиен калдыралар бит! Итнең, әйтик, иң тәмле җирен — чыкылдап торган майлы кисәген калдырып китәләр. Менә дигән свежий йомырканың яртысы ашалмаган килеш торып кала. Май яккан ак икмәк дисеңме... Калдырсыннар да иде. Хыт соңыннан ашап куя торган булсалар икән. Кая ул! Җирәнәләр. Үзләреннән үзләре бит. Әллә! Шул җирәнү дигән нәрсәне белмәдем үзем. Әни дә шундый иде. Ипи катысы белән аш ашаганда берәребез, барыннан канәгать булмыйча, «бүтәнне бир, бу ипине тычкан кимергән», ди башласа, әни, мәрхүм, әйтер иде: аша, аша, тешең нык булыр, дияр иде. Ашадык, тычкан кимергән дип тә тормадык. Бер җиребез дә кителмәде. Минем яшькә җитеп карагыз әле! Минем кадәр таза, минем кадәр чиста була алырсыз микән? Нигә? Чынлап. Валлаhи дип әйтәм: пенсионер карттан да чиста кеше була микән бу дөньяда?!

Ярый әле, калган ризыкларыгызны, исраф итмичә, үзе белеп ашап куючы атагыз бар. Хәзергә. Тора-бара миңа дә үтми башласа? Гаҗәп түгел. Яхшы аш калганчы, яман корсак ярылсын дип тырыша торгач, соңгы вакытларда үземнең дә карыным аш талымлый башларга итә. Яхшы аш калдыкларын туалетка җибәреп хур булырга туры килмәгәе. Өченче ел бер акыллы уполномоченный табылган иде дә бит, азык-төлек калдыкларын махсус әрҗәгә җыеп, ниндидер терлекләргә озату тәртибе кертелгән иде. Әлеге дә баягы, әйберне үз урынына куярга иренүче кавем эшне бозды: кайсыдыр бер ялкавы азык-төлек әрҗәсенә иске ботинкаларын чыгарып салган, тагы бер дурагы ватык бутылкалар тутырган, подлец! Кемдер, тотарга җирәнеп, әрҗәнең капкачын япмый калдырган. Ә теге төк тузаны өчен минем тетмәмне теткән карчык, ишек янына чебен җыела дип, тавыш күтәрде... Алдылар да киттеләр әрҗәне. Хәзер инде минем кебек картлары яки әнә шундый зәhәр карчыклары булмаган кешеләр доброларын туалетка гына тондыралар. Ходайдан курыкканнары ишегалдындагы чүп кәнтәйнерына чыгарып сала. Алар тирәсенә хәзер чебеннәр генә түгел, бөтен урамдагы хуҗасыз этләр, бернинди эткә бирешми торган усал мәчеләр җыела...

## 6. Чәйгүн капкачыныңмы идеологиягә катнашы юк?

Инде тынычланып чәй эчәргә керешим дисәм, чөй өстенә тукмак дигәндәй, каhәр суккан чәйгүн! Ашарга әзләп тә, әзерләп тә торасы юк иде. Бары да өстәлдә. Тегеләрдән калган булса да, берсеннән-берсе тәмле ризыклар. Гадәтем: калган ризыкны ашап куярга яратам. Гомергә шулай. Теләсә нинди бәйрәм ашының икенче я өченче көнгә калганын яратыбрак ашыйм и ләззәтлерәк күрәм. Әле дә мона кызымнан калган ярты тарелка кукәй тәбәсен бик зур иштиhа белән ялмап куйдым... Чәй...

Ә мона чәй мәсьәләсендә эшләр бүтәнчәрәк. Яратмыйм калган чәйне. Яңа пешкән булсын миңа, кайнар булсын!..

Газга куелган алюмин чәйнегем кайнап та чыккан иде инде. Чәй генә пешерәсе. Куана-куана эшлисе эш иде инде. Куанмыйча! Элекке чәйгүнебез ватылганнан соң, өч ай буе чәйне я стаканда, я кружкада пешереп азапландык. Беркайдан чәйгүн табар хәл булмады. Бары

кичә генә Нәфасәткә бер танышы әллә БАМдан, әллә Сахалиннан алып кайтып биргән. Шундый сагынып көтеп алган фаянс чәйгүн! Чәчкәле-чәчкәле! Бөтен шартын китереп, рәхәтен күрергә әзерләнәм. Иң элек тегеләрдән калып суынган чәйне түгим дә, аннары кайнар су белән чайкап, җылытып алырмын дип, тансык чәйгүнне кулыма алдым. Капкачына үрелсәм... Бу ни хикмәт? Чемәкәеннән тотып алмакчы булам, чемәкәе юк. Чемәкәй урынында төптән юан чыгып, өскә таба очлаеп килгән шоп-шома бер нәрсә сөрәеп тора. Капкач тоткасы, имеш! Тотып алмакчы булам — бармак арасыннан шуа да чыга, шуа да чыга. Прәме мыскыл иткән төсле. Шушындый тоткычны кем уйлап чыгарган диген! Үзенчә, моңарчы булган капкачларга охшамасын дигән булган, күрәсең, мәгънәсез нәрсә. Яңалык кертә, янәсе! Ачып кына булмый бит. Ике бармак белән тотып карыйм — юк, өч бармак белән тотып карыйм — юк, биш бармак очы белән кысып тотып карыйм — юк! Шуа да чыга, шуа да чыга... Азаплана торгач, ачтым ачуын. Анда да тотып ачар өчен ясалган очлы нәмәстәкәеннән тотып түгел, сүгенә-сүгенә, пычак очы белән читеннән каерып ачтым. Тәмам чәйнең тәмен җибәрде. Ник шундый мәгънәсез әйберне чыгара икән бу фабрикалар? Үзләренчә, матуррак итик дип, товарыбыз үтемлерәк күренсен дип тырышкан булулары микән, әллә, чәйгүнгә кытлык чорында ничек тә үтәр дип, шаляй-валяй гына эшлиләр микән? Эх, шул чәйгүн төбенә авторының, ягъни шундый фасунны уйлап табып тәкъдим иткән кешенең фамилиясен язып чыгарган булсалар!.. Нигә бездә шундый практика юк? Телевизорда пустяк кенә фильм күрсәтсәләр дә, шуны иҗат итүчеләр дип, азагына кырыклап фамилия тагып чыгаралар. Китаплар турында әйтсәң дә түгел. Әле автор өстенә тагын кемнәрнең генә исем-фамилияләрен күрсәтмиләр? Юк кына открыткада рәсем ясаучы художникның, хәтта фотографның фамилиясе була. Әйтерсең инде өч тиенлек сурәт шул кадәр җаваплы эш! Ә менә аларга караганда мең кәрра кирәгрәк, мең кәрра популяррак булган киң куллану товарлары дисәң — торганы обезличка. Кайсын гына алып карасаң да — кемнең дә булса иҗат җимеше бит алар. Аларның да була шедеврлары, була алып кайткан көнне үк чүплеккә чыгарып ташлый торган халтуралары. Ярый, көнкүрештә кулланыла торган мең төрле вак-төякнең һәркайсының өстенә фамилия язып чыгарырга мөмкин дә булмасын, ди. Ә бит нинди генә вак-төякне махсус тартмага салып, янына табак-табак инструкциясен дә куеп чыгармыйлар? Сабый бала өчен дә көн кебек ачык булган техника кисәген тәфсилләп-тәфсилләп ничек кулланырга өйрәтәләр. Ә шунда авторын да күрсәтергә урын табылмас идемени? Табылса, начар булыр идемени? Болай бит, яхшы әйбер өчен кемгә рәхмәт әйтергә белмисең, халтура өчен кемгә ләгънәт яудырырга. Шуннан китә беркатлы кешеләр арасында сәвиткә тел тидерү. Әтәч тиресеннән тегелгән импорт итекләрне үлә-үлә ала хатын-кызларыбыз. Үзебездә эшләнгән чәмчәле читекләр утыра моңаеп. Шулай эндәшмичә генә тик утыра дип беләсезме сез аларны? Юк, тик утырмыйлар алар. Безнең осталыкларыбызның яманатын сатып утыралар. Кем файдасына бу? Кем әйтә аны чәйгүн капкачының идеологиягә катнашы юк дип?

## 7. Караватмечта

Кердем тегеләрнең йокы булмасенә. Нигә кирәк булды — оныттым. Шул чәйгүн капкачыннан кузгалган ачуым басылып җитмәү сәбәпле, абайламый калганмын: аркылы куелган карават башына бот төбемне бәрдем. Кызурак та барганмын, күрәсең, авыртуы бәгырыгә төште. Шуңа бәрелгән саен котырып ачуым кабара. Иң баш-

та үземә ачуланам. Шуны онытуым, саксызлыгым өчен. Сукыр шайтан, дим, тавык мие эчкән карт пәри, дим, беренче бәрелүең түгел бит, карабрак йөрергә булмыймыни?.. Әмма үземне генә гаепләп каласым килми. Чынлап та, нигә бу кадәр сүлпән эшли безнең рационализаторлар? Кәшфият җитми! Менә шушы караватны гына алып кара. Озынлыгы почти ике метр. Карават куйган урын — ишектән уң як стенага кадәр булган ара — метр туксан. Ә кияүнең буе — метр җитмеш. Димәк, караватны җигерме сантиметрга кыскартсаң, шул урынга әйбәт кенә кереп утырыр иде, башы ишек турысына чыгып тормас, уйлап та тормыйча, җен шикелле дуамал йөргәндә дә берничнди бәрелү куркынычы булмас иде. Нигә шул турыда уйламый карават ясаучылар. Ә уйларга кирәк иде. Фараз итик: теләгән вакытта ансат кына озайтып, ансат кына кыскартып була торган карават ясасалар? Хәзерге техника өчен моның ни кыенлыгы булсын? Озыная-кыскара гына түгел, тарая-киңәя торган итеп тә мөмкин бит. Нигә? Бүлмәңдәге урынга и үзеңнең буеңа чамалап, кыскарттың куйдың. Яки әле яшь чагың, ди. Хатының да юк, аерым квартираң да. Бер генә бүлмәдә торасың. Өйләндең, ди. Ике караватлык урының да, акчаң да юк. Булган караватыңны биш кенә сантиметрга киңәйтеп җибәрдең — и мәсьәлә хәл кылынды. Олыгая килә тагын киңәйтә төш!.. Яки балалар. Бер балага бит бездә үсеп җиткәнче өч-дүрт карават алыштырырга туры килә. Ә мин әйткән карават булса? Үскән саен озайта барасың, кирәк икән, киңәйтә дә бар. Гаҗәп булыр иде, ә? Бигрәк тә безнең замандагы малогабариткалар өчен, ә? Караватмечта! Неужели безнең мебель осталарының берсенең дә башына килми икән шундый гади идея? Бүләк алыр иде бит... Юк, ялкау эшли безнең рационализаторларның башлары, начар.

## 8. Буламыни семья иске-москысыз?

Бар бер караңгы бүлмәбез. Үзем белгәннән бирле артымнан калмый килгән борынгы сандык тора анда. Сандыктан соң модага кереп, инде үзе дә күптән модадан чыккан комод та шунда. Эчләренә тулып онытылган иске-москы арасыннан тегене-моны актарып алыйм дисәң, иң элек ул комод белән сандыкның үзләрен эзләп табарга кирәк: эреле-ваклы катыргы тартмалар, посылкадан бушаган фанер әрҗәләр, таяклары белән бергә бәйләп куелган чаңгылар, төрле упаковкалардан сүтеп алынган кытыршы агачлар, озынлы-кыскалы такта башлары, тагы шунда әллә нинди төенчекләр кәрҗиннәр астында күмелеп калганнар. Ни генә юк ул сандыкта? Ни генә юк ул комод тартмаларында? Табып алырга кирәк миңа хәзер шулар арасыннан ике-өч пар туфли и алып барырга үзләрен мастерскойга, төзәттереп алып кайтырга. Көз җиткән әнә календарьда, көннәр җылы булу белән генә пока беленми тора урамда.

Табылыр ботинкалары, аларына исем китми. Эчемне пошырганы бүтән: ничаклы байлык, ничаклы кием әрәм ята шул сандыкта, шул комод тартмаларында!..

— Ник чүплеккә чыгарып атмыйсыз? — диләр.

— Әйе шул, — дим кайчак үзем дә. — Утыз елдан артык яткан әйберләр бар бит анда. Бер кирәкләре чыкканы юк. Ташлыйм к чорту бөтенесен! — И, ярсып китеп, тотынып караганым да бар. Тик булмый, кул бармый. Ничек барсын? Ямау күрмәгән генә түгел, хәтта сүтеге дә булмаган, хәтта бер генә төймәсе дә төшмәгән драп пальтолар бар бит алар арасында! Җоннан-җефәктән генә беткән хатынкыз күлмәкләре! Плащлар, курткалар, менә дигән трико яки креп чалбарлар, пинҗәкләр!..

Ничек чыгарып ташламак кирәк шундый байлыкны? Көфранәнигъмәт кылу булыр иде бу, борынгыча әйтсәк. Ягъни барлыкның кадерен белмәү, ризыкны аяк астына салып таптау кебек гөнаһ эш булыр иде.

Ташламасаң, кая куясың? Беркемгә биреп булмый аларны хәзер. Сатып түгел, бушка да. Ел саен яңа иске-москы өстәлә генә бара. Рәхәт булган элек байларның эше. Тузган киемнәрен биреп, рәхмәт ишеткәннәр, фәкыйрь-фокра арасында изге кеше булып күренгәннәр. Биреп кара син хәзер үзең кими торган киемеңне берәрсенә! Ишетерсең ишетмәгәнеңне. Дворник хатынга ымлап кына карарга чамалаган идем. Үзенә дип тә түгел, таныш-белеше арасында берәр мохтаҗ кеше табылмасмы дип кенә. Ник авыз ачканыма үкендем. Исәнләшергә дә теләми хәзер. Могтәбәр кешене мыскыл итүче булып калдым. Чүпрәкче дигәне дә юк бит аның хәзер. Ничек мыжымыйсың. Неужели шул кадәр доброны беркая да тапшырып булмый?!

Ярар, алмыйлар икән, үзебездә калсын. Ашарга сорамыйлар, кияү әйтмешли. Әйе, шулай ди кияү, яшь булса да. Кызны әйтмим. Анысы кичә алган кулмәген бүген чүплеккә чыгарып ташларга әзер — берәр җирен яратмаса. Алай булмый бит. Кием-салымы дисеңме, агач-богачлары дисеңме, тартма-әрҗә кебекләрен әйтәсеңме, — иртәгә, иртәгә булмаса, бер елдан, бер елдан булмаса, ун елдан кирәк булып чыгуы ихтимал түгелмени? Үз гомеремдә биш сугыш кичергән бу баш!..

Сугыш димәктән... Шул иске-москы арасында фашист кыйпылчыгы тиеп җиңе ертылган шинелем ята. Тир белән тозланып, мәңге черемәс сыйфатка кергән гимнастеркам бар. Нигә мин аларны чыгарып ташлыйм?

Шулай булгач! Нигә безнең ишегалларында келәт кебекләребез юк? Яки сарай? Пусть подвал булсын. Ичмасам, пичә генә дә юк бит аның хәзер, кирәкмәгән чүп-чарны яндырып котылырга!.. Буламыни семья артык-портыксыз? Буламыни семья иске-москысыз? Иске-москы дигәнең арасында яңадан кадерле затлар булмыймы? Өр-яңа тарих саклана иске-москы арасында, беләсегез килсә!

## 9. Егет диген инде!

Чыктым урамга. Сразы кәеф бозылды. Килә бөтен дөньяның ямен җибәреп мотоцикл, дөмеккере. Урамыбыз шундый әйбәт, тыныч иде. Җәй буе яшеллеккә күмелеп утыра, һавасы сулап туйгысыз иде. Бигрәк тә җәен юкә чәчәк аткан чакларда, кышын йомшак кына кар явып торган көннәрдә. Тик урам ташларының гына, патша заманыннан калган килеш үзгәртелмәгәнгә, кerдeле-чыктылы, чокырлы-чакырлы булулары эчне пошыра да, тротуарыбызның җәйләрен пычрак, кышларын тигезсез, тайгак булуы ачуны китерә иде. Эх, тоташ асфальт җәеп җибәрелсә! — дип хыяллана идек. Кая ул! Буламы соң! Шәһәр өчен магистраль әһәмияте булмаган, читтән килгән кунаклар күзенә чалынмый торган мондый аулак урамнарга кадәр асфальт җиткереп буламы соң!..

Юкка өметсезләнгәнбез. Сизми дә калдык: бер җәйне ялдан кайтуыбызга — урамыбыз тоташ асфальт! Тротуар белән урта юл араларында ямь-яшел бакча үләне. Корыган, картайган агачлар урынына яшь юкәләр утыртылган. Урыны-урыны белән аллы-гөлле кашкарилар, хуш исле тәмәкеләр, пигамбәр тырнаклары чәчәк атып утыра. Сабый балалар кебек шатланышкан идек. Хәзер инде мона... Бүтәннәр ничектер, ә мин, ник җәйделәр бу асфальтны безнең урам-

га дип, уфтанып йөрим. Машиналар күреп алды такыр урамны. Хәтта бер автобус, яңа рейс табып, безнең урам буйлап уза башлады. Бердән, тавыш, икенчедән, газ исе, янган бензин исе. Җитмәсә, машиналардан бушаганрак сәгатьләрдә яшь-җилкенчәк шушы урамга чыгып, мотоциклда йөрергә өйрәнә...

Әнә бит, әнә! Күзе тонган нәрсә! Кая оча шул кадәр тизлек белән, муены астына килгере. Кая үкертә шул кадәр?! Тфү, кыяфәте үзенең! Егет диген инде! Чәче генә ни тора! Кызлардан ни аермасы бар? Күлмәген кара инде. Чуклы-чәчәкле хатын-кыз кофтасы ич инде бу! Хәтта чыраена ук чыккан. Валлаһи, килешми мондый чибәрлек ир-атка. Кай җиреннән чыга диген мондый лихачлык! Кара, ничек борылды... Ә-ә, икенче тилесе килә икән каршына. Бусы тагы мыек үстергән булган. Башындагы җирән пумаласы өстенә! Бигрәк шыксыз. Нәкъ поп. Авызын ничек җырган!.. Очрашкан булдылар. Чү!.. Нәрсә ди? Линиза? Линиза икән шул матур чырайлысы, чәрелдәп тора. «Нихэл, Роберт», диме?.. Чыркылдап көлеп тә җибәрде. Тфү! Кыз диген инде шуны! Чалбар киеп, ботын-чатын аерып, мотоциклга атланып йөрмәсә, айгыр-ашак! Русча сөйләшкән булалар тагын. Икесе дә чыкылдап торган татар бит инде. Исемнәре әйтеп тора: Линиза да Роберт.

## 10. Трамвай фәлсәфәсе

Килеп бастым трамвай тукталышына. Көтәм, күренми килгәне. Күренмәсен, бик әйбәт. Әзрәк ял итә торам... Күренде. Күренсен, бик әйбәт. Озак көтеп вакыт әрәм итмим, димәк. Килеп туктады арткы ишеге борын төбемә. Янымда кеше юк диярлек. Алгы ишек янында гына икәүме-өчәүме селкенә. Яшь башлары белән нигә инде аларга алгы ишеккә тыкшынырга? Монда да чират юк ич! Ашыкмый гына кереп утырам дип, көтәм ишек ачылуын. Ачылмый. Эч яктан арткы ишек каршына җыелган пассажирлар алга таба киттеләр. Пыяла үтәли иреннәре кыймылдаганы күренә, тавышлары ишетелми. Ачуланалар булса кирәк. Димәк, берәм-берәм тикшереп чыгаралар: билетсыз кешеләр юкмы? Булса — штраф! Йөрмә бушлай. Сиңа ышаныч күрсәтеп, кондукторсыз вагон биргәннәр. Ә син! Жулик! Ничек оялмыйсың хөкүмәтне алдарга? Түлә шуның өчен штраф!

Кызык килеп чыга бит, уйлап карасаң. Ни дигән сүз соң ул — кондукторсыз вагон? Димәк, безнең аң-культура ягыбыз шул дәрәҗәгә җитте ки, һәркем билетны үзе белеп ала. Арада берән-сәрән аңсыз кешеләр табыла икән, аңардан гына бөлерлек түгел хуҗалыгыбыз. Тора-бара андыйлар да бетәр. Шундый ышаныч, ягъни кешегә булган олы хөрмәт каршында оятларына көч килер дә, үзләре белеп билет алырга саранланмый башларлар... Әйбәт! Коммунизм җәмгыятенә кереп баручыларга хас матур гадәт яралгысы. Вакытында шулай дип газетага да яздылар. Бер генә тапкыр да түгел. Мин күргәне генә дә биш-алтыга туладыр... Ә ишек һаман ачылмый. Монысы инде, белмим, бик үк... Хәер, сабыр ит, чыгасы кешеләр контролер аркылы үтеп бетсен. Ачарлар... Ләкин... Ләкин сабырын сабыр да, болай да бик ашыкмый торган шәһәр транспортын ясалма рәвештә тоткарлау килеп чыга түгелме соң?.. Әнә ич, ишек һаман ачылмый. Төшеп тә беттеләр кебек. Алгы ишек янында торганнар керә дә башлады. Чү! Кузгалып та китте түгелме соң? Китте шул. Менә сиңа мә! Менә сиңа сабыр төбе сары алтын! Бусы инде гадәттән тыш! Ачыктан-ачык мыскыллау ич инде бу пассажирны! Әле болай ук булмаганда да өнәп бетерми идем кондукторсыз

вагоннарны. Кешегә хөрмәт күрсәтү билгесе сыйфатында гамәлгә кертелгән чара, вагон эчендә бармы-юкмы икәнлеге дә билгеле булмаган бер-ике «ата куян» өчен, дистәләрчә намуслы пассажирларны мыскыллауга әверелә бит. Хәтта кайчакны гомереңдә бер мәртәбә трамвайга утырган гөнаһсыз кешене, автомат авызына каптырырга өч тиен вак таба алмыйча, билет алырга зар булып баруы өчен штраф түләтеп хур итәләр. Юк, яратмыйм мондый кондукторсыз вагонны. Әлегә берәү-икәү генә булса да сакланып калган кондукторлы вагонга барып керсәм, җаным рәхәтләнеп, тыннарым иркенәеп китә.

## II. Табигать сере

Алдатмадым, чираттагы вагон килеп тукталуга, алгы ишек каршына барып бастым. Мине мыскыллауда дәвам иткән шикелле, бу юлы алгы ишек белән бергә үк арткысын да ачтылар. Өстәвенә, төшүчеләр дә булмады диярлек. Алдан да, арттан да. Эчтә дә кеше артык күп түгел. Шулай да утырырга бер генә буш урын да юк. Анысына да исем китмәде. Киръәкле остановкага кадәр аяк өсте узарлык хәлем бар, аллага шөкер! Кинәт... Ни дип әйтим... Әйтергә дә оят минем яшьтәге бабайга. Кыскасы: төште күзем бер чибәр кызга. Утырып бара бу сул яклап тезелгән ялгызлы урыннарның берсендә. Булса да булыр икән шул кадәр гүзәллек! Валлаһи дип әйтәм, егет чагымда да очратканым булмады мондый чибәрне. Хәер, олыгайган саен матур кызлар күбрәк күренә башлый, ахрысы, иратка. Чын. Без яшь чакта, мәсәлән, хәзерге шикелле матур кызлар бар иде микән? Акыл әйтә: булгандыр, ди. Яшьлек белән генә кадерен белмәгәнбездер, ди. Ә бу! Я хода! Әйтмәс җиреңнән әйтерсең. Ходайсыз булсаң да бүтән сүз таба алмассың. Ул нәфислек! Ул гөнаһсыз күзләр! Хәтта өстенә кигән нейлон курткасы белән киң балаклы чалбары да боза алмый аның гүзәллеген. Ул тузылып төшкән коңгырт-кара чәче тагын! Бары да килешеп тора үзенә. Бу табигатьнең серен мәңге аңлап бетә торган түгел. Шундый гүзәллекне яраткан икән, бик әйбәт. Ә мине рәнҗетү нигә кирәк? Ичмасам, күңелеңдәген сиздерерлек итеп, йөзенә карарга да тулы хакың юк. Шулай булгач? Нигә аның шундый бәгырь өзгеч матурлыгын минем күңел күземә күрсәтеп, йөрәгемне җилкендерә ул? Табигатьне әйтәм. Нигә карт кешене болай мыскыл итә?..

Үзенә сиздермәскә тырышып кына тагын бу гүзәл табигать серенә күз салып алам... Күңелемә көфер уйлар килә башлый. Әллә табигать гаепле түгелме? Кешеләр үзләре табигатькә хилаф кануннар уйлап чыгарамы? Күңелемнең әллә кай җирендә шундый нечкә, матур хис уяна ала икән, нигә үзеңне болай кимсетергә? Нигә ул ләззәтле хистән мәхрүм итәргә үзеңне? Булган бит шундый заманнар. Я байлык белән кызыктырып, я куркытып булса да миннән карт кешеләр менә шундый гүзәлләргә хуҗа булганнар. Хәзер дә бар андый илләр. Хәтта безнең илдә дә юк түгел шундый фактлар. Язалар бит, карт галимгә үзе кияүгә чыккан япь-яшь кызлар турында. Дөрес, мыскыл итеп, көлеп язалар. Чынлап та көлке хәлдер инде. Ә бәлки көлке дә түгелдер... Ниндидер могҗиза булып, шушы гүзәлнең миңа күңеле төшсә?.. Фу, әнә нинди мәгънәсез уйлар килә бит җүләр башка. Үзенә сиздермичә генә, яшьлегенә, гүзәллегенә сокланып карап барсам, шунысы да җиткән миңа... Анысын да кызганды мәкерле табигать: кыз үзенә игътибар итүемне сизеп алды. Капыл оялып, кызарып киткәндәй булды. Урыныннан сикереп торды.

— Утырыгыз, бабай, — диде. Минем аптырап, икеләнеп торуымны күреп, өстәп тә куйды: — Гафу итегез, мин сезне күрми килгәнмен...

Минем аңа сокланып каравымны үзенчә юрап, урын бирмәгән өчен аны битәрләвем дип кабул иткән икән, мәнсез кыз! Ичмасам, остановкага җиткәнче урыныннан кузгалмый утырган булса, нинди матур тойгы белән төшеп китәсе идем бит трамвайдан. Юк, аңламый хәзерге яшьләр олы кешенең күңелен, аңламыйлар. Рәхимсез алар.

## 12. Бер тиен

Тукталдым китап киоскасына. Тукталмас идем, бүтәннәр туктый. Ябырылып алалар ниндидер китапны. Басыйм чиратка, кеше белми алмыйдыр. Үзем булмаса, тегеләр карар. Алдым. Бәясе илле тугыз тиен. Тоттырдым сатучыга өч җигермелек. Кайтарып бирергә бер тиенлек вагы юк икән, булгач алырсыз, ди, көтеп торыгыз... Көтми ни! Мин гомумени анда алтмыш тиен түләүчеләр? Киттем. Карыйм, нинди китап алганмын икән? «Особая папка Барбаросса» дигән. Ләкин мине аның исеме түгел, хәтта эчтәлеге дә түгел, бәясе кызыксындырды. Кыйбатлыгы яки арзанлыгы түгел, нәкъ менә илле тугыз тиен булуы.

Мин үзем болай финансист та, экономист та түгел. Әйбер бәяләрен билгеләүнең, әлбәттә, үзенең фәнни нигезләре бардыр. Мәгәр кара акыл белән исәпләгәндә дә күренеп тора — нигә шуны алтмыш тиен итеп куймаганнар? Ә болай... Кем инде бер тиен здача көтеп тора? Хәтта сатучы «мә» дип, өстәлгә чыгарып салса да, ул бер тиенне күп кеше алып тормый. Үзем дә шулай итәм: янәсе, нигә мин ваксынып, аны алып торыйм? Бер тиенгә калган көнем юк, аллага шөкер! Димәк, сатучы ул бер тиенне теләсә дә, теләмәсә дә үзенә алып калырга мәҗбүр.

Тиражына күз салыйк: «өстәмә тираж — 250000» дип куелган. Тәңкәгә әйләндереп карасаң, ике йөз илле мең данә берәр тиенлек күпме була? Ике мең ярым дигән сүзме? Сатучының да, алучының да саф күңелен боза-боза теләсә кем кулына таралып беткәнче, инкассатор сумкасына керсә, дәүләт кесәсен тишәр идемени ул ике мең ярым? «Өстәмә тираж» дигән сүзе дә бар бит әле аның! Төп тиражын да кушып санасаң, ничә меңгә тула торгандыр? Әзме бездә сиксән тугыз тиенлек, туксан тугыз тиенлек яки бер сум туксан тугыз тиенлек и так дали товарлар?.. Неужели мин шул кадәр дурак икән? Әллә мин түгелме дурак?

## 13. Кем җилкәсен кимерә?

Узып барам алтын-көмеш товарлары сата торган «Яхонт» магазины яныннан. Бер кыз чыгып килә магазиннан, икенчесе кереп бара. Танышлар икән, очраштылар магазин ишеге төбендә. Киемнәрен әйтеп тормыйм. Ялангач ботларга да, аршин ярымлы керфекләргә дә, ак иреннәргә, кызыл чәчләргә дә күз ияләшеп беткән. Сүләшкән сүзләре колагыма чалынды.

— Ой, Ася! — диде кереп бара торганы. Шундый исе китеп әйткән була аны, биш ел күрешмәгәннәр диярсең.

Чыгып килә торганы аннан да уздырырга тырыша. Бөтен урамга ишетелерлек итеп кычкырып җибәрә.

— С-о-о-ня! Кая болай?

Җавап кайтарып тормый тегесе, сорау гына бирә.

— Нәрсә бар магазинда?

— Чүп тә юк.

— Йөзек бар дигәннәр иде, күрдеңме?
— Сиксән биш сумлыклары гына калган.
— Ленин районында бар ди йөз сиксән сумлыклары, әйдә киттек!
— Ой, бетермәделәр микән? Әйдә!.. Такси!..
Киттеләр дә бардылар. Сиксән биш сумлыклары гына дигәч, арзанлыраклары беткәнгә борчылалар дип торам, ә алар... Кем җилкәсен кимерә болар? Әтиләренекенме, ирләренекенме? Неужели үзләре таба?

## 14. Утыр әле яннарыма

Арылды бер заман. Кайтып җитәргә шактый. Беләсез Казан урамнарын: тау төшәсе дә тау менәсе. Ял итәргә иде берсәк утырып. Кая китте соң бу эскәмияләр? Бар иде бит, әле мин белгәндә генә бик күп өй буйларында юк дигәндә ике-өч кеше утырып ял итәрлек такта эскәмия була иде. Кайбер урамнарда хәтта капка төбе саен бар иде эскәмия. Прәме Кисловодск терренкурларындагы кебек. Тыны кыскан, я тез буыннары какшаган карт-коры гына түгел, кичләрен парлашып гуляйткә чыккан яшь гашыйкларга да ярап кала иде. Утыралар иде урамнарга ямь биреп, күгәрченнәр кебек гөрләшеп. Кая китте ул эскәмияләр? Ягып бетерделәрме сугыш елларында. Алай дисәң, сугыштан соң да бар иде әле. Хәтеремдә. Хәтта күп иде. Неужели орлап бетерделәр?.. Ни карый бу исполком? Әллә үзләре берәр карар чыгардымы тротуарларны артык-портык эскәмия-мазарлардан чистарту турында? Булыр яшь түрәләрдән, үзләренең аяк авыртмый пока. Йөрәкләр дә таза. Әллә машинага утырып беттеме бары да? Алай дисәң... Әнә ич, урам тулы пешеход. Ярар, урамда булмасын да ди. Иркен булсын ди тротуар. Ә трамвай тукталышларында? Базардан кайтучы хатын-кызга гына булса да ярап куймас идемени? Үзе утырмаса (әйтик, пальтосын кызганып), бәрәңге белән тулы сумкасын куеп тормас идемени?.. Ә минем кебекләр?.. Уф, атлар хәлем калмады. Нишләргә?.. Җитмәсә, шунда, мыскыл иткән төсле, кайдагыдыр радиодан җыр ишетелә:

Утыр әле яннарыма...

Кая утырырга? Чүп тутырылган урна өстенә утырып булмый бит!.. Ап-аек баштан, урам стенасына арка терәп, юеш тротуарга да утырып булмый...

## 15. Әп-чехи!

Әһә, булды! Җан биргәнгә юнь бирә бит. Ашыгыч ремонт дигәнме? Какрас сыңар туфлинең үкчәсе чалшайган. Турайтып бирсеннәр әле...
И нәкъ мин уйлаганча барып чыкты.
— Хәзер эшләп бирәбез! — диделәр.
Турайтулары ничек булыр, мәгәр «утырып торыгыз» дигюләре күңелгә хуш килде. Утырам җәелеп ярым йомшак кәнәфидә. Өстәвенә, оекчан. Пальто төймәләрен җибәрдем ычкындырып, җаннар иркенәеп китте. Рәхәт! Озаграк төзәтсәләр дә сүзем юк. Утырам оҗмахка кергән кебек. Күңел ышанмый. Нәрсә бу? Әллә чынмы? Күргәнем юк, ишеткәнем бар иде — биш-ун минут эчендә төзәтеп бирәләр, дип, кыйбат та алмыйлар, дип. Неужели шул үкчәне тиз генә әдәм рәтенә

кертеп бирерләр? Ай-һай... Мин үзем дә заманында аяк киемнәре артелендә эшләмәгән кеше түгел, беләм: андый үкчәне эшкә кертү өчен кимендә ун көн срок куя торган идек... И берсен генә срогына өлгерткәнебезне хәтерләмим. Шунысы истә: көн саен җигермешәр кеше килеп тиргәп китә иде үзебезне...

Рәхә-ә-ә-т!.. Ай, әгәр бу салкын җил дә өрмәсә!.. Тукта, кайдан өрә соң? Ә-ә-ә, күрерсең рәхәт артына кулы җитми торган мәнсез халык белән! Берсе ишекне ачык калдырып чыгып киткән. Тышта йөргәндә сизелмәсә дә, җылы өй эчендә утырганда бик беленә салкын җил, хәзер бәреп алыр. Кыен булса да, оекчан аяк белән салкын идәнгә басып, ишекне ябып килдем. Утырырга өлгермәдем, тагын өрә. Тагын бер мәнсезе ачык калдырган. Тагы торып яптым. Ул арада тагын...

Рәхмәт инде, бер миңа гына димәгән, ябарлар әле. Тормыйм бүтән... Юк, япмыйлар. Неужели миңа гына өрә? Аптырагач, ишектән чыгучы берәүгә кычкырдым:

— Ябып чык!

Япты ябуын. Инде тыш яктан керүчесе ачык калдырды. Нервыма түзә алмый, аңа кычкырдым:

— Яп!

Ничә рәт кычкырганмындыр, китте покой. Кычкырган саен нервы бозыла бара... Мастерской диген инде! Шушындый шәп яңа йорт. Шундый техника. Ә шул хәсрәт ишекне үзеннән-үзе ябыла торган итеп эшләргә кулларыннан килми. Килер иде, ваем дигән нәрсә җитми...

Ул арада туфлиемне чыгарып та бирделәр.

Өйгә кайтып, тынычлангач кына игътибар иттем: өр-яңа иткәннәр шул ташлар чиккә җиткән туфлине. Ни арада диген? Вакытында куанырга да, рәхмәт әйтергә күңелгә килмәгән. Күпме алдылар диген? Әллә ун тиен шунда, әллә унбиш. Буш инде, буш! Анысына да куанырга онытылган... Әһ-әһ... әп-чехи! Әнә... Куанырсың! Шул ябылмый торган ишек аркасында... Чынлап та, шундый безобразиегә, шундый ваемсызлыкка ничек түзеп торырга кирәк?

## 16. Кем тәрбияли баланы?

Тоташтырдым радионы. Әллә зурлар өчен балалар турында сүли, әллә наоборот. Ничек ашатырга кирәк баланы, ничек киендерергә. Укысын өчен дә, уйнасын өчен дә аңа нинди шартлар тудырырга. Гади генә итеп әйткәндә: ничек итеп аны, эшем иясен, өрмәгән җиргә утыртмаска! Принцлар турында да бу кадәр кайгыртмаганнардыр, билләһи!.. Сигезенче класста укучы бер малайны мактауларын кара! Әнисенә карышмыйча идән себергән, имеш. Чүп чиләген чыгарып түккән! Герой!.. Без аның кебек чакта... Ә берсе әнә начар укый, имеш. Икешәр ел бер класста утыра, укытучыларын да санга сукмый, ата-аналарын да. Дәрес сәгатьләрендә әллә кайларда хулиганит итеп йөри, хәтта орлаша... Ләкин моңа, имеш, малай үзе гаепле түгел, укытучылары, ата-аналары гаепле...

Җитте, ычкындырдым...

Булмас дип әйтмим, бардыр. Дөнья булгач, андыйлары да булыр, хужыраклары да. Шунысын аңламыйм: нигә баланы культка әйләндерәбез? Культка әйләндеме — баламы ул, өлкән абыймы — аңарга карата кешедә чын мәхәббәт бетте дигән сүз. Валлаһи әгәр! Мин үзем нинди бала ярата торган кеше. Ә менә бала турында артык төчеләнеп сөйләгән сүзләрне ишеткән саен, аны бәләкәй алла урынына

куеп, аңа табынып язылган мәкаләләрне укыган саен, балага булган мәхәббәтем кими бара. Алай гына булса бер хәл иде, нәфрәт тудыра балага миндә андый аристократ кайгыртучылар...

Әйтеп бирер идем үземне микрофон алдына чакырсалар. Кем тәрбияли баланы барыннан да күбрәк? Ата-анасымы?—түгел. Укытучылармы? — түгел. Бала тәрбияли баланы, beлэсегез килсә!

## 17. Җырның ертыгы бар

Тыңлыйсым килде концерт. Тагы радионы тоташтырдым. Әһә! Бик шәп. «Урман кызы?» Яраткан көем. Җырчысы да таныш кебек. Тукта, кем әле бу?..

Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
Керфек очларыннан та-ма-ла-а-ар.

— Тамалар?!

Ычкындырдым. Таммый торсын әле!.. Такташ бит «Тамалар» дип язмаган. Бик яхшы беләм, үз авызыннан ишеткән кеше мин Такташны. Өстәвенә, китабыннан да укыганым бар. «Агалар» дип язган бит. «Тамалар» дияргә, графоман түгел бит ул. Керфек очыннан тамчылап тамган нинди көч була ул шагыйрьгә илһам бирерлек? Ничек шуны аңламый җырчы? Ничек редактор дигәне юл куя моңа? Мәрхүм шагыйрьнең поклонниклары ничек түзеп тора диген сутка бирмичә?..

Тукта, ичмасам, берәр әйбәт җыр ишетеп, күңелем тынычланмасмы? Тагы тоташтырып карыйм. Тоташтырдым.

...Чыгып киттем чарасыз.
Күрер күзгә берни түгел,
Чибәрлеккә чамасыз...

Ычкындырдым. Логика диген инде! Күрер күзгә берни торырлык булмагач, ничек итеп чибәр булсын ул мескен? Хөрмәт итмисең икән халык җырын, келәмисең икән аны дөрес җырларга, үз зауkыңа туры китереп, ачыктан-ачык әйт тә бир:

Күрер күзгә дуңгыз төсле,
Чибәрлеккә чамасыз,

— диген. Көләрбез бер рәхәтләнеп. Җырның ертыгы юк дигәч тә... Бар аны ертучылар...

## Сүз азагы

Җитеп торыр. Фамилиясен белмәсәк тә, мыжык картның кем икәнен белдек шикелле. Язмалары басылганны күргәч, бәлки үзе дә килеп чыгар әле. Килмәсә дә үпкәләмәс...

## Вахит Монасыйпов

# ШАТЛЫКЛЫ КАЙГЫ

хикәя



...Иэнекәш, син сорама — мин әйтмим... Заманалар үзгәрде, заманалар... Ә заманаларга ияреп балалар үзгәрде. Хәзер инде безнең ише старый гвардиягә көн бетә башлады, көн... Әллә ни кырып булмый шул. Эшемнән шудырмагайлары, шуннан шүрлим... Юк, юк, мәктәп директоры белән ара безнең шәп, башка укытучылар белән дә борчак пешә минем... Үзең беләсең, унике ел рәттән Ялгыз Нарат мәктәбендә хезмәт дәресләре алып барам, шул дәвер эчендә өстемнән бер генә жалу кәгазе килгәне юк. Алай да отставкага чыкмыйча булмас, эш шуңа бара.

Ник аптырап калдың әле? Әйтеп торам ич: бала-чага көн бирми, дип. Тикмәгә генә «бала чага!» димәгәннәр, чага шул, шөпшә урынына чага, түзәр хәл калмый кайчак... Үзең уйлап кара. Элегрәк безнең мәктәптә шундый тәртип иде. Әйтик, берәр класста парта ватыла икән, туп-туры мине чакырырга киләләр иде: «Искәндәр абый! Әйдә, срочно!» Коридорда идән тактасы кубып чыга икән — «Искәндәр абый, срочно!» Тәрәзә өлгесе ватыламы — «Искәндәр абый, срочно!» Кыскасы, миннән башка бер эш тә көйләнми иде ул заманда. Ә менә соңгы елларда эш кирегә борылды да китте... Хәйран булам. Күз алдында үзгәрде балалар. Хәзерге заман баласы туганда ук җиде класс бетереп туа, диләр.

Кем әле... Исемен онытып торам... Әһә, Галәветдин! Җиденчедә укый. Шайтан алгыры малай! Ут борчасы инде менә. Каян гына белеп бетергән диген бөтен эшнең җаен. Нәселләрендә — ни атасы, ни бабасы — агач-тимер эшләрендә булганнары юк. Бабасы итек баса иде, әтисе — гомер-гомергә көтүче... Әнә шул Галәветдин дигәне котырта да инде башка малайларны...

Шулай бер көн ферма үгезе Бонапарт, бәйдән ычкынып, мәктәп бакчасының рәшәткәләрен аударып, пыран-заран итеп киткән иде. Директор мине шундук чакырып әйтте: «Искәндәр Искәндәрич, ди, бүген үк кичектермичә рәткә сал!» «Ярый, мәйтәм, бүген үк эшләрмен». Берничә сәгатьтән, такта, кадаклар күтәреп, ихата янына килсәм, ни күзем белән күрим! берничә малай умырылып төшкән рәшәткәне урынына утыртып та куйганнар, кулларында чүкеч тә кадак. Араларында әлеге дә баягы Галәветдин... Мине күреп алуга, әйтә бу миңа: «Ачуланмагыз инде, Искәндәр абый, ди, без сезне күрше авылга эш белән киткән дип торабыз...» Ярар, мәйтәм, зарар юк, киресенчә — бик әй-

бәт эшләгәнсез, булдыргансыз, дим. Үзем шулай дим, ә күңелне нидер тырный, үпкәлим дә шикелле, әмма сер бирмим...

Да, энекәш, бар иде заманалар: арба ватылса — утын... Ә хәзер балалар гади утын пүләненнән фаэтон ясамакчылар...

Инде килеп глобус тарихы... шулай бер көн география укытучысы дәшеп алды. Искәндәр абый, ди, бәла чыкты бит әле, глобусыбыз шартлады, ди. Илаһи зур глобус ул. Зурлыгы... зурлыгы әнә апаңның вареньe кайната торган табак зурлыгы. Әнә шул агач глобус, берәрсе ялгыш орынган, күрәсең, күчәреннән чыккан да идәнгә гөрселдәгән... Тизрәк төзәтергә куштылар. Ягъни мәсәлән, ике ярымшарны бергә ябыштырырга. Ярар, мәйтәм, була ул, ялгармын, җир шары күләмендәге проблема түгел. Бүген үк, дәресләр очлануга, әмәлләп бирермен...

Нәрсә авызыңны ерасың, энекәш? Әллә берәр нәрсә сизенәсеңме? Әйе шул, нәкъ өстенә бастың! Шулар инде! Дәресләр бетүгә, барып кердем география кабинетына... Барып кердем һәм... ни күзем белән күрим: берничә малай әлеге глобус тирәсендә кайнашалар. Кулларында «БФ» кләе. Вәт бит, шайтан алгырлары! Шул «БФ» белән ябыштырып та өлгергәннәр глобусны, күчәренә дә утыртканнар. Мине күрүгә, малайлар уңайсызланып калдылар, тик Галәветдине генә телгә килде. Әле шаярткан була: «Искәндәр абый, ди, тикшереп кара әле, ди, «биш»-легә булмаса да, «дүрт»легә эшләдек шикелле...»

Ни әйтергә дә белмәдем... Аптыравымны тыя алмыйча, глобусны, карбыз сайлагандай, чирткәли-чирткәли әйләндерә башладым. «Шәп әйләнә бит, булдыргансыз, дим. «Дүртле» генә моңа аз!» Тик шулай дисәм дә, күңелне нәрсәдер тырный, үпкәлим дә шикелле, әмма сер бирмим...

И-и, син сорама, энекәш, мин — әйтмим... Әле ул гынамы! Тагын бер мөгез чыгарып күрсәттеләр миңа Галәветдиннәр... Ишетә беләсеңдер, безнең колхозның «Миләүшә» исемле балалар бакчасы бар бит. Менә бер көн шул бакчаның мөдире Гөлчирә әйтә, мине урамда очратып: «Үтенечебез бар сезгә, Искәндәр абый, ди, бик зур үтенеч». «Әйт, мәйтәм, тыңлыйм». Балаларга агач пароход ясап бирәсе иде дә, кулыбыздан килми. Ясасагыз, сабыйлар сөенеп бетә алмас иде», ди... Була ул, мәйтәм, сеңелем Гөлчирә! Шундук колак артыннан карандашымны чыгардым: бир, мәйтәм, размерларыгызны, нинди күләмдә, нинди озынлыкта булырга тиеш сезнең пароход... Тик, мәйтәм, бүген сугыла алмыйм, ә иртәгә-берсекөнгә — әбәзәтелне. Мин сезгә, мәйтәм, шундый пароход эшләп бирермен! Утта да янмас ул, суда да батмас!.. Нәрсә, энекәш, авызыңны ерасың, әллә тагын берәр нәрсә сизенәмсең? Шулар инде! Ха-ха!.. Барып кердем икенче көн иртәгесен балалар бакчасына, кулымда инструментлар әрҗәсе... Ие, барып кердем... һәм ни күзем белән күрим: балалар бакчасы йортында илаһи матур бер пароход тора. Морҗасы — кызыл, палубасы — яшел, штурвалы — сапсары... Менә сиңа кирәк булса! Гөлчирә килеп чыкты каршыма, көлә бу: «Соңга калдыгыз, Искәндәр абый, ди, кичә кич Галәветдиннәр килеп киткәннәр иде...»

Кыскасы, утырттылар мине балалар... Пароходка булса бер хәл, төп башына утырттылар бит... Менә уйлап кара инде хәзер, энекәш: безнең ише старый гвардиягә көн бетәме, бетмиме? Отставкага чыкмый булмас... Фермага барсаң инде. Хәер, анда да мәктәпнекеләр еш йөри, эзләре суынмый. Берәүләре — дуңгыз симертешә, икенчеләре — бозау караша, өченчеләре — тавык... Ашыкмыйча булмый миңа. Җиткән, күрдем Казаныгызны, кунак булдым, рәхмәт... Бүген үк кичке поездга төшәм, вакытында кайтып җитәргә кирәк, ату эштән бөтенләй колак кагуым бар. Ул шайтан алгыры Галәветдиннәрдән шәфкать көтәм димә! Тагын бер төп башына утыртмагайлары... Хе-хе...

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ТАТАРСТАН ХУДОЖНИКЛАРЫ СЪЕЗДЫ

Үткән елның 30 сентябрендә Казандагы Актерлар йортында Татарстан художникларының икенче съезды булды. Художникларның ике съезд арасында башкарган эшләре турындагы отчет докладын Татарстан художниклар союзы идарәсе председателе, РСФСРның халык рәссамы Х. Якупов, ревизия комиссиясе отчетын ревкомиссия председателе Г. Рахманкулов ясадылар. Докладлар буенча фикер алышуларда сәнгать белгечләре А. Файнберг, Л. Елькович, рәссамнар Р. Имашев, Ә. Тумашев, А. Абзгильдин, Р. Вахитов, курчак театры директоры Р. Батуллин, сынлы сәнгать музее директоры урынбасары Г. Могильникова, РСФСР художниклар союзы идарәсе секретаре Е. Зверков һәм Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов катнашты.

Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев булды һәм чыгыш ясады.

Съезд художниклар союзы идарәсенең яңа идарә составын сайлады. Татарстан художниклар союзының идарә председателе итеп рәссам Әнәс Тумашев сайланды.

## ХАТЫН-КЫЗЛАРГА БАГЫШЛАП

Халыкара хатын-кызлар елы уңае белән, үткән елның октябрь аенда сынлы сәнгать музеенда (Казан) хатын-кыз образларын гәүдәләндергән әсәрләр күргәзмәсе оештырылды. Өч зур бүлектән (чит ил рәссамнары әсәрләре, рус, совет рәссамнары әсәрләре һәм республикабыз рәссамнарының хәзерге көн хатын-кызлары образларын чагылдырган әсәрләре) торган ул күргәзмәне тамашачылар яратып карады.

## МУЗЕЙГА 80 ЕЛ

Үткән елның октябрь аенда Татарстан дәүләт музее ачылып эшли башлауга 80 ел тулды. Шул уңай белән республика укытучылар йортында фәнни конференция үткәрелде. Анда музейның күп кырлы эшчәнлеге турында музей директоры В. Дьяконов, директор урынбасары В. Писарева, тарих фәннәре докторы А. Халиков, филология фәннәре докторы Е. Бушканец һәм тарих фәннәре кандидаты А. Циницына докладлары тыңланды.

Конференциядә Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов та катнашты һәм музейның хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләү юнәлешендә алып барган эшләре хакында сөйләде.

## ГАРИФ АХУНОВКА 50 ЯШЬ

Г. Тукай премиясе лауреаты, РСФСРның атказанган культура хезмәткәре, СССР Верховный Советы депутаты, Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе, егермеләп китап авторы прозаик Гариф Ахуновка 50 яшь тулды. Шул уңай белән узган елның сентябрь аенда әдипнең юбилее үткәрелде. 19 сентябрьдә республикабызның Әлмәт шәһәрендә аның тормыш һәм иҗат юлына багышланган әдәби-музыкаль кичә булды.

Әлмәтлеләр Г. Ахуновны бик хаклы рәвештә үз якташлары итеп саныйлар. Чөнки ул анда, Татарстан язучыларының Әлмәт бүлеге җитәкчесе буларак, шактый еллар эшләде һәм җәмәгать эшләре алып барды. Шунда үзенең атаклы «Хәзинә» романын, нефтьчеләр турында күп кенә очеркларын, хикәяләрен язды.

Гариф Ахуновның иҗади эшчәнлегенә багышланган әлеге әдәби-музыкаль кичәне шәһәр партия комитетының икенче секретаре Ә. К. Гыйматдинов ачты. Ул язучының күп милләтле совет әдәбиятына керткән зур өлеше турында сөйләде, шәһәр партия комитеты бюросы, хезмәт ияләре депутатларының шәһәр һәм район Советлары башкарма комитетлары исеменнән юбилярга котлау адресы тапшырды.

Аннары күп меңләгән нефтьчеләр армиясе исеменнән «Татнефть» берләшмәсе начальнигы урынбасары Ү. Г. Саттаров юбилярга бораулау вышкасы макеты бүләк итте; «Татнефть» берләшмәсе һәм нефть, газ һәм химия промышленносте эшчеләре профсоюзы өлкә комитетының Почет грамотасы бирелде. Г. Ахуновны Әлмәттә яшәүче әдипләр, Лениногорск шәһәре, «Татнефтьстрой» берләшмәсе, «Дуслык» нефть үткәргече һәм Әлмәт драма театры, Татарстан художниклар союзы, бораулау эшләре идарәсе вәкилләре, укытучылар тәбрикләде.

«Әлмәтнефть» идарәсенең 2 нче РИТС начальнигы Шәһит Таипов нефтьчеләр җыелышында язучы Гариф Ахуновны Почетлы оператор итеп бригада сафына алулары турында белдерде, аңа «Почетлы оператор» дигән таныклык тапшырды. Ә Ленин орденлы «Әлмәтнефть» идарәсе коллективы Гариф Ахуновны идарәнең Почетлы нефтьчесе итеп кабул итте, аның исемен коллективның Почет китабына кертте.

Кичәнең икенче бүлегендә концерт булды. Язучының яраткан җырлары яңгырады. Шәһәр һәм район үзешчәннәре аның пьесаларыннан һәм романнарыннан өзекләр укыдылар.

Фойеда юбиляр әсәрләреннән китап күргәзмәсе оештырылган иде.

Ә 26 сентябрьдә Казанның Төзүчеләр культура сараенда әдипнең юбилей кичәсе булды. Юбилей комиссиясе председателе М. Горький һәм Г. Тукай премияләре лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким алып барган һәм тугандаш республикалардан килгән кунак әдипләр катнашында узган ул тантана кичәсендә А. Гыйләҗев Г. Ахуновның тормышы һәм иҗаты турында доклад ясады. КПСС өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы, ТАССР Министрлар Советы исеменнән юбилярны ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Батыев котлады һәм аңа хөкүмәтебезнең зур бүләге — Хезмәт Кызыл Байрагы орденын тапшырды. Аннары республикабызның партия-совет органнары, хезмәт коллективлары, югары уку йортлары, газета-журнал редакцияләре Г. Ахуновка котлаулар һәм бүләкләр тапшырдылар, юбиляр адресына илебезнең төрле почмакларыннан килгән котлау телеграммалары укылды. Соңыннан республикабызның сәнгать осталары катнашында зур концерт булды. Концертта юбиляр әсәрләре, композиторларыбызның һәм халкыбызның популяр җырлары башкарылды.

## КИТАПХАНӘЧЕЛӘР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә югары уку йортлары китапханәчеләренең фәннипрактик конференциясе үткәрелде. Мәскәү, Ленинград, Вильнюс, Ростов, Томск, Воронеж, Горький, Пермь, Уфа, Чабаксар, Йошкар-Ола, Кострома, Куйбышев, Караганда һәм илебезнең башка шәһәрләрендәге университет һәм институтларның фәнни китапханәләреннән килгән китапханәчеләр катнашында узган ул конференциядә вуз китапханәләрендә информация һәм библиография эшенең торышы һәм аны камилләштерү чаралары турында сүз барды.

## ЧУВАШ ЯЗУЧЫЛАРЫ СЪЕЗДЫ

Үткән елның октябрь аенда күршебез Чувашстан язучыларының чираттагы унберенче съезды булды. Ул съездда шагыйребез Әхмәт Исхак һәм Казанда яшәүче чуваш язучылары Константин Петров, Василий Юдин да катнаштылар. Ә. Исхак дуслар съездында чыгыш ясап, татар һәм чуваш халыклары, әдәбиятларыбыз арасындагы күптәннән килә торган дуслык турында сөйләде, истәлекле бүләкләр тапшырды.

## ЯРЫШ һӘМ МАТБУГАТ

КПСС өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге, Татарстан журналистлар союзы республикабызның Буа, Чистай, Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләрендә һәм Арча эшчеләр поселогында район газеталары һәм күп тиражлы газеталар редакцияләре хезмәткәрләренең һәм эшче-авыл хәбәрчеләренең зона киңәшмәләрен үткәрделәр. Ул киңәшмәләрдә КПСС Үзәк Комитетының «КПССның XXV съезды лаеклы каршылау өчен социалистик ярыш турында»гы карары яктылыгында матбугат алдында торган бурычлар тикшерелде. Съезд алды социалистик ярышын җәелдерүгә, хезмәтнең алдынгы методларын пропагандалауга бәйле мәсьәләләр яктырту, матбугатның оештыру ролен көчәйтү, информация һәм пропаганда чараларына партия җитәкчелеген яхшырту буенча газета хезмәткәрләре үз тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.

## ЖУРНАЛГА ӘЙБӘТ БӘЯ БИРЕЛДЕ

СССР Язучылар союзы идарәсе илебездә басылып килә торган әдәби журнал һәм газеталар редакторларының Бөтенсоюз киңәшмәсен үткәрде. КПССның XXV съездын лаеклы каршылау җәһәтеннән әдәби журналлар алдында торган бурычлар хакында сөйләшүгә багышланган ул киңәшмәдә СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Виталий Михайлович Озеров үзәк һәм республика журналларына бик этрафлы күзәтү ясады һәм, шунда безнең «Казан утлары» журналына да кагылып, аның бүгенге көн сулышы белән сугарылган әсәрләргә киң урын бирүен хуплады. Киңәшмәдә күп кенә үзәк һәм республика журнал һәм газеталары редакторлары да чыгыш ясадылар һәм ирешелгән уңышлары һәм алларында торган бурычлар хакында сөйләделәр.

Безнең журналдан әлеге киңәшмәдә бүлек мөдире Вакыйф Нуруллин катнашты.

## ТӘРҖЕМӘ — ДУСЛЫК КӨЧЕ

Үткән елның сентябрь аенда Вильнюс шәһәрендә литва әдәбиятын тәрҗемә итүчеләр (ә алар шактый күп: 1400 совет әдибе һәм 350 чит ил язучысы икән!) киңәшмәсе уздырылды. Халыклар һәм әдәбиятлар дуслыгын ныгыта торган тәрҗемәләрнең теориясе һәм практикасы турында җитди сүз алып барылган ул киңәшмәдә Мәскәү, Ленинград, Украина, Белоруссия, Грузия, Төркмәнстан, Үзбәкстан, Эстония, Осетия язучылары-тәрҗемәчеләре катнашты. Киңәшмәдә Болгария, Венгрия, Германия, Польша, Румыния һәм Чехословакия тәрҗемәчеләре дә килгән иде.

Ул киңәшмәдә Татарстан язучылар союзыннан СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре шагыйрь Зәки Нури катнашты һәм чыгыш ясады.

## КОНКУРСЛАР ЛАУРЕАТЫ

Бөек Җиңүгә утыз ел тулу уңае белән узган ел «Военные знания» журналы «Халык батырлыгы» дип аталган конкурс үткәргән иде. Ул конкурста безнең якташыбыз С. Звягинцев та катнашты һәм журналның өченче премиясенә лаек (фотоаппарат) булды. Сергей Андреевичның бу уңышы очраклы хәл түгел. Ул үзе сугышта танкист булып хезмәт иткән һәм Ватан сугышы турындагы китапларны системалы

укып бара. Моңарчы ул «Советская Россия» газетасы үткәргән «Бөек Октябрьга илле ел һәм социалистик илләр дуслыгы» конкурсында (1967 ел) бишенче бүләккә, аннары шул ук газета үткәргән конкурста (1968 ел) дүртенче бүләккә лаек булган иде.

Моннан тыш Сергей Андреевич халыкара конкурсларда да актив катнашып һәм уңышка ирешеп килә. Мәсәлән, ул «Монголия Халык Республикасы — безнең дустыбыз» конкурсында диплом белән, «Фашизмны җиңүгә утыз ел» конкурсында Болгария телевидениесе һәм радио комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## ШАГЫЙРЬ ЮБИЛЕЕНА БАГЫШЛАНДЫ

Инде байтак еллардан бирле һәр елның көзендә «Социалистик Татарстан» газетасының Муса Җәлил исемендәге күчмә зур призына Казанда татарча көрәш ярышлары үткәрелеп килә. Андый ярыш узган елның октябрь аенда да оештырылды. Герой шагыйребез Муса Җәлилнең тууына 70 ел тулу юбилеена багышлап үткәрелгән ул ярышта йөздән артык татарча көрәш осталары катнашты. Үз үлчәүләрендә Наил Хәмидуллин (Саба районының Ленин исемендәге колхоз терлекчесе), Наил Зәйнуллин (Түбән Камадан), Михаил Чернов (Питрәч районының Ильич исемендәге колхоз механизаторы), Фидаил Шакиров (Казан ветеринария институты студенты), Данил Галиев (Түбән Кама нефть химиясе комбинаты эшчесе) беренче урыннарны яулап алып, батыр калдылар. Ә командалар арасында беренчелекне Түбән Кама районы көрәшчеләр командасы яулап алды. Ул командага «Социалистик Татарстан» газетасының Муса Җәлил исемендәге призы тапшырылды.

## УЧИЛИЩЕНЫҢ ИҖАТ ЯШЬЛЕГЕ

Илебездәге иң өлкән художество уку йортларыннан берсе булган Казан художество училищесының ачылуына узган елның октябрь аенда 80 ел тулды. Шул 80 ел эчендә бу училище бик күп талантлы рәссамнар тәрбияләп чыгарды. Исемнәре бөтен дөньяга билгеле булган атаклы рәссамнар И. Репин, Н. Фешин заманында шушы художество мәктәбендә укыганнар. Бу уку йорты совет власте елларында республикабыз өчен кадрлар әзерләүдә һәм сынлы сәнгатьне үстерүдә аеруча зур эш башкарды. Ул күп санлы рәсем осталары, графиклар, скульпторлар, театр художниклары әзерләп чыгарды. Идел буе республикалары өчен милли сәнгать кадрлары әзерләүдә дә бу училищеның хезмәте зур булды. Училище бу өлкәдәге эшен хәзер дә уңышлы дәвам итеп килә. Аны тәмамлаучыларның байтагы Мәскәү, Ленинград һәм башка шәһәрләрдәге югары художество уку йортларында укый.

## МОРДВА ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ИҖАТ ОТЧЕТЫ

10 октябрьда Саранск шәһәрендә мордва язучыларының IX съезды булды. «Ике съезд арасында мордва әдәбияты үсеше проблемалары» дигән отчет докладын идарә председателе И. М. Девин ясады. Бүгенге мордва совет әдәбияты, заман герое турында таләпчән һәм эшлекле зур сөйләшүдән торган фикер алышуларда Мәскәү нәшриятларыннан килгән язучылар, тәрҗемәчеләр, шулай ук күрше республика язучылары да катнаштылар. Съезд идарәнең яңа составын сайлады. Председатель итеп И. М. Девин, секретарь итеп И. Д. Пиняев сайланды.

Безнең Татарстан язучылары союзыннан вәкил булып бу съездда шагыйрә Гөлшат Зәйнашева катнашты.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Казандагы М. Горький музеенда бөек рус шагыйре Сергей Есенинның тууына 80 ел тулуга багышланган әдәби кичә үткәрелде. Казан дәүләт университеты доценты Л. Юдкевичның С. Есенин иҗаты турындагы кереш сүзеннән соң, кичәгә килгән поэзия сөючеләргә шагыйрьнең шигырьләре укылды. Соңыннан Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе артистлары көче белән концерт булды.


* * *

Прозаик Хәсән Сарьян, шагыйрьләр Рөстәм Мингалимов, Рәшит Әхмәтҗанов республикабызның Октябрь районы колхозларындагы культура сарайларында әдәби кичәләр үткәреп, китап сөючеләргә бүгенге татар әдәбиятындагы яңалыклар хакында сөйләп, үзләренең яңа әсәрләрен укып кайттылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1975 ел, 17 октябрьда игълан ителгән Указы нигезендә, совет сынлы сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре өчен, рәссамнарыбыз **Мәхмүт Усман улы Усманова** һәм **Александр Миронович Родионовка Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде.

# ГАЗИ КАШШАФ



1975 елның 9 декабрендә, кыска вакытлы каты авырудан соң, Миргази Солтан улы Кашшафетдинов (Гази Кашшаф) вафат булды.

Гомеренең соңгы көннәренә хәтле эш, иҗат белән янып яшәгән тырыш, гадел, яхшы күңелле иптәшебез арабыздан китте.

Хезмәт юлын «Кызыл Татарстан» газетасында әдәби сотрудник булып башлаган Гази Кашшаф күренекле тәнкыйтьче, язучы, студентларның яраткан остазы, актив җәмәгать эшлеклесе булды.

Бөек Ватан сугышы чорында Гази Кашшаф Татарстан Язучылар союзына җитәкчелек итте, ун еллар буе «Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторы булып эшләде. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни сотруднигы, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының өлкән укытучысы, татар теле һәм әдәбияты һәм журналистика кафедрасы доценты булды. 1960 елда филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен диссертация яклады.

Гази Кашшаф 40 еллык иҗади эшчәнлегендә әдәбият һәм театр сәнгатен үстерүнең актуаль проблемалары буенча тәнкыйть мәкаләләре, татар совет культурасының аерым эшлеклеләре иҗаты хакында монографияләр бастырып чыгарды, язучыларның сайланма әсәрләренең, тематик җыентыклар һәм дәреслекләрнең редакторы булды.

Гази Кашшаф, беренчеләрдән берсе булып, Муса Җәлилнең иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнүгә күп вакытын, көчен куйды. Аның «Муса Җәлил» китабы укучыларның киң массасында хаклы рәвештә популярлык казанды.

Гази Кашшаф республикабызның иҗтимагый-политик тормышында актив катнашты. Ул күп тапкыр КПССның Татарстан өлкә комитеты, Казан шәһәр һәм Бауман район комитеты члены итеп сайланды, хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр Советы депутаты булды. Аның иҗади һәм җәмәгать эшчәнлеге партия һәм хөкүмәтебез тарафыннан югары бәяләнде: Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет билгесе» орденнары һәм медальләр белән бүләкләнде.

Гүзәл кеше, күренекле язучы, Коммунистлар партиясенең тугрылыклы улы Гази Кашшафның тормышы бик күпләргә үрнәк булырлык. Аның якты истәлеге күңелләребездә мәңге сакланыр.

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ идарәсе,**
**«КАЗАН УТЛАРЫ» журналы.**

## Хөрмәтле укучыбыз!

Журналыбызның 2 нче саны Ленин премиясе лауреаты, Советлар Союзы Герое, шагыйрь Муса Җәлилнең 70 еллыгына багышланып чыга. Сез анда тугандаш республикалар язучыларының һәм татар шагыйрьләре Сибгат Хәким, Зәки Нури, Рәшит Гәрәйләрнең Муса Җәлилгә багышланган шигырьләрен, шагыйрьнең иҗаты турында фәнни мәкаләләр, язмалар, истәлекләр укырсыз, фоторәсемнәр белән танышырсыз.

Журналыбызның бу санында Атилла Расихның «Айлы төннәр» дигән романын баса башлыйбыз. Ул «Ямашев» романының дәвамы булып, сез анда электән таныш әдәби геройлар белән очрашырсыз.

Гәрәй Рәхим, Хәниф Хөснуллин, Роберт Миңнуллиннарның партиягә багышланган шигырьләре, Рөстәм Мингалимовның «Самолетлар оча» дигән хикәясе — авторларның яңа әсәрләре.

Журналыбызның публицистка бүлегендә Жан Миндубаевның «Алга карап, еракны күреп» дигән һәм Татарстан журналистлар союзы идарәсенең председателе Шәмси Хамматовның «Бишьеллык һәм публицистика» дигән мәкаләләре бар.

Габдулла Тукайның 90 еллыгын каршылап, сезнең игътибарга Ибраһим Нуруллинның «Тукай» исемле публицистик әсәреннән өзекләр тәкъдим итәбез.

«Нәниләр дөньясы» бүлеге сабыйларны Шәукәт Галиевнең «Үз итеп» дигән шигырьләр бәйләме белән таныштырыр.

Журналның тышлыгында «Яшә, партия!» дигән җыр басыла. Җырның сүзләрен Әнвәр Давыдов, музыкасын Бату Мулюков язган.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210